ISSN 0206—4

# Казан утлары

4.1983



# КАЗАН УТЛАРЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

4

1983

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

**М. МАЛИКОВА. Ак давылда тал бөресе.** Роман... 3
**Г. АФЗАЛ. Туган илдә Тукай рухы.** Шигырьләр 86
**С. КУДАШ. Сигезьюллыклар.** Шигырьләр . . . 91

ӘДӘБИ МИРАС

**Х. ТУФАН. Карлар астыннан.** Шигырьләр . . . 94

МӘХМҮТ ХӨСӘЕНГӘ 60 ЯШЬ

**М. ХӨСӘЕН. Шинель.** Шигырьләр, җырлар . . 97

ЯРОСЛАВ ГАШЕКНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

**Богелмәнең шанлы көннәре** . . . . . . . . 100
**С. АНТОНОВ. Кызыл чех.** Документаль повестьтан өзекләр . . . . . . . . . . . . 101

**Ш. МАННАПОВ. Кешеләр эзләп барам.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 110
**Л. ЗӨЛКАРНӘЕВ. Ядәч.** Шигырьләр . . . . . 113

АЗЫК-ТӨЛЕК ПРОГРАММАСЫ — БӨТЕН ХАЛЫК ЭШЕ

**М. ГАЛИЕВ. «Кече Артек» хуҗалары.** Очерк . . 115

«АВЫЛ ОФЫКЛАРЫ» КОНКУРСЫ

**М. ӘҺЛИУЛЛИН. Өр-яңа мәсьәләләрне чишкәндә.** Очерк . . . . . . . . . . . . . . 123

УНБЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК: КЕШЕЛӘР ҺӘМ ЭШЛӘР

**Р. ВӘЛИЕВ. Көчле агым.** Очерк . . . . . . 129

ИБРАҺИМ НУРУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

**И. НУРУЛЛИН. Киләчәккә карап** . . . . . . . 141

БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

**Ә. БАЯНОВ.** Замандашларым . . . . . . . . 147
**Ф. ЗӨЛКАРНӘЕВ.** Чакма чакмый ут чыкмый . . 151

БИБЛИОГРАФИЯ

**ЗӨЛФӘТ.** Ак буранда туган шигърият . . . . 160

ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

**Р. НИЗАМИЕВ.** Биеклеккә чакыру . . . . . . 162

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

**Р. НӘФИКОВ.** Иң бөек максат . . . . . . . 164
**Г. МӨХӘММӘДОВА.** Балачак истәлеге . . . . 174
**Ш. РАХМАНКУЛОВ.** Тукай Троицк шәһәрендә . . 176
**Ә. КӘРИМУЛЛИН.** Тапшырылмый калган бүләк 179

СӘНГАТЬ

**Ә. ИСМӘГЫЙЛОВ.** Жанр ачыклыгы һәм тормыш дөреслеге . . . . . . . . . . . . . 181

МИН ШАБАПНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

**Р. МОСТАФИН.** Кешелеклелек таланты . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 190

Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор* **РЕНАТ ХАРИС**

Редколлегия: **ШАМИЛ БИКЧУРИН, МАНСУР ВӘЛИЕВ, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, РӘИС ДАУТОВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ,** *җаваплы секретарь* **РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН,** *баш редактор урынбасары* **РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ, ЗӘКИ НУРИ, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ**

Техник редактор *Р. Сөләйманова*
Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Г. Салихҗанова*

Адрес редакции: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-09, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-63, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 25.01.1983 ел. Басарга кул куелды 15.03.1983 ел. ПФ 07016. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65049. Заказ Я-44. Бәясе 90 тиен.

Типография издательства Татарского обкома КПСС.
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

© «Казан утлары», 1983 ел.

## Мәдинә Маликова

# АК ДАВЫЛДА ТАЛ БӨРЕСЕ

РОМАН

### Беренче бүлек



Тынлы оркестр уйнаган дәртле марш авазы, иркен, биек залга сыеша алмыйча, коридорларга ташып чыкты. Бүген монда яшь врачлар ант бирергә җыелганнар иде.

Залның ике ягындагы тар, биек тәрәзәләр артында, яшьләрнең кузгалган күңеледәй тынгысыз җил куе өрәңге ботакларын тирбәлдерә. Тәрәзәләрдән өстә, түшәм астында ук диярлек, бөек табибларның портретлары эленгән. Күбесе сакаллы, кырыс чырайлы, карашларын залдагыларның баш очыннан каядыр еракка төбәгәннәр, әйтерсең лә үзләренә генә мәгълүм олы бер хакыйкать хакында уйлыйлар. Аларның мәгърур кыяфәте Зәйтүнәнең күңелен шомландырып җибәрде: бу даһиларга тиңләшү — табиб булу гади адәм баласы өчен мөмкин эш микән?

— Зюзю, карале, нинди гладиолуслар!— дип төртте Зәйтүнәгә уң ягында утырган Лариса.

Ике кыз рәтләр арасыннан чәчәкләр тулы ләгән күтәреп баралар иде. Менә алар биек сәхнәгә менделәр, кызыл бәрхет җәелгән озын өстәлдәге савытларга гладиолусларны бүлеп утыртып куйдылар. Лариса, муенын сузып, урыныннан кузгала төшеп, аларны күзәтте. Ул бүген бөтенесен уздырган — капрон халат кигән. Эчтән чәчәкле күлмәк бизәкләре аермачык күренеп тора. Кечкенә башлыгы җирәнсу вак бөдрәләре өстендә калфак кебек кенә эленеп тора. Гадәттә бик пөхтә, килешле киенә белә Лариса, әмма киемендә нинди дә булса төгәлсезлек калдыра: я өске сәдәфен элэктерми, я якасын күтәреп куя. Бүген дә шулай: халат җиңнәрен терсәгенә кадәр сызганып куйган. Башка берәүгә ятышып та бетмәс иде, ә менә Ларисага мондый төгәлсезлек тә ямь өстенә ямь генә биреп тора!

Ул озын кызыл тырнаклы бармаклары белән канәфер чәчәкләрен бөтерә, атсыз бармагындагы балдак елык-елык итә.

Кызлар барысы да бертөсле ак халатлардан, әмма игътибар белән караганда, киемнәрендә нииндидер аермалык та сизелә: Кифаяның энә халат итәгендә юылып бетмәгән марганцовка таплары бар, ә Вера башлыгына кызыл җеп белән медицина эмблемасын — озын аяклы савытка уралган елан сурәтен чигеп куйган...

Кинәт оркестр тынды, залда тирән сулышка охшаган «ш-ш-ш» дигән аваз ишетелде. Ишектән пөхтә костюмнар кигән бер төркем кеше ке-

реп, сәхнәгә таба юнәлделәр. Болар — яшьләрнең остазлары, галим-врачлар иде. Иң алдан ачык коңгырт костюмы өстенә аксыл кофтасының киң якасын чыгарып салган, кыска кискән күперенке чәчле ханым — профессор Ильясова күтәрелде. Елмая төшеп, залга җиңелчә генә баш иде, борылып, янындагы ирләргә нидер әйтеп алды, тегеләр аңа көлешеп җавап бирделәр. Ир-ат арасында, алар белән бертигез дәрәҗәдә озак еллар эшләгән хатын-кызлар, кагыйдә буларак, кыяфәтләре белән дә, үз-үзләрен тотышлары белән дә тупасланып, кырысланып китәләр. Җәмилә Закировна бу йогынтыга бирешмәгән иде. Сәхнәдә, алсу-кызыл гладиолуслар артында, ул, көмеш йөзек кашындагы асылташ төсле, бар карашларны үзенә җәлеп итеп торды. Бу минутта аңа һичкем илле сигез яшь бирмәс иде.

Тантаналы җыелыш барсының да аягүрә басып, байракларны каршы алуыннан башланды. Уртача буйлы, каратут йөзендә зур күзлеге һәм саллы ияге күзгә бәрелеп торган ректор, трибунага менеп, йомшак, әмма буйсындыручан тавыш белән яшьләрне диплом алып, мөстәкыйль тормышка басулары, үзенчә әйткәндә, «безнең коллегаларыбыз булуыгыз белән» котлады.

Ниһаять, ант кабул итү минуты килеп җитте. Барысы да аягүрә бастылар. Ректорның салмак, тантаналы тавышы диварларга бәрелеп яңгырый, ерак гасырлардан килгән, барча табиплар өчен мөкатдәс булган сүзләрне — Гиппократ антын биектәге даһилар да тын калып тыңлыйлар иде шикелле.

«Табип Аполлон, Асклепий, Гигия, Панацея белән ант итәм»...— «Ант итәм...» дип, тыенкы тавыш белән башкаларга кушылып кабатлады Зәйтүнә. «Ант»...— диделәр кебек кырыс даһилар. «Табиплык сәнгатенә өйрәткән кешеләрне атам-анам белән бертигез санармын...» Бу сүзләрне Зәйтүнә сәхнәдә, кызыл гладиолуслар артында басып торган профессор Ильясовага карап пышылдады. «Авыруларга һәртөрле зыян һәм гаделсезлек кылудан тыелырмын... гомеремне саф һәм керсез үткәрермен... Нинди генә йортка керсәм дә, мин анда авыруның файдасы өчен керермен, алдан уйланган, гаделсез һәм зарарлы нәрсәләрдән, бигрәк тә хатыннар һәм ирләр белән гыйшык эшләреннән азат булырмын...»

Зәйтүнә белә бит инде бу сүзләрне, күптән белә, ләкин бүген тантаналы яңгыраганда нигә алар күңелгә утлы күмер булып төште соң әле? Гыйшык булу, мәхәббәт утында яну гаеп эшмени?..

«Сер булып сакланырга тиешле ни генә белсәм дә,— дип яңгырады ант сүзләре,— мин аны беркемгә дә фаш итмәм. Бу антымны какшаусыз тоткан өчен миңа тормышымда һәм сәнгатемдә кешеләр арасында бәхет һәм мәңгелек дан килсен, антын бозган яки ялган ант биргәннәргә исә моның киресе булсын!»

Соңгы сүзләр дәһшәт белән яңгырагандай булды.

— Ант итәм! Ант итәм! Ант итәм!— дип гүләде зал.

Утыргычларны шыгырдатып, урыннарга утырдылар. Остазлар шәкертләренә соңгы тапкыр теләкләрен әйтә башладылар.

Доцент Дәүләтшин торып баскач, залдагыларның башлары тагын да югарырак күтәрелде, күзләр киңрәк ачылды. Изаил Харисович турында студент кызлар тыныч кына сөйләшә дә алмыйлар иде. Аның кара чәчләре астыннан агарып күренгән киң йөзеннән гүяки кызларның күзенә нур сибелде.

Ул, трибунага менгәч, йөзен тәрәзәгә таба борды, залдагыларга үзе белән сокланырга мөмкинлекләр тудырды.

— Сез яшьләрнең күңеленә изге очкын салу өчен без кулдан килгәнчә тырыштык,— дип елмаю аша башлады ул сүзен. Аның калын тавышы колакка ягымлы яңгырашлы һәм шул кадәр көчле иде ки, артык ник яңгырамасын өчен аңа тыелыбрак сөйләргә туры килә иде шикел-

ле. Аның бөтен кыяфәтеннән үз-үзенә ышаныч, егетлек, көч бөркелеп тора иде.

— Көчле!— диде Лариса күзләрен аннан ала алмыйча.— Кызганыч, безнең группаны укытмады. Шулай бит, Зюзю?

Ә доцент залдан күтәрелгән соклану дулкынын тоеп тора, алай гына да түгел, бу дулкында күнеле белән ләззәтләнеп йөзә иде.

— Инде хәзер бу очкынны учакка әверелдерү сезнең үз кулыгызда. Иманым камил: сезнең арадан да медицина күгендә йолдыз булып балкырлык кешеләр үсеп чыгар!

Кызлар учларын кызганмыйча кул чабарга керештеләр. Профессор Ильясовага шул алкышлар астында трибунага күтәрелергә туры килде.

Ул залның тынычланганын сабыр гына көтте. Җәмилә Закировна йөзенә яктылыкның ничек төшкәнен дә чамаламый, тавышы да доцент Дәүләтшиннан соң артык нечкә, зәгыйфь булып тоелды, шыбырдашып утырган яшьләр аның беренче сүзләрен ишетми дә калдылар. Ләкин ихласлык, йөрәк түреннән чыккан хис бар иде профессор Ильясованың кыяфәтендә һәм тыныч тавышында. Зал аны ишетү өчен, ихтыярсыздан тынып калды.

— ...Студентларга соңгы фатихамны биргән саен, мин үземнең остазымны искә төшерәм. Безнең институт белән хушлашуыбыз бүгенге тантанага охшамаган иде. Без хәтта соңгы имтиханны да тапшыра алмадык. Дипломны безгә ансыз гына бирделәр.

Кифая Ларисага таба сузылып:

— Безгә дә шулай итәселәре калган!— диде.

— Ватан сугышының башланган көннәре, күбебез фронтка ашыга иде. Безнең карт укытучыбыз трибунага менде дә: «Газизләрем! Мин сезгә бер генә нәрсә телим! Исән-сау әйләнеп кайтыгыз!»— диде һәм елап җибәрде. Мин бәхетле, чөнки шәкертләремә андый теләк теләргә туры килгәне юк. Тыныч дөньяда эшлик, дим мин сезгә. Боз болай да аяусыз көрәштә. Кешелекнең явыз дошманнары белән көрәшнең алгы сызыгында без. Мин сезгә бу фронтта җиңүләр телим! Бәлки, һәр җиңү өчен сезнең күкрәкләрегезгә орден да такмаслар, ләкин һәр җиңү — ул кеше гомере! Врач исеме зур бүләк. Аталар балаларын озатканда болай диләр: мин сиңа фамилия бирдем, исемне үзең яулап ал. Без сезгә белем бирдек, врач исемен үзегез яулагыз. Кешеләрнең газапларын җиңеләйтүдән куаныч табып яшәгез, бәхетнең иң зурысы шул.

Зал кул чабуларга күмелде.

— Сихерче!— диде Лариса, соклану катыш көнләшү белән.

*
* *

Тантана тәмамланып, байракларны озатканда, кисәк сискәндереп, зал артындагы оркестр уйнап җибәрде — зеңгелдәп җиз тәлинкәләр бер-берсенә бәрелде, трубалар күкрәп куйды һәм янә дәртле марш башланды.

Ректор, башын чак кына ия төшеп, профессор Ильясовага юл бирде. Җәмилә Закировна зал кырыеннан ишеккә таба юнәлде, башкалар ана иярде.

Ул җитез адым белән бара, тәрәзәдән төшкән кояш таңкаләре аның чәченда ялтырап китә, ә йөзендә куаныч катыш ямансулык чагыла иде. Оясыннан балаларын очырган кош ямансулыгы иде бу.

Коридорга чыккач, ул ректорга таба борылып:

— Минем сезгә сүзем бар иде,— диде.

— Рәхим итегез, Җәмилә Закировна, теләсәгез, хәзер үк сөйләшергә мөмкин.

Алар тукталып торган арада, башка галимнәр ары узып китте, иң соңгы булып доцент Дәүләтшин бара иде. Җәмилә Закировна карашы белән аны озатып калды.

Әнә ул — пөхтә, килешле зәңгәр джинси костюмы аркылы мускуллары сизелеп торган атлет гәүдәсе белән коридорны иңләп бара, костюм якасы өстеннән тар сызык булып күзне камаштырырлык ап-ак күлмәк якасы чыгып тора, бу сызык аның чәчен тагын да карарак итеп күрсәтә. Каршы килгән студент кызлар, ул узып киткәч, барыр юлларын онытып, үзара пышылдашып калалар, аларның шыпырт тавышында, алланган бит очларында соклану, олылау ярылып ята.

Сокланмый мөмкин дә түгел доцент Дәүләтшинга! Аның очарга талпынган бөркет шикелле чак кына алга авышкан сынында, коңгырт ботинкалар белән паркет идәнгә нык басып баруында ук көч, көне-ае белән арта барган гайрәт сизелә. Биек, иркен коридорны кысанлап, ашкынулы адым белән киләчәк үзе барадыр шикелле.

Аның артыннан җиңел, тавышсыз гына атлап килгән җыйнак гәүдәле профессор Ильясова, үсеп-ныгып житкән, уңган һәм батыр улына карап куанган ана шикелле, эчке горурлык хисе кичерә иде. Адым саен гайрәте арта барган бу егет аның — профессор Ильясованың шәкерте бит!

Дәүләтшин баскычка борылганчы, Җәмилә Закировна аның артыннан каерылып карап калды.

Кабинетына кергәч, ректор «Т» хәрефе сыман куелган өстәлләрнең түрдәгесе артына — үз урынына түгел, ян өстәл кырыена барып басты, ишарә белән Җәмилә Закировнага каршысыннан урын күрсәтте.

— Бер атнадан мин китәм бит инде,— диде Җәмилә Закировна, икесе дә утыргач. Аның Совет хатын-кызлары комитеты делегациясе составында гарәп иленә барачагын ректор белә иде инде. Гаҗәпләнерлек нәрсә түгел: профессор чит илләрдә булгалый, моннан ике ел гына элек ул, мәсәлән, Вьетнамда йөреп кайткан иде.

Бүлмәдә беразга тынлык урнашты, ачык тәрәзәдән агачлар шавы ишетелә башлады.

Алар дистә еллар буе бергә эшлиләр һәм бер-берсен якын итәләр иде. Мондый очракларда, ягъни Җәмилә Закировна берәр йомыш белән башкалага барганда — бу юлы да ул ике-өч көнгә Мәскәүгә тукталачак — ректор аңа бик мөһим йомышлар кушып җибәрә торган иде: министрлыкка керергә, ВАКка сугылырга, кайбер галимнәрне күреп сөйләшергә... Ахыр чиктә, таныш-белешләренә сәлам күндерә иде.

Җәмилә Закировна сораулы карашын әңгәмәдәшенең күзлегенә төбәде. Күзлек пыяласында чалшаеп тәрәзә чагыла иде. Ректор аның тел төбен аңлап, чак кына көлемсерәде:

— Атна-ун көннән Мәскәүгә Изаил Харисович та барачак. Аналарның һәм балаларның сәламәтлеген саклау институтына бер-ике атнага командировка сорый. Алар белән үзе алдан сөйләшеп куйган, барысын да җайлаган. Молодец егет сезнең ул шәкертегез, Җәмилә Закировна! Өр-яңа өлкәдә эзләнүләр алып бара, һәм, әйтергә кирәк, шактый уңышлы алып бара. Фәнни конференцияләрдә төпле чыгышлар ясый, зур галимнәр белән кыю сөйләшә. Кыяфәт бар, сөйли белә, энергия дә, эрудиция дә житәрлек. Теләсә нинди авыр мәсьәләне ерып чыгарлык егет!

Җәмилә Закировна ректорның әйтми калган сүзләрен күңеленнән дәвам итте: «Безнең йомышларны да бик яхшы итеп үти».

Җәмилә Закировна күңелендә ирексездән кузгалган көнләшү хисен басарга тырышты: «Бигрәк яхшы, миңа артык мәшәкать булмас...»

Ректор бераз тынып торды да, тагын телгә килде:

— Ә шулай да, Дәүләтшинны кафедрадан җибәреп, хата эшләдегез,

ахрысы, сез, Җәмилә Закировна. Үзегезгә менә дигән алмаш булып өлгерә иде.

— Төрле казанда кайнап чыныгу яшь кешегә файдалы булыр, дип саныйм мин үзем.— Җәмилә Закировна сер бирмәскә тырышты, әмма ректор аның яшерен ярасына кагылган иде.

Әйе, Дәүләтшин Ильясова кафедрасында үсте, кандидатлык диссертациясен аның кул астында яклады.

Моннан бер ел элек кенә институтның шул ук профильдәге икенче кафедрасына күчте ул. Бу карарын: «Мин сайлаган тема белән ныклап шөгыльләнү өчен анда мөмкинлекләр күбрәк»,— дип аңлатты. Профессорның Дәүләтшинны бер дә җибәрәсе килмәгән иде югыйсә...

Ильясова ректор кабинетыннан чыкканда, Изаил Харисович кабул итү бүлмәсендә секретарь кыз белән сөйләшеп тора иде. Башын күтәреп профессорга карагач, аның йөзе кинәт үзгәрде, күзләрендә сагаю чагылды.

— Изаил Харисович, минем сезгә бер авыруны күрсәтәсе килә иде,— диде Җәмилә Закировна.

— Ярдәмем тиярлек булса, бик шатмын, Җәмилә Закировна. Берәр якын кешегезме әллә?

— Юк, миңа беренче килүе. Ярдәм сорап хат язган иде дә, минем җавапны алуга килеп тә җиткән. Үзбәкстаннан, Диләрам исемле бик сөйкемле кыз.

— Әгәр теләсәгез, мин сезнең клиникага килермен.

— Мин аның үзен сезгә җибәрә алам. Вакытын гына әйтегез.

Авыруның диагнозы, очрашу вакыты турында сөйләшкәндә, Җәмиләә Закировнаның башына һич көтелмәгән бер уй килде: икенче кафедрага күчкәннән бирле, доцент Дәүләтшинның бер генә мәртәбә дә ярдәм сорап профессор Ильясовага мөрәҗәгать иткәне булмаган икән.

*

* *

Кемдер аның бит очын назлап сыйпый иде шикелле, Зәйтүнә шул назга елмаеп уянды, берара, керфекләрен күтәрергә иренеп, назның кабатланганын көтеп ятты. Ниндидер татлы төш күргән кебек иде, тик онытылган, күңелдә сөенечле хис кенә калган. Ул йөзенә төшкән кояш нурыннан башын борып, күзләрен ачты. Төше түгел, өне сөенечле бит аның. Әнә өстәлдә, чәчәкле клеенка өстендә зәңгәр катыргы — диплом ята, аның янындагы пыяла савытта ике канәфер чәчәге. Урындык аркасына ак күлмәк эленгән, ак туфлиләр идән уртасында тәгәрәшеп яталар. Тулай торакның бер бүлмәсендә узган тантана мәҗлесе көн яктыргач кына таралды. Киемнәрен урынына рәтләп куярга Зәйтүнәнең хәле дә калмаган иде.

Бу күлмәк белән туфлиләр Зәйтүнәнең гомердә бер була торган зур бәйрәменә шаһит булганнар иде инде — ул туена да шуларны кигән иде. Кызлар чыгарылыш кичәләренә дә, туйларга да актан киенәләр. Иң тантаналы, иң истәлекле көннәрендә алар — ап-ак. Ә менә табиплар көн дә актан йөриләр. Әллә соң аларның гадәти, гади көннәре булмый да микән?

Актан киенеп, ике тапкыр ант бирде Зәйтүнә. Беренчесендә — гомеремне иремә, туачак балаларыма багышлармын, дип. Икенчесендә — акылымны, сәламәтлегемне, тырышлыгымны кешеләрне авырулардан саклау эшенә бирермен, дип.

Ике дөнья өчен бик җаваплы кеше ул хәзер. Аның берсе — Әнвәр — мәхәббәт белән тулы өй, икенчесе — авыруларның зары тулы больница. Беренчесендә ул хатын һәм... ана да булачак бит әле. Ә икен-

чесендә ул бүгеннән — табип. Бу ике дөньяны бер күңелгә сыйдыру мөмкин микән?

Зәйтүнә торды да стенадагы түгәрәк көзге каршына килеп басты. Бүгеннән ул — врач, кешеләр аңа өмет һәм ышаныч белән текәләчәкләр. Ләкин аның кыяфәте ул өметләрне акларлык булып күренәме соң?

Урта буй, нечкә сын. Ул болай төнге күлмәктән баласымак булып күренә, ак халат кигәч кенә җитдиләнеп китә. Ә менә йөз... түгәрәк, ак йөз, нечкәреп киткән сары кашлар, зәңгәр күз, турсайган иреннәр. Ирен читендәге миң тагын... Чәчне кистереп, Лариса киңәш иткәнчә бөдрәләтеп җибәрсәң, олысыманрак булып китәр идең инде... Әмма Әнвәр рөхсәт итми. Зәйтүнә үзе дә ир хатыны, энисе кебек, чәчен толымлап үреп йөрергә тиеш, дип уйлый. Кайбер халыкларда шундый йола да бар бит: кызлар бертөрле йөртә чәчне, хатыннар икенче төрле... «Карурманда адашкандай, чәч толымнарыңда адаштым»,— ди аңа Әнвәре...

Их, ник кенә китте соң әле ул әллә кайларга, нигә бүгенге көндә шул адашкан хәлендә Зәйтүнәсе янында түгел? Ул да ике дөньяда яши шул. Аның икенче дөньясы — эше, парниклар хуҗалыгы. Инженер Уразов ул хуҗалыкта теплицалар кору турында хыялланып йөри. «Нефтьчеләр торба вагъдә иттеләр әле, Зәйтүнгөл, тизрәк барып алырга кирәк».— «Тимер-томыр качмас, бер-ике көнгә соңрак барсаң да»,— дигән иде аңа Зәйтүнә. «Андый затлы малны яткыралармы соң. Элэктерә алсаң бик шәп инде. Ике көннән кайтам мин, сагынып көтеп тор!»

Нигә кирәк ул тимер торбалар? Карурманнарда адашкан кебек, мәхәббәт бакчаларында адашып кына яшәп булмас идемени, шушындый көннәрдә генә булса да?

Ә Зәйтүнә үзе Әнвәрнең күзенә генә карап торыр иде.

Ләкин... медицина дөньясы булмаса, ул Әнвәрне очрата да алмаган булыр иде. Минзәләдә медучилище тәмамлап, авылда өч ел эшләгәч, монда Казанга килмәгән булса... Врач булу теләге монда китерде аны һәм мәхәббәтен дә ул шушында тапты.

Уку Зәйтүнәгә җиңел бирелә иде. Башкаларның үзәгенә үткән анатомия, хәтта латин да бер-ике кабатлауга истә кала, шигырь кебек ятлана иде. «Aliis inserviendo consumor»,— дип кабатларга ярата иде ул борынгы бер табипның сүзләрен.— «Башкаларга якты булсын өчен, янып көл буламын».

Фәнни түгәрәкләргә йөрү, концертларда катнашу да аз тоела, күңел каядыр ашкына иде. Аэроклубта парашют белән сикерү түгәрәге барлыгын ишеткәч, башка кызларны да шунда барырга үгетли башлады. «Азабың көчәйгән икән»,— диде аңа Лариса. «Андый шөгыль ихтыярны ныгыта, ә врачка ихтыяр көче бик кирәк». Лариса Зәйтүнәнең бу сүзләренә кул гына селтәде.

Аэроклуб университет каршындагы иске бинада иде. Зәйтүнә анда ят егетләр, ят кызлар арасына ялгызы барып керде.

Парашют белән сикерү өчен алдан өч ай укырга кирәк икән. Укытучысы инструктор дип атала, ул укучылары кебек үк студент егет, аны барсы да Әнвәр дип кенә йөртәләр иде. Башта Зәйтүнә аны терекөмеш тамчысына охшаткан иде. Бер аймы, ай ярыммы узгач, бөдрә чәчле, үткен коңгырт күзле бу татар малаеннан күңелгә җылы нур иңгәне сизелә башлады. Шуннан соң Зәйтүнә аны нур шәүләсенә тиңли торган булды. Була бит шундый якты тап, әллә каян гына стенага килеп төшә дә, «тот мине, тот» дип каршыңда үчекли башлый. Син аңа учыңны сузасың, ә ул читкә тайпыла.

Сабакны да үртәгәндәй көлемсерәп кенә аңлата иде ул. «Парашют баулары буталса, аларны кискәндә, пычакны үзегезгә каратып тотмагыз, югыйсә башыгыз алдан төшеп китәр».— «Инде барысы да тәр-

типтә икәнен ышангач, җайлап утырыгыз да, туган илнең гүзәллегенә карап хозурланыгыз». Алдан-арттан парашют таккан Зәйтүнәнең зал кырыендагы кечкенә самолет кабинасына керә алмыйча азапланганын күзәтеп торганда ул, башкаларга карап: «Күккә менгәч, бик җиңел чыгыла аннан, ә керүе тагын да җиңелрәк була,— дигән иде.— Кайберәүләр куркудан ничек кире кереп утырганнарын сизми дә калалар. Дөрес, кызлар арасында моңарчы андыйның булганы юк әле», һәм Зәйтүнәгә шундый итеп көлемсерәп карап куйды, әйтерсең лә нәкъ менә аның бу эштә беренче буласына ышана иде.

Утызлап кеше укып йөргәннәр иде, ә менә аэродромга Зәйтүнә берүзе барып җитте, чөнки анысына бик зур үҗәтлек кирәк булып чыкты. Аэроклубның чибәр, әмма чытык чырайлы врачы, Зәйтүнәнең авызын ачтырып карады да:

— Сезгә күккә менү турында түгел, җирдә яхшылап дәвалану хакында уйларга кирәк,— диде.

Чыннан да ул чакта Зәйтүнәнең тамагы авыртып йөри иде.

Ләкин бу каршылык кына Зәйтүнәне туктата алмый иде инде. Сикерүнең үзеннән дә бигрәк, нур шәүләсенә охшаган егетнең үртәп әйткән сүзләре үҗәтләндерде аны.

Үзе урынына врачка барырга Ларисаны күндерү җиңел булмады булуын. Зәйтүнә аңа атна буе аш пешереп ашатты, бик сирәк очрый торган китаплар табып бирде.

— Врач миңа, парашютсыз да сикерә аласың, дип әйтте,— дип мактанып кайтып керде Лариса.

Бу минутта ул үзенең нәрсә югалтканын белми, Зәйтүнә дә үзенең ни табачагын аңламый иде әле. Ул бары тик үз ихтыярын чыныктыру, Әнвәр каршында ныклыгын исбат итү турында гына уйлый иде.

Әйе, самолеттан сикерү чыннан да бик куркыныч булып чыкты. Алгы кабинага утырган очучы — егетләрдәй нык бәдәнле хатын-кыз иде, ни сәбәптәндер, ул, Зәйтүнәне күргәч, җилдә каралган йөзен чытып куйды. Күрәсең, парашютлар авырлыгыннан бөгелә төшеп, тупас ботинка башлары белән чирәмне тырнап көч-хәлгә атлап килгән кызның кыяфәте аңа ошамады. (Бу зур ботинкаларны Зәйтүнәгә аэродромда кидерделәр, босоножкалар белән сикерү рөхсәт ителми иде).

Зәйтүнә кабинага җайлы гына кереп утырды. Югарыда, очучы хатын зур пыяла күзлеген елтыратып борылып карагач, кабинадан чыгарга вакыт икәнен аңлап, моны да җиңел эшләде. Ләкин менә канатка басып, сынын турайткач, аяк астында, упкын кебек тирәнлектә агып яткан җирне күргәч, башы әйләнеп китте, бармаклар кабина кырыена аерып булмаслык итеп чытырдап ябышты, кабинага кире керәсе, нык тимер утыргычка береген утырасы килә башлады.

Ул артка карап тора, аркадан җил этә, җан кабина эченә тарта иде. Гөрелте аша кычкырган тавыш ишетеп, ул артына борылып карады. Анда гыйфрит күзе төсле пыяла күз, зур ачылган авыз күренде. Зәйтүнә очучының: «Сикер!» — дип кычкырганын аңлады.

— Сикер! Сикер! Сикер!

Сикерергәме? Бумы сикерү? Бу бит үзеңне, һәр күзәнәге белән самолет тимеренә чытырдап ябышырга омтылган тәнеңне ышанычлы терәктән аерып, бушлыкка, төпсез упкынга ыргыту дигән сүз!

Ул күзләрен чытырдатып йомды да, бармакларын көч-хәл белән каергандай итеп, кабина кырыеннан ычкындырды. Тыгыз һава аны канаттан йолкып алды, йөзтүбән мәтәлдерде...

Инструктор аңлатканда, барысы да бик гади иде шикелле: самолеттан аерылгач та: «Бер-ике-өч»,— дип ашыкмыйча гына алтыга кадәр санnetwork, аннары баш өстеңә күтәрелеп карыйсың. Әгәр дә шуңарчы парашютың ачылмаган булса, күкрәгеңдәге каешка беркетелгән боҗраны тартып аласың — запас парашютны ачасың.

Ә монда кая ул санау да кая баш очына күтәрелеп карау! Эреп юкка чыккандай буласың икән. Кемдер култык астыннан тотып, кисәк туктаткандай иткәч кенә, исенә килде Зәйтүнә. Шунда гына күтәрелеп карады: баш очында ак чатыр булып, парашют чайкала иде. Шунда аның күңелен һичкайчан булмаган очыну, рәхәтлек биләп алды, андый рәхәтлекне очар кошлар гына тоя ала торгандыр. Ул киң каешларга рәхәтләнеп урнашты да, таганда атынгандай чайкалып куйды.

Ул бер урында тирбәлеп тора, бары тик җир генә үзгәрә: офыклар тарая, агачлар зурая, тузанлы юл киңәя бара иде. Зәйтүнә әле якынаеп килгән аланлыкка, әле биегәеп барган күккә карады, бер көлде, бер җырлады. Бары тик урман кырые читкә шуышып, такыр чирәмлек нык ук якынайгач кына, Әнвәрнең тагын бер киңәшен искә төшерде: ул парашют бауларын тарткалап, бу атынуны туктатырга тиеш иде ләбаса! Ләкин инде соңарган иде, җир кинәт аңа ташланды, ул, яны белән бәрелмәс өчен, чирәмлеккә таба аякларын сузарга чак өлгерде. Каты җир аяк табаннарына килеп бәрелүгә, ул тәгәрәп китте.

Кинәт авырайган ботинкаларның җайсызлыгын тоеп, бераздан торып басты, җил уңаена сузылган парашют бауларын тарткалый башлады.

Тапталган чирәмлек буйлап велосипедка утырган берәү килә иде. Зәйтүнә ерактан ук Әнвәрне таныды. Егет берничә адым кала ук велосипедыннан төште, сулышына кабып:

— Иминлекме?— дип сорады. Аның тавышында борчылу сизелә иде.

— Әйбәт!

— Нишләп болай ерак китереп ташлады соң ул сине?

— Ул гаепле түгел... Мин үзем... курыктым.

Әнвәр аның бу сүзләрен шаяру дип кабул иткәндәй елмайды.

Парашютны икәүләп җыйгач, алар велосипедка утырып чирәмлек буйлап киттеләр. Зәйтүнә аркасы белән егетнең кайнар күкрәген, йөрәк тибешен тоеп барды. Һич көтмәгәндә болай егет кочагына керү бары тик шушы минутта, очар кошлар кебек күктә талпынып төшкәннән соң, күңелнең очынган чагында гына мөмкин иде. Шушы талпынуны, очынуны Зәйтүнә белән бергә Әнвәр күңеле дә кичергәнгә генә мөмкин иде бу.

Алар менә шулай йөрәк тибешләре аша гына, сүзсез генә беренче тапкыр аңлаштылар.

*
* *

Кадерле хатирәләрдән арынырга тырышты Зәйтүнә. Шул беренче сүзсез аңлашуның яктысында күңел ныграк җылынсын иде...

Әмма чәй эчәргә утыргач, бу яктылыкны йомшак кына күләгә каплагандай булды. Өстәл башында утырганда, бүлмәнең ике як стенасындагы ике рәсем бик яхшы күренә. Аларның берсен — уң яктагы караватестендә эленеп торганын, тулай торакта бергә яшәгән кызлар туй бүләге итеп китергәннәр иде. Пикассоның «Мадам Жаклин»ы. Кара сызыклар белән генә ясалган хатын-кыз рәсеме. Аның йөзендә тирән моң, ятлар белән түгел, дуслар белән дә уртаклашып булмый торган яшерен сагыш бар. Агарынган, суырылган ул. Нәрсә изә аның күңелен, ничек җиңеләйтеп була аның сагышын? Ләкин бу хакта уйлаучысы, кайгыртучысы, хәленә керүчесе юк, күрәсең, Мадам Жаклинның. Ялгыз ул, япа-ялгыз, ялгызлыгы бөтен кыяфәтенә бәреп чыккан.

Әмма хисчелеге, уйчанлыгы, сагышы белән матур, сөйкемле үзе... Ә менә гәүдәсе... Мадам Жаклинның буй-сынын тасвирлаганда, мәшһүр рәссамның каләме бөтен сизгерлеген, тылсымлы көчен кинәт югалт-

кан диярсең. Хатынның гәүдәсе озынча зур шакмак, аяклары кечерәк шакмаклар, муены — улак. Аяк бармаклары киселгән ботак төпләре кебек тырпаешып торалар. Шул шакмакларның берсе янына икенчесе ничек куелганга карап кына, хатынның тезләрен кочаклап утырганын чамаларга була. Нәрсә бу — кубизм дигән стильнең чагылышы гынамы, әллә югыйсә рәссамның бу образга үз мөнәсәбәтен белдерүеме? Нигә шулай җансыз итеп тасвирлаган ул бу сынны?

Рәсемне бүләк итеп тапшырганда, Лариса киная белән: «Зюзю! Нәкъ синең рухта инде бу!» — дигән иде.

Хәзергә кадәр шулар исенә төшкән саен моңланып, шомланып уйлана Зәйтүнә: нәрсә әйтмәкче булды икән Лариса моның белән?

Туйдан соң берме-икеме ай узгач, Әнвәр каршы стенага тагын бер рәсем алып кайтып элде. Монысы төсләр белән ясалган кыз сурәте. Авторы да танылганнардан түгел. Алмалары пешеп килгән агач янында бер кыз туктап калган да, башын бора төшеп, кемгәдер карап елмайган. Аның бизәкле яулыгы шома чәченнән шуышып, толымнары түбендә генә тотылып тора, гәүдәсе шул кадәр табигый сызыклар һәм төсләр белән тасвирланган ки, сулыш алганда, ачык муенындагы эре гәрәбәләре тибрәлеп куялар шикелле. Рәсемне элгәч, Әнвәр мәгънәле итеп:

— Менә күрәсеңме, хатын-кыз нинди була!— диде.

— Һәр рәссамның үз стиле,— дип каршы төште Зәйтүнә.— Бу реализм әсәре, ә Пикассо яңа методлар эзләгән.

— Методны әйтәммени мин? Хикмәт күңелдә, хисто, йөрәктә!

Аннары башын ия төшеп, текә маңгае астыннан ягымлы карады да, сәер генә итеп каш сикертеп куйды. Сәнгать әсәре хакында җитди сүз барганда, аның кыланышы Зәйтүнәгә бик тә урынсыз тоелды. Ничектер кыен булып китте хәтта.

Хәзер дә, рәсемнәргә күз салган саен, Әнвәр ничектер үзгәреп китә, ул, ике рәсемнән соң өченчесенә карагандай итеп, хатынына текәлә, ниндидер соравына җавап эзли, нәрсәдер көтә кебек. Андый минутларда аның коңгырт күзләренең көйдергеч утыннан качасы килә.

Рәсемнәрне күләгәдә калдырып, кичләрен яшел торшер яктысында икәүдән-икәү утырган чакларда бик рәхәт Зәйтүнәгә.

Торшердан төшкән йошак яктылык астында, Әнвәр өстәлгә алсу кәгазен җәя, готовальнясын ача. Аның сизгер, нечкә, хәрәкәтчән бармаклары готовальняның кызыл бәрхете эчендә ялтырап яткан ак тимер каләмнәргә һәм җәзбәләргә җан өргәндәй итәләр. Һәм кәгазьдә төгәл, пөхтә сызыклар пәйда була.

Өстәл янына китабын тотып Зәйтүнә килеп утыра. Ул әледән әле башын күтәреп ирен күзәтә. Әнвәр сызымнарны шигырь язган шагыйрь яки җыр чыгарган композитор кебек ләззәтләнеп сыза.

Әйе, тимергә җан өрә белә аның Әнвәре.

Тик менә утны бөтенләй сүндереп, караңгыда калгач, хатыны янында аның бу тылсымлы көче нигәдер бөтенләй юкка чыга. Иренең кайнар бармаклары орынуга, Зәйтүнәнең тәне агачланып киткәндәй була. Эчтә ут, тышта — агач... Туйдан соңгы беренче төндә үк барлыкка килгән бу тартыну, оялу үтәр дип уйлаган иде Зәйтүнә, күнегермен, гадәтләнермен, дип өметләнгән иде.

Ләкин гадәтләнә алмый, киресенчә, торган саен бу тартыну арта гына барган шикелле. Соңгы вакытта бу читләшү тагын көчәйде сыман әле. Чөнки алар икәү генә түгел инде, озакламый өчәү булырга тиешләр. Һәм бу өченче җан иясе хакына Әнвәр күңелгә тагын да якынрак тоелса да, аннан оялу, тартыну хисе тора торып көчәя генә бара.

Хәзер менә мадам Жаклинның агач гәүдәсен күргән саен, күңелне шомландырып Ларисаның кинаяле сүзләре искә төшә: «Синең рухта инде бу, Зюзю!»

*

* *

Әнвәр кайткач, утырып чәй эчкән табынны җыеп та өлгермәгәннәр әле, тышкы якта кемнәрнеңдер күңелле шаулашканы ишетелде, кыңгырау зыңгылдады.

Ишек ачылуга, очынып, күгәрченләй гөрелдәп Лариса килеп керде, Зәйтүнәнең муенына асылынды.

— Зюзю! Беләм бит мин сезнең хәзер генә нишләп утырганыгызны!

Ул башын борып, кысан коридорга чыга алмый басып торган Әнвәргә карады.

— Безне сагынып, безне сөйләшеп утыра идегез. Шулай бит, Анварчик?

Лариса артында Кифаяның давылдагы кебек тузган чәче, зур авызы күренде. Аннары ишекне тутырып зур гәүдәле, төз, нык муенлы Хөсәен килеп керде.

— Менә сезгә күчтәнәч!— диде Лариса очлы бармагы белән аның тарафына ишарәләп.— Котыптан кайткан ак аю! Зюзю, Анварчик! Мине котыбына алып китәргә кайткан бит ул! Алып китәргә дә башкаемны харап итәргә йөри! Шулай ук йолып калучы булмас микәнни?

Хөсәен аның сүзләренә тыныч кына елмайды, билен бөгә төшеп, сак кына Зәйтүнәнең кулын кысты һәм Әнвәрнең иңнәреннән кочып алды.

Кунаклар кайсы урындыкка, кайсы караватка урнашкан арада, Зәйтүнә яңадан табын әзерләргә керешә.

Димәк, Хөсәен Ларисаны алырга кайткан, дип уйлады ул. «Барыбер минсез яши алмаячак!» — дигән иде Лариса, хак икән. Аллә күрәзәлеге бар инде ул Ларисаның! Әнвәр турында әйткәне рас килә күрмәсен тагын! Ничек дигән иде әле ул? «Ах, Зюзю, егетнең асылын эләктергәнсең, якты утка күбәләк күп очучан, сак бул!» Бу кисәтүдә кызыгу, хәтта көнләшү дә бар иде шикелле.

Нәкъ шул вакытта Хөсәен белән аның арасы суыныбрак торган иде. Лариса егете янына чыкмый, мендәренә капланып, караватында ята, Зәйтүнә Әнвәр белән урамнарда озаклап йөргәннән соң кайтып кергәч, Лариса сикереп торып, чәйнектән салкын су эчә. Аның күз карашы Зәйтүнәнең күңеленә шом сала иде. Ярый, бераздан Лариса белән Хөсәеннең аралары җайлашты тагын.

Аралары җайлану өчен мөмкинлекләре күп иде шул аларның. Икесе дә тулай торакның бер үк катында яшиләр, бер кухняда аш пешерәләр. Кичләрен караңгы почмакта пар күгәрченләй гөрелдәшкән тавыш ишетелсә, бүтән булмас, шул Хөсәен белән Лариса булыр. Баһадир гәүдәле, әмма карап торышка юаш холыклы Хөсәеннең патшабикәсе булды бу кечкенә буйлы, чөенке борынлы, җирән бөдрә чәчле Лариса. Ул үзенең агачтан бик нәфис итеп уелгандай бармагы белән кай тарафка ишарәләсә, ягымлы елмайган егет шул тарафка атлап китәр иде. Кулга ияләшкән филмени!

Бәйрәмнәрдә Лариса күңелле мәҗлесләр оештырырга ярата. Нәкъ менә ул әзерләгән табыннарда күп кенә кызлар, шул исәптән Зәйтүнә дә гомерләрендә беренче тапкыр вино авыз иттеләр. Андый табынларга егетләр-кызлар акча гына җыялар, калган барысын Лариса әзерли: Хөсәенне иртәп базарга бара, бик оста сатулаша, алган бер әйберсен пөхтәләп төреп, егетнең портфеленә сала, салат-фәлән ясаганда, балык тазартканда да егетне яныннан җибәрми иде.

Лариса белән дуслашкач, егетнең өс-башы чистарды, элек чалшаебрак йөри торган ботинка башлары турайды. Югыйсә яхшы укуы, фәнни

түгәрәктәге эшләре белән бөтен институтта дан тоткан Ленин стипендиаты Нигъмәтуллинның аңарчы күзгә карарга да вакыты калмый иде бугай.

Барсы да аны, диплом алгач та аспирантурага керер, ике-өч елдан диссертация яклар, дип уйлаганнар иде. Ә ул, институтны Ларисадан бер ел элек тәмамлап, Төньякка, Сургут каласына направление алды.

Ларисаның үгетләрен, ялваруын, хәтта каһәрләвен тыныч кына елмаеп тыңлады да үзенекен итте:

— Чын врач булыйм дисәң, тормыш казанында кайнарга, мөстәкыйль эшләп карарга кирәк. Үзеңне сынарга кирәк башта!

Ул көннәрдә Лариса бөтерчектән борауга әйләнгән, таш күңелне дә тишәр кебек иде югыйсә.

Хәтердә, бер кичне Лариса түше чигелгән төнге күлмәген киеп, караватта чәчен бигудигә урап утыра иде.

— Ничек соң, чынлап та китәргә булдымы инде Хөсәен?— дип сорады Зәйтүнә.

— Китсә тагын, кендегем берекмәгән әле,— дип җавап кайтарды Лариса.— Мин бит аны аэроклубларга барып, күккә менеп эзләп йөрмәдем! Аякка үзе килеп уралды. Китсә китәр, ил бетмәсә, ир бетмәс, ди иде минем әби.

Ларисаның бу рәвешле ямьсез итеп дустын тешләве урынсыз һәм аңлаешсыз иде, әмма Зәйтүнә аның авыр сүзен үткәреп җибәрергә тырышты. Кәефсез чагы, ялгыш ычкындыргандыр, дип юанды.

Айлар узгач, уку елының ахырына таба Ларисаның Хөсәенгә ачуы бераз басыла төште булса кирәк. Ул чакта инде Зәйтүнә тулай торактан киткән, лекцияләрдә генә очрашалар иде, шулай да ишетте: Лариса Хөсәеннең үзе кебек үк сабыр, тыныч, ягымлы язылган хатларына җавап бирә башлаган, имеш...

Менә инде Хөсәен Ларисаны алырга кайткан икән. Тәмам килешкәннәр, димәк.

Зәйтүнә чәйнеген күтәреп кухнядан бүлмәгә кергәндә, Әнвәр белән Хөсәен, изүләрен чишеп, идән буйлап үрмәләп йөриләр иде. Идән тулы кәгазь, кәгазьләрдә сызым, сызымнарда әлеге дә баягы шул теплицалар.

— Мин ул парник хуҗалыгының исемен үк үзгәрттерәчәкмен әле!— ди Әнвәр кайнарланып.— Совхоз итәчәкмен мин аны!

Караватт кырыена утырган Лариса бөтен гәүдәсе белән аңа таба авышкан, ләкин сызымнарга түгел, аның йөзенә текәлгән иде.

— Искиткеч, гаҗәп!— диде үзе Әнвәрнең сүзен хуплап.

Кифаяның кичәге мәҗлестән соң йокысы туймаган, ахрысы, кырыйдагы урындыкта иснәштереп утыра. Нигә иярттеп йөри икән аны Лариса? Бер дә пар түгелләр бит югыйсә!

Хәер, чамаларга була. Лариса дөньяны күп күргән кеше, офицер гаиләсендә үскәнгә, илне аркылыга-буйга күп гизгән, акыл җыйган, Кифая кебек килешсез киемле ямьсез кыз янында үзенең балкып торганын белә.

— Туктаусыз эше турында сөйләп торган ир белән яшәгән хатынга рәхмәт инде,— диде Кифая өйне яңгыратып.— Кунакларны сызым белән сыйлыйлармы әллә сездә?

Әнвәр, башын күтәреп, аңа гаҗәпләнеп карады:

— Эх сез! Үзегез врач әле җитмәсә! Кышын-язын яшелчәнең кирәклеген миннән дә бигрәк сез белергә тиеш!

— Анварчик, беләбез, бик беләбез!— Лариса тирән итеп, йөрәк түре белән көрсенеп куйды.— Әйдәгез әле, дуслар, Әнвәрнең изге хыяллары тормышка ашсын өчен берәр кәсә күтәрик әле. Гөнаһ булмас, шулай бит? Әй, ак аю! Сумкадан күчтәнәчне ал! Зюзюнчик, ярдәм итимме?

— Юк, сез аңлап бетермисез әле, бетермисез!— диде Әнвәр идәннән

сызымнарын җыйганда.— Безнең хуҗалыкта эшләүче хатыннарның хәлен белсәгез иде сез! Метр ярым тирәнлектәге чокыр төбенә март аенда яшелчә утырта башлыйлар. Парник эченә басарга ярамый, алар чокыр өстенә аркылы такталар куеп шуларга күкрәкләре белән ятып эшлиләр. Билләһи, андый чакта мин алар яныннан узарга оялам, әйләнеп үтәм. Хатын-кызга бозлы такта өстенә күкрәге белән ятып эшләргә ярыймыни? Шуннан соң алар сезнең янга йөри башлыйлар инде.

— Безнең Әнвәр бөтен дөньяны бүген үзгәртеп корыр иде, әгәр кулыннан килсә,— диде Зәйтүнә иренә сокланып һәм аның сәерлегеннән көлемсерәп.— Ул әйтә, шәһәрләрдә дә бер генә карыш җир дә әрәм ятмаска тиеш, газоннарга арыш чәчәргә кирәк, ә скверларда алмагачлар, чияләр үстерергә күптән вакыт, ди. Без әле аның белән «Арыш чәчәге» дигән исемәй чыгарганнарын көтәбез!

— Ә нигә, арыш серкәсеннән дә татлы ис дөньяда юк. Мин шаккатам: парфюмерлар шуны да аңламый микәнни соң?

— Әнвәр белән без шәһәр урамнарында бер машина да калмаган көннәрне күрергә өметләнәбез әле,— дип дәвам итте Зәйтүнә.— Йөкләрне җир астыннан салынган торбалар буйлап кына йөртәчәкләр, ә кешеләр һәрберсе канатлар тагып очып йөриячәкләр.

Бу сүзләрдән Кифая шаркылдап көлеп җибәрде, Хөсәен үзалдына «хым» дип куйды, Лариса күзләрен тутырып тагын Әнвәргә текәлде.

— «Арыш чәчәге» дигән исемәйнең беренче шешәсен үзем сатып алачакмын! Теләсә нинди бәягә, бөтен мал-мөлкәтемне бирер булса да. Ә алмагач чәчәкләренә төренгән, хуш искә күмелгән шәһәр өстеннән канат җилпеп очу... Эх, татлы төш кенә шул ул!

— Ә нигә төш кенә! Хәзерге заманда техниканың моңа көче җитәрлек. Алай карасаң, безнең бабайларга телевизор да төш кебек тоелган!— диде кызып киткән Әнвәр.

Хөсәен идән уртасында баскан килеш бу бәхәсне тыңлап торды да:

— Анысы шулай, ә менә Төньякта эшләүчеләрне витамин белән кем тәэмин итәр икән?— дип куйды.— Анда бит чын батырлар эшли. Нефтьчеләр изге кешеләр, алар синнән җаннарын да кызганмаячаклар. Акчасын да бирерләр, материалын да табарлар, рәхмәтен дә әйтерләр.

— Әйдә безнең белән, Анварчик!— диде кинәт өзелеп киткән тавыш белән Лариса.

Аның бу сүзләреннән бүлмәдәгеләр тынып калдылар.

— Туктагыз әле, монда башлаган эшне очлыйсы бар...— диде кызарынып, буталып Әнвәр.

— Әйдәгез әле, табын янына утырыйк,— диде Зәйтүнә бүлмәдәгеләрнең нидәндер кыенсынып калганын күреп.

Өстәл янына утырганда, Хөсәен аның сул ягына туры килде. Яннан караганда, егетнең маңгае калкурак,ияге чыгынкырак, иңбашлары киң — гомумән бөтен бәдәне тагын да гайрәтлерәк күренә икән. Әллә соң Себернең җил-бураннары шулай чыныктырганмы аны? Сүзен дә әнә ничек үлчәп кенә, хуҗаларча нык итеп сөйләшә. Сургутта ул больницаның баш врачы икән. Күрәсең, институтта ул үзенә багланган өметләрне аклый алмас, фән юлында уңышка ирешү аңа насыйп булмас инде. Фән сәнгать кебек бит ул: бар гомерне үзенә багышлауны таләп итә, ыгы-зыгы килгәнне, кабаланганны яратмый. Ә баш врачның мәшәкате күп аның. Иң катлаулы авыруларны карау, врачларның булдыксызларын эшкә өйрәтү, рентген, УВЧ аппаратлары артыннан чабу, больница бинасын төзекләндерү, ягулык булдыру эшләре аның бөтен вакытын, көчен йотар. Тирә-юньдә хөрмәт белән аны «олы врач» дип атарлар, әмма төшкә генә керердәй татлы хыяллар белән мавыгырга аның вакыты да, мөмкинлеге дә калмас. Боларны күз алдына китерсәң, Ларисаның бу рәвешле вәсвәсәләнүен аңларга да була.

— Мин хыялы канатлы кешеләр хөрмәтенә бокал күтәрәм,— диде ул. Табын янында врачларның эше хакында сүз китте.

— Бүгенге врачның һәркайсы Әбугалисинадан яхшырак дәваларга тиеш,— диде Әнвәр.— Күпме дарулар, яңа аппаратлар сезнең кулда.

— Аппарат кешене үзе генә дәвалый алмый шул,— диде Хөсәен көрсенеп.— Әбугалисина кебекләргә медицина мәңге мохтаҗ булачак.

— Гиппократлар, Әбугалисиналар заманы узды инде,— диде кисәк Лариса ачулы тавыш белән.— Хәзер специализация заманы. Медицина өлкәсендә йөз илле төрле белгеч бар. Йөз илле төрле! Кендек врачы гына юк бугай әле. Анысын да булдырырлар, мөгаен. Әйтик, менә безнең Кифая участок врачы була инде. Берәрсе эч авыртып килсә, ул аның өчен үзе баш ватып утырмый, хирургка, инфекционистка я башка берәрсенә җибәрә.

Кифая зәңгәр буйлы юбка өстеннән кигән кызыл чәчәкле кофтасын тарткалап куйды. Аның эш хакында сөйләшәсе дә килми иде. Ул шәһәрдә калу өчен эшне җайлап, бер больницадан чакыру кәгазе дә алып куйган иде. Әмма яшь белгечләрне эшкә җибәрү комиссиясендә министрлыктан килгән ир уртасы кеше ул кәгазьне ике бармагы белән генә тотып селеккәләде дә:

— Без белгечләрне кая җибәрергә икәнен үзебез хәл итәбез,— диде.— Халык сезне алты ел укытты, аңа иң кирәк җирдә эшләп күрсәтегез әле.

Шулай итеп, Кифая авыл җиренә, анда да әле район үзәгенә түгел, үзәктән егерме биш чакрым диме ераклыктагы авылга китәчәк. Аның бәхетенә каршы, анда берничә колхоз берләшеп, өч катлы больница салып куйганнар икән.

— Син, Кифая, бер дә аптырама,— диде Лариса дустын үчекләп.— Мондагы авыл себер түгел әле ул. Сургутта әнә суларга һава да җитми, диләр. Син «инолас»ны гына онытма.

Хөсәен аңа гаҗәпләнеп карады:

— Нинди инолас ул тагын?

— Врачка ике «ин»ны, өч «ол»ны, бер «ас»ны истә тотарга гына кирәк.

Зәйтүнә, Хөсәеннең сагаеп, Әнвәрнең ихлас кызыксынып тыңлаганын күргәч, шаркылдап көлеп җибәрүдән чак тыелып утырды.

— Авыл врачына килгән халык күбрәк баш авыртудан я эч авыртудан зарлана,— дип бик җитди дәвам итте Лариса.— Баш авыртканда аспирин я анальгин бирергә кирәк. Ике «ин» булдымы? Эч авыртса — бессалол. Менә сиңа бер «ол». Урта яшьтәгеләрне ике сортка бүлеп эш итү яхшы. Ирләрнең эче авыртса — аллахол яхшы, хатын-кызларга — норсульфазол.

— Нишләп андый аерма?— дип сорады Әнвәр.

— Женси аерма!— диде Лариса көлүдән чак тыелып.— Ирләрнең эчү-тарту бавырларын бозган була. Ә хатын-кызның үз җафасы. Өч «ол» булдымы? Ул гына аз тоелса, карчык-корчыкка холосас тәкъдим итү яхшы. Бик яраталар.

— Ансат икән!

Зәйтүнә сискәнеп куйды. Хөсәеннең мондый кырыс сөйләшкәнен аның моңарчы ишеткәне юк иде әле.

— Әйе-е, ансат...— дип сузды Әнвәр.

— Зыянсыз да,— диде Кифая.— Анысыннан канәгать булмаганнарын шәһәргә озатырга кирәк. Участок врачына килгәннәрнең уннан тугызына барыбер берничек ярдәм итеп булмый. Практикада күрдем инде: анда тезелешеп пенсионер карчыклар утыра. Картлык чиреннән кемне терелткәннәре бар?

— Әбиләрнең рәхмәте зур була аларның. Бер йомшак сүздән дә

сызлануларын оныталар, бер елмаюдан да шифа табалар,— диде Зәйтүнә.

— Сиңа рәхәт, әллә кая китеп, ятлар арасында интегеп йөрисе түгел!

Менә шулай: Зәйтүнәгә авыз ачып сүз әйтергә дә ирек бирмиләр. Ул җайлы кияү эләктергән дә, Казанның үзендә, клиникада акушер-гинеколог булып җайлы гына урнашып калды янәсе. Дәвалау факультетының теләсә кайсы студентыннан сора син, кем булырга телисең, дип. Ул я терапевт, я хирург, я акушер-гинеколог булам, дияр. Исемнәре дә, эше дә дәрәҗәле ул белгечләрнең. Ә менә Лариса белән Кифаяга кем булырга туры килер, анысы билгесез әле. Дөрес: чиста-пөхтә Лариса турында студентлар: «Наша Лора будет лором»,— дип шаярышалар иде. Маңгаена елкылдап торган түгәрәк көзге беркетеп, кешеләрнең ачылган авызына инструментлар белән генә үрелеп утыру аңа чыннан да бик килешәчәк иде. Ләкин төньякта алай гына утыру мөмкин булыр микән соң?

Хөсәен, Зәйтүнәгә аркасын куеп, Ларисага таба борылды:

— Сез нәрсә, институттан шул «инолас»ны гына белеп чыктыгызмы әллә?

— Я инде, ул кадәр аю булма,— дип гөрелдәде Лариса.— Көлүеңне оныттырдыларммы әллә? Шаярабыз гына ич без. Аңлыйсыңмы, ша-я-рабыз.

— Кешенең сәламәтлеге белән, әҗәл белән шаярмыйлар!

— Уф алла, нинди әҗәл булсын, ди!— Лариса аның күкрәгенә сыенып, куллары белән баш артын сыйпады.— Себер женнәре алыштырып җибәрдеме әллә сине? Пәри алыштырган малайларны, беләсеңме, нишләтәләр бездә? Мич алдына утырталар. Шуннан соң пәри үз баласын кызганып алып китә. Ә мин сине көлдереп гаҗизләндерермен, кети-кети итәрмен, пәри кызганганчы көлдерермен...

Зәйтүнәгә Ларисаның егет муенын тырнаштырган очлы бармаклары гына күренә иде. Гаҗәбе шунда: Хөсәеннең горур башы шул бармакларның хәрәкәтенә буйсынып иелә барды, иелә барды һәм, ниһаять, тәмам бөгелеп, Ларисаның күкрәгенә терәлде. Урыныннан торып баскан Лариса, егет башы аркылы Зәйтүнәгә горур караш ташлады.

Ләкин бу гына җитми иде әле Ларисага. Гайрәтле егетнең башы иелү генә аз иде аңа. Арыш һәм алмагач исенә төренгән гүзәл кала өстендә канат җилпеп очу турында хыяллана иде ул. Ни уйлый, ни сөйли бу үзсүзле себер аюы? Нефтьчеләрне витаминнар белән тәэмин итү, аларның рәхмәте турындамы? Нәрсә белән шөгыльләнә ул? Мәңге бетмәс хасталарның зарларын тыңлау, себер бураннары эчендә андамонда йөрү беләнме? Ә башка берәү кошлар кебек очу турында хыяллана.

Берсичә итеп канатларны үзеннән кала тагын кемгә куяр ул?

*
* *

Иртәнге конференция тәмамлангач, врачларга соңгы киңәшләрне биргәннән соң, Җәмилә Закировна үз бүлмәсенә кереп, өстәлдәге кәгазьләрне караштырды да, җиңел сулап куйды. Бетте. Бүгеннән башлап бер-ике атнага ул клиника ваемнарыннан бушанып торачак. Хәзер өйгә кайтырга да юлга җыенырга. Кичке поездга чаклы вакыт бар әле.

Шунда аның йөрәк түренә утлы очкын төшеп көйдергәндәй итте. Нилектән бу? Җәмилә Закировна башын күтәрде һәм сул ягында, ике тәрәзә арасындагы рәсемгә карап, тынып калды.

Кызгылт-сары металлга уелган бу рәсемдә сабыена иелгән ана су-

рәтләнә иде. Профессор Ильясовага аны Ереван шәһәрендә узган зур бер киңәшмәдә бүләк иттеләр. Бик зурлаганнар иде анда Җәмилә Закировнаны:

— Табигать серләрен ачу юлында тагын бер мөһим адым ясаганыгыз өчен...— дигән сүзләре хәтердә калган.

Табигать серләрен ачу! Нинди мәгънәле сүзләр бу!

Дөньяга яралганнан бирле кеше үзенең кемлеген һәм нидилеген белергә тырыша. Ләкин хәзер дә әле галимнәр, без үз-үзебезне космосны белгәннән дә азрак беләбез, диләр. Ә кешенең яшәешендәге серләрнең иң бөеге — ул безнең якты дөньяга килүебездер, мөгаен.

Кызгылт-сары металлга уеп ясалган бу рәсем шул могҗизаны — тәннән — тән, җаннан җан яралу могҗизасын искәртә иде. Ана белән бала икесе йомшак, нәфис, сыгылмалы өзелмәс бер сызык ярдәмендә тасвирланганнар, яшь ананың сабыена текәлгән карашындагы наз җылысыннан күз кабаклары күперебрәк тора.

Кайчакларда, нәрсәне дә булса исенә төшерергә тырышканда яисә зиһене таралганда, Җәмилә Закировна шушы рәсемгә карап уйлана. Ишеккә каршы эленеп торганга, бүлмәгә кергәннәрнең дә күзе иң элек шуңа төшә. Диләрам дә бу картинага игътибар иткән иде.

Диләрам! Җәмилә Закировнаның йөрәге сулкылдап куйды. Диләрам! Менә кем өчен сыза икән бит аның күңеле!

Әйе, Диләрам сабыен кочкан яшь хатын сурәтенә керфекләрен сирпеп бер күз салды һәм шундук боегып китте, аның вак сипкел белән чуарланган озынча каратут йөзе тимгелләнеп кызарды. Урындыкка утыргач, вак толымнарының берничәсе яңагына төште, башын түбән игәнгә, түбәтәе өстендәге аллы-гөлле чигешнең бөтен бизәкләре күренде, ул үзбәк ефәгеннән тегелгән күлмәгенең кыска җиңнәрен озынайтырга теләгәндәй, тарткалап куйды.

Башкалар өчен бик гадәти тоелган бу рәсем Диләрамның бәгырен телде, гүя ул аның кешеләрдән кимлеген искәртә иде. Балалар турындагы һәр сүз, җыр яисә рәсем аның тормышын агулый иде — чөнки Диләрамны язмыш һәр хатын-кызга тумыштан бирелә торган табигый сәләттән — ана булу сәләтеннән мәхрүм иткән. Дөрес, бу кимчелек аның тәнен сызландырмый, әмма күңелен һич тындырмый иде: кайсы гына кыз бала гомерен корыган агач кебек уздырырга теләсен соң?

Хәсрәтенең ачылыгын, бөтен өмете Җәмилә Закировнада гына икәнен аңлатырга сүзләр таба алмады Диләрам, буталды, тотлыкты. Ләкин профессор аның хәлен кыяфәтеннән үк аңлый иде. Безгә килеп дөрес эшләгәнсез, диде ул. Сезгә ярдәм итәрдәй операцияләрне мин үзем ясамыйм ясавын, ләкин бездә ул эшнең танылган остасы бар. Берничә кешегә операция ясады инде, барысы да уңышлы узды, хәзер кызлар кияүгә чыктылар, әни булдылар.

Җәмилә Закировна Диләрамны Изаил Харисович янына үзе алып барып, аның клиникасына урнаштырды.

Бүген Диләрамга операция ясаячаклар. Изаил Харисовичка ышанып була — кулы оста булу бер хәл, ул авыруларны операциядән соң да күңел биреп карый. Хәтта аларны өстәлдән каталкага да үзе күтәреп сала иде монда чакта, ул эшне дә беркемгә ышанып тапшырмый иде. Төннәрен үзе теләп клиникада уткәргән чаклары да күп булды.

Ләкин нигә соң йөрәк түрендәге утлы очкын һаман көйдереп тора, нигә Диләрамның чык кунган йөзем җимеше төсле күзләре күңелдән һич китеп тормый?

Язылмаган кагыйдәләр профессорга, башка кафедраның клиникасына барып, андагыларның эшенә катнашып йөрергә кушмыйлар. Ләкин күңелендәге бу сызлавыкны ерак юлга алып чыгып китсә, кайтып кергәнче тынгы белмәячәк иде Җәмилә Закировна.

Кагыйдәне бозып булса да Диләрам янына кереп чыгарга ниятләде ул. «Өйгә кайтканда юл уңае бит, операция башланды микән, башланса, ничегрәк бара икән, шуны гына белешермен дә китәрмен»,— дип үз-үзен акларга тырышты.

Икенче клиника Казан каласының яшьлеккә кумелгән борынгы урамында, сырлап-бизәп салынган ике катлы борынгы бинага урнашкан иде.

Трамвайдан төшкәч, Җәмилә Закировна урам чатындагы чуен бюст янында адымнарын чак кына акрынайтты. Атаклы галим Вишневскийның сыны дүрткырлы кара баганадан калкып чыккан төсле итеп коелган, ул, үз эченә йомылып, бөтен ихтыярын, рухи көчен бер ноктага төбәгән. Кулына перчатка тартып кия — җитди операциягә әзерләнә. Җәйге җылы, якты бу иртәдә, сары тәлгәшләреннән бал коеп утырган куе юкәләр ышыгындагы бу сын кешеләргә дөньяда бәхетсезләр барын, аларга ярдәм кирәген кисәтеп торадыр сыман.

Гинекология бүлеге клиниканың икенче катына урнашкан. Аның иркен, биек коридорына сул яктагы тар тәрәзәләрдән кояш төшеп, иске паркет идәнгә буй-буй сузылып яткан. Изаил Харисович профессорны ерактан ук күреп алды да каршысына атлады.

— Хәерле иртә, Җәмилә Закировна! Бик вакытлы килеп җиттегез! Операциягә әзерләнәбез!

Остазын күптән көтеп торган диярсең, озын гәүдәсен алгарак авыштыра төшеп, тешләрен җемелдәтеп каршысына килеп тә басты.

Елмаешып исәнләшкәч, Җәмилә Закировна доцентның халатын бүлтәйтебрәк чыгып торган бил турысына ымлады:

— Үсәбезме, Изаил Харисович?

— Дәрәҗә өчен бераз анысы да кирәк, Җәмилә Закировна. Югыйсә авырулар бала-чагага саный.

— Ә мин бер генә минутка. Бүген китәм, шуңа танышым белән саубуллашырга дип кердем. Аның монда башка беркеме дә юк бит, күңелен күтәрергә кирәк бераз.

Чыннан да, операция четерекле, Диләрам монда ник килгәнен туганнарына да, якыннарына да әйтмәгән иде.

Җәмилә Закировна Дәүләтшинга чын күңелдән уңышлар теләде дә, коридорның күләгәле борылышына, андагы ак ишекләрнең иң ахыргысына таба юнәлде.

Диләрам кулъюгыч өстенә стенага беркетелгән көзге каршында чәч тарап тора иде. Җәмилә Закировна килеп кергәч, ул кулындагы сөяк тарагын идәнгә төшереп җибәрде, үз күзләренә ышанмыйча, бер тын профессорның көзгедәге чагылышына карап торды, аннары, бу чагылышны югалтудан курыккандый, әкрен генә борылды.

— Җәмилә Закировна... Җәмилә Закировна! Ә мин сез килмәссез дип курыккан идем! Шул хәтле курыккан идем, Җәмилә Закировна!

Ул профессорның кочагына ташланудан көчкә тыелып тора, ләкин аңа якын килүгә кара йөзем җимеше төсле күзләреннән чык тамчылары түгелә башлаячагын да сизә иде.

Мондый чакларда авыруларга тәмам җебеп төшәргә ирек бирү ярамый, Җәмилә Закировна бик тыныч, хәтта бераз кырыс тавыш белән:

— Борчылырга бернинди сәбәп юк, Диләрам,— диде.— Сез авыртуны сизмәячәксез, йоклап кына аласыз, ә торуыгызга бөтенесе үткән була. Изаил Харисович бу эшкә алынган икән, сөенергә генә кирәк.

Доцентның исемен ишеткәч, Диләрам карашын аска төшерде.

— Операциягә сез дә керәсездер бит, Җәмилә Закировна?

— Мин монда бит инде, Диләрам! Мин монда...

Ашыгып шәфкать туташы килеп керде.

— Ахунова, сез нишләп басып торасыз? Мин сезгә укол ясагач әйттем бит, ятып торырга кирәк, дип! Егерме минуттан сез йокыга китәчәксез!

Диләрам айнып киткәндәй булды, идәннән тарагын алып, чәчен тарарга кереште. Аның нечкә беләзекле кулы тарагын баш түбәсеннән аска шудырган саен, тез астына кадәр төшкән чәч агымы чайкалып куя иде. Менә ул маңгай турыннан кечкенә бер тотам аерып алды да, тегәрҗептәй нечкә итеп үрә башлады.

— Сез нәрсә, кырык үрем ясарга уйлыйсызмы әллә?— диде пошаманга төшкән шәфкать туташы.— Каягыз, үзем генә үреп куям!

Диләрам аны читкә этәрде, хәрәкәтләре йокымсыраган кешенеке кебек салмаклана башлаган иде аның.

— Ашыктырмагыз,— диде Җәмилә Закировна шәфкать туташына.— Үзе теләгәнчә үрсен.

Диләрамның күнеккән нечкә бармаклары күз иярмәс тизлек белән хәрәкәтләнә иде. Ул чәчен гадәттәгечә, әнисе, әбисе үргәнчә үрергә тели, гүяки бу аңа җан тынычлыгы, операциянең уңышлы тәмамланачагына ышаныч бирә иде.

Җәмилә Закировна караватларында шым гына утырган биш-алты хатынны күздән кичерде, кырый тумбочка өстендә өелеп яткан кулъяулыкларны күреп алды. Алар ал, яшел, зәңгәр ефәк белән читләнгән, өстәгесенең чигешенә энә кадалып, аннан сары җеп сузылып төшкән иде.

Профессор гаҗәпләнеп тумбочкага якынрак килде.

— Чигә ул,— диде, шыпырт кына ияге белән Диләрам тарафына ымлап, янәшә караватта утырган хатын.— Туйга әзерләнә... Ярәшкән егете бар икән...

Диләрам толымнарын үреп бетерде дә, барысын бергә җыеп, башы тирәли кыршау итеп урап куйды, өстеннән ак кыекча бәйләде. Ул арада каталканы тәгәрәтеп керттеләр. Диләрам авырлык белән менеп ятты — аны тәмам йокы баскан иде инде. Ул үзенең бөтен киләчәген, мәхәббәтен, булачак туен, гомерен — барысын, барысын да башкалар кулына ышанып тапшырган, нинди генә куркыныч янаса да, ни бер хәрәкәт ясап үзен яклый алмаячак иде.

Аның сузылып яткан нечкә сынына карагач, Җәмилә Закировнаның күңел түрендәге теге очкын төшкән нокта тагын сызлый башлады.

Ул каталка артыннан иярде. Операционный турына җиткәч, кинәт, үзе дә сизмәстән, шәфкать туташына:

— Миңа да чиста халат табылыр бит сездә?— диде.— Кулны да юарга кирәк булыр.

Ул бераз соңарыбрак керде. Изаил Харисович белән ассистент өстәлгә иелгән башларын күтәреп карамадылар, тәбәнәк эскәмияләргә тезелеп баскан ак халатлы, маскалы егетләр-кызларның кайберләре генә профессор тарафына күз сирпеп алды — доцент бу операциясенә дистәгә якын яшь врачны да чакырган иде.

Җәмилә Закировна тавышсыз адымнар белән алардан чак кына читкәрәк, ассистент артына барып басты.

Бер карауда күңеле тынычланып китте аның: операционныйда тәртип, һәркем — операция сестрасы, наркотизаторлар, хәтта аны-моны җыештырып торучы санитарка да — һәммәсе үз эшләрен белеп, тәгәл башкаралар. Яңа урында да сынатмаган иде Дәүләтшин, зур гына коллективның оста бер оештыручысына әверелгән иде...

Үзенең дә хәрәкәтләре пөхтә, житез, һәм — профессор шунысына аеруча игътибар итте — йомшак, сак иде, скальпель нәкъ кирәгенчә генә сыза, тамчы да артык яра ясамый. Тыныч, җиңел эшли доцент, шул арада битлек астыннан бәрхет кебек ягымлы булып чыккан тавыш белән аңлатма да биреп өлгерә.

Менә операциянең иң төп, иң җаваплы өлеше башланды. Изаил Харисович скальпель белән озын гына итеп сызып җибәрде.

Шунда кинәт нидер булды: һава эсселәнеп киттеме, тәрәзәләрдән төшкән яктылык кимедеме, Җәмилә Закировнаның колагы томаландымы — доцентның тавышы ерагайды, сүзләре аңлашылмый башлады. Нидер үзгәрде, ләкин моны профессордан башка беркем сизми иде әле.

Җәмилә Закировна ассистент янына ук басты да, битлек астында кызышып киткән иреннәрен авыр хәрәкәтләндереп:

— Изаил Харисович, уң якны күтәреп карагыз әле,— диде.

Доцентның саргылт перчатка эчендәге бармаклары кабырга астында зур гына төергә юлыктылар. Аның куе кашлары арасына ике буразна уелып керде, ул тураеп басты да, маңгаеннан тир тамчыларын сөртеп алырга дип үрелгән операция сестрасының кулын этәреп җибәрде.

— Нәрсә карап торасыз?— диде тупас итеп ассистентка.— Хирургларга шалтыратыгыз, хәзер үк берәрсе килеп җитсен!

Ассистент, доценттан яше белән шактый өлкән хатын, ак күләгә кебек тавыш-тынсыз гына операционныйдан чыгып китте.

— Кетгут!

Изаил Харисович әле генә ясаган яраны кире тегәргә кереште. Хәзер инде операцияне алдан уйлаганча дәвам итү мөмкин түгел, ә шешне бары тик тәҗрибәле хирург кына алырга тиеш иде.

Доцентның бармаклары кинәт агачтай катыланды, ахрысы, алар орынган урынга кан савып, күгәргән таплар кала башлады. Ни тыелырга тырышса да, Җәмилә Закировна:

— Саграк,— дими булдыра алмады.

Ул арада ассистент борылып керде: күршедәге хирургия клиникасында операция бара икән, беркем керә алмый, дигәннәр.

Эчтәрәк тагын берәр нәрсә юкмы, дип авыруны тикшереп торган Изаил Харисович нидер мыгырданды, сүзләре аңлашылмады.

Җәмилә Закировна чыгып, унбишенче больницага, профессор Петровка шалтыратты. Шөкер, ул урынында булып чыкты.

Ильясова әйләнеп кергәндә, яңь врачлар юк иде инде.

Алар икесе — зур галим врачлар — бер чарасыз кара-каршы басып тордылар — алар арасында ярдәмгә мохтаҗ Диләрәм ята, аның һәр сулыш алуы, йөрәк тибеше Җәмилә Закировнаның чигәсендә сулкылдау булып чагыла иде.

Медицинаның өч дәвалау чарасы бар: сүз, үлән, пычак, диләр. Профессор Евгений Михайлович Петров бу чараларга тагын берне өстәгән иде: кыяфәте белән дә дәвалый иде ул: аның үзен күргәч үк сызланулар кимегәндәй була иде.

Бу юлы да операционныйга киң җилкәле, таза гәүдәле профессор килеп кергәч, сулыш алулары җиңеләеп китте, күңелдәге авыр ташны алып ташладылармыни. Ул өстәл янында басып торган кешеләрне көлемсерәүле карашы белән күздән кичерде дә, гөрелдәп:

— Сез дә безгә эш таптыгызмыни, коллегалар? — диде.— Ну, нәрсә әзерләп куйдыгыз монда миңа?

Ләкин бер минуттан аның йөзеннән елмаю галәмәте качкан иде инде.

— Сез нәрсә, дуслар, авыруны тикшерми генә өстәлгә салдыгызмы әллә?

— Сюрприз!— диде Изаил Харисович берни булмагандай.— Безнең эштә сюрпризлар булгалап тора шул, Евгений Михайлович!

— Дәреслекләрне ешрак укыштырырга кирәк, сюрпризларга сирәгрәк юлыгырсыз. Сез бит авыруны операциягә салганчы ашказаны-эчәк системасын тикшерергә тиеш идегез! Методиканы һаман бозгалап торасыз, кара эшне яратмыйсыз, беләм мин сезне!

Евгений Михайлович моны шаяргандай итеп кенә әйтте, әмма барыбер аның болай әйтүе юкка түгел иде. Күрәсең, ул доцент Дәүләтшинның ниндидер гөнаһларын белә иде...

— Хәер, Җәмилә Закировна ассистент булып басса, без бу хәлдән котылу чарасын табарбыз, дип уйлыйм,— диде ул алдагы кинаясен җиңеләйткәндәй итеп. Ләкин бу сүзе дә юкка түгел инде: шушы бер җөмләсе белән ул ансат кына итеп Дәүләтшинны операциядән бөтенләй читләштерде дә куйды.

Алар, соңгы җөйне салып баш калкытканда, операционныйда доцент юк иде инде.

— Менә күпме эш ясадыгыз бит сез мина, хәзер инде көннең көнендә авыру янына килеп йөрергә кала,— диде Евгений Михайлович.

— Сездәй осталарны эшсез тотмаслар инде! Мәсәлән, әгәр үземә операция кирәк булса, беркая да бармаячакмын, сезнең больницага гына кереп ятачакмын,— диде шаярып Җәмилә Закировна.

Юри генә әйтелгән бу сүзләрнең ел ярымнан чынга ашачагын алар берсе дә башларына да китермәделәр, әлбәттә.

*

* *

Лариса халык арасында әллә каян күзгә ташланып тора. Вокзал артына, перронга чыгу белән, Зәйтүнә аны күреп алды да Әнвәргә:

— Әнә, безнекеләр!— диде.

Зур-зур чемоданнарын аяк очларына куеп, Хөсәен, Кифая, Лариса сөйләшеп торалар иде. Кифая янында Лариса балкып күренә. Биек үкчәле кызыл туфли, кызыл чалбар, зәңгәр ефәк кофта, җирән бөдрәләр, битен яртылаш каплаган кара күзлек. Кояшта янган нәфис, шома тире астында кечкенә калак сөякләре уйнаклап ала, алар арасындагы уенты, билгә таба тирәнәя төшеп, бар карашларны үзенә тарта иде. Үз мәшәкатьләре белән тыз-быз йөргән кешеләр аның тарафына борылып карамыйча үтмиләр. Хөсәен, аны очраклы кешеләрнең карашыннан ышыкларга теләгәндәй, сумкасын аркасына табарак шудырды. Лариса борылып карады, Зәйтүнә белән Әнвәрне искәреп, күзлеге астыннан елмайды:

— Зюзю, Анварчик! Вот молодцы! Без, инде килеп җитә алмассыз дип куркып торабыз тагын!

Якын дуслар белән саубуллашканда ни сөйләшәсең? Иң мөһиме инде күптән әйтелгән, шул ук вакытта күңелне нечкә сагыш уты көйдерә: дустың синең тормышның бер ямьле өлешен үзе белән алып китәдер сыман. Сәерлеген, бераз җиңел уйлавын белсә дә, ярата иде Зәйтүнә шат күңелле, хәрәкәтчән, ачык һәм пөхтә Ларисаны, аның белән яшәү кызыграк иде.

Алар әлегә янәшә басып торсалар да, бу югалтуның авырлыгы күңелне изә башлаган, ләкин үзләре моны сиздермәскә тырышалар, кутәренке тавыш белән шаярышалар иде.

— Миннән ахмак кеше бар микән, Зюзю? Кем соң инде үзе теләп себер китә?

Көлешеп, декабрист хатыннарын искә алдылар.

— Без синең исемне Волконскаялар, Трубецкаялар белән рәттән тарихка язып куярбыз,— диде Әнвәр.

— Әйе-әйе, анда нәкъ менә Нигъмәтуллина фамилиясе җитми иде! Лариса күзлек астыннан йомры гына булып күренеп торган сөйкемле борынын җыерып көлде.

Барысы да дәррәү борылып, узып барган Җәмилә Закировна белән баш иеп исәнләштеләр. Профессор янында урта яшьләрдәге бер хатын белән ир кеше бара иде.

— Кемне озатасыз? — дип сорады Җәмилә Закировна.— Мин унберенче вагонда,— диде аннары Лариса белән Хөсәенгә.

Вагоннарга утыра башладылар. Тар коридор буйлап кысрыкланып эчкә уздылар.

Купеда кара-каршы бер ир белән хатын утыралар иде. Ишек ачылгач, хатын торып басты. Карап торуга егерме биштән узмаган бу хатынның ике чигәсендәге чәч тотамнары көмеш сыман агарып тора, бу аның елмаюдан балкыган яшь чыраена сәерлек бирә иде.

— Динә!— дип кычкырды кинәт арттан килеп кергән Кифая.— Әллә син берәр кая барасыңмы?

Көмеш чигәле хатын сөенеченнән көлеп җибәрде, Лариса белән Зәйтүнәне читкә этеп, Кифаянең кочагына сыенды.

— Исәнме, Кифая! Юк, мин китмим, җанкайны озатам менә! Елашып, хушлашып утырабыз!

Ул көлеп, үртәп, башын иеп утырган ирнең юка аксыл чәчле түбәсенә карады.

— И, синме соң инде елый торган кеше! Сине елата алмаслар, шулай бит, Мөдәррис!

— Исәнмесез!— диде Мөдәррис, башын күтәрер-күтәрмәс кенә. Маңгаена сибелгән йомшак чәче астыннан аның очлы борыны гына елтырап күренеп китте.

— Китә бирсен, тотмыйбыз!— диде Динә, тагын көлеп.— Гел кайтмаса да, сүзебез булмаячак. Хөррият бездә!

— Мөдәррисеңә эре борчак ашаттыңмы әллә? Сөйләшәсе дә килми,— диде Кифая. Мөдәррис кыска җиңле шакмаклы күлмәге астыннан йомры иңбашын гына сикертеп куйды. Ул купеда купкан ыгы-зыгыга да, хатынының үчекләп әйткән сүзләренә дә битараф калды.

Хушлаша башладылар. Лариса, күзлеген салып, башта Кифаяне, Зәйтүнәне кочаклап үпте, аннары Әнвәрнең муенына сарылды. Әнвәр дә башын бормады, авызын Ларисаның иреннәреннән тартып алырга ашыкмады. Зәйтүнә аның күзләрендә күңелне шомландыра торган сәер елмаю кабынганын күреп алды.

Чыгып киткәндә генә искәрде ул: бу ыгы-зыгыда ир белән хатын иркенләп хушлаша да алмадылар бугай. Мөдәррис һаман түрдә утыра, ә Динә ишек төбендә калган. Ул «хуш» дип җиңелчә генә кулын селекте дә, беренче булып чыгып та китте.

Перронга чыккач, шактый вакыт вагон тәрәзәсе каршында басып торырга, пыяла аша аңлашылмый торган сүзләр әйтешергә, елмаешырга туры килде. Тыштагылар да, эчтәгеләр дә бер зарыгу кичерә, бу кыенсыну, күзләрен кыса төшеп, юка ирен читләрен өскә күтәреп карап торган Мөдәрриснең йөзендә аеруча нык чагыла иде. Ул әледән-әле бармакларын пыялада тыпырдатып нидер аңлатырга тели, ә Динә аңа көлеп кенә җавап бирә иде.

Ниһаять, вагоннар дыркылдап алдылар да, алга таба шуыша башладылар. Озатучылар ясалма елмаю белән кулларын болгап, бераз янәшә баргач, кайтыр юлга борылдылар.

Динә Кифаяне култыклап алды да көлә-көлә нидер сөйли башлады. Читтән карап торганда анекдот сөйлидер дип уйларга була иде аны.

Трамвай тукталышына җитәрәк, Кифая Зәйтүнәне чакырып алды:

— Зәйтүнә, Динәне бер бәладән коткар әле, зинһар.

Динә, шаяргандай итеп, Кифаяне читкәрәк тартты, аның киң итеп тегелгән җиңсез юка күлмәге тартылып, сынына сыланып алды. Хатын йөкле иде. «Бу миннән алданрак табачак баласын,— дип уйлады Зәйтүнә.— Биш айлык чамасы булыр».

— Сиңа бер сүз әйтсәң, шул булыр инде,— диде Динә Кифаяне җиңелчә шелтәләгәндәй итеп.— Иләк авыз!

— Кирәкмәгән кешегә сөйләмим бит мин аны! Зәйтүнә клиникада

эшли, бөтенесен булдыра ала. Тәҗрибәсе зур аның, яшьлегенә карама!

Кифая Әнвәргә карап алды да, Зәйтүнәнең колагына өреп һәм кытыгын китереп:

— Котылдырып чыгар инде шуны, эшлә бер яхшылык, буш итмәс,— дип пышылдады.

— Нәрсәдән котылдырып? Шушы хәленнәнме?

— Хәле шундый булмаса, ул минем белән синә ялынып та йөрмәс иде инде!

Зәйтүнә артка тайпылды.

— Мин андый эшләр белән шөгыльләнмим. Нәрсә ул, үз акылындамы соң? Алданрак карасын иде!

— И, кыланмасана! Яхшылыгыңны кызганасың инде, шул гына! Кайгырма, авылдаш, Фидая белән сөйләшеп карарбыз. Әйдә, әнә дүртенче трамвай килде!

Кифая Зәйтүнә белән төксе генә саубуллашып, Динәне трамвай ишегенә таба әйдәде. Аларны этә-төртә трамвай ишегеннән берсе өлкәнрәк, икенчесе яшьрәк ике хатын чыктылар.

Картрагы Зәйтүнәдән:

— Харьков поезды килмәдеме икән? Белмисезме?— дип сорады.

— Белмим шул.

— И, ходаем, соңга калдык микән инде! Кайчан шушы поездлар баш катырмый гына расписание белән йөри башлар!

Аңа ияргән яшь хатын кулындагы чәчәк бәйләмен баш өстенә күтәргән иде, кемнеңдер терсәгенә бәрелеп, күзлеген төшерә язды. Аны кулына алды да, йөгерә-атлый, карт хатын артыннан китеп барды.

...Ул кичне Зәйтүнә ире янында гадәттәгедән ныграк оялу сизде. Әнвәр дә ничектер тынып калган иде, сызымнарын кулына алмады, йөзендә теге вагон эчендәге сәер елмаюны саклаган килеш, тиз генә чишенеп урынына ятты. Нур шәүләсенең яктысы бүген Зәйтүнәгә түгел, каядыр читкә, ә бәлки шушы төндә караңгылыкны ерып, тәрәзәләре белән балкып, күңелле тыкылдавы белән тын кырларны, урманнарны уятып, еракка ашкынган поездга юнәлгән иде бугай...

Зәйтүнә беренче тапкыр күңеленә көнләшү иңгәнен тойды. Ул караңгыда төнге күлмәген киеп, ире янына ятты, бар кыюлыгын, батырлыгын җыеп, аңа елышты.

— Сиңа орынырга да куркыныч бит хәзер,— диде Әнвәр пышылдап.

— Ул чаклы түгел инде... Өч айлык кына бит әле...

— Юк, барыбер онытылырга ярамый. Саклангапны ходай саклар, ди безнең әни. Йокла тынычлап. Синең хәлдә йокы бик тәмле була, диләр.

Һәм ул Зәйтүнәдән читләште. Үзенең сүзләрен йомшартырга теләгәндәй, учы белән хатынының иңеннән сыйпап куйды, ләкин бу — нур шәүләсенең шуышып үтүе генә булды, аның яктылыгы янә караңгыга, каядыр еракка сикерде.

*

* *

Дүртенче трамвайдан кабаланып төшкән карт хатын белән яшь хатын нәкъ минутында килеп җиттеләр. Харьков поезды туктаган гына, вагоннарның ишеге ачылып, беренче пассажирлар төшә башлаган иде. Карт хатынның тәҗрибәсе җитәрлек икән, вокзал артына чыгуга:

— Әйдә, Алтынчәч, әйдә,— дип, күзлекле хатынны сулгарак тартты.— Бишенче вагон менә монда ул.

Ләкин Алтынчәч кинәт аягы авырайган сыманрак атлый башлады, кулындагы чәчәк бәйләмен себерке шикелле аска төшерде, калын пыялалы күзлек ялтыравында ук аптырау, каушау сизелде.

— Әйдә инде,— дип ашыктырды аны өлкән хатын.— Әнә, күрәсеңме, вагоннан чыгып килә җанашым! Линар, Линар, без монда!

Халык төркеме өстеннән йомры башы шактый ук күтәрелеп торган таза гәүдәле ир кеше, чемоданын болгап, боларга таба атлады.

— Саумысыз, Мөһимә апа, иминлекме!

— Исәнме, җанашым, саумы! Менә, Алтынчәч тә килде. Сине каршы аласымны белгәч, өзгәләнде, мин дә барам, дип. Каршы килмәдем, күңеле булсын, дидем.

— Әйбәт, бик яхшы,— диде Линар. Аннары тыгыз тешләрен күрсәтеп елмайды: — Ну, Алтынчәч, нихәлләр бар?

Эре адымнар белән барып, буш сул кулы белән Алтынчәчнең аркасыннан баласытып кагып куйды. Алтынчәч кызарынды, күтәрелеп бер генә карады да, егетнең тешләреннән күзе чагылгандай, башын аска иде.

— С приездом!— дип кулындагы чәчәк бәйләмен сузды.

— Кая, бир чемоданыңны!— дип бөтерелде Линар тирәсендә Мөһимә.— Юлда арыгансыңдыр!

— Что син, Мөһимә апа!— дип, таза муенын текә генә борды Линар.— Сиңа чемодан асып, үзем ике кул селтәп барырга кем дип белдең син мине!

— Менә шулай инде безнең Линар!— дип Алтынчәчкә карап, ачык шәмәхә төсле кримплен күлмәгенә көчкә сыйган күкрәкләрен дерелдәтеп көлеп алды Мөһимә.— Кешегә салына белми, җанаш!

Аның иртә сулган киң, майлы битендә Линар белән чиксез горурлану ярылып ята иде.

— Такси алабызмы соң?— дип сорады Линар.

— Инде ике адымга такси яллап тормабыз,— диде Мөһимә.— Барасы җирләрегез булыр әле. Рәхәтләнеп икәү парлашып әйләнерсез кала урамнарын таксида!

Алар берәр-икешәр катлы агач йортлардан торган, тар, шау-шулы урам буйлап киттеләр. Юл буе Мөһимәнең ирләрнеке кебек калын тавышы тынып тормады. Аның сүзләрен бары тик машина улавы гына күмеп китkәли иде дә, Линарның тыныч, тәкәббер тавышы бүлгәли иде. Апасыннан ким дигәндә егерме биш яшькә кечерәк булса да, ул үзен олысымак тота һәм баланы өйрәткәндәй, Мөһимәне акылга өйрәтә иде.

Сүз квартир хакында барды. Мөһимәгә яңа квартирны кеше белән бирәләр, ягъни ике бүлмәле квартирның кече бүлмәсенә күчәргә тәкъдим итәләр икән.

— Өйдәш торыр заманнар үтте инде,— диде Мөһимә кызып.— Әйттем әле квартбюродагы Михайлов дигән кешегә, атаң малын өләшеп утырмыйсың, дидем. Минәйтәм, гомер буе фабрикта эшләп саулыгын югалткан кеше, хезмәт ветераны мин, дидем, цыкага барып җитәрмен, үзәгегезгә үтәрмен, минәйтәм.

— Куркытып тотынма син, апа! Бүкәй белән кемнең котын алмакчы буласың! Син кешенең күңелен күрергә тырыш, көйләү җаен тап! Закон белән хәзерге заманда дурак кына йөри.

— Квартир сатып алырлык акчам юк шул минем. Булса да бирмәс идем. Үземә кирәк. Закон белән үзәкләренә үтәм әле мин аларның, хокук дип асларына су йөгертәм!

Алар ике катлы агач йортның тар-текә баскычыннан күтәрелделәр. Мөһимә өч йозакны бер-бер артлы шалтыр-шолтыр ачты да кунакларны эчкә чакырды. Коридорлы, мичле, ике бүлмәле борынгы квартир иде бу. Өстәлдә ашъяулык, урындыкларда ситсы кисәкләреннән ясалган корама япмалар, тәрәзәләрдә челтәрле кашагалар, түрдә түгәрәк көзге — кыскасы, оста куллы җиңгиләр җиһазлаган авыл өйләрендә

генә була торган рәхәтлек, ямь бар иде бу өйдә һәм мондагы гадилектән күңел иркенәеп китә иде.

Алтынчәч шкафтан ваза алып, чәчәк бәйләмен өстәл уртасына куйды да, ак кофтасы белән күксел юбкасы өстеннән Мөһимәнең ситсы халатын киеп, көлсу бөдрәләренә тастымал урады.

— Чалмага охшаганмы?

— Чын изге булгансың,— диде Линар.— Кил, бер пәп итәм.

— Чү!— Алтынчәч, Мөһимә күрмәсен дип, кухня ягына карап куйды.

Алар Мөһимә белән икесе, тату каенана белән килен кебек чөкердәшеп, табын әзерләргә керештеләр. Тиз өлгерделәр: салатка дигән яшелчә турап суыткычка куелган, шулпа пешкән, токмач киселгән, шампан шәрабы суытылган иде.

Табын янында бу өч кеше тәмам үз булып киттеләр. Мөһимә — Украинада һава хәлләре, Линар Казандагы базар бәяләре белән кызыксындылар. Әмма Линар торган җирен артыграк мактый башлаган саен, Мөһимә авызын бөрештереп, сирәк керфекләрен каккалап, энесенә ниндидер ишарә ясарга азаплана иде.

Мөһимә буявы саргаеп кыршылган радиоланы ачып татар көйләре уйната башлады. Линар диванга кырын яткан килеш «Сандугач»ны, «Гөлҗамал»ны, «Шахта»ны тыңлап-тыңлап торды да, кузгала төшеп:

— Ну, монда дөнья һаман шул килеш икән,— диде.— Искергәнсең икән син дә, апа. Радиолаң да кадими заманныкы, җырларың да. Кем җырлый да кем тыңлый хәзер моның ишене!

Ул ишек янындагы чемоданын ачып, аннан магнитофон тартып чыгарды. Шарт-шорт баскалаган иде, аннан карлыккан бер ир тавышы тыгыз ритмлы көйгә җырлый башлады.

Линар Алтынчәчне биергә чакырды. Алтынчәч гәүдәсенең җиңел, хәрәкәтләренең нәфис икәнлеген белә, ләкин барыбер хәзерге заманның модный кызлары шикелле бөтенләй үк таралып китә алмый, тыенкы кылана. Линар исә биергә оста булмаса да, үзен иркен тота, шуңа күрә аңа ни кыланса да килешә. Мөһимә, майлы битен электр яктысында елтыратып, яшьләр биегәнгә сокланып утырды.

Алар киенеп чыкканда, урамнардагы ыгы-зыгы кимегән, шәһәр серле кыяфәт алган иде. Мондый сәгатьләрдә вакыт та үз агышын әкренәйткәндер кебек тоела. Алар, бу тынлыкны бозудан курыккандай, әкрен генә атлап киттеләр...

— Әйдә, бергәләп коньякка барабыз,— диде Линар.— Анапага. Анда диңгез, комлык, кояш. Аннан Новороссийскига, Абрау-Дюрсога барып була. Абрау-Дюрсода булганың бармы синең?

— Юк.

— Тау башындагы күл ул. Суы диңгез кебек зәп-зәңгәр, ярларында өянкеләр үсә. Өянке ботаклары җирдә, суда ята. Ботак астына керсәң, чатыр кебек, беркем күрми. Үбешергә була рәхәтләнеп!

Ул Алтынчәчне сыңар кулы белән генә күтәреп алды да каты итеп иреннәреннән үпте. Алтынчәч күзләрен чытырдатып йомды, тәнен — ялкын, күңелен оялу хисе көйдерде... Киноларда күргәне бар, кызлар үбешкәндә күзлекләрен салалар. Болай, күзлек киеп үбешү көлкедер...

Ниһаять, Линар аның иреннәреннән аерылды, ләкин җиргә бастырмады, күтәреп иңбашына утыртты.

— Карале ныгытып, Абрау-Дюрсо күренмиме?

Чыннан да, бик-бик югарыда итеп хис кылды үзен Алтынчәч. Тын һәм серле шәһәр манзарасы күз алдында киңәйде. Шәһәр өстендә күккә ашкандай калкып торган Кремльнең Спас манарасында нәкъ шул мизгелдә гөлт итеп кызыл ут кабынды. Ул бер кабына, бер сүнә — сәгать уникене сукканны белдерә иде. Ә бәлки, бу сәгать сугуы түгелдер, карт диварларның йөрәк тибешедер? Ә бәлки, алай гына да түгелдер:

караңгы күк йөзе фонында яктырып-сүнеп торган бу ут — маяктыр! Гүя ул корабларга юл күрсәтә, аларны куркынычтан кисәтә. Ә бәлки, ул Алтынчәчне кисәтәдер? Юк-юк, бу ут аңа юл күрсәтә, бәхет теле. Һәм шул яктыга таба барган кораб кебек тирбәлеп бара Алтынчәч.

— Күрендеме?

— Күренде. Төнге диңгез, маяк...

— Ошадымы?

— Ошады.

Линар Алтынчәчне җиргә бастырды.

— Барабызмы соң диңгезгә, Абрау-Дюрсога — дүрт су тарлавыгына?

— Минем ял ноябрьгә туры килә шул быел,— диде Алтынчәч.

— Соң, сора яхшылап. Мондый форсат тагын кайчан була?

— Нинди форсат? Кул урыныннан күчмәс бит?

Линар сул кулы белән галстук төенен бушатып, башын боргалап куйды.

— Путевка табу кыен хәзерге заманда. Быел табып була. Ә киләчәкне кем белгән?

Алтынчәчнең бармаклары Линар йодрыгы эчендә тыпырчынып куйды. Аларның заводында отпускаларга график ел башында төзелеп куела һәм бик төгәл үтәлә. Ялгыз яшәгән Алтынчәчнең ул графикны үзгәрттерерлек нинди сәбәбе булсын? Гаилә хәле үзгәрсә генә инде...

Алар яныннан яшел утлы такси машинасы узып бара иде, Линар сызгырып аны туктатты. Машина, буш урамнардан гадәттән тыш тизлек белән чабып, Ленин районындагы биш катлы йорт янына килеп тә туктады.

Линар таксистка акча сузганда, Алтынчәч аны туктатмакчы иде:

— Җибәрми тор, шуның белән кайтырсың!

Ләкин Линар аны ишетмәде кебек, машина кузгалып киткәч кенә борылып карады.

— Нишләп әле, син мине сагынмадыңмыни?

Алтынчәчнең тамагына утлы төен килеп тыгылды. Сагынмаган кая! Ләкин аны менә шушылай гади генә итеп әйтеп буламыни.

— Күршеләрдән оят...

— Йоклыйлардыр инде. Бөтенесен күреп тормасалар да ярар. Узган юлы берни булмады бит әле.

Соңгысын егет аеруча каты итеп, тавышына шик салып әйтте. Алтынчәч аяк очларына басып, аның күзенә туры карарга тырышты, ләкин Линарның карашы баганадагы лампадан төшкән яктылыкны гына чагылдыра, аларда йомшаклык та, кызгану-аңлау да күренми иде.

— Булды... Узганында да булды.

— Ни булды? Кем алар сиңа? Бик тыкшына башласалар, җибәр син аларны... ераккарак! Бетмәс монда ханҗалар...

Алтынчәчнең тар иңбашлары туңып калгандай бөрешә, гәүдәсе кечерәеп киткәндәй булды.

— Аларда түгел хикмәт, минем үземдә... Яна менә монда, көйдерә.— Ул, кулларын йомарлап, йодрыкларыннан да кечкенәрәк күкрәкләрен кысты. Бу хәрәкәт егетнең карашын ихтыярсыздан аның түшенә җәлеп итте.

— Ну, ярый, иртәгә кайчан килим соң?— диде ул салкын гына.

— Иртәгә шимбә бит әле. Әйдә, Локомотив пляжына барабыз!

— Шунда очрашырбызмы?

— Әйе. Сәгать унберд.

Линар каты учы белән аның иңнәреннән тотты да авырттырып үпте. «Тагын күзлегемне сала алмадым,— дип уйлады Алтынчәч.— Салсаң да уңайсыз. Әрсезләнеп, үпкәнен көткән кебек була... Ә болай көлкедер...»

Ул шактый вакыт аның артыннан карап калды. «Борылып кара, борылып бер кара!» — дип ялварды ул карашы белән егетнең киң җилкәсен тишәрдәй булып. Ләкин Линар борылмады, ул тизрәк олы юлга чыгып, такси машинасы туктатырга ашыга иде.

«Юлдан арып килгән шул...»— дип аны акларга тырышты Алтынчәч. Линарның бу рәвешле артык ялынмыйча гына китеп баруына һәм соңгы тапкыр үпкәндә сизелгән битарафлыгына хәтере калган иде аның. Аларның очрашмаганнарына дүрт ай бит инде. Дүрт ай. Ниләр генә уйлап бетермәде дә ни генә кичермәде бу вакыт эчендә Алтынчәч.

Ул, күршеләрен уятмаска тырышып, баскычтан сак кына менде, ишекнең ачкычын бик әкрен генә борды. Җәй көне бишенче катта су булмый интектерә. Төнлә су килгән икән, ул кранны чак кына ачып юынды, аннары үз бүлмәсенә кереп, тумбочка эченнән шыгырдап торган җәймәләрен алды да, диванга урын әзерләде.

Алсу абажурлы лампа яктысында җәймәләр бигрәк ак, чиста күренәләр. Моннан дүрт ай элек, кышкы бер төндә, шушы җәймәләр өстенә шалкан кебек таза, ак, тыгыз тәнле ир-егет яткан иде. Диван-караватны киңәйтеп, иркенләп яткан иде ул монда... Бу күренеш исенә төшкәч, Алтынчәч үз-үзеннән оялып, җәймә чите белән йөзен каплады. Аннары утны сүндереп, салкынча, бераз катырак җәймәләр эченә чумды. Башыннан ук капланып, истәлекләрен куарга, онытырга теләде, әмма кузгалган күңел тиз генә тынычлана алмады.

Менә дүрт ай инде аның тынгы күргәне юк, дүрт ай инде күңелен әле утка салган, әле боздай өшеткән тойгылардан арына алганы юк. Бу уйлану-газаплар Мөһимәнең туган көне белән котларга барган кичтән башланды. Барып котларга да, телевизордан фильм башланганчы өенә кире кайтырга иде аның нияте.

Ләкин ул кино башланганчы да, ул беткәч тә кузгалып кайтып китә алмады. Нәкъ шул көнне Мөһимәнең туганнан туган энесе — Линар кайтып төшкән булып чыкты. «Мактап кына йөрисең икән, иң якын кешеләрем җыелды бүген»,— дип диванга энесе белән янәшә утыртты аны Мөһимә, «Эчмәсәң, рәнҗим, инде минем хөрмәткә дә бер бокал шампан күтәрмәскә»,— дип кыстый-кыстый эчерде.

Ул көнне «Белгечләр тикшерү алып бара» дигән фильмның чираттагы сериясен күрсәтәләр иде. Кино белән мавыгып киткән Алтынчәч сизми дә калган, бер заман исенә килсә, аның иңбашы егетнең беләгенә терәлгән һәм үзен бу хәлендә бик рәхәт хис итә икән. Ул кылдай тартылып читләште, борылып Линарга карады, егет тә аңа текәлде, һәм аларның карашлары якыннан, бик якыннан очрашты.

Шул мизгелдә Алтынчәч гадәттәге кыюсызлыгын онытып җибәрде: ул кич буе сизми утырган — егетнең уң күзе пыяла икән лабаса. Дөрес, ул шундый матур ясалган һәм оста куелган, нәкъ сул күзе төсле, ләкин барыбер җансыз, нурсыз...

Алтынчәч, гаҗәпләнүен сиздермәс өчен, тизрәк экранга борылды, тетрәнгән бармаклары белән итәген рәтләштерде һәм бу юлы инде аңлы рәвештә иңбашын егеткә таба авыштырды.

Алтынчәч унөч яшеннән күзлек киде, класста бердәнбер күзлекле кыз булды, яхшы укып, алдан йөрергә, бөтен җирдә алдынгы булырга тырышкан кызга бу кимчелек бик нык комачаулый иде. Гел кемсенә иде ул начар күрүе аркасында, ничә еллар буе «Дүрткүз» дигән кушамат тагып йөрде!

Линарның да кимчелеге бар икән... Ул да Алтынчәч кебек үк кимсенеп үскәндер, малайлар-кызлар аңа да берәр ямьсез кушамат таккannardыр...

Бу уртаклык хисе Алтынчәчнең гадәттәге шикчәнлеген, тарсынуын киметте, шуның өстенә Мөһимә электән үк, институтны тәмамлаган Алтынчәч аңарда фатирда яшәгән чакта ук, Линарны яратып һәм кызганып бик күп сөйли торган иде. «Бәхете булмады шул, атасы эчте, анасы холыксызланды, шуның аркасында әллә кая чит җирләргә чыгып китәргә мәҗбүр булды, бәгырь парәсе, аннары килеп хатыннан уңмады... Менә аерылышалар инде... Аенә аерылышканнар инде... Хатыны, җүнсез, бүтәнгә чыгып киткән... Синең кебек ипле-тыйнак, телсез-тешсез бер кызга тап булган булса, гөл эчендә яшәтәчәк егет иде югыйсә...»

Бу кыйссалардан Алтынчәч күңелендә шулай ук үз язмышына охшаш язмыш — яшьтән кыерсытылган, үскәч үз тиңен таба алмаган бер образ туды.

Дөрес, чынбарлыктагы Линар — шалкан кебек тыгыз ак тәнле, туры, юан муенлы ир-егет ул образга охшамаган иде. Ләкин бу — тышкы кыяфәт бит, дип уйлады Алтынчәч, ә бәлки ул эчке сызлануларны яшерер өчен махсус киелгән маска гынадыр...

Һәм Алтынчәч үзенең хыялый җаны белән, бу маска астында, башкаларга күренми торган нечкә күңелне, ялгыз, кызгануга һәм яратуга сусаган җанны күрергә тырышты. Тырышты гына түгел, ул аны күрде, шулай икәнлегенә үз-үзен тәмам ышандырды.

Төн уртасында, кала урамнары буйлап тыгыз карны шыгырдатып җитәкләшеп барганда, бу ышаныч артканнан артты. Егет үзенең бик җаваплы эштә — зур заводның тәэминат бүлегендә эшләвен, командировкаларга еш йөрүен, кала читендә үз йорты белән яшәвен — гомумән гап-гади нәрсәләр турында сөйли, ә кыз аның кыйссасында әйтелмәгәнне — аның яхшылыкка сусавын, үзен аңлаган бер нечкә күңелне гомере буе эзләп таба алмавын ишеткәндәй булып бара иде.

Ул чакта да Линар узып барган машинаны туктатты, ул чакта да Алтынчәчнең йорты янына кайтып җиткәч, шоферга акча сузды һәм тураеп басып кызның терсәгеннән тотты.

— Ник җибәрдең?— диде ул чакта да Алтынчәч.— Үзеңә кайтырга җайлы булыр иде бит.

— Ничек инде, шушылай аерылышыйкмыни?— дип сорады гаҗәпләнеп Линар. Чыннан да, алар иң мөһим сүзләрне бер-берсенә әйтмәгәннәр иде бит әле! Уртак язмыш, балачакның рәнҗешләре, күңелләрнең ялгызлыгы хакында сөйләшәселәре бар иде әле аларның. Һәм Алтынчәч егет белән төн буе шәһәр буйлап йөрергә әзер иде.

Ләкин Линарның уе башкада икән.

— Бу салкын төндә мосафирга бер чынаяк чәй дә эчермәс идеңме әллә? — Ул ялтыравык ботинкалары белән карны каты шыгырдатып таптанды. Харьков тирәсендә кыш миһербанлырак, күрәсең, аның башында бу як өчен ятышсыз эшләпә, өстендә кыска замша пальто иде.— Бер стакан Идел суын да җәллисеңме әллә миннән?

Алтынчәч аның кыяфәтен күздән кичерде дә ишеккә юнәлде.

Кара-каршы утырып, алсу абажур астында шыпырт кына сөйләшкәч, егет чыгып китәр дип уйлаган иде Алтынчәч. Әмма ул кузгалмады, диванга җәелебрәк утырды, көчле куллары белән Алтынчәчне тартып китереп, тезенә утыртты. Әллә нишләде Алтынчәч, әллә ни булды аңа. Күзлек киеп үбешкәнгә оялудан, буйсындыручан гайрәтле кулларның күкрәкләрне пешерүеннән хәле китте. Шуның өстенә шаулаудан, тавыш чыгарудан, күршеләрне уятудан курыкты. Я алла, аннан соңгысын искә генә төшергәндә дә бөтен тәнне ялкын чорный. Аннары... Линар торып утырган иде. Ул капланып яткан Алтынчәчнең аркасыннан сыйпап, колагына иелеп кайнар пышылдады:

— Я, керпе, нигә энәләреңне тырпайттың? Кайчан да булса, кем белән дә булса булырга тиеш идең бит инде син! Рәхмәт, мине көткәнсең. Без бәхетле бүген, шулай бит? Намусыбыз да саф, беркемгә дә хыянәт итмәдек! Әйдәле, урынны әйбәтләбрәк җәйик!

Алтынчәч торып басуга, ул диванны киңәйтте, ак җәймәләр өстенә аякларын киң ерып чалкан ятты да изрәп йокыга талды. Алтынчәч аңа комачауламас өчен диванның кырыена ук шуышты. Аның уйлары буталган иде...

Әйе, ул чыннан да беркемгә дә хыянәт итмәде. Ләкин нигә соң йөрәк авырттырып чәнчи, нигә ул вөҗдан газабына охшаш утта яна? Үз тәненә үзе хуҗа, беркем каршында да йөзе кара буласы юк бит югыйсә!

Ләкин йөзе каралганын сизә иде ул, барыбер сизә иде. Хыянәт итте ул төндә Алтынчәч, башка берәүгә түгел, үз-үзенә, хыялларына хыянәт итте ул. Тормышында мондый борылышны ул һич тә бу рәвешле булыр дип күз алдына китерми иде.

Аның уенча, бу борылышка бик зур әзерлек, тантана, бәйрәм белән килү тиеш иде. Кичләрен бүлмәсендә ялгызы йокысыз ятканда, аның хыялында мондый күренеш күзаллана иде: ул, аяк очларына төшкән озын ак күлмәк киеп, җан сөйгән яры белән янәшә басып тора. Алар биек, иркен бина эчендә. Бинаның стеналары оста рәссамнарның картиналары, сыннар белән бизәлгән, түбәсе күккә ашкан. Тирә-юньдә бихисап шәмнәр яна, илаһи музыка яңгырый. Бәйрәмчә киенгән егетләр аларның баш очында энҗеле таҗлар тотып торалар, укалы киемнәр кигән ыспай агай: «Бәхет килгәндә дә, кайгы-хәсрәт, чир-чор булганда да, гомер иткәндә дә, җан биргәндә дә бергә булыгыз»,— дип күңелне шомландыра торган тылсымлы сүзләр әйтә һәм балдак алышырга, аннары үбешергә куша. Бераздан аларны салмак атлатып ярым караңгы бинадан якты ишеккә таба алып китәләр. Биек баскыч төбендә пар ат җигелгән көймәле арба көтә. Атлар аларны ялгыз йортка алып китә. Ә анда әзер табын һәм кардай ак, йомшак ятак көтә...

Хыяллары бу ноктага җиткәч, Алтынчәч янбашларының, аякларының кызышып авырайганын тоя, уйлары чуалып, аннан да гайресен күз алдына китерергә куркып, мендәр почмагын тешли торган иде.

Аннан соңгысын хыял белән генә күзаллау мөмкин дә түгел икән шул... Башның бөтенләй бушап калуын, тәннең утта януын, ләкин бу януның искиткеч ләззәтле булуын, бер мизгелдә башка берәүнең тәнендә эреп бетүеңне һәм йөрәгең туктап, инде башка яшәмәскә дә риза булырлык дәрәҗәгә җитүне ничек күз алдына китермәк кирәк?

Менә ул — аны тулысынча үзенә буйсындырган, үзе өчен җан бирер дәрәҗәгә җиткергән кеше янәшә ята. Ләкин нигә соң әле бу төндә гамьсез йоклап ята? Хәтта җиңелчә генә гырлаштырып та җибәрә? Күршеләр ишетсә? Аңлашылмас каршылык иде бу Алтынчәч өчен. Таң атканчы әллә ниләр уйлап бетерде ул.

Күршеләр кузгалганчы дип, аннары сагышына да түзә алмыйча, Линарны бик иртә уятты. Егет киерелеп торды, бүлмә буйлап кулларын селеккәләп йөренде. Аның кәефе шәп иде. «Бүген кич туры монда килимме?» — дип сорады ул гади генә. Ничек кенә текәлеп караса да, Алтынчәч аның исән сул күзендә дә, үз-үзен тотышында да дулкынлану сизмәде.

Линар чыгып киткәч, ул башын тотып өстәл янына утырды. Күрше хатын Нәкыя эшкә китешли аның ишеген ачты да:

— Соңга каласың түгелме? — диде. Аннары көлемсерәп өстәп куйды: — Төн бик күңелле узды, ахрысы, синең...

Шул көннән Алтынчәчнең тормышы да, уйлары да икегә бүленгәндәй булды. Аның тышкы кабыгы гадәтләнгән юл буйлап эшкә барды, иреннәр күнегелгәнчә елмаеп, лабораториядәге кызларга сәлам бирде,

куллар таныш эшне башкарды. Ә күңелдән ак, тыгыз, кайнар тәнле егет китмәде.

Аның төннәре, әле йөрәгә туктаса да үкенмәслек дәрәҗәдәге ләззәтле минутлары искә төшүдән ялкынга чорналып, әле миен көйдергән шик һәм газаплардан кара сагышка уралып уза торган булды.

Линар аны шул ике газап арасында калдырып китеп барды. Шикләреннән дә арындырмады, өметләрен дә сүндермәде, ни яктылыкка чыгармады, ни төнгә кертмәде. «Озакламый киләм мин, көт!» — диде. Алтынчәч аның бу сүзләрен бик мәгънәле итеп, «килгәч бергә булу хакында сөйләшербез»,— дип аңлады.

Вокзалда саубуллашканда, Линар пинжәк кесәсеннән блокнот чыгарып, Алтынчәчнең адресын язып алды. Алтынчәч үрелеп, «Ул. Строетлная» дигән сүзне күреп алды. Бер сүздә ничә хата... Дөрес, Мөһимә аның турында, ата-анасы юньсез булу аркасында, рәтләп укый да алмады, дип сөйли торган иде. Ләкин «Строительная» сүзен бишенче класс баласы да дөрес яза бит инде!

Алтынчәч рухына тагын бер газап өстәлде. «Андый шыр надан белән минем нинди уртаклыгым булырга мөмкин?..» — «Мин аңа үсәргә, белемен арттырырга ярдәм итәрмен,— дип тынычландырды ул үзен.— Бергә генә булыйк, бөтенләй башка кеше итәрмен мин аны. Зиһенле бит ул, сөйләшкәндә бер дә ялгышмый!»

Хатлар көтте Алтынчәч, әмма Линар, киткәннән соң, бер хәбәр дә бирмәде. Түзмәде Алтынчәч, Мөһимәгә барды. «И, ир затының кайсы хат язарга ярата соң! — диде Мөһимә.— Алай да миңа Беренче Май белән котлап открытка җибәргән әнә, сиңа сәлам күндергән».

Алтынчәч өч тиенлек открытканы суд криминалисты кебек җентекләп тикшерде. Линар хәрефләрне бер-берсенә тыгызлап кысып, тигезсез яза икән. Сүз саен ике-өч хата...

Шунда аның эче жылынып китте. Линарның ни сәбәптән хат язмаганы билгеле: ул үзенең наданлыгыннан ояла! Язуын күрсәтәсе килми!

Бичара, юкка кимсенә ул, бер дә юкка ояла. Менә килсен генә, алар бу хакта җитди сөйләшерләр. Бу эштә аларның мәхәббәте ярдәм итәр...

Ниһаять, кичә Мөһимә, аның өенә килеп, Линарның телеграммасын күрсәтте. «Киләм, каршы алыгыз».— дип хәбәр биргән егет. «Сине чакырган, сез диярлек тагын кеме бар соң җанашымның!» — диде Мөһимә. Һәм Алтынчәчне вокзалга барырга күндерде, хәттә базардан чәчәк алырга да җәртеп барды.

Инде менә зарыгып көткән очрашу булды. Ләкин Линар Алтынчәч кебек үк түземсезләнеп, янып-көеп көтмәгән ахрысы бу көнне. Югыйсә, болай ансат кына борылып кайтып китмәс иде, болай салкын үпмәс иде. Алтынчәч аның башны миңгерәтеп, кочагында эретерлек итеп, ялкынга чорнап үпкән чакларын бик яхшы хәтерли ләбаса!

Хәер, теге чакта ул аның саф кыз икәнен белми кергән иде бит. Хәзер Алтынчәчкә мөнәсәбәте яхшырган, ихтирамы арткандыр. Ул аның йөз аклыгын саклый, күршеләр алдында оятлы итәргә теләмидер... Чыннан да, кая ашыгырга? Аларның бөтен гомере алда бит әле...

Аларның шалкан кебек ак, тыгыз тәнле кызлары туар. Аксыл чәчле, якты күзле булыр ул...

Кыштырдап торган җәймәләр арасында, бер коега төшкәндәй, бер кояшка күтәрелгәндәй тирбәлеп ятты Алтынчәч.

*

* *

Җәмилә Закировна Мәскәүгә чаклы кызы Ләйлә белән бергә бара иде. Поезд кузгалуга, Ләйлә юлдашлары белән танышып та өлгерде. Алар купесына тагын бер кыз белән бабай туры килгән икән. Бабакай

өске киемнәрен салып куйган, җылы күлмәк белән киң төпле ак штаннан гына калган килеш, кечкенә өстәл кырыена кадаклап куйгандай ныклап утырган иде. Аның ике аягы арасына озын әлмәк булып салынып төшкән ак бауны күргәч, Ләйлә пырхылдап көлүдән көчкә тыелып, проводница янына йөгерде. Янәшә купеда өч ир-ат арасында бер хатын бара икән, Ләйлә аны үзләре янына күчереп, бабайны аның урынына озатып куйды.

Җәмилә Закировнаның исә зиһене таралган иде, юл мәшәкатьләренә кулы бармады, коридорга, ачык тәрәзә янына чыгып басты.

Поезд текелдәп Казаннан ерагая барган саен, аның иңендәге йөк тә җиңеләя бара иде шикелле. Йөгереп узган чакрымнар, әйтерсең лә аның борчуларын берәм-берәм йолкып алып калалар иде. Бары бер генә уйны алар да онытура алмады — ул авыр уй бүген иртән булган хәлләр турында иде. Борчылуы Диләрам өчен генә дә түгел иде профессор Ильясованың — аны карарлар, клиника врачлары да аңа аеруча игътибар бирергә вәгъдә иттеләр, Евгений Михайлович та көн саен барып торыр. Профессор Ильясовага тынгы бирмәгән кеше — доцент Дәүләтшин, дөресрәге аның белән операциядән соң булган сөйләшү иде.

Клиникадан чыгып киткәнче, Җәмилә Закировна аның бүлмәсенә сугылды. Дәүләтшин өстәл артында авыру тарихы тутырып утыра иде, профессор кергәч, аягүрә басып, халатын тарткалады.

— Ялыккансыздыр, Җәмилә Закировна. Берәр стакан чәй китерикме әллә?

Бу минутта ару-талчыгу турында, чәй турында сөйләшергә әзер түгел иде Җәмилә Закировна. Доцент аңа башка сүзләр әйтергә — бүгенге аяныч хәлне ничек тә аңлатырга, авыруның хәлен, операциянең ничек тәмамланганын сорашырга, һич булмаса кызарынып баш иярге тиеш иде шикелле. Ә ул остазының йөзенә туп-туры карап тора, аның агы зәңгәрсуланып торган коңгырт күзләре төбендә борчылу, үкенү, кыенсыну кебек хисләрнең әсәре дә чагылмый иде.

Изаил Харисович профессорның сүзсез торуын үзенчә аңлады, өстәл артыннан чыкты да, сеңлесен юаткандай, өстән аска карап, нелә төшеп:

— Артык авырга алмагыз инде, Җәмилә Закировна,— диде.— Кечкенә генә хата өчен сездәй зур галимгә кем сүз әйтә ала? Кем белә бит алай буласын, мондый очрак миллионга бер туры килә. Евгений Михайловичны чакырып бик дөрес иттегез, сезгә мөнәсәбәте яхшы, сер саклый белә. Ә мин, үзегез беләсез, сезне беркайчан подводить итмәячәкмен!

Профессор баштарак доцентның тел төбе кая барганын аңлый алмый торды. Ул үз колакларына үзе ышанмый иде: Диләрамны тиешенчә тикшерми генә операциягә салуда Дәүләтшин аны — Ильясованы гаепли иде түгелме? Әйе шул, бөтен гаепне аның өстенә аудара. Ул гына да түгел, профессор Петровны да астыртын ният белән, хатагызны йолып калыр өчен чакырдыгыз, димәкче була...

Ә доцент һаман сөйли иде әле, ак башлыгын түгәрәк башына кыңгыр салып, бүлмә буйлап йөренә-йөренә сөйли иде:

— Сезнең бер нәрсәгә игътибар иткәнегез юкмы, Җәмилә Закировна? Була шундый авырулар, ни генә кыландырсаң да, бөтен эшең гел кирегә генә китеп тора, бер дәва да шифа бирми. Андыйларны дәвалау ифрат кыен. Халыкта «кара эчле» дигән сүз бар бит әле. Хак сүз ул, минемчә. Андыйларның кара эчлелеге операция вакытында да үзен сиздерә, бик сиздерә. Бу... кем әле... Ахунова да шундый түгел микән?

— Бәлки, кайберәүләр операцияләрне кара күзлек киеп ясыйдыр, шуңа шулай тоеладыр? — диде Җәмилә Закировна.

Изаил Харисович тагын аңа гамьсез караш ташлады. Җәмилә Закировна аның күз төпләрендә моңарчы сизелмәгән яман шеш күргәндәй тетрәнеп китте...

— ...Булды, әни, төнлә тынычланып йоклабыз, бабакайның гырылдавыннан котылдык.

Ләйлә әнисе янына чыгып басты да, битен вагон тәрәзәсеннән бәргән җилгә каршы куеп, рәхәтлектән күзләрен кысты.

Ә тышта җәйнең иң ямьле чагы. Агачлыклар, авыллар, бәрәңге кишәрлекләре, алмалары тулышып килгән бакчалар, түтәлләрдәге гөлләр — һәммәсе кайнар кояш астында җәйрәп, яшәешнең һәр күзәнәктән тулып ташыган тантанасы булып күкрәп утыралар. Бер-бер артлы алышынып торган гүзәл манзараларга карап туймаслык иде.

— Әни, мин сине үземә әсирлеккә алам бүген,— диде Ләйлә.— Студентларга да, аспирантларга да, авыруларга да бирмим. Монда телефон юк, машина белән дә килә алмыйлар. Бүген син — минем әнием, баштанаяк бары тик минеке генә! Профессорлыгыңны бүгенгә онытып тор!

— Бик онытыр идем дә, Ләйлүгем, менә мондагы уйларны кул белән генә алып ташлап булмый шул! — Җәмилә Закировна кулын баш түбәсенә салып күрсәтте.

— Уйларыңны миңа сөйлә, үзем таратышырмын.

Диләрам хакында Ләйлә белә иде инде. Җәмилә Закировна бүгенге хәлләрне кыскача гына сөйләп бирде.

Ләйләнең әтисенә охшаган, шәрык тибындагы чыгынкырак яңаклы, няк уртасы уенкылы йөзе, озынча соры күзләре әнисен тыңлаган арада күләгәләнеп алды, анда сискәнү, курку, тынычлану, нәфрәт чагылды, коңгырт бөдрәләр белән яртылаш капланган маңгаен вак җыерчыклар сырлады.

Җиңел, хәрәкәтчән, төре гәүдәле Ләйләне беренче күрүдә, кырыкка житеп килә торган хатындыр бу, кафедра житәкчеседер, дип, һичкем әйтә алмас иде. Хәлбуки, ул — Англиянең Оксфорд университетында, Франциядә, Американың Мичиган университетында белем алып кайткан зур укытучы. Бу юлы да Мәскәүгә мөһим эш белән бара: техник вузларда инглиз телен укыту буенча өч курс өчен дәресләкләр язган иде ул, шуларны бөтен ил институтлары өчен чыгарыр алдыннан редактор белән соңгы тапкыр карап чыгарга кирәк иде.

Ләйләнең шәрык кызларына хас булганча кысыбрак уелган үткер күзләре кайбер очракларда әнисе күрмәгәнне күреп ала һәм ул профессор Ильясовага һич көтелмәгән киңәшләр биреп куя иде.

— Әни, син үзеңә килгән авыруларны юкка Дәүләтшинга җибәрәсең,— диде ул бу юлы әнисен тыңлап бетергәч.

— Бу аның темасы бит, Ләйлүк, аның докторлык диссертациясе. Мин андый операцияләрне үзләштермәдем, ә Дәүләтшин — аларның остасы.

— Әни, мин аптырыйм, ничек һаман аңламыйсыз сез: куркыныч кеше бит ул Дәүләтшин! Коточкыч кеше. Бүтәннәр кайгысы юк анда, чөнки ул зур дәрәҗәгә ирешү, дан казану, күп итеп акча эшләү турында гына уйлый. Синең урынга үрмәләргә маташа! Ә сез — элекке буын кешеләре, беркатлы идеалистлар, явыз адәмнәрне чалыш авызлы, тонык күзле, кара чырайлы итеп күз алдына китерергә күнеккәнсез. Җиргә яңа буын килде, яхшылары да, яманнары да яңача хәзер, әни! Эх, «һәр заманның була үзенә күрә сволочы, каһәр суккыры», дип шагыйрь юкка гына әйтмәгән шул! Хәзерге заман сволочларының бер нише чибәр, тәмле телле, уңган, өлгер, елгыр, әни! Үзләренә җай килгәндә, алар яхшылыкны да эшлиләр, тик юлларына аркылы төшәргә генә язмасын. Таптап үтәләр, елмаеп, тәмле сүз әйтеп, басып сыталар алар, әни! Сезнең Дәүләтшиныгыз шундый камырдан!

— Бер хата ясаган өчен кешене баштанаяк карага буярга ярамый алай,— диде Җәмилә Закировна.

— Хатада түгел бит эш, кешенең позициясендә! Үз хатасын башкага йөкләвендә! Әни, син бу хәлне болай калдырырга тиеш түгел. Фаш итәргә тиеш син моны, гыйльми советка чыгарырга тиеш!

— Уйлап сөйлисеңме соң син, Ләйлүк, юкмы? Чит кафедраның эшендә казынып, гаеп эзләү булып чыга бит бу!

— Кеше үтергәнне күтәргә кирәкмени?

Ләйләнең Дәүләтшинны бу чаклы яратмавы Җәмилә Закировнага аңлашылып җитми иде. Хәлбуки, бу фикер Ләйләдә моннан шактый күп еллар элек үк туды.

Заманында студент Дәүләтшин Ләйләдән инглиз теле дәресләре алып йөргән иде. Булачак галим чит телләрдә чыккан медицина басмалары белән танышып барырга тиеш, ә институт биргән белем белән генә бу өлкәдә әллә ни майтарып булмый, дип саный иде ул. Җәмилә Закировна, шәкертләре белән фамильяр мөнәсәбәтләргә керергә бик үк яратмаса да, Дәүләтшинның теләген хуплады, егетне Ләйлә белән үзе үк таныштырды.

Ләйлә каршында Дәүләтшин үзенең профессорга мәгълүм булмаган яклары белән ачылды. Икәүдән-икәү генә калганда, иркенәебрәк утыра, алдын-артын бик үк уйлап тормыйча сөйләшә, чөнки Ләйләне үз тиңе итебрәк саный иде ул. Дәүләтшинның саксыз ычкынган сүзләре, кинаяләре, мыскыллы итеп яки тәкәббер көлемсерәүләре аның яшерен үзәген, чын асылын ачып бирделәр.

Өстәвенә тагын шунысы: егетнең күзләре майлы, күңеле уенчак иде. Ул хәтта үзеннән шактый өлкән, инде кияүгә чыгып, әни булырга өлгергән Ләйләгә дә мәгънәле карашы, баллы тавышы белән ниндидер ишарәләр ясаудан тартынмады.

Изаилнең буйдак чагы иде әле. Ул шактый соң — утыздан узгач кына бер яшь студентканы алды һәм өйләнгәч тә элеккечә үк уенчак булып калды, ирекле, гамьсез яшәвен дәвам итте. Чит телләргә сәләтле булып чыкты үзе. Сөйләм телен тагын да ныграк чарлауны сылтау итеп, һаман килгәләп йөрергә теләк белдергән иде дә, Ләйлә кырт кисте: «Курс тәмам. Инглиз телендә мөстәкыйль шөгыль табыгыз. Мәңгелек студентларны яратмыйм мин».

Ир кешенең кемлеге хатын-кызга мөнәсәбәтендә бик яхшы күренә, әгәр дә хатын-кызга кимсетеп карый, аларны рәнҗетүне егетлеккә саный икән, ул башкаларга да миһербанлы була алмый, дип саный иде Ләйлә, бу карашының хәзергәчә үзгәргәне юк.

— Сабый күңелле шул син,— диде ул кызганулы тавыш белән әнисенә.— Хыянәт итүләрне, астан кисүләрне моңарчы белми яшәгәнсең. Язмыш сине андыйлардан саклап килгән.

— Төрлесе булды инде, Ләйлүгем. Өметләрем өзелгән чаклар да, хыялларым алдаган вакытлар да булды. Мәсәлән, бик якын бер кешем, иң якыным... минем өметләремне акламады... Яшьләрне аңлап җиткермәвем хактыр да, син дөрес әйтәсеңдер...

Җәмилә Закировна кызына мәгънәле итеп, озак итеп карады.

— Әни...— Ләйлә кызарынып чыкты.— Әни... Әйдә, җитди сүзләрне туктатып торыйк әле. Кайткач иркенләп сөйләшербез. Син минем әсирем бит бүген, мин сиңа бары тик сәяхәтең турында гына уйларга әмер бирәм. Утыр әле! — Ләйлә стенага терәп куелган утыргычны жайлап, кулы белән сыпырып алды, үзе дә утырып, әнисенә таба иелде.— Эчеңдәгең тышыңда синең, әни, ә бу заманда алай беркатлы булып яшәп булмый. Урыны-вакыты белән уйный белергә дә кирәк. Чит илләрдә гомумән артык гади булырга ярамый, чөнки анда еш кына га-

дилекне мескенлеккә саныйлар. Урыны белән тәкәббер булу да килешә. Килгән-киткән кешегә карап, алар бөтен ил халкы турында фикер йөртәләр, дия торган идең бит үзең дә. Менә болайрак йөр син анда!

Ләйлә башын артка ташлады да, чокырлы ияген алга чыгарып, күзләрен кыса төшеп, әнисенә горур караш салды.

— Болай итепме? — Җәмилә Закировна як-ягына карап алды да, якындагыларның тәрәзәгә карап торганын күргәч, Ләйләгә охшатып йөреп күрсәтте.

— Ә син көлмә! — дигән булды Ләйлә.— Ние көлке булсын аның. Менә хәзер мин сиңа кофе кайнатам, американча сандвичлар ясыйм, заграница тормышына күнегә торырсың.

— Чәй пешер, куе итеп чәй яса миңа! — дип, сокланып һәм горурланып карап калды Җәмилә Закировна кызы артыннан.

Әйе, кая барса да югала торганнардан түгел аның Ләйлүге. Ә кем тәрбияләде аны шушындый итеп? Әтисе белән әнисе. Хәзер менә ул үзе әнисенә акыл өйрәтә.

Өйрәтерлеге дә бар шул. Чит илләрдә дә әллә нинди хикмәтләр уйлап чыгарып йөри.

Америкада, Ләйләләр группасы белән барган ун кешенең унысына да аерым папка — «досье» ачкан булганнар. Укудан бушап торганда, ял көннәрендә аларның һәркайсын аерым бер гаиләгә алып китәләр — «гади американлыларның тормышы белән таныштыралар» икән, ә ул гади гаиләдә киләсе кунакның кемлеген белеп торсыннар өчен, шул папка — «досье»ны бирә торган булганнар.

Бер тапкыр шундый «кунак»ка баргагда, тышына «Миссис Мансурова» дип язылган папканы үзе алып укыган Ләйлә. Анда бөтенесе теркәлгән: кешенең милләте, нәсел-ыруы, торган җире, белеме, хезмәте... Холык-фигыленә аерым бит бирелгән, ул биткә Ләйлә турында: «Бик бай, кыйммәтле мехлар жыю белән мавыга. Четерекле, нәзберек»,— дип язып куйганнар.

Ләйләнең кыйссасы бу урынга җиткәч, Җәмилә Закировна тыела алмый көлеп җибәргән иде:

— Синме четерекле? Синме нәзберек? Нинди мех жыю ул тагын?

Ә хикмәт менә нәрсәдә икән: анда баруга, һәр кешедән: «Нинди шөгыль белән мавыгасыз?» — дип сорап чыкканнар. Дөресен генә әйткәндә, Ләйләнең бөтен мавыкканы — эше дә гаиләсе — ире белән улы. Ләкин алай дисә, дәрәҗәсе төшәр иде. Күп уйлап тормаган ул: «Мехлар яратам, затлы мехлар коллекциялим»,— дип җавап биргән. «Нинди мех ул?» — «Аеруча чәшке мехын яратам. Төрлесен жыям: көмешсыманын, зәңгәрсуын, сорысын, агын».— «Каян аласыз ул чаклы мехны» — «Күп алар бездә. Безнең Татарстаныбыз затлы мехлары белән бөтен дөньяда дан тота. Ишеткәнегез юкмыни?» — «Кая куясыз аларны?» — «Бүрекләр, туннар, пальто якалары тектерәм, кышкы күлмәкләремә дә куйдырам».

— Нигә, дөрес түгелме әллә? — диде Ләйлә моны әнисенә сөйләгәч.— Якасыз-бүрексез йөргәнебез юк бит әле. Ятларга сер бирмибез!

Һәр илдә йөрүнең үз җае, үз хикмәте бар. Англиядә Ләйләне һаман бер сорау биреп интектергәннәр: «Сез татармыни? Әниегез дә татармы? Әтиегез дәме? Анда татарларны кырып бетермәделәрмени әле?» Сүз белән генә ышандырып булмый, андый сорау бирүчеләрне Ләйлә кунакка чакырган да өчпочмак, чәкчәк-бәлешләр белән сыйлаган. Чигүле читек-башмаклар, китап-альбомнар, йөзек-беләзекләр һәм башындагы бүреген дә куеп, кечкенә генә күргәзмә дә ясаган. Андый эшкә оста ул, ни кирәк буласын алдан чамалап, Казаннан ук бер чемодан тутырып киткән иде, хәзер менә әнкәсе чемоданына да никадәр әйбер-

кара төяде. «Анда безнең исемебезне шундук онытачаклар, ә минә совет кешесе, татар кызлары икәнебез хәтерләрендә калачак,— ди ул.— Чит илгә чыккан һәр кеше — үз халкының көзгесе ул. Шуңа күрә, анда баргач, кибетләргә чабып, вак-төяккә мөкиббән киткән кешеләрне җенем сөйми!»

Ә ул үзе кайчан нишләргә икәнен төптән уйлап хәл итә, кирәк икән, четерекле дә, нәзберек тә була белә. Америкада, бер прием вакытында официант һәр кешедән: «Ни телисез: кофемы, чәйме?» — дип сорашып йөри икән. Безнекеләр гади, ни булса да ярый, дип җавап бирәләр, хуҗаларга артык мәшәкать ясыйсылары килми, янәсе. «Мин күз кыре белән генә күзәтеп утырам, официантның ирен читләренә мыскыллы көлемсерәү бәреп чыкты бер заман,— дип сөйләде Ләйлә бу хакта.— Әһә, мин әйтәм, гадиләрне санга сукмыйсыңмы? Каршыма килеп баскан иде, мин моңа эре генә: «Куе кофе пешерегез миңа,— дидем.— Йөз граммына бер балкашык каймак, ике балкашык шикәр салынган булсын!» Күрсәң иде шунда аның ничек ялагайланып бөгелгәнен!»

Ләйләнең «четерекле, нәзберек» дигән даны шул вакыйгадан соң туган да икән инде.

Әйе, Җәмилә Закировна кызының әнисе юлын дәвам итәчәгенә шикләнми дә иде, ул Ләйләдә кечкенәдән врач хезмәтенә мәхәббәт уятырга тырышты. Ләкин Ләйлә үз язмышын әнисенең башына да килмәгәнчә хәл итте: мәктәпне тәмамлагач, педагогия институтының чит телләр факультетына керде.

Гомере буе, үзе уйлаганча, кешеләр өчен иң мөһим эшне башкарып килгән Җәмилә Закировна өчен аңлашылмас бер хәл булды бу. Чит тел, ни генә дисәң дә, чит бит инде ул! Дәресләрдә утырганда «инфинитив», «перфект», «герундий»лар кемнең генә үзәгенә үтмәгән дә, мәктәп ишеген ябып чыгуга, кемнең генә башыннан очып чыгып китмәгән! Ләйләнең дә бөтен хезмәте шулай җилгә очып барырмы? Нилектән, ни сәбәптән әнисе хезмәтеннән гайрәте чикте соң аның?

Дөрес, еллар узгач, Ләйлә үзе сайлаган юлның дөреслеген исбат итте, бу юл аны дөнья киңлекләренә алып чыкты. Ул безнең илдә беренчеләрдән булып чит телләргә тиз арада өйрәтү методын үзләштерде, зур галим булып үсеп җитте, кафедра җитәкчесе дәрәҗәсенә ирешге.

Ә шулай да... Әгәр дә менә хәзер Дәүләтшин урынында үз каны — Ләйлә булса, хәзерге вакытта кафедраның киләчәге өчен профессорның җаны тынычрак булыр иде... Диләрам белән дә мондый хәлләр килеп чыкмас иде...

Тәрәзә артыннан бер-бер артлы шуышып узган манзараларга болыт күләгәсе төште.

— Әни, син мине ишетмисең инде әллә? — Ләйләнең каз канатыдай йомшак учы Җәмилә Закировнаның баш түбәсенә ятты.

— Чәй эзермени, кызым? Йөз граммына ике балкашык шикәр, бер балкашык сөт өсте салып яса миңа!

Көлештеләр.

Чәй янында Җәмилә Закировнаның уйга чумганын күреп, Ләйлә:

— Әни, син үзең минем янда, ә күңелең әллә кайларда,— дип куйды.— Гомергә шулай булдың син, миңа иң кирәк чакларында ташлый идең дә чыгып китә идең!

Шаярулы тавыш белән әйтелгән бу сүзләрдә бик тирән яшеренгән үпкә бар иде.

Җәмилә Закировна үзе дә борчуларын Гарәбстанга кадәр алып барырга теләмәгән иде дә бит, ләкин эчкә кереп оялаганнар шул алар, артта калмыйлар.

Башларыңа исәп төшсә, качып кына котылам димә икән!

* * *

— Ну, Зәйтүнгөл, без барасы юллар ачык хәзер! Икебезгә ике диплом, бер загс язуы. Төп мәсьәләләр хәл ителгән, яшәргә дә эшләргә генә! — Шулай диде Әнвәр беркөн иртән.

Зәйтүнә эшкә күптән күнеккән инде. Медучилище тәмамлаганнан соң авылда эшләп килгәнгә, ул институт клиникасында еш кына шәфкать туташы вазифаларын башкара иде, операция сестрасы да булды, ашыгыч төнге операцияләр вакытында ассистент булырга да туры килде аңа.

Башкалар, диплом алгач, ялга таралдылар, ә Зәйтүнә өчен тормыш үзгәрмәде дә шикелле: трамвай аны күнегелгән юл буйлап алып китте дә иске урамнарның берсенә китереп куйды. Зәйтүнә туктаусыз машина йөреп торган тар урам чатына килеп басты. Монда һәрчак гөрелдәү авазы, төтен-сөрем, якын-тирәдәге заводларның биек торбаларыннан аксыл-зәңгәрсу пар бөркелеп, сабын-селте исе тарата.

Урамны чыгып, өч катлы, озын фабрика бинасын узгач, кечкенә генә бакча янына килеп җитәсең. Бакча артында «П» хәрефе ясап салынган ике катлы иске бина. Бүген Зәйтүнә шушында — институтның акушерлык-гинекология клиникасында төнге дежур булачак.

Ул алгы бүлмәдәге зур шкаф янында халат киеп тора иде, әчке яктан лаборант Сөембикә апа килеп чыкты.

— Төн тыныч үтәчәк икән бүген,— диде Зәйтүнә аның белән исәнләшкәч.

— Әйе шул, аягым җиңел минем.

— Гөберчәкләрегез ни хәлдә кала соң?

Сөембикә апа үзенең кечкенә лабораториясендә, тәрәзә төбендәге пыяла банкаларда бакалар асрый, аларны назлап «гөберчәкләр» дип атый иде.

— Гөберчәкләр сайраша, тамаклары тук... Ә синең улың булачак, Зәйтүнә. Ачы тавышлы, тиктормас малаегыз булыр, әйткән иде, диярсең. Чибәрләнеп, ачылып киттең, йөзеңә тап та чыкмады... Әллә кәефең кырылды инде?.. Икенчегә кыз табарсың, бер дә аптырама. Кыз балага абый белән үсү рәхәт.

Сөембикә апа, халатын, ак башлыгын салып, шома кара чәчен сыпырды да, пальтосын киеп, алтын тешләрен җемелдәтеп, тыныч төн теләде.

Аның очравын чыннан да хәерлегә юрап була иде: бүген авыр операцияләр булмаган, шәһәр буенча да алар дежур түгел — «ашыгыч ярдәм» авыруларны бирегә китермәячәк. Сестралар бүлмәсенә кереп, авыру тарихларын кулына алгач, Зәйтүнә шуны уйлады.

Хәер... Менә Хәйруллина бар бит әле. Ике көн элек, иртәнге обход вакытында, алтынчы палатада аны күргә таныды Зәйтүнә — Ларисаны озатканда вокзалда очраган ак чигәле хатын Динә иде бу. Кифая сүзендә торган, палата врачы Фидаяны ярамаган эшкә күндерегән. Дөрес, авыру тарихында терапевтның, бала табарга ярамый, дигән белешмәсе бар барын. Йөрәге таза түгел, имеш, Хәйруллинаның. Хак микән? Беренче баласын тапкан бит, ул чакта яраган. Бәлки, йөрәк чире шуннан соң беленгәндер? Алай да була.

Зәйтүнә зәңгәрсу куш бит арасына кыстырылган тагын бер кәгазьне тартып алды. Анда Фидая кулы белән — эре хәрефләр койма тактасы кебек туры утыртылган — бу кичне Хәйруллинаны дәвалау тәртибе бәйнә-бәйнә язылган иде: ярты сәгать саен укол, иң соңыннан — «21 сәг. — йокы». Димәк, шул вакытка Динә котылырга тиеш.

Уколларны Анна Ивановна тиешенчә ясап бара икән инде, берничәсе турына тамга куйган. Урта яшьләрдәге бу шәфкать туташы кори-

дорларны дер селкетеп дың-дың басып йөри, каты тавыш белән кычкырып сөйләшә, әмма үз эшен яхшы белә, оста, намуслы, кайбер мәсьәләләрдә дипломлы врачларны төп башына утыртырлык тәҗрибәсе бар.

Шуны уйлап, Зәйтүнә Хәйруллина янына керергә ашыкмады, кичке обходны өске каттан башлады.

Палатаның ишеге кырыендагы караватта нечкә сынлы яшь хатын ята. Ябык йөзендә күзләре генә утырып калган. Ул Зәйтүнәнең йөзен ике фонарь белән яктырткандай итте. Моннан биш ел элек бу хатын да башка хатыннар белән мәзәк сөйләшеп, көлешеп бирердә бер кичен үткәреп чыккан булган. Бала үстерергә тормышның көе житеп бетми, дип уйлаган ул чакта. Инде менә тормышы көйләнгән, хәзер бала кирәк икән. Бик кирәк... Ләкин теге төннән соң аның ныклыгы бетеп калган. Инде карындагы баланы ничек тә саклап калу чарасын күрергә кирәк...

Зәйтүнә карават кырыена утырып, хатынның нечкә беләзеген кулына алды:

— Хәлебез ничек безнең бүген, Рәзилә?

— Искечә инде...

— Тыныч үткән һәр көн безнең файдага, Рәзилә.

Палатада урнашкан тынлыкта кинәт кенә астан бака кычкырган тавыш ишетелде. Хатыннар көлешеп алдылар. Рәзилә дә сүрән генә елмайды.

— Ишетәсеңме, бакалар да синең күңелне күтәрергә тырыша,— диде Зәйтүнә.— Матур төшләр күреп, изрәп йокласаң, иртәнгә алмагачларның алмалары тагын да тулышкан булыр, алар кызарып пешкәндә, без, мөгаен, сине бәби белән озатырбыз.

Рәзилә тар учларын күкрәге турында аз гына аерып күрсәтте.

— Ирем әйтә, менә шушындый гына кыз тапсаң да, мин сине учымда гына биетеп йөртер идем, ди.

— Ә бәлки без аңа баһадир малай бүләк итәрбез? Үзебездән генә тора бит!

Зәйтүнә Рәзиләнең нечкә бармакларын сыйпады.

Рәзилә караваты янында тагын бер ишек бар — андагы өч кешелек палатада операциядән котылган авырулар ята. Зәйтүнә килеп керүгә, утыз биш яшьләр тирәсендәге хатын аның кулын тотып алды да, күз яшьләре белән чылатып, үбәргә тотынды:

— Рәхмәтләр яусын сезгә! Бүген коридорны урап кердем! Үз аякларым белән!..

Зәйтүнә кыенсынып кулын тартып алды.

Бу хатынны аңа килендәше Кәүсәрия җибәргән иде. Ел буе аяклары сызлап җәфаланган, йөри алмас хәлгә килгән, невропатологта дәваланган, файдасы булмаган. Зәйтүнә анда шеш барлыгын ачыклады, хатынга операция ясадылар... Врач өчен гадәти эш — ә башка берәүнең язмышында нинди зур үзгәреш... Юк, тыныч була алмый врачның эше, палата саен күңелне кузгатып торалар.

Аскы катка төшкәндә, бакалар тавышы ачыграк ишетелде. Алар монда изге вазифа башкаралар, катлаулы очракларда диагнозны ачыкларга ярдәм итәләр. Бик авыр хәлдәге хатыннарны коткарырга ярдәм итә Сөембикә апаның «гөберчәк»ләре. Әмма үлемнән котылган хатыннар, врачларга рәхмәт укыганда, Сөембикә дигән кешенең дөньяда барлыгын да белми калалар. Ә бит бакаларны ул Кабан күленнән үзе тотып ала, үзе асрый. Студентларга күргәзмә әсбаплар әзерләүче лаборант бу эшне үз өстенә алмаса да, сүз әйтүче булмас иде югыйсә.

Терелеп өйләренә киткәндә, кайбер хатыннар шәфкать туташларына тартмалы конфет яки торт бүләк итәләр. Бу күчтәнәч чәй эчкәндә

табын уртасына куела. Тик Сөембикә апага аларны авыз итү дә сирәк эләгә.

...Ә шулай да алтынчы палатага аяк тартмый иде. Ләкин керергә кирәк.

Караватянында басып торган Анна Ивановна кереп баскан докторны күрмәмешкә салышып, Динәгә таба иелде дә, Зәйтүнәне янбашы белән эткәндәй итте. Авырлы хатынның монда керүен күңеле тартмый иде аның. Зәйтүнәдән бераз калышып, палатадан чыкканда, шәфкать туташы шактый ук кычкырып:

— Алты айлык баланы юк итәргә тотынсаң, шул була ул менә! — диде.— Беләбез без андый очракларда йөрәк начар дигән белешмәләрнең ничек алынганын! Җәмилә Закировна гына юк, ул барда бездә мондый эшләр белән шөгыльләнмиләр иде!

Динәгә бик авыр булды. Ниһаять, сәгать уникенче киткәч кенә, ул шешенке иреннәре белән елмаеп, Зәйтүнәгә карады. Аның бу карашында бер җиңеләю чагылды. Ләкин кызарынган күзләренең төбендә оялу, ялвару да бар иде.

Зәйтүнә аның яныннан тудыру бүлегенә ашыкты.

...Бу дөньяда һәр кешенең үз холкы, үз фигыле. Берәүләр тупас, холыксыз, чыдамсыз, икенчеләр үшән, аңгыра, өченчеләр елгыр, тырыш, булдыклы. Берәүләр үз тормышындагы бу мөһим вакыйгага бөтен яшәеше һәм акыл үсеше белән әзерлекле килә, икенчеләр — бөтенләй әзерлексез. Берәүләр үзләренә дә, якыннарына да кадерле һәм иркә, икенчеләрнең кадерен үзләре дә, якыннары да белми.

Монда беркем дә чын йөзен яшерә алмый, бар күңелләр ахыргача ачыла.

Ләкин килә бер минут, бер мөкатдәс мизгел, син дөньяга килгән кешене көтәреп, ананың йөзенә якын китерәсең, җирдә яңа аваз — сабый авазы яңгырый. Шушы минутта әйтерсең лә бер кодрәт белән ана күңелендәге барча керле таплар юып алына һәм йөрәкнең түрендә яткан изге, саф хис калкып чыга. Бу хис — яңа җан тудырган кешенең тантанасы, куанычы. Безне бар иткән, үстергән, яшәткән ул хис барлык аналар күңеленә буыннан буынга күчеп килә. Бу хисне кичергәндә һәммә хатыннар да изге, сөйкемле һәм гүзәл, аларның сафлыгы һәм куанычы башкаларны да үстерә, канатландыра.

Төн эчендә дүрт ананың шатлыктан балкыган карашын күрде Зәйтүнә, һәм алар гаепле ялварып караган күзләрне тәмам оныттырдылар.

*

* *

Зәйтүнәгә әнисе Гөлзәйнәп бер кыйсса сөйләгән иде. Зәйтүнә күңелендә, кубәләк турындагы, Гали белән кәҗә турындагы шигырьләр кебек, бик нәни чакларның хатирәсе булып саклана ул кыйсса.

...Илгә яу килгән.

Кара болыттай ишле, давылдай көчле, яшендәй аяусыз дошман явы килгән ил өстенә. Ярсу йөрәкле батыр егетләр, җилдән җитез атларына менеп, үткен кылыч болгап, дошманга каршы чыкканнар. Әмма дә ләкин давылны ярсу ат белән, яшенне кылыч белән туктатып буламыни? Илнең асыл ир-егетләре яу кырында ятып калганнар, аларның аналары, хатыннары, балалары, дәррәү урыннарыннан кубып, дошманнан качып киткән.

— Җиндек! — дигән дошман буш калган калаларга, авылларга басып кергәч.— Бу байлыклар барсы да безнеке хәзер! — дигән алтынкөмеш тулы казналарны, көтү-көтү малларны күргәч.— Боларның элекке хуҗалары җир йөзеннән юк ителде!

Һәм ул качып киткән хатын-кызларны, бала-чагаларны тәмам юк итәргә шәфкатьсез укчыларын җибәргән. Алар шул кадәр аяусыз булганнар, кара төн булып кара төн качакларны кызганган, аларны киң канаты астына алып, дошман күзеннән яшергән.

— Ерак китә алмаслар! — дигәннәр укчылар.— Иртәнге таң нуры төн канатын эретеп юк иткәч, без ул качакларның берсен дә калдырмабыз!

Ә хатын-кыз, бала-чага, ераккарак китәргә тырышып, төне буе йөгергән. Таң нуры төн канатын юкарта башлаганда, яшь хатын Гөлҗиһан елга ярына барып егылган.

— Бүтән бер адым да атлый алмыйм,— дигән ул.— Карынымдагы балам, бу газаплардан соң урыныннан кузгалып, вакытсыз дөньяга килергә талпына.

Аның янына ыруның иң олы әбисе килгән.

— Түз! — дигән ул яшь хатынга.— Адәм баласы дөньяга килгәндә дә, дөньядан киткәндә дә башкаларга газап-әрнү китерә. Түз, ыңгырашма.

Шәфәкъ нуры көчәя, дошман укчыларының юлын яктырта бара икән. Ләкин елга үз ярында кан коелуын теләмәгән, ак томан пәрдәсен җәеп, качакларны дошман күзеннән яшергән. Гөлҗиһан да тавышын чыгармаган. Укчылар качакларны күрми читләтеп үтеп китkәннәр.

Шул елганың ярында Гөлҗиһан карлыгач баласы кебек арык һәм кечкенә ир бала тапкан. Аның зәгыйфь тавышын ишеткәч:

— Бу балам җитлекми дөньяга килде, гомерле булмас инде,— дигән.

— Кара төн сине канаты белән дошман күзеннән качырды, салкын елга ак томаны белән һәлакәттән саклап калды. Син — ана кеше, үз канатың астында балаңны саклап кала алмассыңмыни? — дигән аңа кендек әбисе. Һәм иңеннән туның салып, Гөлҗиһанның өстенә япкан, сабыйны исә яулыгына урап тун җиңенә тыгып куйган.

— Бу сабый канат ярган бөркет булып җитешкәнче, аңа тән һәм җан җылыңны бир,— дигән.

— Моның әтисе яуда һәлак булды, үзем дә бик хәлсезмен, яши дә алмам ахры,— дип зарланган Гөлҗиһан.

— Син сабыеңны тыңла. Аның тавышы сиңа көч бирер, сине аякка бастырыр, ул синең саклаучың да, яклаучың да булыр,— дигән кендек әбисе. Яшь анага елгадан су алып эчергән, якындагы урманнан җимешләр өзеп китергән.

— Бу суны эч, бу җимешләрне кап, сабыеңа күкрәк сөтеңне имез. Синең сөтең аша сабый шушы туфракка берексен — бу аның туган җире,— дигән.

Көннәр, айлар үткән, бала инде тун җиңенә сыймый башлаган, үз вакытында әнисенең тезенә менеп утырган, үз вакытында, әнкәсенең итәгенә тотынып, елга яры буйлап тәпи киткән.

Менә бер язның кояшлы көнендә кендек әбисе малайны җитәкләп, авыл башына алып чыккан.

— Тыңла, улым! — дигән. Болынлык өстендә тургайлар сайрый, аннан ары урманда күке кычкыра икән.— Ишеттеңме? — дигән кендек әбисе.— Һәр кошның үз җыры бар. Алар ул җырны ата-аналарыннан отып алганнар. Синең атаңның да үз җыры бар иде. Мин аны сиңа өйрәтермен.

Һәм малайның тавышы тургайлар җырына кушылып чәчәкле болын өстендә яңгыраган.

Тагын күпмедер вакытлар узган. Малай егет булып җитешкән, аның тавышы шундый көчле икән, ул җыр башлагач, болыннарда тургайлар, урманда күкеләр тын булып, хәйран калып аны тыңлыйлар икән.

Егет өйләнгән, аның җиде улы, бер кызы туган. Уллары илнең асыл егетләре булып, кызы илнең сылуы булып җитешкән.

Шул чак дошман, бу халыкның яңадан терелеп аякка басканын, мантыганын күреп, янә яу белән килгән. Ләкин бу юлы бер урынына җиде батыр аңа каршы чыккан. Алар явыз дошманны тар-мар итеп, ата-бабаларының җирләрен дә аннан азат иткәннәр.

Хәзер ул җирләрдә Гөлҗиһанның батыр ирениән калган җыр яңгырый, һәр язда яңа сабыйлар, кендек әбиләренең кулларына тотынып, урман-болыннарга чыгалар, ата-бабаларының җырларын өйрәнәләр һәм аларның тавышы тургайлар, сандугачлар җырына кушылып, күкләргә үрелә, ди.

...Менә шундый кыйсса сөйләгән иде Зәйтүнәгә әнисе. Әкиятко охшатып сөйләгән иде, әмма ул әкият булса да, бик тә чынга охшаган үзе.

*
* *

Институтта чакта Алтынчәч химиядән бер егеткә ярдәм иткән иде. Бүлмәдәш кыз көндерде аны бу эшкә:

— Химияне синнән әйбәт белгән кеше юк, минем бер танышка булыш әле,— диде.— Армиядән кайткан егет, белеме саегып киткән.

Бу — озын гәүдәсенә караганда кечерәк тоелган башын алгарак иеп йөри торган, Нәркис исемле егет булып чыкты. Алар атнага ике-өч тапкыр очраша торган булдылар. Нәркис тырыш, дикъкатьле, үзен бик кечелекле тота, ләкин һәрнәрсәне кат-кат аңлатканны ярата иде.

Сигезенче Март бәйрәменә ул Алтынчәчкә гаҗәеп бүләк китерде: йодрыкка сыярлык тимер шар матур итеп челтәрләнгән, аның эчендә шулай ук челтәрле тагын бер шар тәгәрәп йөри иде.

— Станокта үзем ясадым,— диде Нәркис.— Тоташ тимер кисәгеннән эшләнгән ул.

— Нәрсәгә ярый соң ул?

— Ачкычка тагарга була. Андый нәрсә бүтән беркемдә дә юк!

Егет түгәрәк күзләре белән Алтынчәчнең йөзенә текәлгән, әллә мактау көтеп, әллә сынап карый иде. Алтынчәч рәхмәт әйтергә ашыкты. Ачкычына андый зур, авыр әйбер тагып йөрмәс ул йөрүен, ләкин егет тырышкан бит. Аннары колга кебек ир-атның Нәркис исемле булуы Алтынчәчне сәерсендерә, анда хәтта кызгану хисе тудыра иде. Ул үзе дә гомере буе шулай кыяфәтенә ятышмый торган сәер исем күтәреп йөри бит!

Шул көннән микән, әллә аннан да элегрәкме, алар химиядән тыш бүтән нәрсәләр хакында да сөйләшкәли башладылар. Егет китәргә җыенып, китап-дәфтәрләрен бил каешына кыстырып куйгач та — аның бу гадәтен Алтынчәч яратмый, ләкин әйтергә яхшысынмый иде — алар тәмләп чәй эчәләр һәм дөнья хәлләренә кереп китәләр иде. Күбрәк кино-китап турында бара иде сүз. Соңрак, ачылып китеп, таныш-белеш, тормыш-көнкүреш турында да сөйләшкәли башладылар.

Нәркис Алтынчәчне кинога-мазар чакырмады, аулакта очрашырга тәкъдим ясамады. Ләкин аның китәсе килмичә озаклап утыруыннан, һәр сүзне теләктәшлек белән тыңлавыннан гадәти булмаган якынлык сизелеп тора иде. Әкренләп кыз үз күңеленә дә егетнең бик якын булып китүен тоя башлады. Тора-бара ул егетне сагына торган булып китте, ул килмәгән көннәр караңгы булып күренде. Ахырда, чын мәхәббәт шушындый булырга тиеш, дип уйлый башлады Алтынчәч, Нәркисне озатып, чәчен бигудига ураганда һәм йокыга китә алмый яткан сәгатьләрендә.

Дөрес, башкалар яратуны бүтәнчәрәк аңлый. Әнә, күрше карават һаман буш, Тәслимә тиз генә кермәс әле, КАИ егете Тәфтил белән караңгы почмакта торалардыр.

Бер кичне Нәркис чыгып киткәч:

— Алтынчәч, син бик мавыкма, Нәркис синнән көлә генә, баласыта ул сине,— диде Тәслимә.— Хәзер кая китте дип беләсең син аны? Рамиләсе янына китте ул.

— Булмас! — диде Алтынчәч урыныннан торып.— Булмас! Ул андый түгел!

Ул төнен Алтынчәч йокысыз үткәрде. Һәм шунда газапның иң ачысын кичердем, дип уйлады. Мәхәббәт газапларының ачылардан ачылары барлыгын белми иде әле ул.

Ике көннән Нәркис килгәч, ул аннан таныш булмаган Рамилә хакында сорамакчы, һич югында кинаяләп кенә булса да берәр сүз әйтмәкче иде. Ләкин Нәркис аңа шундый саф, беркатлы итеп, һәр сүзенә инангандай карап утыра иде ки, Алтынчәч аның гөнаһсызлыгына сүзсез дә ышанды. Мондый карашның алдавы мөмкин түгел иде. Сизә иде бит ул Алтынчәчнең күңелендә ниләр кайнаганын! Әгәр дә башка берәү белән йөри торган булса, Алтынчәч күңелендә шундый хисләр тудыруга нигез бирер идемени ул? Бу бит кешене җәлладларча җәзалау булыр иде! Юк, Нәркис күңел җәллады була алмый, ул намуслы кеше.

Шулай итеп юатты үзен Алтынчәч.

Ә җәй башында, укулар бетәр алдыннан, кичен, Алтынчәч чәчен бигудига урап азапланганда, сак кына ишек кактылар.

— Алтынчәч! Чык әле,— диде курсташ егет Җәүдәт.

— Чыкмыйм. Сүзеңне шуннан гына әйт.

— Чык инде... Алма бирәм... Ишек аркылы сөйләшә торган сүз түгел...

Алтынчәч башына яулык урап чыгарга мәҗбүр булды. Баш түбәсенә сыя алмагандай тырпаеп торган куе, каты чәчле Җәүдәт, чыгынкы маңгае астыннан сынап карады, алма сузды һәм:

— Син борчылма, гадәти хәл дип кабул ит,— диде.— Бүген Нәркис Рамилә янына күчеп китте.

Алтынчәч тын гына борылып керде дә, урынына менеп ятты.

Мәхәббәт газапларының чыны менә шуннан башланды.

Иртән торгач, ул төймәләрен, брошкаларын саклый торган тартмасыннан Нәркиснең бүләген эзләп табып, икенче каттан тышка ыргытты. Тимер шар асфальтка барып төшүгә урталай аерылды. Ул кисәкләрдән тоташтырылган булган икән, Нәркис аны шунда да алдаган. Әллә сынавы гына булганмы? Әгәр шулай икән, таш күңелле кешенең сынавы булган ул!

«Ник алай иттең?» — дип сорыйсы килде Алтынчәчнең. Әмма очрашкан чакларда тән куырыла, юкка чыгасы, күзгә күренмәс буласы килә башлый, ул хәтта Нәркис барган трамвайга утырмаска тырыша иде.

Менә хәзер алар икесе бер заводта эшлиләр. Нәркис Нәгыймович Бадамшин зур кеше хәзер, баш механик. Гәүдәсе турайды, юанайды, башы иелмәс булды. Тик Алтынчәчнең күңеле генә шул килеш калды. Каршысына баш механик килеп чыкса, заводның чакрымнарга җәелгән мәйданы кинәт тараеп китә, кереп яшеренер урын бетә...

Ә бәлки, чыннан да Тәслимә хаклыдыр, егет белән кыз арасындагы мөнәсәбәт ачык, гади булырга тиештер, барысын да турыдан-туры сөйләшергә һәм теләгәнеңне эшләргә кирәктер? Ә бәлки, Алтынчәчнең ихтыярына каршы килеп булса да, ике арада Линар урнаштырган мөнәсәбәт табигыйдыр, аңа күнегергә генә кирәктер?

Нәркис белән булган хәллардән соң күп вакытлар үтте бит инде. Алтынчәч беркемне дә күңеленә якын итә алмады. Ниһаять, менә аның тормышына Линар бәреп керде...

Аның турында уйлаган чакларында, Алтынчәч Нәркисне искә төшерә, алар белән булган мөнәсәбәтләрне чагыштырып, ике егетнең үз-

ләрен капма-каршы тотуларын күрә, бу капма-каршылык киләчәккә өметне ныгыта иде.

Линарның нияте җитди, әлбәттә, монда икеле-микеле уйларга урын да юк. Ул хатыны белән аерылышуын законлаштырыр, йортын сатып, эшеннән чыгып, Казанга күчеп килер.

Әгәр дә нияте шундый булмаса, ул монда килеп атналар буе яшәп ятар идемени? Бөтен халык алдында парлап пляжга йөрер идемени?

Идел буенда, таллар күләгәсендә утырганда шуларны уйлады Алтынчәч. Линар кул-аякларын таратып ташлап, комга чалкан яткан да күзләрен йомган. Кояшта янып каралуны белмәс ак тәне алсуланып чыккан, корсагы калкыбрак, сулыш алган саен тирбәлеп тора. Йөзендә гамьсезлек, туклык, күңел тынычлыгы чагыла. Бары тик җанга якын кеше янында гына үзеңне шулай гамьсез, рәхәт хис итеп буладыр.

Бар да яхшы, тик менә аның янына куелган магнитофон гына аңлашылмас телдә өзек-өзек көйләр җырлап ачуны китерә, сөйләшергә ирек бирми.

Алтынчәч, тезләрен бөгә төшеп, егеткә яны белән утырган да, кайнар комнан таучыклар ясый, аннары аларны ишеп ташлый. Уйлары да бер оеша, бер тарала аның.

— Каяле, күзлегеңне биреп тор!

Линар җавап көтмичә, Алтынчәчнең маңгаеннан күзлеген тартып алды да, башта яткан килеш, аннары торып утырып, як-ягына каранды.

— Күзне авырттыра бит бу! Кара-кара, җирне күкәй кабыгы кебек кабартып күрсәтә үзе! Ә кешеләрне тукмак хәтле генә итеп калдыра!

Алтынчәч аннан күзлеген алырга ашыкты. Ә магнитофон һаман әлләнәрсә акыра. Нәрсә җебеп утыра соң әле Алтынчәч? Ул үрелеп клавишка басты да магнитофон җырын ярты сүзендә туктатты.

— Тормыш хәлләрен сөйләшик әле,— диде.

Яңадан җәелеп яткан Линар башын күтәреп аңа гаҗәпләнеп карады.

— Нием сөйләшәсең аның?

— Ничек яшисең, нишләргә уйлыйсың?..

Линар кире ятты.

— Менә кайткач ишегалдына багана утыртам әле. Урамдагы төсле биекне, кәкре башлыны. Белсеннәр Шиһаповның кемлеген!

— Кем белсен?

— Бөтенесе! Тирә-күршедә андый баганалы кеше юк әле.

— Ә нигә кирәк ул?

— Уңганлыкны күрсәтә ул. Уңган кешенең бөтен әйберсе югары сортлы була. Быел ишегалдына шундый түтәлләр ясадым, билләһи, сезнең Ирек мәйданындагы гөлләрдән ким түгел!

Алтынчәч күз алдында кояш тотылгандай булды. Багана артыннан йөри икән, димәк, нигезеннән кузгалырга нияте юк моның! Алтынчәч урыныннан торып, суга керде дә, колач салып йөзеп китте. Линар берничә селтәнүдә аны куып җитте.

— Нишләп болай эреләндең әле? Минем яндарак тор, бата башласам, кем коткарыр?

— Хатының бар бит синең,— диде Алтынчәч чәнчергә тырышып.

Линар бер чумып алды. Аннары пырхылдады да:

— Әйдә, көннең ямен җибәрмик әле,— диде.— Бала хакында сүз бара, аңлыйсыңмы? Кызым бар бит минем!

Әйе, Алтынчәч моны белә: Линарның җиде яшьлек кызы бар. Баганасы, гөлләре дә, моңарчы шул калада яшәп ятуы да кызы хакынадыр... Әгәр дә ул кызының язмышы турында уйламыйча, барысын да кинәт кенә ташлап монда килсә, бу аның кызына карата мәрхәмәтсезлеге булмас идемени?

Алтынчәч Линар белән янәшә йөзеп китте, кинәт күзе ачылып,

кояш нурында тәңкәләнеп ялтыраган Идел киңлеген күрде, тәне сунын салкынча назын тойды.

Алар күңелләре белән бер-берсен аңлаша ала, димәк. Бу аңлашу чын рухи якынлыкка әверелсен өчен бөтен көчен куяр Алтынчәч. Тәннәрнең бер-берсенә омтылып та, күңелләрнең аңлашмавы, рухларның каршылыгы — ул мәхәббәт фаҗигасе дигән сүз бит! Алтынчәч бу фаҗигагә юл куймас. Ул егетнең рухын, аның белемен үз дәрәҗәсенә күтәрергә ярдәм итәр.

Һәм Алтынчәч бу изге эшне кичекмичә башларга булды. Ул сумкасына бер шешә «Яблочная» дигән су, өсләренә юка гына сыр кисәкләре куелган ике телем арыш икмәге белән бергә Антуан Сент-Экзюперинын «Нәни шаһзадә» исемле китабын да салып килгән иде.

— Әйдә, әкият укыйбыз,— диде ул китапны алып.

— Валяй.

Линар комга капланып яткан иде, шыбырдашкан тал яфракларына күз салып алды да, башын кулларына салды. Тал күләгәсе аларны ят күзләрдән саклый, егетнең алсу тәненә челтәрле күләгә төшкән, саф су исе, әчкелтем яфрак исе килә — гомумән алар әкияттәге кебек матур мохитта иделәр һәм бу хәл, Алтынчәч фикеренчә, әкиятнең тәэсирен көчәйтергә тиеш иде.

«Алты яшьлек чагымда мин кеше аягы басмаган карурманнар турында укыган идем»,— дип башлады Алтынчәч хисләнеп. Егет дәшми, кыймылдамый, йөзе күренмәсә дә, кыяфәтенә караганда, бик игътибар белән тыңлый иде.

— «Мин шундый бер планета беләм. Анда кызыл чырайлы бер кеше яши. Ул гомере буена бер тапкыр да чәчкә иснәмәгән. Бер мәртәбә дә йолдызга карамаган. Бервакытта да беркемне дә яратмаган. Беркайчан да берни эшләмәгән. Аның бердәнбер шөгыле — саннар кушу. Иртәдән кичкә хәтле ул нәкъ синең шикелле һаман бер үк сүзне кабатлый: «Мин җитди кеше! Мин җитди кеше!» Горурланудан шардай кабара. Ә чынында исә кеше түгел, гөмбә ул!»

Алтынчәч шушы урында туктап сулыш алды. Линар әйләнеп чалкан ятты да, иснәп:

— Әкият шундый буламыни! — диде.

— Ләкин бик образлы бит, шигъри, хисле... Тирән мәгънәле...

Алтынчәч, бу сүзләренең егет зиһененә барып җитмичә, тал яфракларын шыбырдаткан акрын җилдә очкандай юкка чыкканын тоеп, тынып калды.

— Санамыйча яшәп булмый... Чәчкә иснәп, йолдыз санап кына яшәр иде һәркем дә... Әлсерәтте әле, тамак кибеп китте...

Алтынчәч кабаланып сумкасыннан шешә белән ипи телемнәрен чыгарды.

— Шушы гынамыни? — диде гаҗәпләнеп Линар.

— Минем эчәсе килми... Азмыни?

Алтынчәчнең үзенә бу ризык көндезгә дә, кичкә дә җитә иде.

— Ир туйдырган кеше түгел шул син,— диде Линар аның гаебен гафу иткәндәй. Ул шешә капкачын таза теше белән генә каерып алды да, башын артка ташлап, голт-голт эчә башлады. Бу рәвешендә ул зур һәм гайрәтле кыргый җанварны хәтерләтә иде.

Алтынчәч нәрсәгәдер оялып, күлмәген киеп куйды. Алай да бирешергә исәбе юк иде әле аның.

— Анекдот сөйләшәбезме соң әллә? — диде ул.

— Әйдә, сөйләп җибәр! Синең белән бер дә анекдотлар травить иткән юк бит әле.

Линар җанланып китте.

— Бер заман авылдан шәһәргә бер абзый килгән, ди. Моны симфоник оркестр концертына алып барганнар. Абзый дирижерны күреп:

«Бу кешегә шушы рәвешле орчык кзәп торган өчен күпме түлиләр?» — дип сораган. «Биш йөзләп бардыр»,— дип җавап биргәннәр аңа. «Кит аннан,— дигән абзый исе китеп.— Ул хакка мин орчык түгел, бастырык болгап торыр идем!»

Лабораториядә сөйләгәндә бу анекдот бик кызык булып тоелган иде, кызлар тәгәрәшеп көлделәр. Ләкин бу юлы Алтынчәчнең иренена кунган елмаю курыккандай юкка чыкты, чөнки Линар җитди калды.

— Гади халыктан көлгәнне яратмыйм мин,— диде ул аксыл кашларын җыерып.— Орчык селкеп торган дирижерлар түгел, бастырык белән эш иткән абзыйлар туендыра халыкны!

Шундый үртәлеп әйтте ки, әйтерсең, үзе дә халыкны туендыручы иде!

— Алайса, үзең сөйлә!

— Бер заманны Чапаев янына Петька йөгереп килгән,— дип башлады Линар.— «Василий Ивнович,— ди бу,— анда Анька...»

— Ә мин Чапаев кебек изге кешеләр турында анекдот сөйләгәнне яратмыйм,— диде Алтынчәч үчлелек белән.— Гади халык арасыннан күтәрелеп, изге көрәштә җанын биргән кешедән көләргә ярыймыни?

Линар: «Әле син тешли дә беләсеңмени?» — дигәндәй аңа гаҗәпләнеп карады.

Сөйләшер сүз беткән иде.

*

* *

Алар Әнвәр белән кич театрга барырга сөйләшкәннәр иде. Ләкин Зәйтүнә эштән вакытында китә алмады, янына кеше килде. Гамьсез карашлы, аксыл керфекле бу яшь хатынны Зәйтүнәгә килендәше Кәүсәрия җибәргән иде.

Гадәти хәл: һәр врачка үзенә тиешле авырулардан тыш, таныш-белеш, туган-тумачасын, танышларының туганнарын һәм туганнарының танышларын да карарга туры килә.

Хатын Илзирәк исемле икән, Зәйтүнә аны арткы ишектән кертеп, студентлар укый торган бүлмәдә тар өстәл артына утыртты да хәлен сораша башлады.

Хатынның сөйләгәннәре — заманның елдан-ел ешрак очрый торган зары иде. Биш тапкыр балага узган, берсен дә ахырынача күтәреп бетерә алмаган, инде менә алтынчысын йөртә. Монысына да ышаныч зур түгел... Сораша торгач, Зәйтүнә Илзирәк исемле бу хатынның шушы хәлендә үзен ничек тотарга, нидән сакланырга кирәклекне бөтенләй белмәвен ачыклады.

— Сез менә, бухгалтер булып эшлим, дидегез, укыгансыздыр инде? — дип сорады Зәйтүнә.

— Хәзерге заманда андый җаваплы эшкә дипломсыз алырлар, бар. Техникум тәмамладым.

— Ә әни булыр өчен нәрсәләр укыдыгыз?

Илзирәкнең моңарчы ваемсыз күренгән йөзе җитдиләнде, күзләре түгәрәкләнде.

— Аның өчен... уку кирәкмени?

— Ә сез ничек уйлыйсыз? Саннарны кушу, тапкырлау өчен техникум белеме кирәк, ә ана булу, кеше үстерү өчен наданлык та ярыймы?

— И, Зәйтүнә Мәҗитовна! Андый эшне дипломсыз да бөтен кеше булдыра лабаса. Беренчесе без түгел, ата-баба һөнәре.

— Ләкин менә наданлыкның зыяны тигән бит әле! Гади генә нәрсәләрне белсәгез дә, мөгаен, мондый хәлгә төшмәгән булыр идегез!

һәм Зәйтүнә аңа мондый хәлдә нәрсәләрне истә тотарга кирәклеген бәйнә-бәйнә аңлатырга керешә. Илзирәк күзләрен зур ачып тыңлый, ләкин, клиника ишеген ябып чыгуга, врач сөйләгәннәрнең күбесе аның түгәрәк башыннан чыгып җилгә очачагы көн кебек ачык иде.

Зәйтүнә аңа һәр хатын-кыз белергә тиешле гап-гади кагыйдәләрне аңлата. Ләкин ни өчен соң әле боларны врач һәр аерым кешегә сөйләп утырырга тиеш? Менә хәзер кул астында бөтенесе бәйнә-бәйнә, ачык һәм аңлаешлы итеп язылган китап булсын иде дә, Илзирәккә шуны гына биреп җибәрәсе иде. Ул аның үзенә кирәк битен теләгән вакытында ачып, кат-кат укый алыр иде...

Авылда эшләгәндә дә, монда яшь хатыннарны караганда да бу уй бик еш килә иде Зәйтүнәнең башына. Китап кирәк, аны һәркемгә таратырга кирәк. Югыйсә, күпме генә тырышсаң да, бер утыруда теләгәнеңне аңлатып бетереп булмый.

Шул вакыт, эчке яктан ишек ачылып, куркынган тавыш:

— Зәйтүнә Мәҗитовна, сезне уникенче палатага чакыралар! — диде.

Зәйтүнә, Илзирәккә ике айдан тагын килергә кушып, ашыгып өске катка менеп китте. Ишекне ачуга, аның карашы Рәзиләнең шом баскан зур күзләре белән очрашты. Аның караваты янына Анна Ивановна тезләнгән иде.

— Зәйтүнә Мәҗитовна, кан тамырына эләгә алмыйм,— диде ул кулындагы шприцны күрсәтеп.

— Ни булды, Рәзилә?

— Эчем, эчем...

Зәйтүнә шәфкать туташыннан шприцны алды да, бармакларын Рәзиләнең нечкә беләзеге буйлап шудырды. Бармак битләре белән тиресен үтәли күргәндәй булды, корыч энә әйтерсең лә бармакларының дәвамына әверелде, тамырга бик җиңел керде.

Иренең теләге кабул булды, Рәзилә бияләй хәтле генә диярлек бәби тапты. Ир бала.

— Ник еламый ул, ник еламый? — дип үрсәләнде Рәзилә.

Бәби тереклек иясенең иң йомшак чагында — шытымның үсентегә, бөренең чәчәккә әверелгән чорында иде. Инде тырыша торгач, җан керткәннәр иде аңа, сабыйлар бүлегенә илтергә дип күтәргәч, тагын сулышы сизелми башлады. Зәйтүнә аның юка тире белән өртелгән нәни күкрәгенә учын куеп, маска белән каплаган авызын иреннәренә терәде. Ясалма сулыш биреп, йөрәгенә массаж ясау озак дәвам иткәндәй тоелды. Ниһаять, баланың йөрәк тибеше янә сизелә башлады.

Ул урамга чыкканда, җиргә эңгер-меңгер иңгән иде инде. Зәйтүнә бөтен арганнарын онытып, ашыгып кайтып керде, бусагадан атлауга, Әнвәргә бүгенге хәлләр турында сөйләргә дип авызын ачкан иде, аның каралган йөзен күргәч, сүзләре тамак төбенә утырып калды.

Шунда гына исенә төште Зәйтүнәнең: алар театрга соңга калганнар иде.

Бу көнне алар беренче тапкыр сүзгә килделәр. «Син үзеңнең кемлегеңне бөтенләй онытып җибәрәсең кайчакта,— диде Әнвәр каты итеп.— Өйдә синең ирең көтеп тора, йортың бар, җил куып кына яшәп булмый ул!» Зәйтүнә бүген бер кешегә тормыш биргәнен, орлыкның — шытымга, бөренең чәчәккә әверелергә ярдәм иткәнен әйтергә теләгән иде. «Больницада син генә түгел, башка врачлар да бар»,— диде Әнвәр. Зәйтүнә үз эше белән мавыгып Әнвәрнең дә теплицалардан кайта алмый ятуын искә төшерде. «Семьяда берәү эше белән мавыкса бик җиткән,— диде Әнвәр.— Миңа нәкъ үзем төсле кеше кирәкми. Хатын кирәк миңа! Әгәр юньле итеп яшисең килә икән, җайлырак эшкә күч!»

Кыскасы, бик каты үпкәләштеләр алар. Зәйтүнә беренче тапкыр сүзләренең ире күңеленә барып җитмәвен, барып җиткән кадәресенең дә ачу, нәфрәт кенә кузгатканын күреп, аптырады, рәнҗеде, курыкты.

Иртәгесен ял көне иде. Әмма Әнвәр дәшми-тынмый киенде дә чәй дә эчми чыгып китте.

Борчулы чакларында күңелен тынычландыра торган бер чарасы бар иде Зәйтүнәнең — ул да булса кул эше. Бу шөгыль врач өчен бик тә кирәк — чигү-тегү бармакларның ныклыгын, сизгерлеген арттыра. Зәйтүнә бәби өчен күлмәк-башлыклар чигәргә утырды. Кызыл төс — кыз балага, зәңгәр төс — ир балага, диләр. Нинди җеп сайларга икән Зәйтүнәгә? Кемне алыр икән ул кулларына? Зәйтүнә җайлап утырды да күзләрен йомды, булачак сабыен күз алдына китерергә тырышты. Кинәт аның бөтен тәненә ләззәтле дулкын йөгерде, ул карынындагы бала тибенгәнен тойды.

Без барыбыз да кайчан да булса дөньядан китәчәкбез һәм моны белеп яшибез. Ләкин кешенең гомерендә үзен мәңгелек итеп хис кылган минутлар да була. Сөйгәне белән кавышканда һәм карынында бала тибенгәндә үзен мәңгелек дип хис итә адәм баласы. Мәңге яңарып, мәңге яшәреп торган табигать нәкъ менә шушындый минутларда безнең рухыбызда үзен аеруча нык сиздерәдер, ахрысы.

...Күпмедер шулай онытылып торганнан соң, Зәйтүнә кемнеңдер карашын тойгандай булып, кинәт айнып китте. Сискәнеп күзләрен ачты һәм стенада эленеп торган кыз рәсемен күрде. Җан иңгән диярсең, томрап карап тора...

Зәйтүнәнең әнисе Гөлзәйнәп өйдә эленеп торган ике рәсем турында бик кызык кына сүзләр әйткән иде.

— Кара кайгыга баткан бу шакмак гәүдәле хатын,— диде ул мадам Жаклинны күргәч.— Тәнең агач булып, иреңә хаҗәтең калмаса, нибуч каралыр чыраең!

— Нишләп алай дисең, әни? Нишләп иренә хаҗәте калмасын аның?

— Ир кеше ясаган моны, хатын-кыз болай сурәтли алмый. Һәм белеп ясаган, яратмыйча, үчләнеп ясаган. Ярык балта сабы шикелле, үзен утларга атардай булган бу, бичара!

Аннары гәрәбәле кыз каршына килеп басты да:

— Гөлҗиһан сабыннарының тышына ясый торганнар иде мондый киленнәрне,— диде.— Эштән арып кайткан иренә сабын-сөлге биргәндә шушылай елмая торганнар иде безнең заманның яшь киленнәре... Бер елмаю белән дөньяны яктырта беләләр иде шул!

Гөлҗиһан... Бу исем Зәйтүнәнең хәтерендә балачак истәлекләрен уятты.

— Әни, хәтерлисеңме, син миңа җиде айдан туган ир бала турында сөйли торган идең. Аның да әнисен Гөлҗиһан дия идең... Бик борынгы кыйсса, ди торган идең. Ул чакта ук Гөлҗиһан дигән исем булды микәнни?

— Гөлҗиһан иде инде, Гөлҗиһан. Югары оч Шакир кавеменнән...

— Ничек инде югары оч булсын... Кайсы югары оч...

— Соң, аның малае Җантимерне мин үзем белә идем бит әле? Анасы Гөлҗиһан булган. Шундый баһадир адәм иде, ул, мин сиңа әйтим, печән җыйганда кибән башларыннан җырлап җибәрсә, әллә кайларга ишетелә иде. Урманда җиләк җыйганда адашсак, аның тавышыннан болын ягын чамалый торган идек. Минем әби әйтә торган иде, шул Җантимер җиде айлык булып туды, үзем кабул итеп алдым, тун җиңенә тыгып куйдым, ди торган иде. Җиде улы, бер кызы үсте шул Җантимер абзыйның, сигезен дә аерата безнең әби ярата иде, урамда күргән саен башларыннан сыйпап үтә иде. Җиде егет бер йорттан сугышка киттеләр. Икесе әле дә исән.

— Ә син миңа әкият итеп сөйләгән идең,— диде Зәйтүнә чак кына үпкәләгән сыман итеп.

— Соң андый хәл борынгыда да булып торган инде ул. Минем үземә аны әби сөйләгән, аңа да әбисе сөйләгән. Шул Җантимер абзый

хакында, экияттәгедәй булды бу хәл, ди торган иде үзе дә. Бөтен хикмәт тун җиңендә. Җитлекми туса, баланы тун җиңендә генә тотарга кирәк. Сез белеп бетермисез әле борынгы гыйлемлекләрне. Менә бер заман берәр галим тун җиңенең сабыйга шифасы турында китап язар да, бала тудыру йортларында гел шуны файдалана башларсыз әле...

Юк, хикмәт тун җиңендә генә түгел. Хикмәт Гөлҗиһанда, аның мәңгелек булуында.

Күрәсең, рәссам бу хакыйкатьне аңлаган. Әнә ничек тасвирлаган бит ул яшь хатынны. Иңенә шуып төшкән яулыкны тотарга дип күтәрелгән кулы ярты юлда туктап алга сузылган. Өзелеп сөйгән ярына каршы атлаган назлы хатын бу!

Кинәт Зәйтүнәнең күңелен бер уй көйдереп узды: аның беркайчан да Әнвәргә болай елмайганы, аңа таба бөтен барлыгы белән талпынып болай атлаганы юк бит әле! Дөрес, ул ирен ярата, аның белән бергә чакта үзен тыныч, рәхәт хис итә. Әмма Гөлҗиһандагыча балку, андагыча ялкын аларның мөнәсәбәтен моңарчы яктыртканы, җылытканы юк бит әле.

Әнвәрнең кичәге сүзләре төбендә, аның күз карашында ниндидер Зәйтүнәгә аңлашылмас эчке бер мәгънә бар иде шикелле. Хәзер бу мәгънә кинәт ачылды. Театрга соңга калган өчен генә түгел иде Әнвәрнең үпкәләве. Аның төбендә, мөгаен, башка нәрсә ята...

*

* *

Стенадагы рәсемдә ана сабыена элеккечә, чиксез наз белән текәлгән иде. Бүлмәгә кергәч, Диләрам аңа карамаска тырышты, Ильясова каршына килеп, урындыкка җайсыз итеп, яны белән утырды.

Операцияне җиңел кичерде Диләрам, тиз терелде. Инде хәзер аңа өенә кайтып китсә дә була, алты-җиде айдан килер, яңадан операция ясарлар.

Шулай диде Җәмилә Закировна Диләрамга. Бары тик Дәүләтшинның кирәксезгә ясаган ярасы турында гына дәшми калды. Ә ул яра булачак операцияне шактый катлауландырырга мөмкин...

— Иң мөһиме,— син борчулы уйлар уйламаска тырыш, үзеңне саусәламәт, гамьсез бер кыз дип хис ит. Миңа хат язып тор.

Беркатлы син, эчеңдәге тышыңда, ди Ләйлә әнисенә. Әмма авырулар янында хисләрен бик яшерә белә Җәмилә Закировна. Авыру кеше врачның йөзендәге, күзендәге һәр үзгәрешне дүрт күз белән күзәтеп тора, аз гына борчылу сизсә дә бик зур шиккә төшә. Врач — күпмедер дәрәҗәдә артист та була белергә тиеш. Җәмилә Закировна Диләрамга бик шат һәм канәгать кыяфәттә карап утыра иде.

— Их, Җәмилә Закировна, ничек борчылмыйсың. Тагын операциягә керәсе исемә төшкән саен, Изаил Харисович күз алдыма килә дә җаннарым өшеп китә. Әллә ничек караңгы чырайлы булып күренде ул миңа, артык кырыс булып тоелды.

— Сиңа бу операцияне ясамый булмый иде, Диләрам. Доцент дөрес эшләде.

— Ике айдан туй буласы иде, монда отпускыга дип кенә килгән кеше бит мин. Ни йөзем белән күренермен инде хәзер аның күзенә, ни әйтермен?!

Диләрам, чигүле түбәтәен салып, тиз генә күз яшен сөртеп алды.

Аны ничек кирәк алай юатып озатты Җәмилә Закировна, әмма үз күңелендәге шомны таратып бетерә алмады. Әгәр авыру кеше врачка — кара эчле булып, врач авыруга кара чырайлы булып күренә икән, дәвалаудан өмет көтмә. Үзе ышанган врачта дәвалану гына шифа бирә кешегә.

Кабинетка кешеләр кереп-чыгып тордылар, профессор аларга киңәшен бирде, авыруларны карарга вәгъдә итте, иртәгесе көнгә операция билгеләде, ләкин күңел түреннән һаман да Диләрамның чык кунган йөзем җимеше төсле күзләре китмәде.

Нишләргә?

Диләрамны икенче тапкырында Дәүләтшинга алып барырга ярамый. Башка кешегә дә кушып булмый, чөнки Казанда андый операцияләр ясаучы бүтән кеше бөтенләй юк. Хәер, булса да, Җәмилә Закировна Диләрамны башка берәүгә ышанып тапшыра алмас иде. Ул аны дәвалауны үз кулына алды бит инде, операция вакытында ук бөтенесен үзенчә хәл итте, хирургның ассистенты булды...

Ялгызы гына калган арада, ул телефонны алып, Мәскәүне, аналар һәм балалар сәламәтлеген саклау институтын сорады. Мондый операцияләрне анда да ясыйлар, профессор Ильясовага белемен үстерергә шунда барырга кирәк булачак.

Яңа төр операцияләрне үзләштерү — тиз генә эшләнми. Диләрам әйләнеп килгәнче, алты-җиде ай эчендә, бик күп әдәбият укырга, анатомия кафедрасына йөрергә һәм, әлбәттә, доцент Дәүләтшинның операцияләрен карап торырга да кирәк булачак. Әйе-әйе, остаз үзенең шәкертеннән сабак алыр, әгәр бу нәрсә авыруны терелтер өчен кирәк икән, мин-минлек белән санашып торып булмый.

Боларны уйлагач, авыр сулап куйды Җәмилә Закировна. Аның күп еллардан бирле эшләп килгән фәнни өлкәсе бар, ул авыруларны башланган чорында ук ачыклау һәм дәвалау юнәлешендә эшли. Нигездә шушы юнәлештән тайчанмаска тырыша, башка мөһим темалар белән шәкертләрен кызыксындырырга һәм мавыктырырга омтыла.

Яшьрәк чагында аңа төрле темаларга тотынырга туры килде, чөнки фәнни эшләрне ул үзе сайлап алмады, эше сайларга мәҗбүр итте. Гомумән, фән юлына Җәмиләне авырулар этәреп кертте, диярга була.

Хәтерендә: тудыру йортында ул дежур торган бер төндә, носилкага салып, яшь хатынны китерделәр. Аңа күз салуга Җәмилә куркынып китте: хатынның йөзе күгәреп чыккан, сулышы әллә каян ишетелеп тора иде. Ул күзләрен көчкә ачып, өзек-өзек:

— Доктор...— диде.— Баланы... баланы... коткарыгыз. Әгәр ул исән булмаса, барыбер... яшәү юк миңа...

Хатынның тулгагы башланган, ә үзенең керфеген күтәрерлек тә хәле юк иде. Мондый очракларда врач беренче чиратта хатынның үзен коткарып калу чарасын күрергә тиеш. Баланы корбан итү бәрабәренә булса да... Медицина кагыйдәләре шулай куша.

Ләкин бу хатын яңадан күзен ачкач, «балаң юк инде»,— дип ни йөзе белән әйтер аңа Җәмилә, күзенә ничек карар? Бу сүзләр ул хатынны һәлак итү булмасмы?

Өендә ике сабые көтеп утыра иде Җәмиләнең, бала югалтуның нинди ачы хәсрәт икәнен фараз итеп кенә булса да күз алдына китерә ала иде ул. Юк, баланы һәлак итәргә кулы бармады аның. Ләкин нишләргә соң?

Хәзерге кебек, телефоннан шалтыратып кына берәр профессорны чакыртып китереп булмый. Һәркем үз җилкәсенә төшкән авырлыкны үзе күтәргән чак — сугыш вакыты иде бу. Җәмиләнең ире Мөбарәк фронтта иде, бу хатынның да ире, мөгаен, шунда булгандыр. Хатынын һәм туачак баласын явыз дошманнан саклап, ут эчләренә кергәндер ул, ә монда алар врачның көчсезлеге аркасында һәлак булсыннармыни?

Булырга тиеш аларны коткару чарасы, булырга тиеш! Һәм Җәмилә тәвәккәлләде, мондый очракларда әлегә кадәр кулланылмаган чараны кулланды. Бу даруны башка максатларда кулланганы бар иде инде, зыян китермәсенә ышанып эшләде ул моны.

Бер укол — бары бер укол! — ясарга кирәк булды, калганына акушерка белән иксе ярдәм иттеләр, һәм бала исән-сау туды.

Иртәгесен күзен ачкач, яшь хатын иң беренче сүз итеп сабыен сорады. Җәмилә аңа баланы үзе алып кереп күрсәтте. Хатын аның тыныч мыслаган борынына, йомык күзләренә, йокы аралаш имгәндәй мимылдаган авызына карады да елмаеп җибәрде. Һәм шул карашын Җәмиләгә күчерде.

Ул хатынның төсен-кыяфәтен үткән еллар, аккан сулар күптән инде хәтердән юып алып киттеләр. Ләкин теге чактагы елмаюы күңел түрендә һаман саклана. Яңа ачылган гөл чәчәгенең сафлыгы, чисталыгы, матурлыгы, яшәү тантанасы һәм чиксез бәхет бар иде ул караштa.

Мондый елмаю яңа туган сабыена караган һәр ананың йөзендә балкый, һәм,, шул карашның үзенә дә сирпелгәнен тойган саен, Җәмилә Закировнаның күңеленә куаныч дулкыны бәреп керә. Бу караш аның өчен иң зур рәхмәт сүзләреннән, иң олы бүләкләрдән дә кадерлерәк.

Ә теге хатынның кызы туган иде. Кайларда, нечекләр яши икән хәзер? Кырыкка җитеп килә торгандыр, үзенең балалары үсеп җиткәндер инде. Үзенең бу дөньяга исән-сау тууы белән яшь врач Җәмиләне фән юлына этәргәнен белә микән ул?

Каян белсен! Ул төндә Җәмилә үзе дә моны башына китермәгән иде әле. Авыр хәлдәге хатыннар бала тудыру йортына килгәләп торды, Җәмилә ул чараны тагын да кулланмый булдыра алмады. Ул даруны кайчан, күпме микъдарда кулланырга икәнлеген ачыкларга кирәк иде. Җәмилә әлеге дару хакында китап-журналларда булган бар мәгълүматны белергә, аның кеше организмына йогынтысын җентекләп өйрәнергә, клиник күзәтүләр алып барырга тиеш булды.

Бу — зур проблеманы ачуга әйләнде, соңыннан аның докторлык диссертациясенә нигез булып ятты.

Хәзерге вакытта бу чараны куллануның төпле методикасы эшләнгән, ул «профессор Ильясова методы» дип атала һәм күп кенә больницаларда, клиникаларда кулланыла.

Профессор Ильясованың медицина әдәбиятына кергән тагын берничә методы һәм ысулы бар. Алары да үлем чигенә килеп җиткән хатыннарга ярдәм итү теләгеннән тудылар. Аналар, сабыйларына карап, яңа ачылган гөл чәчәге кебек елмайсын өчен булдырылды ул чаралар.

Кинчкә таба Җәмилә Закировна кызына шалтыратты.

— Эштән туры безгә кайт әле, Ләйлүк.

Ә үзе, юл уңаенда китапханәгә кереп, ике кулына ике төргәк китап күтәреп кайтып керде. Берсен ишек ачкан Ләйләгә сузды:

— Болары сиңа, кызым. Мин билгеләгән урыннарын тәрҗемә итеп бирерсең.

— Нигә бу чаклы күп соң болар, әни?

— Яңадан сабакка утырам мин, кызым. Үзең беләсең бит инде, безнең эштә ансыз мөмкин түгел, врачның наданлыгы кеше үтерә. Әйдәле, минем яңа курс башлавымны бәйрәм итеп, өчпочмак пешерик.

Әниләре белән бергәләп пешерену Ләйлә белән Равил өчен һәрчак күңелле бәйрәм була иде. Кызганычка каршы, балалар кечкенә вакытта андый бәйрәмнәр еш эләкмәде: иркенәеп эшкә тотынгач кына, алгы бүлмә стенасына элеп куелган кара телефон сискәндереп зыңгылдый, әниләре, камыр баскан янсә ит тураган җиреннән аерылып, ашыгып кулын юарга керешә, аннары кабаланып киенгән арада балаларга нәрсә эшләргә икәнен өйрәтә иде.

Хәзер инде профессор Ильясованы еш борчымыйлар — шәкертләре үсеп, остарып җитте, әмма өйдә бергәләшеп пешеренүләр барыбер сирәк эләгә — Ләйләнең дә, Равилнең дә үз тормышы, үз гаиләсе. Бу-

генге табын янында кызлары булу Мөбарәк Таһирович белән Җәмилә Закировна өчен күңелле вакыйга иде. Эштәге борчулар турында күп сөйләшмәскә тырыштылар. Мөбарәк Таһирович — танылган галим, хатыны әйтмешли, «яшь-җилкенчәкләр кизүе эләктергән» — «Жигули» машинасы сатып алган, хәзер машина йөртергә өйрәтү курсларына йөри.

— Укырга керде әтиең, «өчле»ләр алып кайта,— диде Җәмилә Закировна.

— Мин гаепле түгел, юл кагыйдәләре гаепле,— диде Мөбарәк Таһирович аларның үз итеп көлемсерәүләренә.— Юл тамгалары югарыга эленгән, ә аста — юлда кешеләр йөри. Кайсына карарга тиеш соң мин? Аска да, өскә дә берьюлы карап булмый бит!

— Шофер булу — галим булу гына түгел ул сиңа!

Табынны җыеп алгач, Җәмилә Закировна иске кара пианиноны ачты да әйләнмәле утыргычка утырды. Лагы тоныкланган бу пианино Ләйлә өчен туган йортның ямьле бер бизәге булып күренә, балачак истәлекләрен саклый иде.

Җәмилә Закировнаның йомшак һәм сизгер бармаклары клавишлар буйлап сак кына йөгереп узды. Бик күп музыкантларны тыңлаганы бар Ләйләнең, әмма әнисен тыңлагандагы шикелле хисләнгәне бик сирәк. Музыка коралында уйнау бармакларның хәрәкәтчәнлеген, төгәллеген арттыра, ди әнисе. Шуны исәпләп, үзлегеннән уйнарга өйрәнгән ул, һәм эше бик тыгыз чакларда да, азга гына булса да, пианино янына утырып уйнап алырга һәрвакыт өлгерә иде.

Ләйләдә ул нәни чактан ук халык җырларына мәхәббәт уятты.

Менә хәзер дә Җәмилә Закировна таныш җыр башлады:

Кара да гынай урман,
Карангы төн,
Яхшы атлар кирәк лә узарга...

Еллар үткән саен, Ләйләнең әнисенә соклануы арта бара. Каян килгән аңа мондый олы күңел, ихтыяр көче, талант? Гади семьяда үскән кыз бит ул. Ләйләнең әбисе яза да белмәгән, бабасы үзлегеннән генә укырга өйрәнгән. Алар борынгыча яшәгәннәр, борынгыча туй иткәннәр: кәләш үзенең киявен зөфаф кичендә беренче тапкыр күргән. Әмма тату гомер иткәннәр, биш бала үстергәннәр.

Җәмилә — уртанчысы. Каян килгән аңа мондый моң, музыка мәктәпләрендә укып та өйрәнеп булмый торган борылышлар, хисләләр?

Борынгыдан, каяндыр бик ерактан, әби-бабалардан күчкән моңхисләрдер бу. Җәмилә күңелендә алардан күчкән байлык, алардан күчкән талант яши. Тик элекке буыннарда ачыла гына алмаган ул, бары тик Җәмиләдә булган рух байлыгына тулысынча ачылырга мөмкинлек булган.

Соңгы елларда Җәмилә Закировнаның уенында һәм җырларында ямансулык көчәя барган шикелле тоелды Ләйләгә. Кызын озата чыккач та ул ничектер ямансу елмайды:

— Нигәдер вакыт-вакыт күңелем тынычсызлана минем, Ләйлүк. Тормышым шулкадәр түгәрәк, менә бу ягы үзгәрсен иде, дип теләрлек тә түгел. Ә тормыш үзгәрешсез булмый бит. Бер-бер хәл булыр дип куркам.— Ул боларны елмаеп әйтте, ямансулавы да бәхет аралаш, җиңелчә иде аның.

Ләйләгә әнисе кичерәеп киткәндәй тоелды. Кайчан гына әле ул, әнисенең итәгенә сарылып, юату яки наз көтеп, күзләренә карый иде. Хәзер менә әнисе аннан күңел тынычландырырлык сүзләр көтә. Ләйлә аны иңнәреннән кочты.

— Әни, без әле бик озак, бик күп еллар нәкъ менә шушылай яшәрбез. Болай гына түгел, куанычлар күп булыр әле безнең. Синең яңадан сабакка утыруың, яңа эшкә тотынуың да юкка түгелдер бит?

Җәмилә Закировна башын күтәреп, кызы белән тигезләнергә теләгәндәй, тураебрак басты.

Икенче бүлек

«Уникенче июньдә 425 рейс белән Сургуттан очам, Лариса»,— диелгән иде телеграммада. Каршы алыгыз, димәгән, ләкин анысы сүзсез дә аңлашыла иде.

Кышын килгән хатларының соңгысында ул: «Җәй башында Казанга кайтам, гостиницада урын алып куя алмассызмы?» — дип сораган иде. Зәйтүнә: «Кил, үзебездә торырсың»,— дип язып җибәрде.

Инде менә каршы алырга да кирәк икән. Җайсызрак чакта килә килүен. Яшь бала, Гөлзәйнәп карчык, үзләре икәү — бер бүлмәле квартирда кысанрак булачак инде.

— Күңелең киң булсын! — диде бу хәлләрне белгәч, картайган йөзендә яшь, нурлы күзләрен балкытып Гөлзәйнәп карчык.

Багажны бирми торганнармы, машина таба алмаганнармы,— Лариса белән Әнвәр аэропорттан төнге бердә генә кайтып керделәр.

Дөньяга җитлегеп туган, сәламәт Тимербулат нииндидер билгесез сәбәптән сыны катып елый, бер тотынса, сәгатьләр буе туктый алмый иде. Бала күтәреп, ишекле-түрле Зәйтүнә йөрөнә; аның артыннан, нишләргә белми, әнисе йөргән.

Ниһаять, бала тынып, ана белән кыз хәлдән таеп, кайсы кая хәл алырга дип ятканнар гына иде, тышкы ишекнең ачылып ябылганы, гаҗәп көр, дулкынланган тавыш белән сөйләшкән авазлар ишетелде, кыңгырау шалтырады.

Лариса ишектән төньякның тыннарны куыра торган салкын, саф җиле кебек ургылып килеп керде. Килеп тә керде, Зәйтүнәне кочагына бөтереп тә алды, иреннәреннән суырып та үпте.

Зәйтүнә кухня ягында чәй яңарткан арада, кунак, ваннага кереп, су шыбырдатырга кереште, табын әзер булуга, кызарынып, кайнарланып килеп тә чыкты. Аның өстендә йөнтәс тукымадан тегелгән буйлы халат, киң җиңе эченнән куллары терсәккә кадәр чыгып тора, озын билбау гәүдәсенең сылулыгын күрсәтә иде. Ул артсыз урындыкка утырганда, итәге ачылып, ак, тыгыз ботлары ялтырап куйды. Лариса аларны капламады. Ул инде җирән бөдрәләрен юеш килеш тәртипкә салган, калку яшькелт күзләре сөенеч, тынгысызлык бөркиләр иде.

Зәйтүнә берничә тапкыр бүлмәдә әби белән бәби йоклаганын әйтеп караса да, Лариса вакыт-вакыт дөньясын онытып кычкырып сөйләшә башлый. Моңа табын уртасына утырган шәраб та сәбәп булды. Лариса берәр рюмка эчәргә Зәйтүнәне дә кыстый башлады, аның бала имезгәнен белгәч:

— Ништяк! — дип кычкырып җибәрде. Бу — аның төньяктан өйрәнеп кайткан яңа сүзе иде.— Һаман имезәсеңмени әле? Җиде айлык дисеңме? Бу заманда кем инде баланы шул хәтле имезә? Аер син аны, Зюзю! Замана баласына кибет сөте ярамаган тагын! Үзеңне сакла! Ирләр алар таза-сәламәт хатыннарны ярата, бөтен сүлен баласына биреп, үзе корып калганнарны түгел!

Үзе шундый шаярып та, үртәп тә, якын итеп тә карый Әнвәргә, һич кенә дә ачуланырлык түгел! Чыннан да үзенекен итте бит, кыстый торгач, Зәйтүнәгә бер рюмка шәраб эчерде. Һәм шунда ук Зәйтүнәне йокы басты.

Ларисаның исә күзләре торган саен киңрәк ачыла, очкынлана барды, ул иркенәеп, табынны үзенчә көйләргә кереште. Ак күмәчне юка телемнәргә турап, аңа май ягып, өстенә төче торма телемнәре, яшел суган салды да, «фирменный бутерброд» дип, өстәл аша Әнвәргә сузды. Әнвәр аның тырпаеп торган, кызыл тырнаклы чәнти бармагына карап сәер елмайган иде. Аларның икесе арасында күзгә күренмәс җеп сузылгандай булды, йокымсырап утырган Зәйтүнә артык һәм чит тоела башлады.

Лариса юлда кичергәннәрен кызык итеп сөйләде. Ничек Свердловскида озак торганын, каршы алмаслар дип борчылганын, аннары Әнвәр белән аймылыш булганнарын кат-кат кабатлады.

— Инде китәм дип аэропорттан чыккач, кире кердем дә таныдым бит мин моны! Чәчен кыскартып кискәнгәдер инде, караңгыда гел бүтән булып күренгән! Минем күңел төшкән иде инде. Ништяк, мин әйтәм, дуслар онытк‌ан мине! Шуннан соң күреп алгач, сөенечемнән нишләгәнемне белмәдем. Бер заман исемә килсәм, мин моның муенында асылынып торам. Син, Зюзю, ачуланма, гөнаһ дип уйлама, ялгыш кына килеп чыкты бу. Минем кебек ел буе сөргендә булсаң, хәлемне аңлар идең...

Зәйтүнә кинәт бастырыла башлагандай сискәнеп куйды, урыныннан торып, бүлмәгә чыкты, җәелмәле ятакка урын әзерләргә кереште.

Ә кухняда Лариса аның саен җанланып сөйли иде:

— Бишенче буын интеллигент бит мин. Зюзю сиңа сөйләгәндер инде.— «Кайчан һәм ник сөйләргә тиеш идем икән мин ул хакта иремә?» — дип уйлады Зәйтүнә.— Безнең нәсел борын-борыннан зур калаларда гомер сөргән. Урбанист каны ага миндә.

— Кан калага тарта, димәк,— Әнвәрнең тавышында көлемсерәү сизелә, әмма бу яратып, үз итеп көлемсерәү иде.

— Кан үзенекен итә ул, аны бернишләтеп булмый!

— Ә Хөсәеннең каны ничек соң?

— Анда саф татар каны. Татар ул борын-борыннан кайда тели, шунда яши. Кайда әҗәл күренсә, аны шунда тарталар. Доктор Нигъмәтуллинның даны анда төньяк балкышыннан яктырак яна.

— Нигә бергә кайтмадыгыз соң? Ял итеп китәр иде,— диде Зәйтүнә алар янына кереп һәм пышылдап кына. Ул ничек тә булса Ларисаны әкренрәк сөйләштерергә тырыша иде. Баланы уята күрмәсен тагын!

— Әүлия ялга чыгамыни! Әүлиягә отпуск юк аңа. Акыллы башлар җәй житү белән көньякка, диңгез буена кача, әүлияләр алар салган камытны киеп төньякта кала. Доктор Нигъмәтуллин хасталарын ташлап китәме соң?

— Синдә дә дәвалнучы кешеләр бардыр бит? — дип сорады Зәйтүнә сак кына.

— Бер семьяга ике әүлия күбрәккә китмәсме? Хөсәен җыйган савап икебезгә дә җитәр әле. Дурак ул! Әллә кемнәрнең ирләрен-хатыннарын күз-колаксыз калдыра алмый, ә менә үз хатынын ялгыз җибәрә ала! Анысына вөҗданы каршы килми! — дип ул, хуплауны көтеп, Әнвәргә текәлде.

...Ул килгәч, өйдә тормыш шау-шулырак, ыгы-зыгылырак булып китте. Лариса бүләк иткән уенчыклар белән идән тулды, ул тараткан хуш истән баш әйләнде. Иртән ванна бүлмәсеннән прическа ясап, иннек сөртеп, ак мех белән бизәлгән йомшак башмакларын киеп чыга, «А-а, батыр!» — дип, Тимербулатны күтәреп ала. «Яхшы йокладыңмы, апа!» — дип, Гөлзәйнәп карчыкның хәлен белешә, аны тыңлап та бетермичә, кухняга кереп, савыт-саба шалтырата башлый. Аның артыннан бала — гүләп, карчык елмаеп кала.

Кич Зәйтүнә кайтуга өйдә ят ризыклар пешкән була: я кузгалак ашы, я гөмбә белән бәрәңге. «Аша, апа, аша, урман җимеше, гөнаһы юк»,— дип, ул гомере буе гөмбә капмаган Гөлзәйнәпне дә кыстап ашата алды.

Вазадан — чәчәкләр, шкафтан коньяк өзелмәс булды.

Табын әзерләгәч, Лариса белән Әнвәр шкаф янында мыштым гына берәр рюмка эчеп куялар, аннары гына карчыкны ашарга чакыралар. Ә кайчакта берәр рюмка гына җитеп бетми, берәмләп бүлмәгә чыгып керергә туры килә, бу кыска сәяхәттән соң Ларисаның тавышы тагы да көрәя, авызы ерыла. Беркатлы карчык бернichә көннән генә: «Синең бу кунагың әллә төшергәләп тә ала инде?» — дип куйды.

Башкаларга гафу ителмәслек кимчелек — кызмача булу да Ларисага килешеп тора, хәтта шул хәлендә дә ул күңелне кайтармый иде.

Ә бер кичне ул әби белән бәбине урамга чыгарып җибәрде.

— Свежий һава кирәк, апа! Олыга да, кечегә дә кирәк!

— Фу, кулларың,— диде Зәйтүнәгә алар чыгып киткәч.— Фермада эшлисеңмени! Син врач һәм зур кеше хатыны. Чәчеңә прическа ясалган, тырнак төпләрең тазартылган булсын! Яле, утыр!

Ул бала әйберләрен юарга дип ванна бүлмәсенә юнәлгән Зәйтүнәнең кулыннан эләктереп алды да өстәл янына утыртты.

— Син менә хәзер киенеп-ясанып куй да, иреңне биеп, көлеп каршы ал. Тамагын туйдыр. Шуннан соң ул ничек итеп ванна бүлмәсенә кереп киткәнен, ничек итеп бала әйберләрен юып атканын сизми дә калыр!

Ул кухнядан җамаяк белән кайнар су алып чыкты да, кер порошогы салып, Зәйтүнәнең бармакларын батырды. Чемоданнан күн савыт алып ачты. Анда кызыл бәрхет өстендә ялтырап тырнак чистарту өчен кирәк-ярак ята иде. Алар Әнвәрнең сызым әсбапларын искә төшерделәр.

— Синең белән бер мәсьәлә турында киңәшәсе бар иде бит әле, Зюзю. Беләсеңме, мин китмәскә кайттым бит.

— Ничек китмәскә?

— Кафедрага урнашасы иде. Мин зур гына фәнни эш башладым. Бик актуаль темага.

Зәйтүнәгә бу гаҗәп тоелды. Институтта чакта Лариса фәнни эш белән бөтенләй кызыксынмый торган иде.

— Шул арадамы? — дип сорады Зәйтүнә.

— Ну, андагы мөмкинлекләрне моннан торып күз алдына китереп тә булмый. Анда конкуренция юк. Мондагы шикелле, нишлим икән, нәрсә белән шаккаттырыйм икән, дип баш ватасы түгел.— Шушы рәвешле һич көтмәгәндә чәнчеп куя торган гадәте бар Ларисаның. Зәйтүнә аның бу сүзен үткәреп җибәрергә булды.

— Миңа хәзер тәҗрибәле галим кул астында эшне төгәлләп куярга гына калды. Абруйлы җитәкче кирәк. Үзең беләсең, хәзерге заманда күкрәге белән алдан юл ярып барыр кешең булмаса, әҗәлдән дару уйлап чыгарсаң да, бар дип тә белмәячәкләр. Ачыш ясаганыңны зур кеше авызыннан әйттерү мөһим.

— Нинди тема соң ул? — Зәйтүнәнең күңелендә көнләшү тойгысы уянды. Ул үзе студент чагыннан бирле бер заводта һавага бүленеп чыга торган матдәләрнең хатын-кыз организмына тәэсирен өйрәнүдә катнаша. Ләкин мөстәкыйль эш белән үзен күрсәтә алганы юк әле.

— Токсикозларны өйрәнәм мин,— диде Лариса Зәйтүнәнең сул кулын җамаяктан алып, йомшак сөлге белән сөрткәндә.— Токсикозларның көчен кан составына карап билгеләү методы.

— Нинди токсикозлар?

— Соңгы токсикозлар. Канда аларның билгеләре бик иртә беленә.

Зәйтүнәнең сыны турайды. Ул, бала тудыру йортында күптән эшләгән кеше, бу мәсьәләнең мөһимлеген бик яхшы белә иде. Элек-электән бала тапканда һәлак булган хатыннарның үлеменә нәкъ менә шул соңгы токсикозлар сәбәп булган да инде. Дөрес, хәзерге вакытта үлемгә үк җиткермиләр, андый очрак бик сирәк була, шулай да токсикозларны вакытында дәвалау мөмкинлеге ачылса, күп бәхетсезлекләр булдырмый калыныр иде.

— Миндә материал җитәрлек,— диде Лариса гади генә итеп.— Йөзләрчә авыру тарихлары. Барысының каннары даими тикшереп торылган, нәтиҗәләре җентекләп язылган.

— Бер ел эчендә йөзләрчә токсикоз күзәттеңме?

— Кызык син, Зюзю. Беләсең бит инде, фәнни нәтиҗәләрне галимнәр үзләре күзәткәннән генә китереп чыгармыйлар. Утыз ел эшләгән бер гинеколог белән дуслаштым мин анда. Хәзер ул пенсиягә чыкты да Белгородка китеп барды. Җыйган материалларын миңа биреп калдырды. Болай алар барыбер файдасыз юкка чыгачак, мин үзем фәнни эшләр белән шөгыльләнергә соңардым инде, ди. Син яшь әле, очлап чыгарсың, кешеләргә файдасы тияр, бәлки, ди. Посылка белән салдым мин аларны монда. Сигез килодан артык булды, почтада алмыйбыз дип карышып маташтылар. Миңа хәзер бер галим ярдәмендә аларны эшкәртеп, гыйльми хезмәт рәвешенә китерергә генә кирәк... Зюзю, сезнең клиникага урнашып булмас микән? Белеш әле, ә? — Лариса аңа күтәрелеп, ялварып карады.

— Ә эшеңнән җибәрәләрме соң?

— Җибәрерләр! Мин үземнең гражданлык бурычымны үтәдем дип саныйм. Һәрберегез берәр ел шунда барып эшләп карагыз әле!

Зәйтүнә монысын да күңеленә якын алмаска тырышты.

— Ә Хөсәен?

— Ул декабрист түгел, мин декабрист хатыны түгел. Яратуы хак булса, үзе минем арттан кайтсын.

Зәйтүнә Ларисаның җирән бөдрәле йомры башына карады. Моңарчы ул дустының җорлыгын, уңганлыгын, пөхтәлеген генә күрә иде, хәзер менә яңа яклары белән ачылып киткәндәй булды. Беренче карашка таулар да шулай карлы түбәләре белән яктырып, күңелне ымсындырып, ялтырап тора, якынрак килгәч кенә алар арасындагы упкыннарны күрәсең. Ниләр ята икән Ларисаның күңел упкыннарында? Эремәс бозлармы? Салкын таш өемнәреме?

— Балагыз да булмаган икән,— дип куйды Зәйтүнә.

— Болай икеле-микеле яшәп ятканда ничек бала булдырасың!

— Бала дөньяны бөтенләй үзгәртә бит ул. Беләсеңме, Лариса, Тимербулат туганнан бирле мин киләчәк турында бик борчылып уйлый башладым әле. Илләр арасында дәгъва чыкканын ишеткән саен, күңелне шом баса. Элегрәк мин политикага бик үк әһәмият бирми идем. Хәзер менә дөньяда булган һәр яңалык минем тормышыма килеп кагыла кебек. Мин аңа тормыш бирдем, мин үземне аның киләчәге өчен дә җаваплы саныйм. Шундый уйлар белән борчылып, төн йокламый чыккан чакларым була. Бала үзгәртә икән кешене, бөтенләй башка карашлы итә икән.

Лариса аңа гаҗәпләнеп карады:

— Ништяк! Тапкансың хәсрәтләнер нәрсә! Сугышның булырынбулмасын синнән сорап тормыйлар инде! Әниләр безне тапкан бит әле, еллар җиңел булмаган. Ләкин менә яшибез! Начар яшибез дип булмый.

— Ләкин син үзең үк менә киләчәк өчен тырышасың бит. Эзләнәсең, ачыш ясарга омтыласың...

— Син миңа шуны әйт: Ильясова белән сөйләшүдән мәгънә бармы? Кайчан барсам җайлырак булыр?

Зәйтүнә дустына гаҗәпләнеп карады.

— Мин белешермен. Лэкин...
— Ул мине җайлы вакытта кабул итсен,— диде Лариса тагын аны бүлеп.— Калганын мин үзем карармын.

* * *

Галимнәрнең үзләренә аерым бишьеллыклары бар: биш елдан биш елга кафедра мөдирлегенә конкурс булып тора.
Узган юлы сайлангач, Җәмилә Закировна, бу соңгысы булыр инде, дип уйлаган иде. Киләсе сайлауга кадәр гомер бик озын булып тоелган иде аңа.
Хәзер менә артка борылып карагач, аның кай арада узганына хәйран каласың. Олыгайган саен, елларның йөгереше кызулана бара: чылк — бер ел узган, чылк — икенчесе... Ул арада синең тормышыңда берни үзгәрмәгән дә шикелле...
Хәер, кайберәүләр өчен бу еллар мәгънәле булды, доцент Дәүләтшин өчен, мәсәлән. Күзгә күренеп үсте ул. Моны Казанда гына түгел, Мәскәүдә дә беләләр икән. Узган елны аналарның һәм балаларның сәламәтлеген саклау институтына тәҗрибә уртаклашырга баргач, профессор Ильясовага моны бик ачык сиздерделәр:
— Сез Казаннанмыни? Изаил Харисовичны беләсездер инде алайса? О-о, менә дигән специалист, зур галим булачак!
Профессор Ильясованың нинди проблема белән кызыксынганын белгәч, барысы да гаҗәпкә калдылар:
— Ә нигә Изаил Харисовичка мөрәҗәгать итмәдегез? Ул барлык яңалыклардан хәбәрдар тора һәм операцияләрне дә бик яхшы ясый.
Арада, тырнак астыннан кер эзләп йөрмиме бу, дип, профессорга шикләнеп һәм өнәмичә караганнар да булмады түгел:
— Сезнең анда талантлы яшьләрне үстерергә бик тырышмыйлар булса кирәк,— диде сары чәчле, чыра кебек ябык озын буйлы яшь бер галимә.— Изаил Харисович булып ул да һаман әле профессор түгел икән!
Бу сүзләрне ул профессор Ильясовага шәхсән үпкәсе бар сыман әйтте. Доцент Дәүләтшин фән юлыннан гына түгел, яшәешнең башка сукмакларыннан да җиңүле адымнар белән бара иде, күрәсең. Сары чәчле галимәнең ачуын аңлап та була, чыннан да, дөньяга шундый остазлар да очрап тора бит: башта мактый-мактый үстергән шәкертләре үзләрен узып китә башласалар, түбәләрен тәяргә керешәләр.
Хәлбуки, Дәүләтшин профессор Ильясовадан үзе китте, һич көтмәгәндә китеп барды, һәм моны Җәмилә Закировна үз вакытында шактый авыр кичерде, моның сәбәпләре турында да кат-кат уйланды. Кайта-кайта уйлана торгач, Изаил Харисовичның электән үк килгән сәерлекләре искә төште: ул, мәсәлән, заводларга барырга яратмый, шефлык эшенә катнашмаска тырыша иде. Төннәрен клиникадан шалтыратсалар, ул беркайчан да телефонын алмый, соңыннан, өйдә юк идем, дип aклана иде.
Дөрес, үз темасына туры килгән авыруларны зур игътибар белән карый, әмма, аның карашынча, гадәтиләрен башкаларга авыштырырга тырыша иде.
— Урамнан килеп кергән һәр кешене дәвалап кына ерак китеп булмый,— дигән иде ул бервакыт.— Алай вакласаң, район врачы дәрәҗәсеннән күтәрелә алмассың. Галимнәр телеһә кирәрлек эш башкарырга кирәк!

Телгә керү, исем казану турында уйлый иде доцент Дәүләтшин. Шуңа күрә аңа беренче кафедраның тоткан юнәлеше гомумән ошамый иде.

Авырулар турында онытып җибәрә иде ул кайчакта. Шуңа күрә Җәмилә Закировна аңа Диләрамны икенче тапкыр җибәрә алмады. Ярты елдан соң яңа операцияне ул Диләрамга үзе ясады.

Хәзер Диләрам аңа рәхмәтләр укып хатлар язып тора, кияүгә чыкты, әни булырга уйласа, тагын Казанга килергә тиеш.

Бер авыруның язмышын ышанып тапшыра алмаганны, тулы бер кафедраның киләчәген Дәүләтшинга ышанып тапшыра ала идеме соң профессор Ильясова?

Ә Дәүләтшинга профессор булу бик кирәк, нәкъ менә Казанда, илгә даны таралган медицина үзәгендә профессор булу кирәк иде аңа. Мәскәү институтының урам кебек озын, иркен коридорларында йөргәндә, иләннән түшәмгәчә дөньядагы иң яхшы приборлар һәм аппаратлар белән җиһазланган лабораторияләренә кергәндә, ниһаять, андагы кешеләрнең туктаусыз чит ил галимнәрен телгә алып сөйләшүләрен тыңлаганда, Җәмилә Закировна Дәүләтшинның бу теләген бик яхшы аңлады. Аңа профессор булу шушы институтка үрмәләү, аннары, бәлки, дөньякүләм аренага омтылу өчен кирәктер дә.

Ә Дәүләтшинның баш өстендә, икенче кафедрада илле яшендәге кеше утыра, ул әле тиз генә китмәячәк, шулай итеп, Дәүләтшинның бөтен өмете профессор Ильясова урындыгында иде.

Җәмилә Закировна исә зиһене ачык, көче җитәрлек чакта, җитәкчелек мәшәкатьләреннән арынып, күп еллар элек башлаган фәнни хезмәтен тәмамлау турында хыяллана иде.

Әмма ул хәзер үз эшеннән китсә, кафедра башына Дәүләтшин менеп утырачак, башка беркемгә дә юл куймаячак.

Бу турыда ныклап уйлагач, Җәмилә Закировна катгый бер карарга килергә тиеш булды. Гаризалар кабул итүнең соңгы көнендә ул ректор янына керде.

Бу юлы ректор аны «Т» хәрефе ясап куелган өстәлләрнең түрдәгесе артына басып каршы алды. Җәмилә Закировна аңа яны беләнрәк утырды да, сүзен турыдан башлады:

— Кафедра мөдирлегенә мин тагын үз кандидатурамны куярга ниятләп торам әле.

Ул, текәлеп, ректорның шакмаклап ясалган кара кысалы күзлегенә карады, әмма калын пыяла күз алмаларын зурайтып күрсәткәнгә, алар һәрвакыттагыча гаҗәпләнгән кебек тоелалар, асылда ректорның ни уйлаганын белеп булмый иде.

— Олыгаябыз, Җәмилә Закировна,— диде ул.— Сезне әле яңа гына сайлаган идек.

Ректор фикерен әйтергә ашыкмады. Хәлбуки, бу гадәти вакыйга түгел иде. Институт тарихында Ильясова яшендәге хатын-кызның мондый урынга сайланганы юк иде әле. Шуның өстенә, ректор үзе дә җаваплы постларга ирләрне куюны хуп күрә, ул хәтта институтка да егетләрне күбрәк алу кирәклеге хакында трибуналардан кычкырып әйтә иде.

— Гаризамны тапшырганчы, бу хакта сезнең фикерне беләсе килгән иде,— диде Җәмилә Закировна.

— Кафедраның эше моңарчы яхшы бәяләнеп килде бит, Җәмилә Закировна. Дөрес Дәүләтшин да гариза бирде, әмма гыйльми совет сезнең көчегезне, энергиягезне исәпкә алмый калмас.

Гадәттә, эшен яхшы алып барган җитәкчене тора салып урыныннан кузгатмыйлар, гыйльми советның карары алдан ук уңай булачагына ышаныч зур иде.

Әмма профессор Ильясова кем юлына аркылы басканын аңлап бетерми иде әле.

*
* *

Ял көнне, барысы бергә җыелышып, Аккош күленә киттеләр. Зәйтүнә белән Тимербулат, Гөлзәйнәп карчык, Әнвәр һәм Лариса бер машинага сыйдылар, такси аларны урман юлыннан җилтерәтеп, унбиш минутта күл буена илтеп тә куйды.

Биек нарат ышыгына җәймә җәеп, иркенләп урнаштылар. Кояш нурында ялтырап яткан судан, хәтфә үләннән, наратлардан аңкыган хуш ис сулышны иркенәйтә, иркенлек карашларны ук үзгәртә иде. Тимербулат җәймә буйлап үрмәли, көлә, шаяра башлады. Гөлзәйнәп кардай ак чәче өстеннән арткарак шуышкан яулыгын төзәтеп, күл суыдай ялтыраган карашын Зәйтүнәгә төбәде дә:

— И, рәхмәт, кызым, монда да алып чыктыгыз,— диде.— Урман күрмәгәнгә бик күптәннән бит инде. Безнең авыл тирәсендәге болыннар, әрәмәлекләр сагынып сөйләргә генә калды. Мондый сахраларны күрсәң шул кала тирәсендә генә күрәсең.

Ул арада Лариса сарафанын нарат төбенә салып ташлады да ачык бизәкле коену костюмыннан гына калды. Әнвәр дә чишенеп ташлаган, зәңгәр трусиктан гына, тик кыенсына бугай, читтәрәк тулгана. Әнә ул агачлар арасында күренеп торган яшел будкага таба китте. Зәйтүнә аңа сокланып карап калды: Әнвәр, буйга уртача гына булса да, гәүдәсе төз, шома тиресе астында мускуллары уйнап тора. Әнә ул җиңел адымнар белән кире килә, нарат ябалдашлары аша төшкән нур аның йөзендә уйный. Ерактан ук:

— Су велосипеды бар, әйдә йөзәбез!— ди.

Зәйтүнә Тимербулатны күтәреп баскан иде, әнисе:

— Баланы нишләтмәкче буласыз тагын?— диде.— Су чәчрәр, салкын тияр, ялгыш күлгә чумдырырсыз, алла сакласын. Үзегез генә йөрегез!— һәм ул Тимербулатны елатып диярлек алып калды.

Әнвәр белән Зәйтүнә күл уртасыннан бер әйләнеп килделәр.

Кызык үзе: су чәчри, тәгәрмәчләр әйләнә, ләкин Зәйтүнә минут саен артына әйләнеп карамый түзә алмады. Анда бала әтисе белән әнисенә таба талпына, әбисе аны тыярга азаплана, ә читтәрәк Лариса кулларын җәеп, кызынып ята иде. Интегә иде Гөлзәйнәп, җаны кыйнала иде аның: ул чишенгән кешегә карарга оялa, пляжларны «шүрәле оясы» дип атый, шәһәр халкының бу кыланышын кыргыйлык дип саный иде.

Зәйтүнә тизрәк ярга чыгарга ашыкты.

— Әйдә, әни, чәй эчик,— дип, термостан чәй салды.— Ә син кунакны йөртеп кил,— диде Әнвәргә.— Миңа чыланырга ярамый.

Әнә алар икесе янәшә утырып йөзеп тә киттеләр. Лариса җыйнак гәүдәсен артка каерыбрак утырган, тыгыз, йомры балтырлары тамчылар арасыннан елтырап, педальләрне кызу әйләндерә, алар Әнвәр белән ярышып, йөрешне тизләттеләр, көлешкән, шаярышкан тавышлары гына ишетелеп калды.

Аргы ярга җитәрәк, велосипед янтаеп китте, алар икәүләп суга сикерделәр һәм узыша-узыша йөзә башладылар. Гөлзәйнәп аларга аркасы белән борылып утырды, озак кына итеп каршындагы наратка карады, аннары шул наратка текәлгән килеш:

— Үзләрен генә... җибәрмәскә иде,— диде.

— Аның ишегә игътибар итмә син, әни!

— Итәргә кирәк, бик итәргә кирәк!— Карчык күлмәк итәгеннән нидер чүпләгәндәй итенеп, тыелырга тырышып карады, ләкин тыела алмады:— Тормышыгыз бик түгәрәк, кызыгучылар күп булыр. Үз хатынын яраткан иргә башка хатыннар ялманып карый. Мәрхәмәтле, нечкә күңелле, кулыма төшерә алсам, мине дә рәнҗетмәс, баш иеп кенә торыр, дип уйлый. Их, үз акылларым булса!— диде карчык кинәт йөрәк түреннән чыккан кисәтүле тавыш белән.— Үз акылынны теләгәнчә итеп балаңа да биреп булмый шул. Авызын ачып йоклаган кешенең эченә елан керә, бер йотым су эчкән кебек кенә иттерә, диләр. Бу да бик юха, ай-яй юха!

Һәрнәрсәне күңел түреннән кичерә торган гадәтен белгәнгә, Зәйтүнә әнисенең бу сүзләрен артык борчылуга санарга тырышты. Аның уенча, көнләшү — ямьсез гадәт, яраткан кешеңә ышанырга кирәк, ышанмау кешене кимсетә иде. Ул бу сөйләшүгә чик куярга, тегеләргә дә игътибар итмәскә тырышып, Тимербулатны кулына алды да, яулык белән каплап изүен чиште. Сабыйның йомшак иреннәре белән күкрәккә орынуы булды, үзеннән балага сулкылдап яшәү көче агылганын тоемлау гына калды, аргы яктан чытлыкланып көлешкән тавыш ишетелмәс булды. Әкрен генә тирбәлгән нарат ябалдашлары арасында, яр буендагы чәчәкләр өстеннән очкан күбәләк, су кырыена сикереп чыккан бака малае янында — шушы гүзәллек, сафлык эчендә алар гүяки улы белән икәүдән икәү генә калдылар.

Алар янына әйләнеп килгәндә, Лариса белән Әнвәр икесе дә бик тыенкы иделәр. Елмаюсыз, сүзсез генә табын янына утырдылар, гомумән, үзләрен бик тыйнак, дусларча ачык һәм әдәпле тоттылар, хәтта Гөлзәйнәпнең сынаулы карашы да алардан гаеп табарлык түгел иде.

Соңрак алар барысы бергә көймәдә йөзеп килергә булдылар. Ачык түшле чуар күлмәген киеп куйган Лариса бу юлы алга утырды. Артка баланы күтәргән Гөлзәйнәп белән Зәйтүнә урнаштылар, Әнвәр аларга йөз белән утырып ишкәкләргә тотынды. Көймәнең бер башында тигез гаиләнең бергә урнашуы Гөлзәйнәп карчыкның күңелен шунда ук тынычландырып та җибәрде, ул тирә-ягына карарлык хәлгә килде. Урман уртасында уелып яткан күл чыннан да сокланып туймаслык иде шул.

Менә алар каршы як ярга җиттеләр, инде көймә борыны терәлә дигәндә генә, алда ерым барлыгы беленде. Аның читләрендә агачлар ботакларын суга төшергәннәр, аларның шәүләләре ерымда үзләре кебек үк ачык булып чагыла иде. Яфраклар арасыннан тәңкәләнеп төшкән кояш нуры су өстендә тирбәлеп уйнап тора һәм аны төпсез, серле итеп, төбендә су кызларын һәм су патшалыгын яшергәндәй күрсәтә иде.

Барысы да тынып калдылар, Әнвәр ишкәкләрне салмак кына күтәреп, тавышсыз төшерергә тырышты. Көймә таллар арасыннан, суда уйнаган нур шәүләләре өстеннән тын гына шуды.

Менә ерым тәбәнәк агач күпер янына китереп чыгарды. Зәйтүнә белән Әнвәр ике яктан мүкләнеп беткән, лайлалы агач субайларга тотынып, көймәне аргы якка этәрделәр. Күпер артында тагын урман белән әйләндереп алынган зур күл ачылды. Аның уртасында балык сыртлары кебек бүлтәеп, ике-өч утрау күтәрелгән, аларга куаклар, алсу һәм сары саз чәчәкләре үскән иде. Утрауларга якын килеп булмый, ярлары ләм икән.

— Әйдәгез, бу исемсез атауларга исем кушабыз, без беренче булып ачтык бит аларны!— диде Әнвәр.

Бу уенга хәтта Гөлзәйнәп тә кушылды. «Изге Зәйтүнә атавы», «Изге Лариса» һәм, әбинең каршы килүенә карамастан, «Изге Гөлзәйнәп» дип исем куштылар атауларга.

Ниһаять, ярга чыгып, җәймәне җәюгә, Гөлзәйнәп ах итеп, кытыршы һәм җылы нарат кәүсәсенә аркасын терәп утырды. Тимербулат изрәп йокыга талды.

Алар өчесе бераз йөреп киләргә булдылар. Лариса озын баулы сумкасын үзе белән алды.

Яшь усаклар арасыннан үтеп, карчыкның күзеннән ычкынгач, ул туктады да:

— Минем монда бер сюрприз бар бит әле,— диде.

— Кирәкми иде,— дип каршы төште Зәйтүнә.

— Ништяк! Син бала имезгәч тә, Әнвәр белән без бала имезмибез бит әле. Мин отпускадагы кеше.

Әнвәр каршы килмәде. Зәйтүнәдән аермалы буларак, аларның мене шундый уртаклыгы да бар иде бит әле! Стакан да, кабар нәрсә дә юк иде, алар икесе бер шешәдән шәраб эчтеләр. Кара шешәнең тышына сөзәргә дип башын игән симез һәм көчле үгез сурәте ясалган иде. Лариса шешәне күтәргәндә, үгез башын иеп, тояклары белән күккә кизәнде.

Шешәне бушатып, зелпе куагы астына яшергәч, Әнвәр:

— Әйдәгез, мин сезгә мәхәббәт агачы күрсәтәм,— диде.

Җавап та көтмичә, очыннан, каршыдагы калкулыкка менеп китте. Мәхәббәт агачы дигәне калкулык өстендәге ачыклыкта икән. Ике яшь агач — каен белән усак — бер тамырдан чыккандай, бер-берсенә сарылып үскәннәр. Хәер, үсүдән бигрәк, уралышканнар алар, әйтерсең лә кемдер юри аларны бау урынына чәбәләгән. Бу чәбәләнү шундый тыгыз ки, кайсының кәүсәсе-ботагы кайда икәнен белерлек тә түгел. Аларның тамырларыннан күтәрелгән дым да адашып берсеннән икенчесенә күчәдер сыман тоела. Урыны-урыны белән ботаклар куллары-аякларны хәтерләтә, игътибар белән караганда, бу ике тереклек иясенә җан иңгәндер дә, аларда мәхәббәт хисе кабынгандыр һәм алар кавышып, бер-берсенә бирелгән мизгелдә оеп калганнардыр кебек тоела. Бу хис шулкадәр көчле булган ки, алар хәтта барча үсемлекләрнең изге кагыйдәсен — кояшка таба үрелеп үсәргә кирәклеген дә онытканнар, башларын түбән игәннәр.

Әнвәр агачларны кат-кат әйләнеп чыкты, аның күзләре гадәттән тыш ялтырый, йөзе тимгелләнеп чыккан, хәрәкәтләре артык иркен һәм бу рәвешендә ул ямьсезләнеп киткән иде.

— Бу яктан карагыз әле! Нәрсәне хәтерләтә, ә?— дип сорады ул.— Сезгә, медикларга гына күрсәтеп була моның ишене!

Лариса агачларны әкрен генә әйләнеп чыкты да сузып: «Ништя-ак!— диде.— Инде агач булып агачлар болай кыланышкач, тәнендә кайнар кан аккан адәм баласы нишләп түзәргә тиеш!»

Әнвәр белән Зәйтүнә күлгә еш киләләр, ләкин беркайчан да бу калкулыкка менгәннәре, бу агачны күргәннәре булмады. Кайчан күргән Әнвәр бу агачны, кем белән эзләп тапкан һәм ни өчен нәкъ менә бүген аны күрсәтергә булган?

Оятсыз ләззәттән башы иелгәндәй бөгелеп төшкән каенның кәүсәсе гадәттәгечә ак түгел, күгелҗем иде. Аның каен икәнен дә яфракларыннан гына белеп була. Аклыгын югалткан иде каен.

* * *

Лабораториядә һәркемнең урыны кишәләр белән бүленеп куелган. Алтынчәчнең өстәле — ишектән кергәч тә сулда, түр почмакта. Ак пластик белән капланган озын өстәл, ялтырап торган пыяла пробиркалар, төрле приборлар, киң тәрәзә төбендә чәчәк атып утырган яран-

нар һәм милəүшəлəр, больницаларга хас чисталык һәм фенол исе, бигрәк тә урынның аулаклыгы — барысы күңелгә күптән якын. Монда килеп, өс киемнәреңне алыштыргач, ак халат белән башлыгыңны киеп куясың да тормышның калган ваемнарыннан арынып торасың, күзгә күренми торган, үзгәрүчән һәм катлаулы дөньяга,— табигатьнең иң вак кисәкчекләре дөньясына үтеп кергәндәй буласың. Бу дөнья үзенең төзеклеге, законнарының тайпылышсыз һәм төгәл булуы белән сокландыра Алтынчәчне. Атомнар, молекулалар үз законнарына, табигатьләренә һәрвакыт тугры булып калалар, беркайчан да алдамыйлар, алар ышанычлы һәм гадел дусларың кебек, икейөзлеләнүне белмиләр. Табигать үзенең чын асылында законнарына тугрылыклы һәм ихлас, ә алдау-ялганны, икейөзлелекне кешеләр уйлап чыгарганнар. Начар кешеләр... Линар кебекләр...

Молекулалар һәм атом-электроннар дөньясында рәхәт Алтынчәчкә. Ул күзгә күренмәс җисемнең пробиркалардагы катлаулы хәрәкәтен, кисәкчекләрнең бер-берсенә тартылышын һәм бер-берсеннән читкә этәрелешен күңеле белән тоя шикелле. Аның кечкенә, әмма нык, сөякчел куллары бу хәрәкәтне үзенә буйсындыра белә.

Химиклар арасында «куллары яхшы» дигән сүз бар. Хәрәкәтләрне төгәл ясый, реакцияләрне пөхтә үти, дигән сүз генә түгел бу. Химикның лабораториядә эше — ул музыкантның пианинода уйнавы кебек. Берәү, бәлки, клавишларга тиешле тәртиптә дә баса торгандыр, ул уйнаган нәрсә көйгә дә охшый торгандыр, ләкин ул көйнең моңы юк, күңелләрне тетрәндергеч көче юк. Көйне моңлы итү, кеше күңелләренә җиткерү өчен үзенә аерым талант, йөрәк хисе кирәк. Химиядә дә шулай. Кайберәүләр матдәләрне тиешле микъдарда үлчи ала, тамчыларны нәкъ кирәгенчә тамыза, ләкин матдәләрнең вак кисәкчеләре ул кушканны үтәргә теләми. Реакция бармый. Син аны теләсә нишләт, бармый.

Андый чакларда гадәттә Алтынчәчне ярдәмгә чакыралар. Лаборатория начальнигы Нәҗия Нәкыйповна аның алтын куллы икәнлегенә ышанган. Әнә ул ишекне ачты да:

— Алтынчәч!— диде.— Бүген телевидениедән киләләр! Шаккатырырлык прибор әзерләп куй әле!

Алтынчәч борылып караганда, ул инде ишекне ябып маташа иде, күперел торган кызгылт чәчләре генә күренеп калды. Катгый сөйләшә җитәкче — сүзен әйтте, җавапны тыңлап тормады.

Моннан берничә ай элек, Нәҗия Нәкыйповна нәкъ менә шушылай ишектән башын тыгып:

— Алтынчәч! Инглизләр янына барып кил әле! Эшләре бармый,— дип кычкырган иде.

Сәгать биш җитә иде инде. Алтынчәч халатын салып, икенче каттан өченчегә, чит илдән килгән белгечләр өчен махсус җиһазланган бүлмәгә менеп китте. Өстәл янына җыелган берничә ир кеше аңа гаҗәпләнеп карадылар: кечкенә буйлы, калын күзлекле бу хатын-кыз аларга ошап бетмәде булса кирәк. Алтынчәч русча сәлам биреп, аларга карамый гына алга узды.

— Никароши прибор!— диде шунда нечкә бармагы белән өстәлдәге фотоэлектрокалориметрга күрсәтеп, озын буйлы, арык гәүдәле егет.

— Нишләп никароши булсын! — Алтынчәч аның ябык ак йөзенә шелтә белән карады. Егетнең изүе чишелгән, кыска халаты таушалган, мамык кебек йомшак, юка чәче чуалган — гомумән, ул тышкы кыяфәтенә әллә ни игътибар бирмәгәндәй күренә иде. Ә зәңгәр күзләре эчкерсез карый.

Тәрҗемәче китеп өлгергән икән инде, Алтынчәч прибор өстенә иелде. Ул чит илләрдә, шул исәптән Англиядә эшләнә торган шундый ук

приборлардан төзелеше белән бераз аерылса да, бер дә алардан ким түгел иде. Ә-ә, менә хикмәт нәрсәдә икән. Бу егет ясалма катнашмада сульфат микъдарын ачыклый, заводтан чыккан суларның составын тикшерү буенча эшли, күрәсең. Мондый очракта приборга өстәмә светофильтр куярга кирәк, ә ул аны онытткан.

Алтынчәч, прибор астындагы кюветны — озынча савытны алырга үрелде. Аны алгач, светофильтрны кую бик ансат. Ләкин иелергә кирәк. Ә ул бүген үч иткәндәй изүе ачык күлмәген кигән иде. Иелгәч, ул тагын да ныграк ачылачак, ә арттан бу кешеләр карап тора... Ул, борылды да, кулы белән изәп:

— Китеп торыгыз! Китегез! Кит!— диде. Өч ир-ат, гаҗәпләнгәннәрен белдереп, аптырап, арткарак чигенделәр. Алтынчәч тиз генә светофильтрны урнаштырды. Күтәрелеп карасa, арык егет аның артына килеп тә баскан. Алтынчәч кызарынып чыкты.

Ләкин егет җитди, ул Алтынчәчнең нәрсә эшләгәнен аңларга тырыша иде.

— Менә болай...

Алтынчәч кулы белән сузылып, светофильтрны күрсәтте.

Егет эчкә сузылды, ләкин зур кулы анда сыймый иде.

Ул елмаеп, сорау белән күтәрелеп карады..

— Син алай булдыра алмыйсың. Сиңа өске капкачын ачып куярга кирәк иде.

Егет аңлаганын белдереп, рәхмәт хисе белән башын каккалады. Кюветны кире урынына куеп, титрованиене башладылар. Алтынчәч өстәлдән кәгазь-каләм алды да:

«— BaCl-0, 001?» — дип язды.

—Да, да!— дип башын иде егет.

Акыл белән, йөрәк хисләре белән аңлашу өчен телләрнең төрлелеге дә комачаулый алмый. Кеше үзенең акыл казанышларын ургаклашканда формулалар, символлар белән аңлаша. Хис-тойгыларын авазлар, ноталар, төсләр белән, елмаю, хәрәкәтләр белән аңлата.

Алтынчәч титрованиенең ничек барганын бераз күзәтеп торды да ишеккә юнәлде. Прибор яхшы эшли иде. Әмма ябык егет аның артыннан килеп, сак кына иңенә тотынды. Алтынчәч борылып карагач:

— Оливер!— дип үзенең күкрәгенә төртте.

— Алтынчәч,— дип башын җиңелчә генә иде кыз.

— Алтынчәч,— дип кабатлады егет үзе өчен ят исемне.— Алтынчәч!— диде зур ихтирам һәм соклану белән.

Дөресен генә әйткәндә, моңарчы Алтынчәчнең исемен болай олылап һәм сокланып караган кеше юк иде әле. Кем белән генә танышсаң да, иң элек башыңа карыйлар. Ә Алтынчәчнең чәче — көл төсле, юка, кыска. Карый кеше, көлемсери. «Туганда минем чәчем сап-сары булган, эти белән әни сөекле кызларына беркемдә юк исем кушарга тырышканнар»,— дип кеше саен аңлатып йөреп булмый бит инде!

Шуннан соң, атнага ике булмаса да, бер тапкыр Нәҗия Нәкыйповна ишекне ачып:

— Алтынчәч! Сине инглизләр чакыра!— дип ярып сала торган булды. Чакыручы гадәттә Оливер була. Кайдадыр бик еракта, диңгезләр, таулар артында, күз күрмәгән илдә туып-үскән, ят телдә сөйләшә торган бу егет үз һөнәрен Алтынчәч кебек үк ярата һәм, иң мөһиме, бу эштә осталыкны, талантны бәяли белә иде.

Аңарчы Алтынчәч завод территориясендә эчке бер сагаю белән йөри торган иде. Чөнки лабораториядән цехларга барганда, киң асфальт юлны ике яклап ышыклап торган агачлык артыннан берәр борылышта баш механик Бадамшинның озын гәүдәсе килеп чыгуы ихтимал. Ул синең яныңнан узып киткәнче, куак булып торасы, яки сукмак читен-

дәге гөлгә әвереләсе, я күбәләктәй очып китәсе — кыскасы, юк буласы килә, ләкин син юк була алмыйсың, кире борылып йөгерергә аяклар ирек бирми, алар, ниндидер мотор ярдәмендә хәрәкәткә китерелгәндәй, алга таба атлый бирәләр. Алтынчәч бик текәлеп асфальттагы ярыкларга карый, ә үзе баш түбәсендә Нәркиснең көйдергеч карашын тоя. Мондый очрашулардан калган хис атна буе йөрәкне сызландыра, бу сызлану икенче очрашуга кадәр җитә иде.

Бигрәк тә Линар белән танышканнан соң йөзе кара итеп тоя башлады ул үзен. Теге чакта, тулай торакта, егете белән үбешеп йөргән өчен Тәслимәне ничек гаепли иде бит ул! Ә хәзер үзе дә шундый булып чыкмадымыни? Аның йөз каралыгы тиздән бөтен заводка фаш булачак, очрашканда, баш механик аның баш түбәсенә генә түгел, гәүдәсенә текәләчәк. Чөнки киләсе кышка ана булачак Алтынчәч, һәм, мөгаен, бу сүз алдына «ялгыз» дигәне дә өстәләчәк. «Ялгыз ана Алтынчәч Вафина» булачак ул киләсе кышка.

Бу хәле аны ике төрле хис арасында йөртә. Бер яктан ул горурлана: менә бит, мин башкалардан ким түгел, ана булачакмын! Икенче яктан кимсенә: ул бүтәннәрдән ким, чөнки кешечә гаилә корып, баласын этиле итә белмәде. Шулай да бу кимсенүне киметә торган бер өмет яши күңелдә. Ә бәлки, сабый этисез калмас әле. Мөһимә һаман юатып тора, Линар ялгыз, ди, тик минә урыныннан кубып, бөтенләйгә күчеп килергә җае гына чыкмый, ди. Андый эш дәррәү генә эшләнми бит ул, дип куя. Менә баланы күргәч, җаны түзмәс, килер, аллаһы боерса, дип юата. Линарның таш бәгырьле булуы мөмкин түгел. Кызы бар бит аның, ә кыз баласы булган ирләр хатын-кызның хәлен аңларга тиешләр, чөнки башкаларның язмышын үз кызларына үлчәп карамый булдыра алмаслар...

Алтынчәч, уйларын шунда бүлеп, телевидение кешеләре килүгә әзерләнә башлады. Катлаулы эш башкара торган прибор әзерләргә кирәк. Әйтик, менә дефлегматор. Катнашмадагы матдәләрне ифрат яхшы аера. Тыштан караганда колбага тоташкан пыяла көпшә кебек кенә үзе...

Лабораториядәге кызлар Алтынчәчнең хәлен күптән сизәләр инде, тик тел белән сорарга гына кыймыйлар.

Ә менә Оливер аның кыяфәтенә бер дә игътибар белән карамый иде, ул бары тик «алтын куллар»ның осталыгын, сәнгатен, җырын отып алырга гына тырыша иде. Мөнәсәбәтләрнең гади һәм эшлекле булуы, бер-берсенең күңелләренә тирән керергә омтылмау кешеләрнең чын бәһасен белергә мөмкинлек бирә икән. Инглиз инженерының их тирамы Алтынчәчнең дәрәҗәсен үстереп җибәрде. Бу чорда Алтынчәч заводта иркенәеп йөри башлады, хәтта Бадамшиннан да элеккечә коты очып тормый иде инде.

Моннан бер ай элек, инглизләр, эшләрен тәмамлап, үз илләренә кайтып киттеләр. Әллә шул да бераз сәбәп булды инде, әллә хәле үзгәрә баргангамы, Алтынчәчнең пошынуы соңгы вакытта аеруча көчәйде...

Ишек артында шау-шу, дөпелдәгән, кычкырып сөйләшкән тавышлар ишетелде, бүлмәгә, сакал-мыеклы яшь кеше ияртеп, Нажия Нәкыйповна килеп керде.

— Менә безнең тәҗрибәле инженерыбыз Алтынчәч Вафина. Әзерме, Алтынчәч?

— Биш минутлык кадр ясыйбыз. Телевидение өчен бу бик күп.— диде сакаллы калын тавыш белән. Әллә каян сизелеп тора: күп төрле халык арасында айкалып, ул инде тарсынуның, оялуның ни икәнен дә оныткан, аягы кая басса, шунда үзен өендәге кебек хис итәргә күнеккән иде.

— Шушымы?— дип сорады ул дефлегматорга төртеп.— Эшләтеп күрсәтегез.

— Ул эшләп тора,— диде Алтынчәч кырку гына. Бу кеше прибордан да бигрәк Алтынчәчнең кыяфәтеннән канәгать түгел иде, ахрысы, карашыннан шул сизелде.

— Бумы эшләп тора? Без тамашачыга нәрсә күрсәтербез соң? Бер пыяла колбамы?

— Әгәр беләсегез килсә, бу колба үзе бер завод кадәр эш башкара.

— Карагыз әле, безнең вакыт санаулы. Хәзер камераларны кертәбез дә...

Ишектән озын тимер тоткаларга беркетелгән софитларны сөйрәп кертә башлаганнар иде инде. Алар артыннан кара елан булып резин көпшәләр идәнгә сузылып яттты.

— Кая монда розетка?— дип як-ягына каранды таза гәүдәле ир кеше.

Лабораториядә моңарчы беркайчан булмаган ыгы-зыгы купты.

— Алтынчәч, син аларга су өчен дистиллятор куй! — диде Нажия Нәкыйповна.

— Дистиллятор? Кеше алдында оят бит, Нажия Нәкыйповна. Химиклар күрер!

Начальник кул гына селтәде.

— Акыллы химик күрсә дә көлер дә бетерер, ә тилегә барыбер түгелмени!

Чыннан да шул тиле өчен булса гына инде. Дистиллятор — зур колба, астына спиртовка куеп, шуның эчендә су кайнатасың. Тизрәк кайнасын өчен аңа калий перманганаты, ягъни марганцовка да өстиләр. Карап торышка гел харап була инде: пыяла савыт эчендә үрле-кырлы сикереп ачык шәмәхә төстәге сыекча кайный!

Чыннан да режиссерның йөзе ачылып китте:

— Менә ичмасам, бу чыннан да зур химияне күз алдына китерә!

— Химия түгел бу, физика,— диде Алтынчәч.

Ләкин аның сүзенә колак салучы булмады, чөнки өстәл янында, гыйфрит күзе кебек объективларын акайтып, телевидение камерасы шуышып йөри иде, режиссер операторга күрсәтмәләр бирә башлады.

Алар урамга чыккач, Алтынчәч, тәрәзә төбендәге гөл чүлмәкләрен кырыйгарак шудырып, ишек алдына карады. Камераны асфальтка җайлап куйганнар, завод күренешен төшереп маташалар. Аннан ни күренә соң? Ә, градирнялар! Чыннан да харап бит кыяфәтләре, бинићая зур чүлмәк рәвешендә үзләре, өсләреннән төрле тарафка пар бөркелә...

Тыштан караганда заводның иң шаккатыргыч корылмалары булып тоела алар. Ә чынында исә бары тик пар җыйгычлар гына ул. Алар парны суга әйләндерәләр.

Заводның төп эшен башкара торган колонналарның исә кыяфәте тыштан караганда бик гади. Алар цехлар эчендә тавыш-тынсыз гына үзләренең катлаулы һәм бик мөһим вазифаларын үтиләр.

Алтынчәч чая режиссерның мәгънәсезлегенә көлемсерәде. Ләкин шунда ук җитдиләнеп: «Мин үзем дә шундый түгелмени?— дип уйлап куйды.— Кешенең чын асылын күрмим, шул градирня кебек кәпрәеп пар бөркегәннәренә кызыгам түгелме мин дә? Күзне кызыктыра, алдый белә шул алар!»

*

* *

Институтта укыганда Зәйтүнә бер завод поликлиникасындагы врачлар белән берлектә фәнни тикшеренүләр алып баруда катнашкан

иде. Ул һавага бүленеп чыга торган газ катнашмасының хатын-кыз организмына тәэсирен өйрәнүдә катнашты.

Бу эш белән профессор Ильясова җитәкчелек итте, завод врачлары аны клиника белән бергәләп башкардылар. Шуңа күрә Зәйтүнә заводта да үз кеше булып беткән иде инде.

Ләкин менә Тимербулат белән өйдә утырган арада ул бу эшләрдән читтә калды. Тикшеренүләрнең нәтиҗәсе югары оешмаларга җиткерелгәнен, бер цехта тулысынча реконструкция ясалганын ишетсә дә, барып күрә алганы юк иде әле.

Цехта һаваның чистаруына ирешә алдылармы икән? Зәйтүнәнең моны үз күзләре белән күрәсе килә иде. Бер көнне клиникада эше тәмамланганнан соң, ул заводка сугылырга булды.

Элекке пропускысының срогы чыккан икән. Ул завод поликлиникасына шалтыратты. Әмма поликлиникада да кабул итү сәгатьләре беткән, врачлар киткән иде. Зәйтүнә цехка шалтыратты. Анда да начальник алышынган икән, нечкәрәк кенә ят тавыш җавап бирде. Зәйтүнәнең кемлеген аңлап җиткермәсә дә, пропуск яздырырга вәгъдә итте.

Завод ишегалдында да күз үзен сиздерә. Сукмак кырыйларындагы өрәңгеләрнең яфраклары яшел әле, ләкин ныклабрак карасаң, алар да төс сала башлаганнар, коңгыртланганнар, катыланганнар, салкынча җил килеп бәрелгәндә, йомшак кына леперләшмиләр, калайдан ясалгандай каты бәрелешеп кыштырдыйлар. Әнә, цехның бетон тартманы хәтерләткән яңа бинасы каршындагы түтәлләрдә дә җәйге гөлләр шиңгән инде, бары тик кашкарыйлар, кызгылт-сары бәрхет гөлләр генә балкып утыра.

Бинага якын килгән саен, ят ис — тәмсез газ исе күңелгә ныграк тия башлады. Зәйтүнә чәчәкләргә үрелде. Кашкарыйлар иссез була, ә менә бәрхет гөлнең исе, якын килсәң, хәтта шул тәмсез исне дә күмеп китә ала икән.

Ләкин бу — иелгән мизгелдә генә, тураеп басуга борынны ярып, тагын күңелне болгандыра торган ис аңкыды.

Әйе, цехны бөтенләй өр яңадан эшләгәннәр икән. Эче иркен, биек. Уң якта идәндә тезелеп торган чаннар өстеннән шуышып краннар йөри, алар үзләренә беркетелгән формаларны чаннарга чумдырып кына алалар — төп эшне шул рәвешле автоматлар башкара. Сулдагы өстәл янында ике хатын сөйләшеп утыралар иде — цехта бүтән кеше күренмәде. Зәйтүнә эчкә керүгә, саргылт плащының сәдәфләрен ычкындырды: биредә җылы, теге хатыннар да кыска җиңле күлмәкләрдән, ялан балтырлы иделәр.

Килеп керүгә тәмсез ис күңел кайтаргыч булып тоелса да, бераздан күнегәсең икән, шуңа күрә хатыннарның да аңа исе китми, калын оеклар, озын җиңле күлмәкләр кияргә кирәклеген дә онытып җибәргәннәр. Менә аларның берсе кранның түрдәге чан янына шуышканын күреп, ашыкмыйча гына шунда таба китте, чан эчендәге сыеклык өстенә утырган элпәне таяк белән сыдырып алып, кырыйдагы савытка ташлады. Тәмсез ис тагын да көчәйде, кран түбәнәеп, зур тукмактай бүлтәеп торган формаларны чан эченә чумдырды...

Формаларга резина ябышып чыга, кран артка чигенгән арада ул резина кибеп, шар хасил була...

Зәйтүнә боларны күзәтеп торганда, артында кемдер:

— Ничек соң, врач иптәш, ошыймы?— дип сорады.

Зәйтүнә сискәнеп борылды һәм кара диагональдән тегелгән костюмлы кеше белән кара-каршы басып калды.

— Исәнмесез. Сез кем буласыз?

— Цех начальнигы Хәйруллин булам.

Начальник өчен Хәйруллин яшьрәк күренә иде, бигрәк тә элекке начальник Галиулла абзый белән чагыштырганда. Җитмәсә балалар шикелле борынын тартып, җиңелчә генә иңбашларын сикертеп куйды тагын. Әмма иңбашлары таза, киң, җиң эчендә нык мускуллар уйнаганы сизелеп тора.

— Мин клиникадан. Зәйтүнә Мәҗитовна,— дип кулын суздьı аңа Зәйтүнә. Хәйруллин аның бармакларын эләктереп алып, кисәк кенә кысты да:

— Мөдәррис Сәләхович,— диде.— Әйдәгез, өскә менеп сөйләшик.

Үзе җавап та көтмичә борылды да, эре һәм нык басып, ишеккә юнәлде. Ул, җилкәләрен алгарак авыштырып, тәҗрибәле өлкән кеше кебек атларга тырыша, ә йомшак чәч белән капланган йомры башы малай-шалайны хәтерләтә иде.

Лифтка утырып, өченче катка сөйләшмичә генә менделәр. Цех начальнигының кечкенә генә бүлмәсендә тагын ике хатын-кыз утыра икән. Хәйруллин түр тәрәзә буендагы өстәл артына кереп утырды да, Зәйтүнәгә каршысындагы урындыкны күрсәтте.

Тәрәзәдән завод корпуслары, торбалардан чыгып җил уңаена авышкан сыек төтен тасмалары күренеп тора. «Күпме һаваны агулыйлар!» Зәйтүнә аркасы белән хатыннарның карашын тоеп, тартынып утырды.

— Мин бу цех һавасындагы зарарлы матдәләрнең хатын-кызлар организмына йогынтысын тикшерүдә катнашкан идем,— дип аңлата башлады ул начальникка. — Шактый көч куелды бу эшкә. Менә реконструкция дә ясалып беткән икән... Җитәкчеләр безне, реконструкциядән соң хәл тамырдан үзгәрәчәк, дип ышандырганнар иде.

— Ну, без вәгъдә биргән хәтлесен эшләдек анысы,— дип аның сүзен төксе генә бүлдерде Хәйруллин.— Цех бинасы иркенәйтелде, вентиляторлар эшли, производство мөмкин булганча механикалаштырылды.

— Ләкин һава! Һавада үзгәреш сизелми бит! Ничек алай булды соң?

Зәйтүнә бу сүзләрне һич тә Хәйруллинга үпкә рәвешендә әйтергә теләмәде, ул бары тик врачларның, инженерларның шушылай бергәләп тырышуы нәтиҗәсез калуга гаҗәпләнгән, бары тик шушы аяныч хәлнең серенә генә төшенергә теләгән иде. Ләкин начальникның кырыс карашы аны каушатып җибәрде, шунлыктан соравы дорфарак чыкты, ахрысы. Өстәвенә ул арттан ике хатынның көлемсерәп күзәтеп утырганын һаман тоеп тора иде.

— Һава! Һава! Без кулдан килгәнен эшләдек. Әгәр дә хатын-кызга бездә эшләү зыянлы икән, китсеннәр! Башка, зыянсыз эшкә урнаштырабыз, пожалуйста! Менә шулай дип карагыз әле сез аларга, авыз ачарга да ирек бирмиләр. Утызар ел шушында эшлиләр. Эш хакы яхшы, пенсиягә иртә чыгалар. Сез, врачлар, үзегез үк беркемнең дә монда эшләгәннән инвалид булганы юк, дисез бит.

— Гел карап, дәвалап торганга шулай инде ул.

— Ансы сезнең эш. Бөтенегез дә безнең кебек биргән сүзен үтәп торсын иде әле!..— Начальник бу сүзләрне аеруча үчекләп, ирennәрен яңа туган ай рәвешенә китереп әйтә башлаган иде, өстәлдәге кара телефон зыңгылдады.— Хәйруллин тыңлый,— диде ул трубканы алып.

Бу юлы аның фамилиясе бик таныш булып ишетелде. Кайда күрде соң әле бу кешене Зәйтүнә? Йөзе дә бик таныш шикелле бит!

Трубканы куйгач, Хәйруллин Зәйтүнәгә астан карап, күзләрен бозлы су кебек елтыратып:

— Шул ук сезнең клиникадагылар монда килеп күрсәтмә биреп йөрергә иренмиләр, ә үз бурычларын һәрвакытта намус белән үти белмиләр. Нәрсә ди әле Гиппократ? Ничек әле аның беренче васыяте? — диде.

Зәйтүнә Хәйруллинның тел төбе кая барганын аңлаудан гаҗиз иде. Җитмәсә, арттан ике тамашачы карап, мөгаен, авыз ерып утыра!

— Зыян китермә, дигән Гиппократ, шулай бит? — диде начальник надан укучыга сабагын искәрткән укытучы тавышы белән.— Сез кешегә зыян китермәскә ант иткән кешеләр. Ә соң клиникагызда гел файдалы эш кенә башкарасызмы сез? Бер дә зыян китермисезме?

Зәйтүнә күзләрен зур ачып, шаккатып аңа карап утырды. Бу Хәйруллин... теге былтыр клиникада яткан Хәйруллинаның ире бит! Шул үзе! Зәйтүнә аларның икесен бергә поездда, Ларисаларны озатканда күргән иде.

Ләкин нигә рәнҗи ул Зәйтүнәгә, ни өчен гаепли? Теге газаплы төндә аның дежур торганын белә микәнни?

— Берәүнең эшеннән гаеп табу икенченең гаепләрен акламый әле,— диде ул.— Кимчелегебезне күргәнсез икән, турысын гына әйтегез. Ләкин цехтагы һаваның да бу хәлдә калуына без ризалашып торырга тиеш түгел.

Ул каушаганын сиздермәскә тырышып, кул куярга дип пропускысын Хәйруллинга таба шудырды.

Икенче көнне клиникага эшкә килү белән, ул алтынчы палата врачы Фидая Галимовнадан Динә хакында сорады.

Фидая Галимовна, сөйкемле, озынча чырайлы, дулкынланып торган кара чәчле, утызлар тирәсендәге хатын:

— Ай, ул Хәйруллина белән әвәрә булып беттек бит без,— диде.— Син декретта чакта тагын керде бит ул безгә. Носилка белән китерделәр. Тырнаклары күгәреп чыккан иде. Бик авыр операция булды. Аның эшләре бөтенләй кире киткән, дип ишеттем әле мин. Баласы да үлгән икән.

— Баласы үлгәнмени?

— Әйе, бер килсә килә бит ул. Операциядән соңгы чорны бик авыр кичерде. Алай да йөрәге таза икән. Җәмилә Закировна үзе карады.

Җәмилә Закировна йөрәк-кан тамырлары системасын кайсыбер терапевтлардан да яхшырак белә иде.

— Ә шулай да зарланмады,— диде Фидая Галимовна.— Бер дә чыраен сытмады, көлә дә шаяра үзе.

Зәйтүнә аның теге төндә сызлану аша елмайганын исенә төшереп, тетрәнеп куйды.

*
* *

Оста кул белән ясалган һәм ачык төсләргә буялган агач уенчык төсле бу кыз студент чакта ук профессор Ильясовада яхшы тәэсир калдырган иде. Сайлап алган темасы бик мөһим, кыска гына вакыт эчендә үзе дә шактый материал туплаган, башкаларның тәҗрибәсе белән дә танышырга өлгергән.

Кыскасы, Җәмилә Закировна Лариса Сөнгатовнаның эшенә өметле дип карый иде.

Зур химик заводның поликлиникасында аена бер тапкыр профессор Ильясова авыруларны кабул итә. Шундый бер көнне график буенча аның белән бергә Нигъмәтуллина барырга тиеш булгач, Җәмилә Закировна аны бу эштә дә сынап карарга мөмкинлек туганын уйлап куйды.

Бу зур завод ерак, каланың бөтенләй икенче читендә, ә профессорның махсус машинасы юк. Алар башта трамвайда, аннары троллейбуста бардылар. Җәмилә Закировна утырган, Лариса аның янына баскан, икесе дә тәрәзәдән яңгыр чылаткан урамнарны, күзгә кырау-

лардан көйгән агачларны сүзсез күзәтә, һәркайсы үз уйларына чумган иде.

Менә ун ел инде ай саен бу озын юлны уза Җәмилә Закировна. Шушы еллар эчендә кала бик нык үзгәрде. Менә бу урында Казан елгасы аша салынган дамбаны үтүгә, тәрәзәләренә кадәр җиргә сеңгән йорттлар тезелеп утыра иде. Аларны сүтеп урынын сөрделәр дә, үлән чәчеп, агач утырттылар, калку итеп чәчәк түтәлләре ясадылар. Эчтәрәк фонтан атып утыра, аннан да арырак, Яшьләр үзәгенең соры бетон бинасы. Уңда исә тезелеп киткән тәрәзәләре белән унөч катлы нәшрият бинасы калыккан. Урам киң, күз күреме иркен, биек биналар бер-берсеннән ерак утыртылган.

Әйе, дөнья бик нык үзгәрде, тик Җәмилә Закировна үзе генә үзгәрмәгән шикелле. Заводка ул һаман элеккечә теләп бара, аңа якынайган саен кәефе үк яхшыра.

Элек-электән профессор янына авырулар үзләре килә торган булганнар. Тәмам сабырлыгы төкәнгәч, башка өмете калмагач кына килгән адәм баласы галим табип янына һәм еш кына аның бу килүе инде соң булган.

Ә менә профессор Ильясова үзе кешеләр янына бара. Сау-сәламәт дип саналган, станокларда дөберд.тәп эшләп торган хатын-кызлар белән очрашырга бара ул. Баштарак аның бу нияте кайберәүләргә сәер тоелган иде. Кафедра бер заводта профилактик эш алып бара иде бит инде. Хәлбуки профессор Ильясованың бу заводка килеп йөрүе очраклы түгел иде, анда хатын-кызлар күп эшли, алар химик матдәләр белән эш итәләр һәм, өстәвенә, директор Лукьянов Мөбарәк Таһировичның күптәнге танышы иде.

Инде өлкәнәеп килүенә карамастан, яшьлек елгырлыгын саклаган, заводтагы хатын-кызларның кем дигәндә яртысын мәхәббәт утында яндырган Лукьянов та баштарак сәерсенеп куйды.

—Безнең заводның поликлиникасы бик яхшы бит, бөтен белгечләр бар,— диде.

— Алар авырган кешеләрне дәвалыйлар, ә без авырмасыннар өчен тырышачакбыз.

— Ярый, сез бездә махсус кабинет ачасыз, ди, ә бездән шуның өчен ни сорыйсыз?

Директорның тирән акыл чагылган күзләрендә хәйләкәр көлемсерәү кабынды.

— Сез договор белән безгә акча түләрсез.

— Күпме?

— Байлыгыгызга карап.

Директор көлеп җибәрде:

— Хәйләкәр сез!

Завод шәһәрдәге иң бай предприятиеләрнең берсе иде.

— Ә без ул акчага клиника өчен яңа җиһазлар алачакбыз,— диде Җәмилә Закировна.

Ә ярты елдан, бер мәҗлестә очрашкач, Лукьянов Җәмилә Закировнага шаяртып бармак янады:

— Сез миңа авыруларны киметергә вәгъдә биргән идегез, ә үзегез дистәләгән эшчене больницага салгансыз. Алай план үтәп булмый бит!

— Әгәр дә сез еллар буе ремонтламаган станокларыгызны берьюлы ремонтлый башласагыз, планыгыз нишләр иде соң? Әллә кешеләрнең бөтенләй ватылганын көтеп торыйкмы?

Чыннан да баштарак алар шактый кешене эштән азат иттеләр, чөнки аларда башланып килгән авырулар таптылар. Ә бер елдан соң больничныйга чыгучы хатын-кызларның саны бик нык кимеде. Профессор Ильясовага моның өчен күз яше түгеп рәхмәт укучы да, кочак-

кочак чәчәк киттерүче дә булмады. Ләкин нәкъ менә шушы казанышы— бик күпләрне авыр чирдән, куркыныч операцияләрдән саклап калуы Җәмилә Закировнага иң зур куаныч бирә дә инде. Ул һәр авыр операцияне врачларның эшләп җиткермәү нәтиҗәсе дип саный иде. Киләчәктә авыр операцияләр сирәк вакыйга булып калачак, чөнки кешеләр үзләрен үзләре карый белергә өйрәнәчәкләр.

Яшь врачларны да эшнең нәкъ менә шушы юнәлешенә өйрәтергә кирәк.

Җәмилә Закировна күз кырые белән генә Ларисага карап алды. Бил турыннан гына торган кара күн пинжәк, эре шакмаклы киң, озын юбка, бәйләгән берет кигән, муенына салган шарф очлары тезенә төшеп тора. Троллейбустагыларның күбесе аңа текәлгән. Лариса — модный киемнәрне иң беренчеләрдән булып кияргә күнеккән.

Поликлиниканың медсестрасы, яшь, оялчан Вәсилә аларны проходнойның ишек төбендә үк көтеп тора иде инде. Алар эчкә кереп, ян коридорга борылгач, яннарыннан күзлекле яшь хатын узып китте, аның күгәренке йөзе сагышлы иде.

— Кем бу?— дип сорады Җәмилә Закировна Вәсиләдән.

— Бумы?— Вәсилә турникетка кергән хатынга борылып карады.

— Ә-ә, Алтынчәч апа. Үзәк лабораториядән. «Алтын куллы лаборант» ярышларында гел комиссиядә утыра, кызлар аннан куркып тетрәп торалар.

— Ул сезгә учетка баскандыр инде, әйеме?

Кемнеңдер күзгә күренмәс кулы Вәсиләнең йөзен алга мангандай итте.

— Ю-ук,— диде кыз сузып.— Алтынчәч апаның бу айларда безгә килгәне юк. Ну... ул ялгыз бит. Шуңа килми торгандыр, дибез. Үзебез барып әйтергә яхшы түгел.

Вәсилә, ялгыш сүз ычкындыргандай куркынып, профессорның йөзенә текәлде.

— Менә нәрсә, Вәсилә, син Алтынчәч апаңны минем янга чакыр әле. Прием бетүгә керсә, яхшы булыр иде.

...Ул ишектән алга таба авышыбрак, кыюсыз гына керде. Бусага янында ук тукталып, калын күзлек аша профессорның йөзенә керфек тә какмый текәлде, әйтерсең лә карашы белән: «Йөземә кара, йөземә генә, гәүдәмә күзеңне төшермә»,— дип ялвара иде.

— Утырыгыз,— диде профессор каршындагы урындыкка ишарәләп.

Алтынчәч өстәлнең икенче башында язып утырган Ларисага аркасы белән урнашырга тырышты. Профессор бу хакыйкатьне аңлады: бу хатынның күңелендә шеш булып сагыш утыра, кисеп җибәрмичә, ягъни авырттырмыйча гына ул шешне дәвалап булмый. Ә җаны сизгер, күңеле нечкә, сабырсыз, анестезия чаралары файда бирмәячәк. Иң яхшысы — кискен хәрәкәт белән шешне ярып җибәрү. Һәм Җәмилә Закировна скальпель белән кисәк сызгандай итеп:

— Сез авырлы,— диде.— Бу хәлегездә сез врачның игътибарын җәлеп итәсез. Учетка бастыгызмы әле?

— Өлгерермен әле, ашыгыч түгел...— Алтынчәч борылып, җилкәсе аша Ларисага сагаюлы караш ташлады, аның баш күтәреп карап торганын күргәч, куырылып килгәндәй булды. Профессор аның хәлен аңлады.

— Лариса Сөнгатовна, онытып торам икән, минем директорны күрәсем бар иде. Секретарьдан белешегез әле, монда микән? Булмаса, кайчан килә.

Лариса профессорга мәгънәле караш ташлап, кабинеттан чыгып китте.

— Сезнең өчен хәзер иң мөһиме, баланың нормаль үсеше, шулай бит?— диде Җәмилә Закировна Алтынчәчкә.— Аның өчен беренче чи-

ратта сезнең сәламәт һәм шат булуыгыз кирәк. Күңелегез бик төшенке күренә, эштә бер-бер хәл булдымы әллә?

Алтынчәч юк дигәнне аңлатып башын селкеде.

— Ананың кәефе балага бик нык тәэсир итә,— дип дәвам итте Җәмилә Закировна.— Сезнең мондый хәлдә йөрүегез аның файдасына түгел. Әйтегез әле, нинди борчуыгыз бар? Бәлки, мин ярдәм итә алырмын?

Алтынчәч башын иеп:

— Дөньяда бәхетсез мәхәббәт дигән нәрсә дә бар бит,— диде.— Әйтик, кыз егетне ярата, ә егет икенче бер кызга гашыйк...

— Була андый хәлләр. Ләкин андый мәхәббәт өченче берәүнең яралуына нигез була алмый бит әле,— диде Җәмилә Закировна сак кына.

— Аны салкын акыл белән сөйләү җиңел. Ә янган йөрәк нигезеннән тикшереп торамыни? Егет башка берәүгә өйләнә, еракка китеп бара...

Алтынчәч, бутала-бутала, араларның мәңгегә өзелгәнен аңлатырга тырышты. Җәмилә Закировна аны бүлдермичә тыңлады. Ул инде скальпельнең өстән генә шуып үткәнен, хәсрәт шешен төбенәчә яра алмаганын аңлаган иде. Бусы — өстәрәк ятканы, сөйләп була торганы. Иң эчке серен Алтынчәч, бәлки, беркемгә дә ачмастыр.

— Сөйкемле сөягегез бар, димәк, бер караш, бер елмаю белән кешеләрнең күңелен эретә аласыз.

Профессорның шушы бер җылы сүзе дә Алтынчәчнең йөзенә җан кертте. Йөзеннән үк күренеп тора — сәламәтлеге бик шәптән түгел иде бу хатынның. Ләкин куркытырга ярамый, Җәмилә Закировна аңа бик саклык белән генә тикшерелергә, киръксә дәваланырга күндерергә тырышты.

Лариса — зирәк хатын икән, Алтынчәч чыгып киткәч кенә керде.

— Директор иртәгә генә була, диделәр,— диде ул мәгънәле итеп.

Алар киенеп чыкканда, проходнойда Алтынчәч тора иде. Ул кулындагы кәгазьгә стенадагы игъланнан нидер күчерә иде. «Инглиз сөйләм телен тиз арада үзләштерү буенча курс... Чит ил белгечләре белән эшләүче барлык инженер-техник персоналга мәҗбүри... Институт бинасында... доцент Мансурова...» дип укыды Җәмилә Закировна узып барышлый гына. Лариса игълан каршында тукталып калды. Җәмилә Закировнаны урамда гына куып җитте.

— Җәмилә Закировна, безнең кафедрада да шундый курслар оештырылмас микән?

— Планда андый нәрсә юк иде әле.

— Җәмилә Закировна, сез ничек уйлыйсыз, әгәр мин Ләйлә Мөбарәковнага барып, менә шушындый бер курска язуын үтенсәм, каршы килмәс микән? Нинди рәк ул, бик кырыс түгелме?

— Минем аның студенты булганым юк бит әле,— диде бу сүзләрне шаяруга борып Җәмилә Закировна.

— Артта калабыз бит, Җәмилә Закировна, бу заманда инглизчә сөйләшә белмәү бик зур наданлык билгесе. Әгәр мин үзем кызыгыз янына барып сөйләшсәм, сез ачуланмассызмы?

— Ник ачуланыйм? Үзара килешәсез икән, бик яхшы.

Җәмилә Закировнаның уйлары бөтенләй башкада иде.

*
* *

Үенны балалар гына яратамыни? Юк, үенны кеше җитлеккәч тә, олыгайгач та ярата. Ләкин еллар узган саен, без уйнарга ояла башлыйбыз, аннары аның рәтен бөтенләй онытабыз. Өлкәннәрнең уен ди-

гәне дә житди эшкә охшап кала. Без һәр кылганыбызны тырышып, көчәнеп башкарырга омтылабыз.

Хәлбуки, күп кенә очракларда безгә уйнау хәерле булыр иде. Уйнап кына эшләнгән эш җиңел бирелә, рәхәт башкарыла.

Ләйләнең укыту методы нигездә уенга корылган.

Монда ул үзе «Леди Ләйлә», аның тирәсендәгеләр — шаһлар, министрлар, атаклы артистлар, сәяхәтчеләр. Монда гади кеше юк.

Курсларны Леди Ләйлә үз кафедрасында алып барырга ярата. Биредә аның ике дистә елга якын эш дәверендә булдырган үз дөньясы, үз рухы. Коридорга керү белән үзеңне яңа бер дөньяда итеп тоясың. Стенага зур стенд ясалган: уртада Лондонның Темза елгасы аша салынган күпере, анда, бер-берсенә сыенып, егет белән кыз басып тора. Ә тирәли инглиз мәкальләре: «Яхшы ирне кулга төшерер өчен хатын сукыр булырга тиеш», «Телсез хатын белән чукрак ир генә яхшы пар була алалар...» Дөнья халыклары шаяра белә!

Аудитория стенасына Вестминстер сарае, Зур Бен манарасы ясалган. Һәркемгә таныш бу силуэтларда әчке бер мәгънә, сагыш һәм өмет бардыр шикелле, якынрак килсәң, андагы күгелҗем томан артында Шекспир һәм Вальтер Скотт геройларын күрерсең кебек.

Бу рәсемнәр, стендлар, күргәзмә әсбаплар, барысы да студентлар кулы белән ясалган. Кайчак йомыкый гына күренгән студентлар да ачылып китеп, шундый берәр хикмәтле әйбер эшләп куялар.

Бүген укытучының да күңеле аеруча күтәренке: Мәскәүдән аның өченче дәреслеген җибәрделәр. Димәк, зур эш тормышка ашкан, китаплар өчесе дә дөнья күргән, дигән сүз.

Мондагы аудиторияләрдә урындык-өстәлләр гадәттәге тәртиптә тезелеп тормыйлар, дәрес саен урыннан урынга күчереләләр.

Ләйлә беренче тапкыр очрашканда ук үз укучыларына шулай аңлатып куя.

— Беренче курсны тәмамлагач, сезне бик еракларга илтеп ташларга була, сез инде адашып йөрмәячәксез, ачтан үлмәячәксез. Ипи-тоз сорап алырлык, юл сорарлык сүзләр беләчәксез...

Һәр уку елының программасы шул рәвешле ачык итеп куела.

— Шуның өстенә без сезнең белән ул халыкларның фикерләү үзенчәлекләрен аңларга тырышачакбыз. Төрле телдә сөйләшкән халыклар бер-берсеннән аермалы фикер дә йөртәләр бит.

Алай да доцент Мансурова үзенең төп максатын әйтеп бетерми. Ул яшьләргә тел өйрәтү белән генә чикләнеп калмый, моны тәрбия чарасы итәргә, яшьләрне уңган, киң карашлы, олы йөрәкле итеп үстерү чарасы итәргә омтыла.

Заманында беренче тапкыр кафедрага укытырга килгәч, ул, чит тел дәресләренең ялыктыргыч һәм авыр икәнен күреп, бик борчылган иде. Ул дәресләрне җанлырак, күңеллерәк, нәтиҗәлерәк итү чараларын эзли башлады. Студентлар күбрәк сөйләшсеннәр, теле ачылып килгән бала шикелле, ялгышсалар да оялмасыннар, ничек тә үз фикерләрен аңлатырга тырышсыннар. Баланың теле бер ел эчендә ачылып бетә диярлек. Ә нигә соң зиһене үткер, акыллы, житлеккән яшьләр чит телне унар ел тукып та өйрәнә алмыйлар? Сабый чактагы сәләт кешедә елдан-ел кими бара, шуңа, дип аңлата кайберәүләр. Юк, хикмәт анда түгел, унҗиде-егерме яшьтә телгә сәләт ике-өч яшьлектән ким булмый, бары тик телгә өйрәнү методларының уңышсыз булуын гына күрсәтә бу хәл.

Ләйләнең методы чит телдә сөйләшүгә тиз вакыт эчендә өйрәтү курслары өчен дә бик яхшы булып чыкты.

Бүген Ләйлә яңа җыелган шундый группа белән дүртенче дәресен үткәрә. Ул аудиториягә килеп кергәч, барысы да елмаештылар, тик Вафина Алтынчәч дигән хатын гына житди калды.

Лэйлә уртага басты да, кулын өч тапкыр чәбәкләп:

— Башлыйбыз! — диде.

Шул чак ишек ачылып, Нигъмәтуллина килеп керде. Үзе генә түгел, бер ир кеше белән.

— Леди Лэйлә, мин сезгә тагын бер шәкерт алып килдем.

— Леди инглизчә генә аңлый. Сезнең юлдашыгыз леди белән ничек сөйләшергә уйлый соң? Сез миңа чакырылмаган килеш приемга килгәнсез. Ягез әле, үзегезне бу хәлдә ничек тотарга тиешсез?

Тирә-юньдәгеләр бөдрә чәчле, урта буйлы, эчтән яктырып торгандай ачык йөзле ир кешегә елмаешып карадылар. Ә Лэйлә аңа горур карап басып тора, аның сыны мәгърур, шоколад төсендәге күлмәге гәүдәсенә бик килешле. Эре итеп бөдрәләткән чәче пөхтә, ләкин гади. Көнчыгыш хатын-кызларына тартым йөзендә гадилек белән бергә үз дәрәҗәсен белү, көнбатыш кешеләренә хас үзен иркен тоту да сизелә.

— Әйдәгез, алып килгәнсез икән, аны миңа тиешенчә тәкъдим итегез,— диде ул Ларисага борылып.

— О, мәрхәмәтле леди!

— Гадирәк. Безгә, инглизләргә, япон этикетына хас төчелек килешми.

— Хөрмәтле леди... рөхсәт итегез... минем юлдашым...

— Инженер Уразов,— дип башын иде ир кеше һәм вәкарь белән генә килеп лединың кулын үпте.

— Әйдәгез, гомуми әңгәмәгә катнашыгыз,— диде Лэйлә. Ул уртага ике егетне чакырып, аларга химик элементлар хакында әңгәмә корырга тәкъдим итте.

Бу дөньяда кызыклы нәрсәләр шул кадәр күп, аларны белергә ун гомер җитмәс. Кеше акылы ирешкән нәрсәләр һәр өлкәдә таң калдыра. Химия белән кызыксына башлагач, Лэйлә моңа тагын бер тапкыр хәйран калды. Аларның институты химик-инженерлар әзерли, шуңа күрә ул дәресләренә шушы фән буенча текстлар кертте. Моның өчен институт китапханәсендә тезе белән шуышып шактый күп йөрде, чөнки инглиз телендәге химия китаплары аскы киштәләргә тезелгән иде. Аларны укый торгач, Лэйлә бу фәнгә шәрык кайнарлыгы белән гашыйк булды. Менделеев таблицасы гына да «Мең дә бер кичә» кебек икән, һәр элемент турында әкият, поэма, кыйсса язып була. Химиядәге ачышларның тарихлары үзләре бер детектив роман шикелле.

Лэйлә ул китаплардагы тарихлардан чит тел дәресләрендә уйнау өчен әңгәмәләр төзеде. Ике егет шул әңгәмәләрнең берсен уйныйлар. Берсе химиягә гашыйк кешене, икенчесе — битарафны. Лэйлә рольләрне капма-каршы рухтагы кешеләргә тапшыра. Оялчаннан — чаяны, дәртлерәктән — сабырны уйната ул. Алай кызыграк, кешенең холкы да тәрбияләнә.

Бу әңгәмә бетүгә, ул читтәрәк торырга тырышкан Вафинаны уртага чакырды.

Егетләр аның каршына өстәл китереп куйдылар, дәрәҗәлерәк күренсен өчен, Лэйлә өстәлгә үзенең яңа чыккан китабын китереп салды.

— Сез тәэминат министры. Ә сез, леди Лариса, аннан пенсия сорарга киләсез.

— Пенсия өчен мин яшьрәк әле,— диде Лариса русчалап.

— Ә сез — биюче. Җиде яшьтән башлап, унбиш ел биедем, закон минем якта, диегез. Сезнең эшләми генә акча аласыгыз килә, яки киеүгә чыгарга җыенасыз!

— Ну инде, без егермедән узган кешеләрне дә җәмгыять җилкәсендә асрый башласак,— дип вата-җимерә инглизчә каршы төште Алтынчәч.

— Леди Вафина! Һәркемгә түгел, миңа гына! Мин бөтен илгә бер! Мин әле тагын биермен, тик миңа бәби кирәк бит. Ансыз да булмый, ә ирләргә ышаныч, үзегез беләсез...

Лариса киная белән бөдрә башлы инженерга күз салды.

— Бәлки, Англия ирләре мондый кинаяне күтәрмидер?— диде кемдер кырыйдан.

Китте гадәттәгечә бәхәс, шаяру, көлү.

Лариса үзсүзле иде, ләкин министр да каты торды, ниһаять, сүзне тәмамлаганын аңлатып, урыныннан торып басты.

— Гафу итегез, леди Нигъмәтуллина, минем кабул итү сәгатем тәмамланды. Тагын егерме елдан рәхим итегез!

— Сез әле егерме ел шушы урында утырмакчымы? Мин сезгә каршы тавыш бирәчәкмен!

Карале, Ләйлә Вафинаны йомыкыйга санап йөри иде, минуты житсә, кыяфәте нинди горур була ала икән. Ларисаның соңгы сүзләрен санга сукмаганын белдереп, ияген күтәреп, күзлек пыялаларын гына елтыратып куйды. Йөзе нурланды, сәламәт кыяфәт алды.

— Шәп министр бу, моңа ышанырга була!— диештеләр тирә-якта. Ләйлә Ларисаны чакырды.

— Сез миңа бу шәехнең дүрт хатыны арасыннан иң сөеклесе.— Ул Әнвәрне ишарәләп чакырды.— Ул сезне үзе белән чит илгә сәяхәткә алып бара. Шәех әфәнде, сезнең Гарәбстанда тагын өч хатыныгыз, алардан туган шактый күп балаларыгыз, чүлләрдә бихисап куй һәм дөя көтүләрегез, берничә сараегыз бар. Гарәп шәехе — бик бай һәм горур кеше. Сезнең хатыныгыз... ай-яй, гарәп шәехе хатынын болай йөртәме? Җиң сәдәфләрен каптырырга, түшне капларга кирәк булыр. Ә башыгызга пәрәнҗә киегез. Яулык бөркәнсәгез дә ярап торыр...

— Хатын шәп, шәехнең зәвыгы бар икән,— диде шактый иштетереп кемдер.

Ларисаның башына яулык бөркәделәр, бер егет алар каршына басып:

— Ә бу кем? Ни өчен ул чик аша яшеренеп узмакчы була? Йөзен ачып күрсәтсен! Мин кем узганын белергә тиеш!— диде.

Инженер Уразов әле берничә тапкыр гына булганга, рольләргә кереп бетә алмаган, сүзләрдә бутала иде:

— Ноу, ярамый... Минем хатын...

— Ә мин каян беләм? Ә бәлки сез хатын дип берәр шпион я контрабандист алып кермәкчедер? — Егет Ларисаның яулыгына кулын сузды.

— Ярамый... Нәмәхрәм!— диде аптырагач Әнвәр.

— Марихуана!— диде таможенник ролен уйнаган егет.

Шундый уен-көлке белән дәрес сизелми дә үтеп китте.

*

* *

— Карале миңа, карале!

Лариса биленә таянып, урам фонаре яктысына кереп басты.

— Нигытып кара!


Гәүдәсен кысып торган күн пинжәк, киң итәк, йөнтәс берет кигән Лариса әле генә мода журналыннан сикереп төшкән кебек күренә иде. Яшь, чибәр, чая! Урам фонареның алдавыч яктысы аны курчак кебек күрсәтә иде.

— Әйт, минем кай җирем аннан ким?

— Кемнән, Лорочка?

— Леди Ләйләдән кимме мин?

— Ну, Лора, таптың чагыштырыр кеше... Ул бит... Ул бит...



*Тавил Хажиәхмәтов рәсеме*

— Нәрсә, ул хатын-кыз түгелме әллә?

— Ул бит бөтенләй икенче дөнья кешесе! Бу инде пешкән җир җиләген... ничек дип әйтим...— Әнвәр як-ягына каранды,— ну, тулган ай белән чагыштырган шикелле.

— Ә мин кем синеңчә? Җиләкме, аймы?

Әнвәр тамак төбе белән генә көлеп куйды.

— Әйдә, аныклап бетермик әле. Минем өчен син тулган ай да, татлы җиләк тә. Мин сине беркем белән дә чагыштырырга җыенмыйм.

— Мин аннан ким түгел, шулай бит?

— Юк инде, юк инде,— дип шаярып аның аркасыннан сыйпады Әнвәр.

— Ә нишләп аның бөтен эше шулай көйле генә бара да, нишләп минеке һаман тупикка килеп терәлә икән соң?

— Ну, Лорочка! Инде син дә зарлансаң! Егетләрнең мена дигәннәре сөя үзеңне, сайлап ал. Күпме кешеләр керергә хыялланып та керә алмаган институтта укыдың, нинди мактаулы профессор кул астында эшлисең. Канәгать була белергә кирәк!

— Ништяк! Инде син дә минем хакта болай уйлагач, кемгә зарымны сөйләрмен! Иргә чыктым — ялгыштым... Үзең беләсең бит инде... Һөнәр сайладым — ялгыштым! Профессорда — анысында да ялгыштым!

— Нигә? Кешеләрне дәвалау ошамыймыни? Аларның газапларын җиңеләйтү канәгатьлек бирмимени?

— Үз ихтыярың белән гомереңне хасталар арасында уздырасың инде, шул! Сызлану, сыкрану, шакшылык! Кайберсенең янына барасы килми. Тир исе аңкый, тешләре тазартылмаган, чәчләре тузган, халатлары шакшы! Үзеңнән һәрвакыт больница исе килә! Фу!

Алар урамнан баралар иде. Бу сүзләрне әйткәндә, фонарь турысыннан узып киткәнгә, Ларисаның йөзе күләгәдә калды. Әнвәр аптырап аңа карады, сүз табалмый берничә адым атлады. Аннары гаҗәпләнүен бик үк сиздермәскә тырышып:

— Ә миңа... врачлардан бөтенләй башка сүз ишетергә туры килә,— диде.

— Шул бер ягы бар инде: хасталар арасында айкалып кайткач, яшәүнең кадерен ныграк белә башлыйсың. Бер йотым су эчү дә олы бәхет булып тоела. Бу Ильясова да бик вакчыл кеше булып чыкты. Инде бөтен нәрсә ачык бит югыйсә, ә ул яңадан яңа тикшеренүләр таләп итә, фәнни эшне дөньяга чыгарырга рөхсәт бирми, әллә кая заводларга барып йөрергә мәҗбүрмен.

— Бала табарга кирәк сиңа,— диде кинәт Әнвәр.— Э-э...— ул бераз тотлыгып торды,— врачлар әйтә... ана булгач, кешеләргә мөнәсәбәт бөтенләй икенчеләнә, ди. Авыруларны үз балаң кебек күрә башлыйсың икән. Бала нинди хәлендә дә күңелгә газиз бит.

— Санын җыя алмаган карт, ямьсез хатыннарны балаң итеп күрү өчен акылдан шашкан булырга кирәк! Кем әйтте сиңа ул сүзне? Ә-ә, Зәйтүнә, әлбәттә!

— Кем булыр иден соң син? — дип ашыгып аның сүзен бүлде Әнвәр.

— Хәзерге акылым булсамы? Чит телләр институтына керер идем. Тәрҗемәче булып китәр идем. Я манекенщица. Матур киенеп, чибәр кешеләр арасында бөтен дөнья гизеп йөрер идем рәхәтләнеп. Әллә булдыра алмас идемме?

Лариса, башын күтәреп, аның каршына чыгып басты. Фонарьларның күзне алмаштыра торган яктысында күңелне иләсләндерә торган дәрт, хис бөркелә иде аның йөзеннән.

Әнвәрнең иреннәре кипшенде.

— Төрле милләт егетләренең йөрәкләре түшәлгән юлдан гына йөрер иден,— диде ул.

— Әйт әле, Анварчик, әйт әле дөресен генә, нигә бераүләрнең бәхете аягына уралган да, нигә минем тормыш һаман чалыш-чолыш бара? Балачагымда әти белән әни икесе ике якка китеп, мине әле әбиемә кайтарып ташлап, әле үзләренә алып башымны катырдылар. Анда кайсына карарга белми идем. Ә бу Ләйлә ата-анасын да үзе сайлап алган диярсең. Атасы профессор, анасы профессор. Ильясова да хәйләкәр, медицина ягына тартмаган, күренекле һөнәр сайлаткан кызына!

— Җаны теләгәнне үзе сайлагандыр, әнисе авызына карап тормагандыр, бәлки,— дип Ләйләне яклады Әнвәр.— Һөнәрдә түгел хикмәт, минемчә, кешенең үзендә!

Әнвәр сүзне икенчегә борырга тырышты:

— Бир әле сумкаңны, иңеңне баса. Нишләп бу хәтле авыр, таш тутырдыңмы әллә?

— Әйе, яшь белә кешеләр! Акыл белән яшиләр!

Әнвәр йомшак сумканы капшап, шешә барлыгын чамалады.

— Запас белән йөрисең икән.

— Премия ул миңа, яхшы эшләгән өчен,— диде Лариса.

— Сезгә премияне натуралата бирәләрмени?

— Акчалата алмыйбыз, ришвәт була. Ә мондые — чәчәк, конфет ишесе гөнаһ түгел.

— Күпме вакыт врач белән яшәп, андый премия бирелгәнен белми идем.

— Нәрсә беләсез соң сез? Ни беләсез?!

Алар трамвай тукталышына килеп чыктылар. Икесенә бер якка барасы, чөнки Зәйтүнә Ларисага квартирны каршы йорттан табып биргән иде. Бер студент кыз белән кечкенә генә бүлмәдә яши Лариса. Баш тыгар урыны бар, әмма шунысы җайсыз, теләгән кунагын алып кереп кенә булмый.

Әнвәр, трамвайдан төшмичә, арырак китәргә булды.

— Мин синең белән шушында хушлашам инде, Лорочка. Моннан үзең генә кайтырга курыкмассың бит?

— Ә син кая?

— Теплицаларга җылыны бүген генә җибәрдек. Торбалар чыдармы, карап кайтырга кирәк. Төнлә төрле хәл булуы ихтимал. Үзе юкның күзе юк.

Лариса үпкәләгәндәй итте:

— Минем сыйдан баш тартасыңмыни?

Ул сумканы алып, озын бәвын иңенә киде.

— Башка вакытта, Лорочка.

— Анварчик, мин сине үзем белән чакырдым бит бүген, нинди күңелле җәрескә алып бардым. Әйдә, син дә мине чакыр.

— Кая?

— Теплицага. Минем гомеремдә бер тапкыр да теплица күргәнем юк. Ә күрәсе килә. Кыяр-помидорлар ничек үсә икән анда?

— Хәзер анда кыяр да, помидор да юк әле. Утыртырга әзерләнәбез генә.

— Минем белән күңелсез булыр, дип куркасың инде.

— Әйдә алайса,— дип әйтеп ташлады Әнвәр үзе дә сизмәстән.

Лариса иңе белән аның күкрәгенә сыенды. Аның бу хәрәкәтеннән тән эсселәнеп китте, Әнвәр кеше-кара күзеннән яшеренергә теләгәндәй, куртка капюшонын күзенә төшеребрәк киде. Ул күзе майлы елтыраганын, эчке мәгънә белән елмаеп барганын үзе дә сизә, моны трамвайдагылар да күрәләр дип шомлана, ләкин карашын да, елмаюын да үзгәртә алмый иде. Үзе теләмәсә дә, тәне Ларисага тартылып эсселәнә иде аның.

Трамвайдан соң троллейбуска күчеп утырдылар. Шәһәр читенә чыккач, ниһаять, ул кап-караңгы бер төштә туктады. Уң якта җирдән шактый күтәртеп сузылган юан-юан торбалар шәйләнә, алда завод утлары җемелди.

Әнвәр Ларисаның туңып киткән кулын каты итеп кысты да, сулга, биек коймага таба алып китте. Капка каршыда гына иде, шактый озак шакыганнан соң, эчке якта лаштыр-лоштыр аяк тавышлары, аннары карт кешенең: «Кем анда!» — дип сораганы ишетелде.

Капка ачкан каравылчы юлга аркылы басып, җентекләп Ларисага текәлде.

— Мин теплицаларны карап чыгам әле,— диде Әнвәр һәм карттан ышыклабрак Ларисаны эчкә үткәрде. Алар караңгыда агарып күренгән озын корылмага таба киттеләр. Теплица ишеге төбенә җиткәч, Әнвәр коры гына:

— Аягыңны сөртеп кер,— диде.— Безнең мастерлар гомумән чит кешеләрне теплицаларга кертмиләр.

— Алайса, кермәм.

Әнвәр аны көйләп маташмады, моны сизгән Лариса аягын ныклап сөртте.

Гөлт итеп ут кабынгач, ул бераз күзләрен челт-челт йомды да, як-ягына каранды. Теплицаның эче ямьсез, күңелсез булып күренде. Полиэтилен түшәм, пыяла стеналар, ике яктан сузылган торбалар, баганалар, кара җир. Җитмәсә эссе, бөркү, бер мизгелдә куллар, бит һәм кара күн пинжәк суга манчылгандай дымланып чыкты.

— Шушымыни инде синең җан атып йөргән теплицаң?

— Син аны март айларында күрсәң иде. Кара урман кебек була ул. Яфрак арасында качкын ятарлык. Сабаклардан озын-озын кыярлар асылынып тора. Менә былтыр, уртага бер рәт булып райком секретарьлары тезелеп баскан иде. Республика җитәкчеләре аларны ниндидер бер киңәшмә вакытында монда экскурсиягә алып килделәр. Күзләре дүрт булды начальник абзыйларның... Рельска абына күрмә. Шуннан... теге абзыйларга бераp кыяр өзеп алырга да рөхсәт иттек. Балаларына күчтәнәчкә.

— Нигә берәрне генә?

— Җиткән. Мастерлар аны беләсеңме күпме хезмәт куеп үстерәләр. Һәр үсемлекне сабый караган кебек тәрбиялиләр.

Теплица хакында сөйли башлагач, Әнвәр тынычланып, дәртләнеп китте.

— Романтично. Тик бөркү генә. Тагын да бераз торсак, мин тәмам пешеп җитәчәкмен, син мине шул килеш тотып ашый алачаксың.

— Әйе шул, бөркүрәк,— диде күңелсезләнебрәк Әнвәр.— Үсемлекләргә дым кирәк, җылы кирәк. Нишлисең, мастерлар чишенеп эшлиләр.

— Егетләргә күзләргә җайлыдыр инде.

— Юк, әйтәм ич, монда куелык, берни күренми. Алар ишекне эчтән бикләп куялар. Былтыр кышкы салкыннарда күзгә йокы кермәде инде. Әгәр шунда утырткан әйберләребез өшесә, хур була идек. Ике көн карыйбыз, өч көн — җылы! Пыяла астында суганнар өшеп бетте, мондагылар калды. Шундый көннәр өчен генә булса да дөньяда яшәргә була, Лорочка.

Әнвәр аның иңнәреннән кочып күкрәгенә кысты. Лариса аяк очларына басты да, аның иреннәренә үрелде. Вокзаллардагы ише генә түгел, каты итеп, озак итеп, тынны буып үпте ул бу юлы.

— Узган елны җиңүең белән котлап,— диде аннары тирән сулыш алып.

Әнвәр аңа җавап бирә алмады, тизрәк чыгу ягын карады. Икенче

бүлмөнец ишеге янында ут кабызып кына карады ул, өченчесенең янында тынып кына торды, башкалары янына бармады.

— Ярый, сине ялыктырып йөрмим инде,— диде.— Ул-бу булса сизелер әле.

— Алар барсы да шушылай бушмы?

— Суган утырттык инде. Озакламый тишелеп чыгачак. Суганга да иртәрәк әле, бер өлеше генә тишелеп чыга, калганы уянып житмәгән була. Аларны кире алып яңадан утыртырга туры килә. Андыйны недогон диләр.

— Уянмаган?— Ларисаның тавышында зур кызыксыну ишетелде.— Суганның да уянганы, уянмаганы буламыни?

— Була шул.

— Суган да шулай булгач, кешегә ни кала,— дип көрсенде Лариса.— Суган башының да һәркайсының үз җылылыгы, үз вакыты, димәк. Алар өчен дә төгәл генә кагыйдә юк. Ә кешеләр өчен закон куелган! Кызлар унсигездән алда кияүгә чыкмасын, аннары ирен генә сөйсен, башкаларга күз салмасын... Ә йөрәк, ә кешенең табигате андый законга туры киләме? Ә бәлки минем йөрәгем шундый недогон шикелле уянмагандыр әле! Ә бәлки мине иртә утырткаоннардыр! Хәзер генә вакытым житкәндер минем!

Һәрнәрсәдән шундый бер көтелмәгән нәтиҗә чыгара белә Лариса, кеше башына килмәс рәвешле уйлый. Чыннан да шулай бит. Зәйтүнә белән Әнвәрнең мөнәсәбәтендә дә шундый недогон кебегрәк нәрсә бар. Житлекмәгән аларның мәхәббәте, җанланмаган. Уянмаган әле Зәйтүнә... Шулай да... Шулай да Әнвәр аның уяначагына ышана. Менә аның да язы шаулап килер һәм гөрләвекләр булып ганлә тормышына бәреп керер. Сабыр итәргә кирәк Әнвәргә. Күңелне кузгата торган, карашының кешеләрдән оялырлык дәрәҗәдә үзгәртеп, иреннәрендә ят елмаю тудыра торган бу хатыннан читтәрәк булырга кирәк. Хыянәткә барырга ярамый. Әле дә соң түгел, капка төбенә чыгарга да троллейбуска утырырга, өенә озатып саубуллашырга... Капкадан гына чыгарга кирәк, калганы үзеннән үзе эшләнер...

— Бу шешәне кая куябыз соң?— диде Лариса.— Кире ташып йөрмәбез бит инде. Синең теплицада үскән уңышың өчен бокал күтәрәсем килә минем. Дөрес, закусканы әзерләп куймагансың икән.

Бу житди сәбәп иде. Әнвәр кайнарланган мие белән шуны уйлады. Закуска юк, ә Лариса кебек нечкә табигатьле хатын закускасыз гына, урам уртасында шешә авызыннан шәраб эчмәс.

— Янымда син булганда, закускага аптырамабыз,— диде Лариса.— Баш инженерның монда бер почмагы бардыр бит инде.

— Бар,— диде Әнвәрнең иреннәре ихтыярсыз.— Ничек булмасын, бар, әлбәттә.

Моны ул баш инженер буларак дәрәҗәмне күтәрәм, шуның өчен генә әйттем, дип акланырга тырышты. Ләкин йөрәк шашып тибә, йөрәк моның ни өчен әйтелгәнен яхшы белә, ул алданмый иде.

Кечкенә бүлмәнең стеналарына ямьсез яшькелт-соры обой ябыштырылган, өстәл кырпылып беткән; анда тәртипсез рәвештә сызым битләре, кәгазьләр аунап ята. Әнвәр беренче тапкыр бүлмәсенең күңелсезлеген күреп оялды, ләкин Лариса стенага түгел, ян-яктагы иске диванга караган иде.

— Начар түгел,— диде ул.— Җылы, ләкин тегендәге ише бөркү түгел. Әйтәсе дә юк, начальство яхшы яши инде ул!

Ул сумкасыннан биш йолдызлы коньяк тартып чыгарды. Әнвәр почмактагы тумбочка өстеннән стакан, яртылаш су салынган графин алды. Графин күптән юылмаган, стакан таплы иде, әмма Лариса борынын җыермады, кәгазь сорап алды да, аны чылатып, стаканны ялтыратып та куйды.

— Бокаллар тотарга кирәк, иптәш баш инженер. Зур начальниклар килә үзегезгә, каршыгызда пионерлар кебек тезелеп райком секретарьлары басып тора, ә сез аларны кунак та итмисезмени соң?

— Кирәк булса, күңел ачарга моннан яхшырак урын табарлар.

Әнвәр стаканга яртылаш коньяк салды.

— Тутырып!— диде Лариса.— Икебезгә дә житәрлек булсын. Утны да сүндерергә вакыт. Әллә син караңгыда минне тапмам дип куркасыңмы? Качыш-качыш уйнарбыз, кызык булыр. Я, менә яныма диванга утыр.

Коньяк ачы булып тоелды. Әмма закуска — Ларисаның иреннәре татлы да, утлы да иде. Алай да Әнвәрнең аңы бөтенләй үк томаланмаган иде әле.

— Тешләмә...— дип пышылдады ул.

— Чын ләззәт сызлану белән була,— диде Лариса һәм каршы әйтергә ирек бирмичә, янә авызын сулышы белән томалады. Әнвәрнең күз алдында һаман әле Зәйтүнә белән Тимербулат шәйләнә: «Китәргә кирәк, әле соң түгел»,— дигән уй айкала иде.

Лариса аның иңенә йомшак кына сыенды да, бөтенләй моңарчы булмаганча итеп:

— Әнвәр, әйт әле, теге чакта аэроклубка Зәйтүнә белән мин дә килгән булсам, син безнең кайсыбызны сайлаган булыр идең?— диде.— Ул мине үзе белән чакырган иде бит. Соңыннан мин аның өчен белешмә дә алып йөрдем әле. Хәтерлисеңме? Их, шунда ник кенә бармадым икән соң мин? Бәхетеңне кайчан табасыңны белсәң икән! Белмәдем шул мин, белмәдем! Хәзер шуның газабын күрәм инде менә!

Әнвәр аның бөдрәләрен сыйпап кулын аска шудырган иде, бармаклары яшькә чыланды. Лариса елый иде.

— Соңрак та бу хатаны төзәтеп була иде, ә син тулай торакка килгән чакларыңда да мине күрмәгәндәй кылана идең. Ничек газапладың син мине, Әнвәр, нинди утларда яндырдың! Син минем бердәнберем идең бит! Гомерлеккә шулай булачак идең!— Лариса аның муенынннан кочып алды да, күкрәгенә ятып үксп башлады.— Хәзер син мине бер бозык хатын дип уйлыйсыңдыр инде. Минем башка чарам юк бит, Әнвәрем, йолдызым! Син мине үзең чакырмый идең бит. Әбием әйтә торган иде, Әнвәр йолдыз дигән сүз ул дип. Минем Әнвәр исемле кардәшем бар иде авылда. Син шул минем буй җитмәс йолдызым булып калырсың микәнни инде? Ерак йолдызым булырсыңмы? Синең белән болай бер утыру өчен башларымны җуләргә салырга туры килде бит миңа.— Ул кинәт башын күтәрде дә, Әнвәрне иңнәреннән тотып селекте.— Нишләп утырасың инде болай! Куып чыгар мине! Тотып сугып җибәр! Гайрәтемне чигерерлек берәр нәрсә эшлә ичмасам! Гомер буе бу утларда яна алмыйм бит инде мин!

Моңа кадәргесенә Әнвәр түзә иде әле. Монысы соңгы тамчы булды. Әнвәр аны кочагына алды да бөтен дөньясын онытты.

*

* *

— Күзеңә ни булды синең?— дип сорады Зәйтүнә иртә белән.

— Ә, бумы?— Әнвәр тышкы ишек янына беркетелгән көзгегә карады. Чыннан да, аның күзләре кызарып чыккан иде.— Бу соң салкын тию бәласе инде. Теплица бик эссе бит.

— Син ул теплицаларыңны сәламәтлек чыганагы дип мактанган идең бит әле.

— Мастерларга чыннан да шулай. Алар бер кергәч чыкмый эшлиләр. Ә миңа кереп-чыгып йөрергә туры килә. Бер эссе, бер салкын.

— Каты чәй белән юып җибәр,— диде Зәйтүнә.— Әнә, чәйнектән салып ал үзең.

Ул инде иртәрәк торып киенеп куйган, хәзер Тимербулатны киендерә иде. Иртәнге сигезгә баланы яслегә илтеп җиткерергә кирәк, ә ясле ерак, трамвай белән барасы.

— Һаман шул теплица да теплица,— диде Зәйтүнә.— Миңа да җиңел түгел бит. Баланы ясләдән алыр идең ичмасам.

Аның ире белән сөйләшер сүзе күп иде. Ләкин Әнвәр төнлә соң кайта. Теплицаларны җайлап җибәргәндә ул былтыр да шулай көннетөнгә ялгап эшләгән иде. Ул кайтканда Зәйтүнә йоклаган була. Ә сөйләшәсе килгәнен бер-ике сүз белән генә әйтеп бетерерлек түгел. Берничә көн инде авырып йөри ул. Өченче көнне дә эштән кайтканда температурасы утыз тугыздан арткан иде. Дарулар эчеп яткач, тән эссесе иртәнгә беткән иде. Җыенып эшкә китте. Ләкин йөткергәләп торуы бетмәде.

Зәйтүнәнең сөйлисе килгәне — аны бик зур начарлыкта, антына хыянәттә гаепләүләре.

— Миңа бик зур гаеп ташладылар бит әле,— диде ул көйсезләнгән Тимербулатның пальто төймәләрен эләктерергә тырышып.— Бер авыру хатынны сөйләгән идем бит әле узган елны? Биш айлык баласын төшерде?

— Андый хәлләр сездә булгалап тора инде,— диде Әнвәр. Аның башы авырта иде.— Улым! Улы-ым! Кил әле миңа!

— Шуның ире әйтә, сез, ди, авыруларга зыян китерәсез, ди.

— Браксыз эш буламыни хәзерге заманда? Җыен ахмакның сүзен тыңласаң, башың катар. Тыңлама син андыйларны. Минем улым тү-тү бара... Бәбиләр янына, тәтиләр белән уйнарга. Кочакла әле, улым, әтиеңне. Менә шулай, менә шулай...

Әнвәр белән аңлашып булмады.

— Кая китер, соңга калабыз,— диде Зәйтүнә. Көзгегә ялт кына карап, шома чәчен артка таба сыпырып куеп, беретына толымын тутырып киде дә, саргылт плащын бала ботинкаларыннан сакларга тырышыбрак, улын кулына алды.— Бәлки син алырсың Тимербулатны?

— Үзең беләсең бит, Зәйтүнә, торбаларның бер җөе генә ярылса да күпме хезмәт юкка чыгачак.

— Кайтып ашап китәрсең.

— Алай итсәң була. Сау бул, улым. Хуш-хуш, диген. Менә шулай, менә шулай...

Ясләдә Тимербулат тагын елап калды. Зәйтүнә чыгып киткәндә, аның бөтен битен авызы гына тәшкил итә иде шикелле. Бичара сабый. Нихәл итәсең, әбиең авылга кайтып китте шул. Өч ай эчендә оныгын бик күп һөнәрләргә өйрәтеп китте: диванга менәргә, кул-аягын күрсәтергә, чүлмәккә утырырга, кулын чәбәкләргә. Тагын да күп нәрсәгә өйрәткән булыр иде әле. Тик менә көзгә таба шәһәрдә карчыклар өчен тормыш күңелсезләнә. Инде ишегалдындагы эскәмияләрдә ак яулык бәйләгән карчыклар тезелешеп утырмый. Гөлзәйнәп карчык шундый карчыклар янына батыраеп барып утыра иде дә, дөнья хәлләрен, узган гомерләрне сөйләшеп керә иде. Инде хәзер бала белән озаклап тышта йөреп булмый — суытты, яңгырлар башланды. «Авылда мин ичмасам ишегалдына чыгып чебиләрем белән сөйләшәм, казларга сәлам бирәм, бозау муеныннан сыйпыйм»,— дип авылын сагына башлады карчык. «Бер генә күзәнәгемнең дә монда торасы килми»,— диде ул бер көнне. Шуның өстенә килене Мөнирәдән, чөгендер алырга йөри башладык, дигән хәбәр дә килеп төшкәч, көнендә кыздырып кайтып та китте. Алар анда минсез яши алмыйлар, диде.

Тимербулатны яслегә урнаштырырга туры килде. Җитмештән узган карчык эшнең иң кызу җиренә ашкына, әле кызына, әле улына ярдәм итәргә ашыга иде.

Зәйтүнә эшкә бер трамвайдан икенчесенә күчеп бара. Көн болытлы, явып тормаса да, күңелгә авыр, җилле, салкынча. Тагын Хәйруллиннар искә төште.

Әнвәргә, игътибарга алма, дип әйтергә җиңел. Ләкин Хәйруллинның сүзендә хаклык та бар. Чыннан да Зәйтүнә зыян китерде. Дөрес, бу эшне ул башкалар ихтыярына буйсынып кына кылды. Әгәр Динә үзе моны теләмәсә, Кифая апа ялган белешмә табуда булышмаса, Фидая палатасына салып, иң каты чараларны күрә башламаса, Зәйтүнә үзе генә беркайчан да бу эшкә бармас иде. Ләкин болар да аның гаебен акламый. Динәне палатага салгач та күрде бит. Аның хата эшләвен дә сизде. Нигә соң шул чакта ук аның белән ныгытып сөйләшмәде? Нигә үгетләмәде, ниятеннән ваз кичтермәде?

Бу уйларның ачысы менә ничә көн инде тынгы бирми Зәйтүнәгә. «Үткән эш кайтмый, үкен син, үл, ела»,— ди шагыйрь. Ләкин киләчәк бар бит әле. Киләчәк шулай ук бик ышанычлы түгел. Хәйруллинага бер операция ясап, гомерен көчкә саклап калганнар бит инде. Яңадан тагын бер шундый ук операция ясарга туры килсә — ә андый хәлләр булгалый, больницага бер кергән кеше һаман әйләнеп кайтучан була!— ул чакта аның ана булуга соңгы өмете дә өзеләчәк.

Мондый үкенечле уйлар һәр врачның башына килгәнен дә белә Зәйтүнә. Табиплар хаталарның тагын да аянычларын кичерәләр әле. Кайсы гына табип, әгәр башкача эшләгән булсам, бәлки мондый хәл булмас иде, дигән газаплы уйлар белән башын иеп, табут янында басып тормаган!

Мондый үкенечләрнең үз башына да төшәчәген белә иде ул, ләкин моның белән һич тә ризалашырга теләми иде. Аның нидер эшлисе, ничек тә гаебен йоласы килә иде.

Нишли ала ул хәзер? Динәне чакырып китерергә, сәламәтлеген ныклап тикшерергә, кирәк булса, дәвалау чараларын күрергә кирәк. Менә шуны эшли ала Зәйтүнә! Бу — аз түгел.

Ире аша чакыртырга да китерергә. Авыр эш түгел. Зәйтүнә бүген үк заводка, Хәйруллинга шалтыратырга булды.

Ләкин кич җиткәч, шалтырату белән генә чикләнмәскә, үзе барып килергә кирәк тапты. Цехтагы хәлләр хакында да сөйләшәсе бар иде бит әле.

Проходнойга керүгә, турникеттан аның каршына Хәйруллин үзе килеп чыкты. Маңгаен күксел эшләпә белән каплап куйганга, очлы борыны елтырап күренә, ирен читләре, үртәгәндәй, өскә күтәрелгән.

— Исәнмесез, доктор. Тагын безгәме?

— Әйе, сезгә.

— Онытмыйсыз безне, ә? Хәзер әйтермен, пропуск язарлар.

Ул җавап та көтеп тормыйча, тар коридорга таба борылды.

— Минем сезнең белән сөйләшәсе бар иде,— диде Зәйтүнә аның артыннан куып җитеп.

— Мин китәм шул инде.

Хәйруллин коры сөйләшә иде. Зәйтүнә ник килгәненә үкенә башлады. Бу кеше аны аңламас, көләр генә, мөгаен.

— Алайса миңа да пропуск кирәкми, мәшәкатьләнмәгез.

Зәйтүнә тышкы ишеккә борылды. Бу юлы Хәйруллин аны үзе куып житте.

— Сез кая кайтасыз?

— Барыбер түгелмени?

— Әйдәгез, мин сезне озатып куям.

Тышта, бетон баскычка борыны белән төртелеп диярлек, чия төсле «Москвич» тора иде.

Хәйруллин кыска күн пальтосы кесәсеннән бер бәйләм ачкыч чыгарды.

Ул машинаны хәтәр кызу йөртә икән. Шулай да әңгәмәнең җебен үзе, салмак сөйләшә.

— Сез тагын шул мәсьәлә хакында сөйләшмәкче идегез инде, билгеле,— диде ул.— Цех һавасында газның микъдарын киметүгә ирешергә, эшчеләргә респираторлар кигезергә.

— Юк, мин сездән гафу үтенергә теләгән идем,— диде Зәйтүнә нык тавыш белән.

— Гафу? Нәрсә өчен?

— Сез үзегез теге чакта миңа әйттегез бит. Бик зур гаеп ташладыгыз миңа. Ул төнне мин дежур идем. Бу хәл минем күз алдымда булды.

— Нинди хәл? — дип, Тукай почмагында машинасын кисәк туктатты Хәйруллин. Ул Зәйтүнәгә зур гаеп ташлаганын, аңа бәгырь ярасы ясаганын гүяки бөтенләй оныткан иде!

Ләкин Зәйтүнә сүзен ахырынача дәвам итәргә булды.

— Без барысын да тиешенчә эшләдек,— диде ул. Мөдәррис Сәләховичның күзләре күк, керфекләре кыска булса да куе икән, һәм әгәр дә үчекләгәндәй өскә күтәрелгән юка ирен читләренә карамасаң, карашы беркатлы икән.

— Хатыныгыз тиешле белешмәләр алып кергән иде, формаль яктан караганда без аңа нәкъ шушындый ярдәм күрсәтергә тиеш идек. Ләкин шулай да мин Динә белән ачыктан-ачык сөйләшергә, аны ниятеннән ваз кичтерергә тиеш идем.

Хәйруллин аңа гаҗәпләнеп карады.

— Ах, сез менә нәрсә хакында сөйләшмәкче икәнсез!

Ул машинасын сак кына кузгатты да каршыга килгән трамвайны уздырып җибәрде. Аның карап торуга ук каты, әмма җыйнак куллары руль тәгәрмәчен йомшаграк тота башлады, машина йөрешен әкренәйтте.

— Кызык,— диде ул алга караган килеш.— Мин дә сезне искә алгаладым бу арада, доктор Зәйтүнә. Сезгә исемегез белән генә дәшәргә ярыймы? Ә миңа Мөдәррис кенә диегез. Яшькә бер чама бит без.

Ул тынып калды. Рөхсәт тә сорамыйча, сыңар кулы белән кесәсеннән сигарет алып капты, машинадан кабызгыч алып кабызды. Машина дамба буйлап бара башлады. Аны узгач, Яшьләр үзәгенә таба борылды да, хәзер инде судан бушап калган, күңелсезләнгән бассейн янында туктады.

— Инде без икебез бер нәрсә хакында берничә көн буе уйланганбыз икән, әйдәгез тынычлап кына сөйләшеп алыйк.

Ул машинаның ишеген ачып куйды.

Сул якта — елга ярындагы иңкүлектә агачлар шәрәләнеп калган, саргайган яфраклар да анда-санда гына күренә. Ундагы гөл түтәлләре кап-кара итеп казып ташланган. Өстән соры болыт юрганы күңелне басып тора, тирә-юнь ямансу иде. Бары тик Яшьләр үзәгенең күксел бетон бинасы янына утыртылган зәңгәр чыршылар гына, ел фасылларына бирешмичә, үзләренең гадәти төсен саклаганнар иде.

Зәйтүнә күптәннән инде үзенең шушындый бер аулаграк урында туктальп, уйланып, кем белән булса да тыныч кына сөйләшеп торганы юклыгын уйлап куйды. Аның барлык борчулары урын өстендә, караңгы бүлмәдә, күзенә йокы кермичә, талчыккан аяклары гүләвен тыңлап ятканда кичерелә.

Ә табигать шундый мәһабәт, тыныч һәм шушындый сулып барган чагында да күңелне иркенәйтеп җибәрерлек матур.

— Доктор Зәйтүнә, Зәйтүнә,— диде Мөдәррис, аңа таба борылып.— Сез гафу итегез мине. Теге чакта үртәгәнем өчен гафу итегез.

Зәйтүнә аның үткен якты күзләренә тутырып карады. Әйе, бу кеше аны бирегә алып кереп, азга гына булса да тормыш ыгы-зыгысыннан аерып, бераз ял иттерергә уйлаган икән, сүзнең дә ул көтелмәгәнен һәм күңелгә җиңеллек китерә торганын әйтергә тиеш иде, әлбәттә...

— Сез хаклы, доктор, мин сезне үчекләргә тиеш түгел идем. Цехта һава зарарлы, бигрәк тә хатын-кызларга. Ләкин бит ул менә ничек килеп чыга. Бу шарларны ясау ысулын тапканчы, аның төгәл технологиясен булдырганчы, инженерлар мең төрле катлаулы мәсьәләне чишәргә тиеш булганнар. Латекс нык булсын, сузыла торган булсын, күпләп эшләрлек булсын, арзанга төшсен. Бу мәсьәләләрнең барысын да хәл итеп бетергәнче, инженерлар үзләре ул сыек латекста баштанаяк коенып эшләгәннәр инде, билгеле. Сәламәтлегебезгә зыян килә, дип тормаганнар. Аның зарарлы икәнлеге дә кемнәрдер зарар күргәч кенә ачыклана бит. Кюри-Склодовская белән Жолио-Кюри сукырайгач кына атом нурларының зарарлы икәнлеге беленгән.

— Һәр яхшылыкның бер начар ягы була, димәкче әллә сез?

— Медицинадагы шикелле, һәр дару бер яктан файда бирсә, икенче яктан зыян китерә, диләр бит.

— Күпкә китсә.

— Күпкә китмәсә, сез аның зыянлы икәнен үзегез дә белмисез, шулай бит?

— Мин сезне аңладым,— диде Зәйтүнә.— Нәрсәнең дә булса зыянлы икәнен без зыян күргәч кенә беләбез.

— Хәзер, тулы заводларны эшләтә башлагач, кыен шул инде,— диде Мөдәррис.— Мин бу хакта күп баш ваттым, төрле заводларда да булдым. Яңа чаралар уйлап табарга кирәк. Без күргән чаралар файда бирми.

— Ә сез ул чаннарны каплап тора торган итегез,— диде Зәйтүнә.

— Башыгыз йомры икән!— Мөдәррис көлеп куйды.— Булмый шул, капкач астында да әлпе хасил була, аны барыбер сыдырып алырга кирәк, шунсыз форманы манчып булмый. Әлпене алганда газ нык бүленеп чыга. Нәкъ шул моментта, безгә үч иткәндәй, сез килеп һаваның анализын аласыз да инде.

Ул күңелсез генә көлеп куйды.

— Соң ул әлпене техника сыдырсын, кеше якын килмәсен!

Мөдәррис машина ишеген япты.

— Рәхәт сезнең белән, доктор Зәйтүнә. Әллә үземнең булачак рацтәкъдимнең соавторы итеп аласы инде сезне. Мин дә нәкъ шул хакта баш ватып йөрим бит. Ләкин аның бер кыенлыгы бар: чандагы сыеклыкның күләме, ягъни биеклеге үзгәреп тора.

— Үзгәрми торган итегез!

— Сезнең ирегез инженермы әллә?

— Инженер,— диде Зәйтүнә көлеп.— Тик башка өлкәдә. Теплицалар кора.

— Ну ул инде гел зыянсыз ачышлар гына ясый торгандыр.

— Алай ук түгел шул. Элек андагы эшчеләр салкыннан җәфалана иде, хәзер, теплица коргач, эсседән интегәләр.

— Менә күрдегезме? Һәрнәрсә ике яклы була шул. Хәзер кая барабыз?

— Сез мине тыңлап бетермәдегез бит әле. Динә безгә килсен иде. Киңәшләшергә, карарга кирәк аны.

— Динәне сез генә тыңлата торганмы соң? Психиатрга җибәрергә кирәк аны!

Иреннәрен кысып, каты итеп әйтте бу сүзләрне Мөдәррис. Зәйтүнәнең җанына боз тиеп киткәндәй булды. Иренең бәгырен шушы хәтле катырыр өчен нишләргә тиеш икән хатын-кыз? Зәйтүнә Динәнең теге төндә кичергәннәрен хәтеренә китерде.

— Ул да үз хатасы өчен мең җәзасын алды инде,— диде.— Сез, ирләр, хатыннарның хәлен аңламыйсыз гына.

— Ә сез, сез аңлыйсызмы соң? — диде Мөдәррис, шактый ук кычкырып. Зәйтүнә артка чайкалып куйды.

— Гафу итегез.— Мөдәррис эшләпәсен салып маңгаен уды. Аның маңгаенда эшләпә кырыеның эзе кызарып тора, ул хәсрәт сызыгы булып тоела иде.— Гафу итегез. Мин сезгә тагын кеше гаебен йөклим. Бәлки, барлык хатыннар да андый түгелдер. Бәлки, сез андый түгелдер.

Зәйтүнә, чыгарга теләп, машина тоткасын тарткалады.

— Мин сезне илтеп куям,— дип, аның кулыннан каты итеп тотты Мөдәррис. Аның бармаклары калтырана иде.— Хәзер илтеп куям...

*

* *

Алтынчәч кич укуга бармады. Болай да ул анда күңел күтәрү өчен генә йөри иде. Аның хәзер инглизчә сөйләшүе кемгә кирәк?

Инглиз теле кайгысы китте әле Алтынчәчтән. Акушер-гинеколог аңа бүген үк больницага ятарга кушты. Кабинетыннан да чыгармыйча, ашыгыч ярдәм машинасы белән үк озатмакчы иде. Андый чакта акушерлар күп сөйләшеп тормыйлар. Алтынчәч аның кулыннан чак кына котылды. «Ванна коенмыйча кермим больницага,— диде.— Теләсә нишләтегез, бу килеш кермим. Анда бүген юыну мөмкинлеге әллә була, әллә юк. Беләм мин больница хәлләрен». Шундук кулыннан язу да язып бирде: «Бүген үк профессор Ильясова клиникасына барып ятам».

Әлбәттә, коенуда түгел иде сәбәп. Анда кереп ятканчы, Алтынчәчнең Мөһимәне күреп сөйләшәсе килә иде. Линардан берәр хәбәр юк микән. Ул больницада чакта килеп, күрешми китмәсен тагын...

Мөһимәнең тәрәзәләрендә ут юк иде. Урамда көтеп йөрергә Алтынчәчнең сабырлыгы җитмәде, ул вокзал янындагы кибеттән әйләнеп чыкты. Нәниләр кирәк-ярагы сата торган бүлек янында озак басып торды. Кайбер әйберләрне врачлар алдан ук алып, юып, үтүкләп куярга кушалар. Ләкин шул ук вакытта халык арасында ырым бар: алдан әйбер-кара әзерләп кую хәерлегә булмый, имеш. Дөрес ырым түгелдер, мөгаен, кайсы гына хатын бәби көткәндә нәни күлмәк-башлыклар текмәгән дә кайсы гына аларга аллы-гөлле бизәкләр чикмәгән. Тик менә Алтынчәч бу ләззәттән үзен мәхрүм итә, ырымнарга ышанмаса да, ә бәлки туры килер дә, соңыннан үкенермен, чигүле нәни күлмәкләр өстенә күз яше түгәргә туры килмәгәе, дип юк-юк та шикләнеп куя. «Бала исән-сау туса, ялангач йөртмәм әле, лаборатория кызлары булса да әзерләп китерерләр»,— дип юатты ул үзен бу юлы да.

— Бик яхшы күлмәкләр бар менә, мондый җылы-йомшаклары ялан булып тормый,— диде аңа сатучы хатын.

— Куркам,— диде Алтынчәч ачыктан-ачык.— Алдан әзерләргә кушмыйлар.

— Аңа карап тормый халык, әзерли. Үкенгәнен күргән юк әле. Хәзер сабыйларны бик карыйлар бит. Исән калмаганнары бик сирәк.

Алай да Алтынчәч әйбер-кара алмады. Нәни күлмәкләргә сокланып карап торды да әкрен генә атлап китеп барды.

Мөһимәнең уты кабынган иде. Өй эче бу юлы бөтенләй башкача булып күренде: бүлмәләрдән ташландык ис килә, ә корама япмалар ялгыз кешенең бушка вакыт уздыру чарасы гына булып тоела иде.

Мөһимә дә бу юлы Алтынчәчнең килүенә артык сөенмәде шикелле. Дөрес, чәй куйды куюын, әмма аның хәлен сорашмады, үз зарын түгәргә кереште. Йортка кергән улыннан, килененнән зарланды, хәзерге заман яшьләренең игелексезлеген, мәнсезлеген каргады.

Табын да шактый ярлы иде: чәй янына май белән сыр гына куелды. Алтынчәч Линар хакында сүз башларга вакытның җайсызлыгын чамалый, ә Мөһимә исә энесен бөтенләй оныткан сыман кылана иде. Инде Алтынчәч ике чынаяк чәй эчте, хәлбуки аңа сыеклык эчүдән тыелырга кирәк, бер чынаяктан артыкны эчәргә һич ярамый иде. Табын янында чәйдән соң да шактый утырдылар, киленен каргый-каргый Мөһимәнең тамагы карлыкты. Ә кирәк темага алар бөтенләй якынлашмаганнар да иде әле. Мөһимә төсен җуйган иске халат төймәсен ялгыш эләктергән, шуңа күрә ул җыерылып тора. Аның чәче тузгыган, крем сөрткән бите майлы коймак кебек ялтырый иде.

Сорамаска кирәк иде Алтынчәчкә Линар турында. Ләкин сорамый да булдыра алмады.

— Линар кайчанрак килер икән?— диде ул аяк өсте баскач.

— Белмим шул, бер дә бу арада гына килер сыман күренми. Ә хат килгән иде, мине кунакка чакырганнар. Хатыны язган.

— Хатыны?— диде Алтынчәч.

— Ие шул, кайткан, мөртәт. Тәмам башын катырды шул мескенемнең. Нихәл итәсең, шундый аждаһа хатыннар ашый инде асыл ирләрнең башын! Бернишли алмый безнеке дә, кызын бик ярата шул, бәгырь парәсе, ансыз яши алмый.

Шундый шартлатып сөйли, әйтерсең лә, Алтынчәчне монда чакырып китереп Линар белән үзе таныштырмаган, әйтерсең лә хәзерге минутта Алтынчәчнең кыяфәтен күрми, аның хәлен бөтенләй белми!

— Минем аны күреп сөйләшәсе бар иде,— диде Алтынчәч.

— Бик сөйләшер идең дә, ничек күрерсең икән соң? Белмим шул инде, белмим. Килеп чыгар бер килүен дә, тик кайчан икәне генә билгесез. Хатка да язып булмый. Хатыны ачып укыса, көн күрсәтмәс үзенә. Начар хатын белән бәйләнгән ирнең көн күрәсе юк инде!

Бусы инде Алтынчәчкә дә бәрелде. «Чыннан да, мин хәзер үземне дә рәтле кеше дип саный аламмыни?»— дип уйлады Алтынчәч караңгы урамга чыккач. Трамвайдагы кешеләр, урамда аның яныннан узучылар, хәтта багана башларында янган лампочкалар да аның начар хатын икәнен, кеше иреннән корсак күтәргәнен беләләрдер сыман тоелды.

Аның күршесе, озын, арык буйлы Нәкыя соңгы вакытта гадәттәгедән дә катырак басып йөри, зур кулларында савыт-сабаны аеруча нык шалтырата иде. Баштарак ул Алтынчәчнең ир кеше белән танышуын хуплагандай күренде. Әгәр дә Алтынчәч кияүгә чыгып куйса, бу тар, кысан бүлмәдә мәңге яшәмәсләр, ничек тә булса аулаграк квартир табу җаен карарлар, дип уйлаган иде ул. Ләкин егет айлар буе күренми торгач, ә Алтынчәчнең гәүдәсе күзгә күренеп калынайгач, күршенең мөнәсәбәте үзгәрде. Яшь балалы ялгыз хатын белән бер квартирада яшәү кемгә рәхәт?

Алтынчәч өстен алыштырды да урынга ятты. Аның күршесен түгел, үз-үзен дә күрәсе килми иде.

Әгәр дә мондый хәлләр башка берәр кыз башына килсә, Алтынчәч, мөгаен, аны гаепләр иде. Үзеңә тиң булмаган, хатынлы, балалы ир белән ничек шулай бозылып йөрү мөмкин? Башка кызны Алтынчәч гаепләр иде, ә үзен ул гаепләп кенә калмый, үз тәненнән үзе нәфрәтләнә!

Яратмый иде бит ул Линарны! Алар арасында ул көткән, ул белгән мәхәббәт кабынырга вакыт та булмады, булса да ул Линар кебек ярлы күңелле, бар хыялы — ишегалдына биек багана куеп, шуның башына урам лампасы асу булган, Экзюперины аңламый торган, хәтта рәтле анекдоттан көлә дә белмәгән кешене ярату мөмкинмени?

Нигә соң Алтынчәч аның белән очрашты? Очрашкач та беренче карауда кемлеген танымады. Ярый, анысы шулай да булсын, ди. Бер тапкыр очрашып, ялгышканын аңлагач, нигә соң ул аның белән тагын күрешергә риза булды, нигә?

Менә шушы тәне, кайнар тәне, аның рухына буйсынмады. Кирәкми, бармыйм, диярга тиеш булган иреннәр акылны тыңламадылар, куллар, Линарның кулларын этәсе урынга, аның учында йомарланып тын калды, иреннәр аның каты иреннәренә орынып сызлануны түземсезлек белән көттеләр. Аның тәне Линар кочагында эреп бетәргә һәм шул минутта юк булырга риза иде.

Әгәр моңарчы кем дә булса Алтынчәчкә мондый хәлнең — рух белән тәннең бер-берсенә каршы халәттә булуын сөйләгән булса, ул ышанмас иде. Моңа ышану мөмкин түгел. Кеше болай бер төрле уйлап, икенче төрле яши алмый!

Акылга буйсынмаганы өчен, зиһенне томалап ләззәт ялкынында янганы өчен күралмый Алтынчәч үзен. Аның тәне мондый гөнаһ белән җирдә яшәргә хаклы түгел. Ләкин ул хәзер изге бер җанга, гөнаһсыз җанга кабык булып хезмәт итә. Бары тик шушы вазифаны үтәр өчен генә яшәргә хокукы бар аның якты дөньяда.

Әнә ул тәнне тибрәндереп тибенә. Алтынчәчнең газапларын оныттырып, иреннәрен елмаерга мәҗбүр итә, күңелне баскан ташның авырлыгын оныттыра. Ул кыз булыр, әнисеннән сафрак яшәр. Кызы бәхетле, сәламәт үссен өчен, ул мондый газапларга дучар булмасын өчен, бөтенесен эшләр Алтынчәч.

Иртүк профессор Ильясова янына барыр ул.

*Дәвамы киләсе санда.*

## Гамил Афзал

# ТУГАН ИЛДӘ ТУКАЙ РУХЫ

●

Кешеләр, язмышлар, вакытлар
Тыгызлап төенгә төйнәлгән.
Йөрәккә язылган фактлар
Сызылып калкына түбәннән.

Шикләнгән, сокланган вакытлар
Хәтердә төенгә төйнәлгән.
Йөрәккә уелган фактлар
Моң булып калкына түбәннән.

Танышлар, йөзләре ап-ачык,
Исемнәр җуелган, онытылган,
Бишьеллык капкасын киң ачып,
Баралар замана артыннан.

Кешеләр, гамәлләр, фактлар
Хәтердә, югалмый берсе дә,
Сөенгән, көенгән вакытлар
Җанланып, күңелләр көрсенә.

●

Халыкның җаны җырында;
Илләр кичмә, еллар кичмә,
Сыздырып басу юлында:
«Тау астында салкын чишмә...»

Ә җырның гомере озын,
Әкият кебек айлы кичтә
Җырла, улым, җырла, кызым:
«Тау астында салкын чишмә...»

●

Кызарып шәфәкъләр янды
Яктыкүл якларында.
Уйлаган уйларым калды
Урал-тау артларында.

Карасам, күзләрем талды
Моңайган чакларымда.
Җанымның яртысы калды
Урал-тау артларында.

●

Арысам,
Егылсам —
ятларга карамам,
Теш кысып торырмын яңадан.
Күкләрдә очарга,
суларда йөзәргә
Елмаеп туганмын анадан.

●

Ак каеннар шаулап үскән үрле
Гөл-чәчәкләр илен кем күрде?
Саф җилләргә каршы йөз аклыгы,
Күңел якын итте бу җирне.
Бер кайгысы булса, биш шатлыгы —
Тормыш матурлыгы мең төрле.

●

Былтыргыдан быел яхшырак дип,
Өзеп-кисеп фараз кылынса,
Кеше үзен яхшыртырга тиеш
Гомер буенча.

●

Сүзе көчле бөекләрдән көнләшәсең,
Кардәшеңә үз телеңдә эндәшәсең.—
Көйләсәң — моң, сөйләсәң — сүз, җырласаң — җыр:
Туган илдә Тукай рухы мең яшәсен!

●

Әле болын, әле яшел урман,
Бормалы юл үтә сөзәкләп,
Гөл, чәчәкләр үскән бизәкләп.
Гомер буе юлда очрый торган
Яхшы кешеләргә мең рәхмәт!

●

Мең еллык хатирә тирбәлгән,
Чәчәкләр чайкалган дала бу.
Күзләре таңнарга төбәлгән,
Өметле, инсафлы бала бу.
Мең еллык хыяллар балкышын
Тирбәтеп яшәргә кала бу.

●

Кайгың йот, йөзең — ут, күзең — ут...
Терелай утларда янсаң да,
Елмаеп, теш кысып фронт тот,
Далада берүзең калсаң да!

●

Гомер буе күңел үргә менә,
Сәлам әйтеп Идел җилләренә,
Әллә кайда илләр, гөлләр матур;
Мин кадерле шушы җирдә генә.

●

Бу — ватан, бу — синең туган җир,
Изге җир — ятсаң да, торсаң да.
Җаныңның яртысын ярып бир
Чәчәкләр чайкалган һәр таңга!

●

Көн сүрелгән, шәфәкъ кызарган.
Бүтән яшьлек килә уйнап-көлеп,
Син белмәгән законнарны белеп,
Син йөри алмаган юллардан.—
Син көнләшмә инде шулардан.

●

Әллә гомер буе ут йотасы,
Кайларга җитеп лә туктасы,
Кайсы юлда, кайсы үрдә икән
Гомернең иң биек ноктасы?

●

Болыт килә, яңгыр килә,
Таллар тирбәлә сөенеп,
Әллә елый, әллә көлә,
Агым суларга иелеп...

●

Даһи акыллардан сабак алгач,
Гыйлем каршысында баш идек.
Күсәк тотып патша була алмас,
Хаким була алмас вәхшилек.

●

Шушындый ук гөлләр үскән түтәлләрдә,
Үргә үрелеп күз төшерсәң үткәннәргә,
Тау битендә җылы җилле җәйге кичтә
Айга карап җыр уйлаган бүтәннәр дә.

●

Соң гына яз килә, соң гына җәй,
Соңлап кына йомшак җил өрә.
Сүрән климатлы чор микән, әй,
Шагыйрьләр дә соңлап өлгерә.

●

Яшәүнең мәгънәсе — хезмәт,
Әгъзалар татлы талганчы,
Маңгайдан тирләр тамганчы.
Бүтән төрле сөйләүчеләр —
Мәми авызлы ялганчы!

●

Ялгызлык йөрәкне талдыра,
Йөрәкне талдыра ялгызлык.
Танышлар хәтерне калдыра,
Елмая астыртын явызлык.
Шомлану кайгыга салганда,
Горурлык соклана ялганга.

●

Дөнья күрү, һава сулау — кыйбат,
Көнне-көнгә, елны-елга ялгап,
Үзең өчен генә яшәү — оят,
Җирне, суны, җәмгыятьне алдап.


●

Давыллы юлларда, хәвефле борылышта
Дәртләндереп хәтәр җилләр исә;
Тып-тыныч тормышта йөрәккә мүк үсә,—
Гөл үсәргә тиеш, югыйсә.

●

Заман аты ут сулады дөбер-дөбер,
Сөрә тимер, оча тимер, йөзә тимер,
Тагын күпме тимер төпле еллар килер?—
Миңа кәккүкләр юрады озын гомер.

*1982*



*Тавил Хажиәхмәтов рәсеме*

## Сәйфи Кудаш,

Башкортстанның халык шагыйре

## СИГЕЗЬЮЛЛЫКЛАР

### Булгандыр ул...

Әллә инде яшен уты булып
Алдымнан ялтырап үттең син?
Әллә инде яз җилләре булып,
Дим буйларын җилпеп истең син?

Юк, бу яшьлек гади өн түгелдер,
Булгандыр ул серле төш кенә.
Тик төшләрдә генә була торган
Тылсымнан яралган эш кенә!

### Бик теләсәң...

Бик-бик теләсәң дә сөйкәлергә,
Чит пальмага карап инәлмә.
Сөйкәл әйдә туган туфрагыңда
Үскән каен яки имәнгә.

Абынсаң да алга атлаганда,
Абын үз җиреңнең ташына.
Сугыла калсаң, башка куллар түгел,
Туган анаң суксын башыңа.

### Бик беләсең килсә...

Бик беләсең килсә, туганым,
Ничек яңгыравын җырларның,
Бик матур бер көнне кырга чык,
Кошлар тынган чакта җырлашып.

Җырла шул чак сөйгән җырыңны,
Яңгыратып туган кырыңны,
Җырларыңның ничек булганын,
Әйтеп бирер яңгырап урманың.

### Кагылма йөрәгемә...

Буш икән дип беләкләре,
Тагылма беләгемә.
Куш икән дип йөрәккәе,
Кагылма йөрәгемә!

Йөрәгемдә — йөрәге бар,
Беләге бар — беләктә.
Юк анда һич буш урыннар
Башка берәр йөрәккә!

## Тик шулай да

Юк, син чибәр түгел дан тотарлык,
Башны-күзне әйләндерерлек,
Бер кашык су белән бер йотарлык
Һәм телләрне бәйләндерерлек.

Тик шулай да минем йөрәгемдә
Сөю уты кабындырдың син,
Мәхәббәт алласы каршысында
Тезләндереп табындырдың син...

## Күрәсем килә

Кышкы кояш сыман кырыс карап,
Нигә читтән генә үтәсең?
Бу карашың белән йөрәгемне
Бөтенләй туңдырып китәсең.

Белсәң иде минем йөрәгемнең
Бик зарыгып язлар көткәнен.
Күрсәм иде яз кояшы булып,
Синең бер елмаеп үткәнең!

## Ни калдырдың?

Бөркет очкан тауда йон кала.
Былбыл кунган талда өн кала.
Болан чапкан кырда эз кала.
Чәчән узган юлда сүз кала.

Әй, син, кеше затлы батырым,
Эшкә кушып алтын акылың,
Кадерен белеп яшәү хакының,
Ни-нәрсә калдырдың дөньяда?

## Илһам болытлары куера

Илһам болытлары куера
Күңелем күкләрендә.
Шигырь яшеннәре җыела —
Шартларга күкрәгемдә.

Тапмыймын үземә урын,
Талпынам, өзгәләнәм.
Бу минутта минем өчен
Тар кебек бөтен галәм!

## Һич хакың юк

Һич хакың юк зарланырга,
Мәйдан юк дип, тарланырга.
Барлык эшнең ачкычлары
Баскычлары үз кулыңда.

Эш дисәң, ул баштан ашкан,
Эшлә көн-төн туктамастан.
Эш артына бәхет баскан,
Кочакларга кочак ачкан.

## Ян, әйдә...

Ян, әйдә, дөрлә, йөрәгем,
Там, әйдә, җиргә, тирем.
Тирләремнән сугарылсын.
Ашланып туган җирем.

Мин тумадым бу туфракны
Тик таптап яшәр өчен.
Бәлки тудым бер көн аны
Бер бакча ясар өчен.

## Юлга чыксаң...

Юлга чыксаң, алдыңдагы
Киртәләрне алып бар син.
Үзеңнән соң үткән юлчы
Син үткәнне белеп торсын.

Юлдагы чокыр, баткакка
Таш һәм басма салып үт син.
Синнән соң үткән юлчылар
Моннан мәшәкатьсез үтсен!

## Йөз суы

Йөз суың китсә кулыңнан,
Кайгырып чикмә газап.
Бер тапкыр тиреңне туксаң,
Табарсың аны кабат.

Йөз суың китсә битеңнән,
Бу чакта эшләр харап!—
Йөз тапкыр тирең туксаң да,
Таба алмассың азак!..

## Нәрсә калыр?

Чыбык янына чыбык үссә, урман була,
Таш өстенә ташлар ятса, курган була.
Егет янына егет басса, гаскәр була,
Калкан булып Туган илен саклап тора.

Чыбык артлы чыбык ауса, урман бетә.
Таш өстеннән ташлар төшсә, курган бетә.
Егет яныннан егет китсә, калкан ава,
Калкан ауса, таянырга нәрсә кала?

## Тынса янудан

Ут атмаса — вулканнарның сүнгәне.
Чәчәк атмаса — гөлләрнең сулганы.
Ләм капласа — тирән күлнең кипкәне.
Бакча тынса — сандугачның киткәне.

Тынса янудан шагыйрьнең йөрәге,
Китсә аны ташлап илһам шаукымы,
Бу инде өнсез калуның билгесе,
Һәм каплавы аны кабер салкыны...

## Үтсәм иде...

Язсам әгәр берәр яңа шигырь,
Бәхет толпарына атланам.
Язган кебек тәүге шигыремне,
Яшьлек зәукы белән шатланам.

Йөрсәм иде шигырь кырларында
Шул толпарга һәр чак атланып.
Үтсәм иде калган гомерне дә
Шушы бәхет белән шатланып.

# Хәсән Туфан

*Олы шагыйребез Хәсән Туфан әдәбиятыбызга бай шигъри мирас калдырды. Шагыйрьнең архивында да матбугатка чыкмаган байтак әсәрләре саклана.*

*Без бу санда шагыйрьнең әле дөнья күрмәгән шигырьләреннән берничәсен укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итәбез. Аларны журналыбыз өчен филология фәннәре кандидаты, Хәсән Туфан иҗатын өйрәнүче галим Мәсгут Гайнетдинов әзерләде.*

## ...Карлар астыннан

Сугыш елларында ил эшендә —
Ир эшендә үскән балалар
Кар астыннан чыгып килә торган
Язгы чәчәк сыман чаялар.

Язың кебек, Себер, көләч алар!
Ашкыналар — эшкә ярарга!
Үтерелгән, үлгән ир-атларның
Киеме инде таман аларга.—

Яшәү, шулай, берни булмагандай,
Дәвам итә яңа яшьләрдә.
Туктый алмый тормыш, сүнә алмый,—
Яшәргә лә дәшә, яшәргә...

*1951*

●

Тимер юллар буйлап күпме үтсәң,
Ул юлларның ташын, комнарын
Һаман актара бит шушы кызлар,
Кулларына тотып ломнарын...

Безгә чәчәк чөеп калды бер кыз —
Сөйгәне дә юктыр, күрәсең...—
Чуен изеп үтте буләген.

Бәлки, шулай, газиз сөюен дә
Туп изгәндер... сугыш кырында.
Кулын болгый-болгый көлеп калды,
Үксеп-үксеп елар урында.

## Китмик әле...

Азмы сине сагынып яшәдем мин [1],
Яшьлек дустым, яшьлек юлдашым!
Нинди генә хәлдә булсам да мин,
Ачык миңа дуслык кочагың.—

Юлдаш, кулдаш, уйдаш хәлдә, Кудаш,
Синең белән бергә юл барам.
Бик күңелсез булыр беребез китсә,
Китмик әле, китмик дөньядан!

## Иртәләрнең берсе

Әйләнә Җир, тавыш-тынсыз гына,
Иртәнге көн янына табан:
Айлы төн үтәли узып бара
Кояш чыгыш ягына Казан.

Янып, балкып Җиргә төшеп китте
Метеор үзенең орбитасыннан,
Бөек һөҗүм вакыты җиткәнлекне
Хәбәр иткән ракета сыман.

Горизонтта яңа таң калыкты,
Триумфаль капка шикелле.—
Киләчәккә табан аккан Ыкны,
Зәйне, Ижны, Сөнне, Иделне

Таң капкасы аша яңа көнгә
Алып килеп керде Җир шары.—
Сабантуйга барган кебек итеп
Эшкә чыга безнең ил тагы.

Табигатьне гүя атакалап
һөҗүм башлап, кырый төбәктә
Районнарны кыю җитәкчеләр
Алып кереп китте көрәшкә:

Алып керде алар — Минзәләне,
Бөгелмәне, Әлмәт, Шөгерне,—
Генераллар дивизияләрне
Җиңүләргә илткән шикелле.

*1940*

●

Бәйрәмдәге өстәл тирәсендә,
Искә алып күргән-белгәнне,
Бәхәсләшеп утыра замандашлар,
Тема итеп күптән үткәнне.

Әйбәт киңәш биреп,
Мәрхүмнәргә
Юл күрсәтә бүген һәммәсе:
— Тегеләй итсә, болай булыр иде,—
Үзе гаепле ул!— янәсе.

Уйга калып карап тора Тарих,
Колак салып кызу бәхәскә,
(Бу бәхәсне хәл итәрлек серне
Ул беләдер белүен, әлбәттә).

---

[1] Башкортстанның халык шагыйре Сәйфи Кудашка багышлап язылган.

Замандашлар минем
Каударлана,—
Килә, димәк, белеп китәсе.—
Ә Тарихка нәрсә? Тарих кала,—
Ул бит мәңге дәвам итәсе...

●

Җил килә дә сыйпалана:
Мине ярата имеш,—
Серләремне сөйләтә дә
Илгә тарата имеш...—

Сыйпанма, җил, сыланма, җил,
Йөрмә тәрәз төбемдә!—
Исемнәрен, билләһидер,
Әйтәсем юк һичкемгә!

«Минем исем аның өчен
Кадерсездер,— дисеңме,—
Серләремне саклый алмый
Хәерсезем» — дисеңме?! —

Кит әле, кит, сыйпанма, җил,
Йөрмә тәрәз төбемдә,—
Исемнәрен, билләһи дим,
Әйтәсем юк һичкемгә.

*1957*

●

Сезнең җизни җизнимени?—
Безнең җизни — вәт җизни!—
Апаның биш йөргәне бар,
Шуның берсен дә сизми;—

Безнең җизни илдә бер:
Сакалына — егерме яшь,
Йөрәгенә — йөз дә бер.

*10/IV-1948.*

●

Берәү — бите тәтине,
Берәү — нәни тәпине,—
Берәү исә сөя ярның
Кайсы — иң дә әпиле.

Берәү — малга өйләнә,
Берәү — данга өйләнә.—
Я, илаһи, безләрне дә
Шундый бәндә әйләмә!

*18/VII-1948.*

# МӘХМҮТ ХӨСӘЕНГӘ 60 ЯШЬ



*Бөек Ватан сугышында катнашкан, батырлыклары өчен орден һәм медальләр белән бүләкләнгән шагыйрь Мәхмүт Хөсәенгә 60 яшь тулды.*

*Казахстанда туып үскән шагыйрьнең беренче китабы Ленинградта 1945 елда басылып чыга.*

*Бөек Ватан сугышыннан соң М. Хөсәен Казан университетын тәмамлый, мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбияты укыта, озак еллар Татарстан китап нәшриятында эшли. Кырык елга якын иҗат дәверендә аның күп санлы шигырь китаплары басылып чыкты. Сонет жанрының татар шигырендә табигый яңгыраш табуында да М. Хөсәеннең тырышлыгы зур булды. М. Хөсәен матур әдәбиятны, шигъриятне армый-талмый пропагандалаучы буларак та билгеле. Әмма М. Хөсәен — барыннан да бигрәк, халыкка җырлары белән танылды: ул — күренекле татар, башкорт һәм казах композиторлары көйгә салган ике йөздән артык җыр авторы. Шагыйрьнең күп җырлары, романслары республикабызда уздырылган әдәби-музыкаль конкурсларда премияләр белән бүләкләнгән. Аның бу авыр жанрдагы фидакарь хезмәте аерым игътибарга, ихтирамга лаеклы.*

*Шагыйрьне юбилее белән котлап, без бу санда аның төрле елларда язылган һәм җырга әйләнгән шигырьләрен урнаштырабыз.*

## Мәхмүт Хөсәен

### Шинель

Походларда йөргәндә,
Ут-суларга кергәндә,
Көч бирәсең арган тәнгә,
Назлап солдат күңелен,
Каптырмалы,
Киң, ермалы
Һәм сырмалы шинелем!

Кургаш уклар тишсә дә,
Озын юллар кичсә дә,
Кыршылса да, кер кунса да,
Югалмый ямең синең,
Каптырмалы,
Киң, ермалы
Һәм сырмалы шинелем!

Мендәрем дә син минем,
Юрганым да син минем,
Туңган чакта җылытучы
Учагым да син минем,
Каптырмалы
Киң, ермалы
Һәм сырмалы шинелем!

Солдат та сине сөя,
Маршал да сине кия.
Синең белән җиңеп бергә
Үттек без дошман җирен,
Каптырмалы,
Киң, ермалы
Һәм сырмалы шинелем!

Агарлар бик күп сулар,
Узарлар бик күп еллар...
Сине хөрмәтләр буыннар,
Җанга ятышлы кием,
Каптырмалы,
Киң, ермалы
Һәм сырмалы шинелем!

## Сәйдәш моңнары

Назлый Идел дулкыннарын
Кояш нурлары.
Кояш нурларыдай җылы
Сәйдәш моңнары.

Сандугач сайрап уята
Урман-кырларны;
Сандугачны сокландыра
Сәйдәш моңнары.

Сагыш белән тибрәнгәндә
Йөрәк кыллары,
Иң әйбәт юаныч безгә
Сәйдәш моңнары.

Сәйдәш җырларына гашыйк
Хезмәт уллары.
Күңелләрдә тибри мәңге
Сәйдәш моңнары!

## Далаларым

*Чабан җыры*

Далаларым, сезгә карап дулкынланам,
Мин бит күпме язлар ямен күргән чабан.
Җырлап килəм домбра чиртеп ат өстендә,
Яшьлек дәрте янып тора шат йөземдә.
Уа, малым, ай, ширкенай,
Җәйләүләрем иркен, бай!

Далаларым, сездә үстем, кымыз эчтем,
Көтү әйдәп күпме борма юллар кичтем.
Төнен учак ягып үтте яшь чакларым,
Бәйгеләрдә ат уйнатып аз чапмадым!
Уа, малым, ай, ширкенай,
Туган ягым иркен, бай!

Далаларым, һәркөн саен ямьләнәсез,
Чиксез муллык дәрьясына әйләнәсез.
Үсә күңел, канатлана сезгә карап,
Без бәхетле дип җырлый күк һәммә тараф.
Уа, малым, ай, ширкенай,
Туган илем иркен, бай!

## Кояшым бул!

Керфекләрең, кара керфекләрең,
Сөрмәле дә алар, куе да.
Эчләренә кереп бер адашсам,
Чыга алмам гомер буена.

Таңнар белән күзем ачылуга,
Син төшәсең, тик син уема...
Йөрәгемә илһам иңдерүче
Кояшым бул гомер буена.

## Әнием миләше

Газиз әнкәй, синең истәлеккә
Утырттым мин миләш агачын.
Оныта алмыйм, балам, дигән сүзең,
Оныта алмыйм җылы карашың,
Таң нурыдай якты карашың.

Киләм, әнкәй, күңел тулган чакта
Серләшергә синең миләшкә.
Тормышта бик авыр булган чакта
Чакырам мин сине киңәшкә.
Өзелеп карыйм синең миләшкә.

Син гел, әнкәй, исән күңелемдә,
Бүген дә син рухи терәгем.
Бакчалардан күзен карый сыман
Кызыл миләш булып йөрәгең,
Миләш булып карый йөрәгең.

## Агыйдел вальсы

Агыйдел Агыйдел түгел,
Алкаланып акмаса.
Бер дә үсмәс иде күңел,
Мәхәббәтен тапмаса.

Агыйделдә аяз таңнар
Аксыл нурлар тарата.
Үзләренә яхшы ярлар
Гомерлеккә карата.

Кояш белән куна чыклар
Агыйделнең талына.
Мәхәббәткә чын гашыйклар
Кояшым дип табына!

## Бәрәңге

Вак-вак итеп турап, яшь киленнәр
Табаларда сине биетә.
Булы боткаң ашап, эшчән ирләр
Тәннәренә җылы йөгертә.

Йодрык кадәрле,
Йомры гәүдәле,
Ак тәнле,
Ах, тәмле,
Бигрәк тәмле бәрәңге!

Кабыгыңны салып, моңсуланып,
Кайнар шулпаларга төшәсең.
Мичләр кызуында алсуланып,
Учак көлләрендә пешәсең.

Йодрык кадәрле,
Йомры гәүдәле,
Ак тәнле,
Ах, тәмле,
Бигрәк тәмле бәрәңге!

Тукай да бит сине җырлап йөргән,
Бабайлар да мактап сөйләгән.
Бер як та юк сине үстермәгән,
Бер кем дә юк сине сөймәгән.

Йодрык кадәрле,
Йомры гәүдәле,
Ак тәнле,
Ах, тәмле,
Бигрәк тәмле бәрәңге!

# БӨГЕЛМӘНЕҢ ШАНЛЫ КӨННӘРЕ

*Егет солдат Швейк... Күренекле чех язучысы Ярослав Гашекның бу популяр героен кем генә белми икән? Язучының тууына йөз ел тулу уңаеннан 1983 ел, ЮНЕСКО карары буенча, Гашек елы дип игълан ителде.*

*Бөтен дөньяга билгеле булган роман авторы гражданнар сугышы вакытында меңләгән интернационалистлар белән бергә Совет власте өчен барган көрәштә актив катнаша. Советлар Россиясендә, Мәскәүнең үзендә, Коммунистлар партиясенә керә, Самарада (хәзерге Куйбышев шәһәре) Кызыл Армиянең интернационал частьләрен төзи. Кызыл Йолдыз орденлы легендар Бишенче армия составында Симбирскидан Иркутскига кадәр барып җитә. Армия политбүлегенең көчле җитәкчесе, ялкынлы пропагандист-агитатор, күп санлы матбугат органнарында җаваплы эшләр башкаручы...*

*Милли һәм интернациональ матбугат органнарын үстерүгә Гашек аеруча зур өлеш кертте. Ул күп санлы матбугат органнарын җитәкләү белән генә чикләнмәде, күбесен үзе оештырды, еш кына мәкаләләр, репортажлар белән чыкты, ил тормышын һәм халыкара хәлләрне яктырткан материаллар язды. Шунысы кызык — алар барысы да рус телендә язылганнар.*

*Киң күңелле, олы йөрәкле Гашек тирәсенә кешеләр һәрвакыт тартыла торган була, авыр минутларда ул аларга гел ярдәм кулын суза. Язучы үзенең шәхси бәхетен дә Советлар Россиясендә таба. Уфадагы армия типографиясен җитәкләгән чагында ул Шура Львова исемле татар кызын очрата, аңа гашыйк була. 1920 елның азагында алар икәүләшеп Чехословакиягә кайтып китәләр. Шура Львова гомеренең азагына хәтле шунда яши, 1965 елның 8 декабрендә генә вафат була.*

*Рухланып, халык азатлыгы өчен көрәшергә дип туган иленә әйләнеп кайткан Гашекны анда бик нык әзәрлекли башлыйлар. Язучының Россиядә революция ягында булуын кичерә алмыйлар. Әмма Гашекның фикерләрен инде бернәрсә дә үзгәртә алмый, авыр шартларга да карамастан, язучы ачыктан-ачык яшь Совет республикасын яклап чыга. 1957 елны, Совет властеның илле еллык юбилее көннәрендә ЧССР Президенты Указы белән Я. Гашек «Совет власте өчен көрәштә күрсәткән хезмәтләре өчен» үләннән соң Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнде.*

*Коммунист язучыны безнең илдә дә зурлап искә алалар. Мәскәү, Уфа, Иркутск, Чиләбе шәһәрләрендә аның исемен йөрткән урамнар бар. Шулай ук Иркутск, Красноводск, Куйбышев шәһәрләрендә Гашек яшәгән яки эшләгән йортларга мемориал такталар куелган.*

*Свердловск, Таллин театрларында совет композиторы А. Спадавеккиа765ның «Егет солдат Швейк» исемле операсы куелды. Гашекның Советлар Россиясендә үткәргән елларына багышланган «Зур юл» исемле фильм илебезнең бөтен экраннарын йөреп чыкты. Фильм совет һәм чехословак кинематографлары тарафыннан эшләнгән.*

*Чех язучысы, ялкынлы интернационалистны хөрмәтләп, безнең илдә күп эшләр эшләнә. Бу мәсьәләдә Татарстан аеруча кайгыртучанлык күрсәтә. Күренекле сатирик 1918 ел ахырында Бөгелмә шәһәрендә хәрби комендант ярдәмчесе була, анда тәртип урнаштыру буенча күп эшләр башкара. Хәзер инде Гашек алтмыш биш ел элек эшләгән шәһәрен танымас та иде. Соңгы елларда шәһәр бигрәк тә үзгәрде. Яңа йортлар, яңа заводлар, фабрикалар, нефть институты. Шулай да кайбер урыннарны ул таныган булыр иде. Мәсәлән, киң экранлы «Мир» кинотеатрыннан язучы исемен йөрткән урам сузыла. 1918 елны хәрби комендатура урнашкан йорт та шуннан ерак түгел. Бу йортта 1966 елның 15 гыйнварында Я. Гашек музее ачылды. Унҗиде ел эшләү дәверендә анда йөзләрчә мең совет кешеләре һәм чит ил кунаклары булдылар.*

*1970 елның 26 апрелендә Совет Армиясе Чехословакияне фашистлардан азат иткән көнне Бөгелмә театрында С. Антоновның «Йөрәгем Россия белән» исемле пьесасының премьерасы булды. Пьеса Я. Гашекның гражданнар сугышы елларындагы эшчәнлегенә багышланган. Шул көнне Чехословакиянең СССРдагы илчелегеннән, театр коллективын һәм тамашачыларны котлап, телеграмма килеп төшә. «Бу премьера — истә калырлык зур бәйрәм ул» диелгән иде анда.*

*Язучының эшчәнлегеннән Бөгелмә генә түгел, Казан үзе дә исендә тота. Монда бер урам һәм республиканың 28 нче номерлы иң яхшы китапханәсе аның исемен йөртә.*

*Швейк турындагы роман утызынчы елларда ук татар телендә басылып чыга. Гашекның 100 еллык юбилее уңаеннан Татарстан китап нәшрияты романның русчасын бастырып чыгарды.*

*Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында егет солдат Швейк турына инсценировка куелды. Татарстан радиосы язучы хикәяләре буенча эшләнгән «Бөгелмә коменданты» исемле спектакль тапшырды.*

*Республика матбугатында Я. Гашекның тормышы һәм иҗатына багышланган материаллар әледән-әле күренеп тора. Традицион совет-чехословак дуслыгы айлыкларында язучының әсәрләре, мәкаләләре, очерклары басыла. Совет-чехословак дуслыгы җәмгыятенең Казан һәм Бөгелмә бүлекләре китапханәләрдә, мәктәпләрдә, предприятиеләрдә артистлар, музыкантлар катнашында төрле кичәләр, әңгәмәләр уздыралар. Кыскасы — хәзерге көндә, 65 ел үткәч тә, Гашек гел безнең белән. Ул һәрвакыт социализм, тынычлык, халыклар дуслыгы өчен көрәшүчеләр арасында. Ә аның Швейгы, хикәяләре, юморескалары, фельетоннары, мәкаләләре һаман әле нацизмга, дингә, реакцион сугыш чукмарларына каршы көрәш алып бара. Гашек үзенең тормышы һәм иҗаты белән халыклар дуслыгын ныгыта.*

*Бу санда без В. И. Ульянов-Ленин исемендәге дәүләт университетының журналистика кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты Станислав Антоновның язучы тормышына багышланган яңа китабыннан өзекләр тәкъдим итәбез.*

## Станислав Антонов

# КЫЗЫЛ ЧЕХ

### ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬТАН ӨЗЕКЛӘР



к гвардиячеләрдән ишеренергә Гашекка актерлык сәләте дә бик нык ярдәм итә. Әмма гади кешеләр булышмаса, актерлык белән генә ул ерак китә алмаган булыр иде.

Ул Самарадан төньяк-көнчыгыштагы Зур Каменкага юл тота. «Ул тирәдә Идел буе мордвалары яши,— дип уйлый ул үзенчә.— Киң күңелле, ярдәмчел халык».

Һәм бу фикер дөрескә чыга. Беркөнне аны атлы агай куып җитә дә:

— Кая барыш, агайне,— дип кәбестә төягән олавын туктата.

— Барам әле,— ди Гашек,— юл барырга салынган.

— Бар, туган, бар,— ди агай бер дә исе китмичә. Әмма күпмедер дәшми торгач:— Самарада казаклар халыкны суя. Утыр әйдә арбага, бергәләп тынычрак булыр,— ди.

Гашек шундук агай янына менеп кунаклый.

— Анда хәзер мәхшәр,— дип дәвам итә агай.— Бер көнне шулай базарга барышым, каршыга Лукашовка авылының Петр Романович кайтып килә. Самарадан кайтышы икән. Кире борыл, ди бу миңа, шәһәргә кергәндә, аклар бөтен нәрсәне алып калалар. Күршем Дмитрич баласа тап булды. Олавын бушатырга кушкач, карышып маташкан да, тегеләр шундук кылыч белән чапканнар.

Мордвин агай, сөйләп бетереп, Гашекка карап-карап алды. Карашында: «Аңлыйм хәлеңне, синең дә шуннан качуың»,— дип язылган иде.

— Шундый хәлләр,— дип авыр сулап куйды ул,— бу якларга килеп чыгып дөрес эшләгәнсең. Бездә яшеренергә була. Халык тәмам гарык иде инде ул патшадан. Хәзер ичмасам һәркемгә җир бирелде, әаклар аны тартып алмакчы.

Олаучы кесәсеннән тәмәке янчыгы чыгарды да:

— Сиңа Иделнең теге ягына чыгарга иде,— диде.— Кичкә мена кайтып житәбез, анда безнеңчә киенерсең. Ә иртәгесен — дүрт ягың кыйбла.

Иртәгесен Ярослав мордва крестьяны киемендә юлын дәвам итте. Төшлектә нииндидер татар авылын узды. Авылны чыкканда, аны бер татар кешесе куып житте.

— Качып барасыңмы?— дип сорады ул, турыдан ярып, һәм, тегенең җавабын да көтеп тормастан, бер бөтен икмәк сузды.— Юлда кирәге чыгар.

Мондый изгелек онытыламы соң?!

Ун-унбиш минут та үтмәде, арттан тагын бер татар куып житте, русчаны вата-җимерә, олы юлдан барма, елга буеннан кит, дип аңлатты. Аерылышканда берничә тапкыр:

— Олы юлда казак, олы юлда казак,— дип кабатлады һәм бер кап тәмәке, шырпы, төрергә кәгазь бирде.

Кичен генә Гашек Зур Каменкага килеп житте.

Бер көнне кызылармеецлар арасында «теге яктан» чыккан бер кеше күренде.

Ул көнне фронтта тын иде. Сугышчыларның күбесе вакытлыча клуб ителгән зур сарайга кереп тулганнар. Анда үзешчәннәр концерты бара. Концерт азагында «теге яктан» килгән кеше сүз сорап ала да алга чыгып баса.

— Унбишенче елның язында,— дип башлый ул сүзен,— мин бер мәсьәлә уңаеннан үзебезнең полк руханиен мәче тизәге тутырылган капчык белән чагыштырган идем. Шуның өчен хәрби төрмәгә ябып куйдылар. Суд булганны көтәргә хәзерләнеп, камерага керсәм, таныш тавышлы берәү миңа: «Исәнмесез, пан Гашек!» дип эндәшә. «О, мәйтәм, син ничек монда?» Бу минем иске дус Швейк үзе иде. Ярты сәгать кенә элек аерылышкандай, ул шундук: «Безнең Будейовицта...» дип, чираттагы бер тарихны сөйләргә тотынды...

Гашек, сокланырлык итеп, булдыклы солдат Швейк маҗараларын сөйли, тиз арада аудиторияне кулга ала. Бер-бер артлы сугышчыларның күз алдыннан Австрия армиясенең көяз офицерлары, азгын поплары үтә. Залның игътибары Гашекка канат үстерә, рухландыра һәм ул җимерелергә тиешле иске дөньяның череклеген Швейк маҗаралары аркылы исбатлый.

Гашектан соң алгы рәткә кырыс йөзле большевик-агитатор Петр Васильевич Казьмин чыгып баса.

— Минемчә, иптәшләр,— ди ул,— без бурычыбызны үтәрбез. Иптәш Швейк борчылмасын, акларны да куарбыз, Казанны да, бөтен Идел буен да чистартырбыз.

Шулай итеп, Гашекның әдәби герое Совет власте өчен көрәшә башлый.

12 сентябрьдә Кызыл Армия Ленинның туган шәһәре Симбирскины аклардан азат итә. Ул көннәрдә газеталарда Ленинның кызылармеецларга җибәргән телеграммасы басыла. «Туган шәһәрем Симбирскины азат итү — яраларыма иң шифалы, иң яхшы бәйләү булды»,— дип язылган була анда.

Гашек монда нәкъ шушы көннәрне килеп чыга. Бөтен халык бәйрәм итә, шатлыкның чиге юк, ә ул нишләргә дә, кая барып төртелергә дә белми йөри. Җитмәсә, бернинди документ-фәләне дә юк.

Әмма юкка гына борчылган икән Гашек. Аңа ышаналар. Һәм ышанучыларның берсе карт коммунист, революцион хәрәкәттә актив катнашкан Василий Николаевич Каюров була. В. И. Ленин аны яхшы белгән, эшчәнлегенә югары бәя биргән. Шушы кеше Гашек язмышын хәл итүдә зур роль уйнаган. Аның кайгыртучанлыгын, җылы мөнәсәбәтен язучы соңыннан да искә алып сөйләгән. Яңа эш урынына китәр алдыннан булган сөйләшү язучының бигрәк тә исендә кала.

— Уңыш телим сезгә,— ди Василий Николаевич.— Анда җиңел булмас, җаваплы эш. Дөресен әйтергә кирәк, кыенлыклар юлда ук башланачак. Сезгә бернинди транспорт та бирә алмыйбыз. Кулыгыздагы мандат белән азык-төлек тә, кунар урын да табарсыз. Бу сезнең өчен яңалык түгел, авыллар аша үткәнегез бар. Тиздән Бөгелмәдә булырсыз дип ышанам. Сез анда бик кирәк. Бик тә,— дип ул Гашекның кулын кыса.

Бу сөйләшү 1918 елның октябрь уртасында була.

Өяз шәһәрчеге Бөгелмәдән аклар куыла. Әмма хәлләр шәптән түгел: икмәк, азык-төлек җитешми, ачыктан-ачык спекуляция бара. Совет властена каршы саботаж дәвам итә...

Шундый көннәрнең берсендә хәрби комендатурага уртача буйлы, башкалардан әллә ни аерылып та тормаган бер кеше килеп керә. Хәер, ачык-җылы карашлы зәңгәр күзләре аны башкалардан аера иде булса кирәк.

Ул тиешле кешене эзләп табып честь бирә дә:

— Белдерергә рөхсәт итегез, Австрия императорының 91 нче пехота полкы, 11 нче маршевой ротасының элекке рядовое, хәрби әсир, хәзерге көндә исә данлы Кызыл Армия рядовое Иосиф Швейк хезмәт вазифаларын үтәр өчен Бөгелмәгә килеп төште!— дип тезеп китә.

Укучыларга бу бәлки бик сәер тоелыр. Бөтен дөньяга билгеле әдәби герой Бөгелмәгә ничек килеп чыккан? Фантастикамы әллә бу? Юк, барысы да үз урынында. Ярослав Гашек үзенең героен әсирлек аша Кызыл Армия сафларына китерергә уйлаган. Ул «Швейк Бөгелмәдә» исемле әсәр дә язмакчы булган, тик өлгерә генә алмаган. Кыскасы, булдыклы солдат Швейк язучы үзе үткән юлдан үтәргә тиеш булган. Бөгелмә — шул юлның бер тукталышы.

Революциягә хәтле чыккан энциклопедияләрнең берсендә Бөгелмә турында болай дип языла: «Тимер юллар Бөгелмәне һәм өязне бөтенләй әйләнеп уза... Ике больница, картлар йорты, 3 классны училище, хатын-кызлар монастыре, земство китапханәсе. Җомга көннәре — базар. Өч аракы заводы...»

Халык составы буенча да Бөгелмә бик чуар була. Бала-чаганы да исәпкә алсаң, анда 16 мең кеше яши. Иң зур категория — шәхси милек тотучылар — 3 мең чамасы. Тимерче, слесарь, балта остасы, столяр кебекләр берән-сәрән генә булса, маляр, итекче, мичче кебекләр дистәләп санала. Кыскасы — шәһәрдә халык власте таянырлык кеше бик аз була.

Шулай да коммунистлар аптырап калмыйлар. Җиң сызганып, революцион тәртип урнаштырырга керешәләр. Бу эшне комендант вазифаларын вакытлыча башкаручы М. Федоров алып бара. Нәкъ шул көннәрдә, ягъни 1918 елның 14 октябрендә шәһәргә Гашек килеп төшә. Һәм үзенә хас энтузиазм күрсәтеп, баштан-аяк эшкә чума. Беренче көннәрдә ул армия өчен җылы киемнәр җыюны оештыра.

Беркөнне иртән комендатурада Гашек яңа хәбәр ишетә — комендант Иван Широков килеп төшкән һәм үзенә җыя икән.

26 октябрьда шәһәрдә шушындый приказ тарала:

Приказ 1

§ 1

Шушы көннән шәһәр коменданты вазифаларын башкарырга керештем.

§ 2

Ярдәмчеләрем итеп Шпетульский, Домницкий, Таранов һәм Гашек иптәшләрне билгелим.

Кыска вакыт эчендә Гашек үзен намуслы, принципиаль һәм эшлекле хезмәткәр итеп күрсәтә, шәһәрдә тәртип урнаштыру буенча армый-талмый эшли.

Азык-төлек мәсьәләсен хәл итү беренче чиратта тора. Авыр хәлдән файдаланып, жуликлар һәм спекулянтлар бәяләрне күтәрәләр. Күп кибетләр бөтенләй ачылмый. Өстәвенә — чигенгән чакта аклар тегермәннәрне җимергәннәр, тәгәрмәч каешларына хәтле алып киткәннәр. Шәһәр онсыз-икмәксез кала.

Гашек хуҗалары качкан тегермәннәрне торгызу эшенә керешә. Күп тә үтми, шәһәр халкы һәм хәрбиләр даими рәвештә икмәк ала башлый.

Шушы хәлләрдән файдаланып, Телегин дигән сәүдәгәр бәяләрне күтәрә, кибеттә сатып алучылардан көлә, мыскыл итә.

— Сатып алмагач, нигә буталып йөрергә?! Пычрак кына ташыйсыз,— ди ул.

— Киндер маен күпмедән җибәрәсең?— ди бер карчык.

— Фунты кырык сум,— ди теге күзен дә йоммыйча.

— Син нәрсә, Гурьяныч, шаштыңмәллә?— диешәләр кибеттәгеләр.

— Мәскәүдә хәзер майның фунты йөз сум, мин әле арзанга бирәм, иртәгә кырык сигезгә дә күтәрүем бар.

— Бу — спекуляция!— ди арадан берәү.

— Күп сөйләнмә, агайне. Ниткән спекуляция ди ул. Кара нинди суыклар башланды, сугыш бара. Теләсәм, иллегә дә алырсың. Без бит сәүдәгәр — вак халык. Безгә — акча, сезгә — товар. Шулай булгач... Нишләмәк кирәк. Аласың.

Комендатураның бу мәсьәләдә көрәш алып баруын күреп, кайберәүләр Телегинның кыланмышларын килеп-килеп сөйли. Җитмәсә, урлаган товар белән сату итә икән. Аннан яшереп, фәхешханә тотуы беленә.

Комендант бу эшне Гашек белән Тарановка тапшыра.

— Карак карак инде, ачыклап та торасы юк, атарга да үтерергә үзен,— ди арадан берәү.

— Алай ярамый,— ди Гашек.— Фактларны тикшерергә кирәк. Совет власте беренче чиратта — дөреслек, хаклык дигән сүз. Кем булуына да карамастан, тикшерергә тиешбез. Сәүдәгәргә баргач, барыннан да элек шуны онытмагыз.

Телегин аларны бик ачулы каршылый. Күзләре нәфрәттән кысылган.

— Берни әйтмим. Хакыгыз юк. Бездә ирекле сәүдә. Товар минеке: телим икән — сатам, телим икән — черетәм!

Кырыс йөзле солдатларны күргәч, тегенең дәрте сүрелә төшә. Сорауларга җавап та бирә башлый. Гаепләүләрне, әлбәттә, кире кага. Эш тупикка терәлә дип торганда... Гашек тыныч кына читтә басып торган приказчикка игътибар итә. Таранов сәүдәгәрдән сорау алган арада тегенә сиздерми генә приказчик янына килә.

— Хәлләр ничек соң, агайне,— ди ул сүз башлар өчен.— Ник читтә басып торасың? Әллә куркасың инде?

— Ник куркыйм. Просто кәеф начар, авырып торам бу арада,— ди приказчик теләр-теләмәс кенә һәм сүзне бетерер өчен читкә борыла.

— О, бу — житди сәбәп,— ди Гашек, тегенең хәленә кереп.— Дөрес, аны кайчак исәпкә алып тормыйлар. Менә, мәсәлән, бер жинаятьчене тотып асарга тиеш булганнар, ә ул тоткан да ливерный колбаса ашап агуланган. Борып-борып эче авырта икән бичараның. Маңгаена салкын тир бәреп чыккан.

Приказчик кызыксынып аңа борыла, ә Гашек, күрмәмешкә салынып, сөйли бирә:

— Ну, врачлар, әлбәттә, тегене дәваларга тотына. Жәзалауны кичектерәләр. Ике атна буе жинаятьчене дәвалыйлар. Һәм бер көнне доктор аңа сез котылдыгыз, ди. Ә иртәгесен, бөтен шартларын туры китереп, асып та куялар, чөнки ул инде дар агачы өчен ярарлык була.

Гашек күпмедер тукталып тора, аңа приказчикның уйлануы кирәк.

— Төрмәгә эләккән кешедән көнләшерлек түгел инде,— дип алып китә ул бераздан.— Бигрәк тә хужасы аркасында эләккән кешегә. Минем менә Мартин исемле бер танышым бар иде. Ул Рамм исемле графның дуңгызларын карады. Күргәзмәгә дигән дуңгызларын. Көнен дә, төнен дә бер тынгылык күрмәде, бичара. Шулай бер көнне граф белән графиня килеп керәләр дә чучканың температурасын үлчәргә керешәләр. Термометр, үч иткәндәй, сигез градус урынына жиде ярымны күрсәтә. Шау-шу куба. Мартин гаебен танырга мәжбүр була, баласы авыру сәбәпле дуңгызның температурасын вакытында үлчи алмаган. Граф, күп уйлап тормастан, тегене эшеннән куып чыгара. Ә Мартин, үч итеп, тота да чучканы суя. Тагын тавыш куба. Графиня аңына килә алмый ята. Мартинны — төрмәгә. Бичара алты ай камерада ялгыз утыра. Ә барысы да хужа өчен тырышканга...

Шунда приказчик бер көлә, бер калтырана башлый.

Ә Гашекка шул гына кирәк тә. Тимерне кызу чагында сугып калырга тырыша.

— Менә шундый кабәхәтләр аркасында интегәм дә инде,— ди ул.

— Ничек?

— Шулай. Телегин кебекләр халыкка көн күрсәтмиләр. Ә минем халыкка ярдәм итәсем килә. Шуңа күрә Россияне алардан арындырмыйторып туган илгә кайттым юк. Житмәсә, моның тагын бер сәбәбе бар, шул тота.

— Ул нинди сәбәп тагын?

— Тәк, пустәк кенә кебек үзе, әмма эштә ярдәме зур. Мин кешенең күзенә карап, уен белә алам.

— Чынмы?

— Ипидер менә. Нигә алдашыйм,— ди Ярослав бер дә исе китмичә.— Сине просто кисәтеп куюым. Ошыйсың син миңа, парин.

Гашек приказчикка якынрак килә дә ярым пышылдап:

— Мин бит болай да нәрсәнең кайда ятуын беләм. Әлегә дәшмим генә. Телегин үзе яки башка берәү әйтмәсме дип көтәм. Әйтсәң, соңыннан үзеңә жиңелрәк була бит... Ә тәртип бездә каты. Чеканың бәлдерүләрен укыгансыңдыр.

— Укыдым,— дип пышылдый тәмам башы әйләнгән приказчик.

— Революциядән әйбер яшерү уен эш түгел,— ди Гашек, кемнедер кызгангандай, авыр сулап. Ә үзе приказчикны күзәтә. Һәм кинәт, чекерәеп, тегенең күзләренә карый. Гашекның карашын күтәрә алмый приказчик, битен кулы белән каплый. Аннан йөзен ача да ишеккә ымлый. Гашек аның артыннан чыга.

Күп тә үтми, Гашек, балкып, бүлмәгә килеп керә. Приказчик барысын да сөйләгән: товарны кем китерүен дә, нинди бәягә сатуын да, күпме табыш алуны да — барысын да.

Кибет шундук ябыла, сак куела, ә сәүдәгәргә товарың Кызыл Армия файдасына конфискацияләнә дип әйтелә.
Сәүдәгәр тиресенә сыеша алмыйча дулый.
— Жалоба язачакмын,— дип кычкыра.
— Бик дөрес эшләрсез,— ди Гашек, тегенә борылып,— тик фәхешханә тотуыгызны да әйтми калмагыз. Анысын да ябарбыз.
Телегинга су сипкәндәй була. Гашек та кайсы жепне тартасын белә. Мондый эшләр өчен баштан сыйпамаячаклар.

Нәрсә белән генә шөгыльләнергә туры килми аңа монда? Җирле Советларның эшчәнлеген көйләү дисеңме, сәүдәне җанландыру, элекке офицерларны, полицейскийларны исәпкә алу һ. б. Гашек дуслары белән Кызыл Армия частьларына торак урыннары таба, шәһәрне саклауны оештыра — болар бик күп көч һәм вакыт таләп итәләр. Шуңа да карамастан, Гашек, китапханәгә кереп, китаплар актарырга да вакыт таба. Шәһәрне азат иткәч, алпавыт Елатович йортына аклар белән качып киткәннәрнең чит телдәге китапларын җыялар. Алар тау булып өелеп ята. Шуларны тәртипкә кертү, аралау яшь укытучы Анна Шишеновага тапшырыла.
Бер көнне эшләп утырган укытучы янына бер ир-ат килеп керә, записка суза. Запискада түбәндәге сүзләр: «Гражданин Гашекка чит телдәге китаплардан файдалану рөхсәт ителә».
— Гафу итегез. Записканы мин юри китердем. Буталчык вакыт. Шигегез калмасын дидем. Ә сезнең исемегез ничек?
Кыз исемен әйтә, Гашек куен дәфтәрен чыгара.
—Анна,— дип кабатлый ул, аннан иҗекләп:— Вла-ди-ми-ров-на,— дип язып та куя.— Ә хәзер эшкә тотынсак та ярый.
Алар французча китапларны аралый башлыйлар. Гашек кызның бу телне яхшы белүен күреп:
— Миңа немецча китапларны араласам яхшырак булыр, французча начар беләм,— ди.
Киткәндә ул, саф французча итеп, кыз белән саубуллаша. Тегесе гаҗәпкә кала. Гашекның француз, немец, инглиз, итальян, венгр, поляк телләрен яхшы белүен ул каян башына китерсен!
Яшь укытучы Гашек белән комендатурада еш очраша. Бер килүендә язучы аның ни өчендер кәефе кырылганын күрә.
— Сез нигәдер борчулы, бәлки мин ярдәм итә алырмын?— ди.
— Һич кенә дә ат таба алмыйм,— дип зарланып ала кыз.— Китапларны яңа җиргә күчерәсе бар. Кемнән сорасам да, атлар мөһимрәк эштә диләр. Белмим инде нишләргә дә...
— Соң нигә комендатурага мөрәҗәгать итмисез? Ярдәм күрсәтербез. Хәзер үк. Китаплар да бик мөһим эш бит. Бик мөһим. Мин аны беләм инде...

Гашек хәрби әсирләргә дә бик игътибарлы булган. Бөгелмә елгасы аръягындагы лагерьга барып, чехлар, словаклар, венгрлар, немецлар, серблар белән еш кына әңгәмәләр үткәргән, аларга Совет властеның политикасын аңлаткан.
— Беркем дә сезне монда калырга мәҗбүр итми. Сез ирекле. Телисез икән, өегезгә кайтып китәсез, әмма сез бит пролетарийлар, эшче халык. Әгәр сезгә халык власте кадерле булса, кулыгызга корал алып, буржуйларга каршы көрәшегез, ярдәм итегез рус пролетариатына.
Икенче бер килүендә ул әсирләргә 15 ноябрьда «Правда» газетасында басылган Республика Хәрби Революцион Советы приказын укый,

чехлар белән словакларга туган илләренә кайту өчен тулы гарантия бирелүен аңлата.

Кичләрен, ыгы-зыгы тынгач, Гашек комендант ротасында булырга ярата.Ниләр генә сөйләми ул солдатларга. В. И. Ленинны тыңлавы турында да, Самарада күргәннәрен, фронт хәлләрен, чит ил хәбәрләрен — барысын да житкереп тора. Еш кына туган илен телгә ала.

— Их, дуслар,— ди ул, хыялга бирелеп китеп,— сез Праганы күрсәгез иде, иң матур шәһәр бит ул!

— Шупашкар да матур шәһәр,— дип куя шунда бер чуваш.

—Дөрес, һәркемнең үз шәһәре, иң матур шәһәре бар. Күпме анда зиннәтле сарайлар, мәһабәт ныгытмалар. Вифлеем часовнясына карыйсың да магистр Ян Гус тавышын ишеткәндәй буласың. Ул безнең милли героебыз, 500 ел элек халыкны эксплуататорларга каршы күтәргән.

— Алайса, күптән башлагансыз икән,— дип куя арадан берәү.

— Ә Рәсәйдә әллә күптән түгелме? Степка Разин белән Пугачевны гына ал... Күптән инде Иделнең алар үткән төшләрен күрәсе килә. Бездә дә Идел кебек матур елга бар — Влтава.

Гашек, хискә бирелеп, күзләрен үк йома. Ә бераздан:

— Их, сагындым да соң туган якларны,— ди.— Рәсәй матур, ә Прага — туган жир. Аңлыйсызмы?

Солдатлар аның хәлен аңлап баш кагалар.

Кыен хәлләрдән чыгарга Гашекка тапкырлыгы ярдәм итә.

Бер көнне комендатурага ашыгыч телеграмма килеп төшә: жибәрелгән хәрби частьларны каршылагыз, торак урыннары белән тәэмин итегез, диелгән була анда. Эзли торгач, иске казарма табыла. Тик анда кереп булмаслык пычрак, тәрәзәләре каткан, кая карама — үрмәкүч оясы. Моны ничек рәткә кертергә? Эшче куллар житешми, ишләргә дә белгән юк. Шунда Гашек уйлап таба:

— Хатын-кызлар монастыре,— ди ул.— Анда бит тик яталар.

— Ничектер яхшы түгел,— диләр иптәшләре.— Изге жир бит.

— Берни булмас ул изгеләргә. Эшләп күрсәтсеннәр әле бер. Юкса бар белгәннәре — дога уку да гайбәт сату.

Шундук боерык жибәрә Гашек. «Монастырь игуменьясына. Шушы кәгазьне китергән кеше белән казарманы тәртипкә салу өчен, кичекмәстән илле кеше жибәрегез».

Күп тә үтми, үтәүче кире әйләнеп кайта. Игуменья боерыкны үтәүдән баш тарткан.

— Болай булгач, үземә барырга туры килер,— ди Гашек.— Күптән дини темаларга сөйләшкән юк иде.

— Кызылармеецларны да ал. Сак бул,— ди комендант Широков.

— Абруй өчен бер-ике сугышчы алмый булмас. Кызларның да күңеле күтәрелер.

Хәрбиләрне күреп, монастырь хуҗасы куркуга төшә. Монахиняларны жыярга кушкач, бөтенләй югалып кала.

— Политбеседа үткәрү өчен,— дип аңлата Гашек.

Кара стена булып тезелешкән монахинялар сафыннан пышылдаулар ишетелә:

— Хәзер бөтендөнья революциясе турында әкият сөйләячәк.

Гашек көлемсерәп куя, шунда көтелмәгән бер план туа.

— Сезнең арада иске тормышка кайтырга теләүчеләр юктыр дип уйлыйм,— дип башлый ул сүзен.

Рәтләрдән ризасыз мыгырданулар ишетелә.

— Апалар-сеңелләр, мин сезне күп көттерергә жыенмыйм. Бу фани дөнья ыгы-зыгыдан тора. Тән рәхәтләренә бирелеп китеп, хезмәт дигән изге бәхетне онытып жибәрү дөрес булмас иде. Сезгә мәгълүм булган-

ча. Изге Павелның Фессалоника халкына җибәргән мөрәҗәгатендә болай диелгән: «Сезгә васыять итеп шуны әйтәм: әгәр кем дә булса эшләмәсә, ашамасын да».

— Менә молодец,— дип пышылдый шунда олы яшьтәге кызылармеец.— Ничек итеп изге апостолларны революция эшенә җигә.

Шунда игуменья алга чыгып баса да сөйләүчегә ачу белән текәлә.

— Алла бәндәсе, җавап бир: ул казармада безне нишләтмәкче буласың? Өстеңә гөнаһ алма, ходай гафу итмәс.

«Хәйләкәр карчык,— дип уйлап ала Гашек.— Ни өчен чакырганны белә торып, мәсьәләне куертмакчы... Авызын томаларга кирәк».

— Сезгә анда эш юк. Яшегез узган,— ди Гашек тыныч кына.— Яшь итегез, ә илле кызны казармага җибәрергә барыбер туры киләчәк.

— Ялварып сорыйм, харап итмә кызларымны!— дип үкерә хуҗабикә. Аның скандал кубарасы килә.

— Чиркәү милкенә берәүнең дә кагылырга хакы юк. Ә эш кызларга таныш. Авыр эш түгел. Алар гына булдыра алырлык. Солдатлар да канәгать булып калачак.

— Антихрист!— Карчык акырып ук җибәрә.— Алла хакы өчен харап итмә кызларымны. Моның өчен тәмугта яначаксың!

— Алла ярдәм бирсен сезгә. Казармада күтеп торалар. Ирләргә ярдәм кирәк,— ди Гашек.

Шунда хатын-кызлар елаша башлый.

— Православныйлар!— дип кычкыра Гашек бар көченә.

Кинәт тынлык урнаша. Барысы да аңа төбәләләр, көтәләр. Ә Гашек берни булмагандай сорап куя:

— Соң идәннәрне юып чыгару шул кадәр авырмыни соң ул?

— Шул гынамы?

— Шул гына... Ант итеп әйтәм. Игуменья сезгә бу хакта әйтмәдемени?— Һәм ул карчыкка борыла. Теге исә башын аска ия.

— Ай-яй-яй, хәтерегез начар икән,— дип башын чайкый Гашек.— Чистарткач, казармага кызылармеецлар урнашачак. Каршы түгелсездер бит?

Шулай итеп бу мәсьәлә дә хәл ителә. Гашек башлап җибәргән бу эшне соңыннан да дәвам итәләр. Монахиняларны төрле эшләргә чакыра башлыйлар.

Ноябрь башында хәвефле хәбәр алына: аклар Кызыл Армия частьларын чигенергә мәҗбүр иткәннәр. Дошман шәһәргә якынлаша, унунбиш чакрым гына кала. Бөгелмәдәге бөтен гаскәр фронтка озатыла. Комендатураның да өч ротасы алгы сызыкка китә. Гашек та сугышчылар белән. Ул монда зур политик эш алып бара.

— Күңелегезне төшермәгез, егетләр,— ди ул атышлар тынып торган арада.— Акларның уңышы — вакытлы нәрсә генә ул. Без аларны туктаттык, тиздән куып та җибәрербез, менә ярдәм генә килсен, арт сабакларын укытырбыз без аларның, табаннарын ялтыратырлар.

Шулай булып чыга да. Тиздән резерв килеп җитә, дошман алып ташлана. Бөгелмә ирекле шәһәр булып кала.

Декабрь ахырларында комендатурага күрсәтмә килеп төшә: Гражданский революцион комитетка тиз арада хезмәткәрләрнең анкетасын җибәрергә.

Дәфтәр битенең яртысы хәтле бланкка гади генә сораулар язылган. Ярослав та бланк тутырырга дип утыра, күз алдыннан сорауларга сыймый торган күпме хәлләр уза.

«Хәзерге көндә нинди вазифа үтисез һәм нинди числодан».

Кәгазьгә түбәндәге сүзләр языла: «1918 елның 16 октябреннан комендант ярдәмчесе».

Кыска әйтелгән, әмма шушы фронт буе шәһәрендә кәгазьгә сыймаган күпме рухи һәм физик көч түгелгән, күз алдыннан күпме язмышлар узган.

«Октябрь революциясенә кадәр кем булып эшләдегез?»

Монысы да — гап-гади сорау. Ә уйлый башласаң, үзе бер гомер. Әдәбияттагы беренче адымнар, китаплар, фельетоннар, хикәяләр... Анархистлар партиясе, илдә шау-шу кубарган үз партияңне булдырырга йөрүләр, власть вәкилләре белән даими тартышу, акча җитмәү, эшсез интегүләр... Әдәбиятта аны тиз күреп алалар, уңыш та тиз килә, дөнья шаулатып йөрүләр, аннан уңышсызлыклар башлана... Барысы да чуар калейдоскоп пыяласы кебек хәтердән уза. Шулай да ул сорауга бер сүз белән җавап бирә: «Журналист».

Әйе, аның бөтен гомере вакытлы матбугат белән бәйле. Беренче әсәре — «Чегәннәр бәйрәмдә» исемле очеркы 1901 елның 26 гыйнварында ук басылып чыга. Башкалары да газета-журнал битләрендә күренә килә. Ул легионерларны Чехиянең азатлыгы өчен көрәшкә өнди, рус революциясен яклап чыгышлар ясый. «Журналист» сүзен язганда күцелендә газета, журналларда эшләү теләге тагын кабына. Үткен каләме белән революция дошманнарын фаш итәсе килә.

«Шәхси милеккә мөнәсәбәтегез».

Моны укыгач, Гашек елмаеп куя. Ни дияргә? «Милек»... Аның беркайчан да милке булмады. Һәм ул аңа омтылмады да. Шәхси милек аны бәйләп куяр иде. Ә аңа ирек кирәк. Шуңа ул бер сүз генә яза: «Юк».

Һәм соңгы сорау: «Совет властена теләктәшлек күрсәтәсезме?»

Күпләр «күрсәтәм» дип яза. Ә Гашекның анкетасында башкача: «Коммунист».

Кыска да, аңлаешлы да. Коммунист — Совет власте өчен көрәшүче. Моннан да ачык итеп ничек әйтә аласың?!

*

* *

Гашек Бөгелмәдә ике ай ярым хезмәт итә. Күп вакыт түгел, тик андый катлаулы чордагы ике ай ярым вакыт тыныч тормышның елларына тора. Андагы очрашулар, хәлләр, вакыйгалар язучы өчен зур мәктәп була.

Гашек монда зур имтихан үтә, күп нәрсәгә өйрәнә һәм иң мөһиме, Совет власте өчен барган көрәшнең мәгънәсенә төшенә, яңа тормыш сулышын тоя.

Русчадан **СОЛТАН ШӘМСИ** тәрҗемәсе.

# Шамил Маннапов

## Апрель авазы

«Җәмәгать, ишетми калмагыз:
Мәгарә ишеге ачыла.»
Гүяки,
Шулай дип һәр елны Мәйданга
Апрельнең җилләре чакыра.

Без килдек Тукайлар варисы —
Хәкимнәр хикмәтен тыңларга.
Апрельле халкыма мең рәхмәт —
Күңеле моңга бай булганга.

Апрель ул әниең шикелле,
Аналар ни тели — билгеле:
«Оланнар, яшәгез дуслыкта,
Саклагыз Ватанны сез, илне...
Булыгыз бәхетле, гомерле».

Аналар теләге күп төрле,
Төбендә — энҗедәй яхшылык.
Бу изге теләкне без ничек
Яшибез тормышка ашырып?

Яшибез зур-бөек семьяда,
Урын киң сиңа да, миңа да.
Бу — Ленин төзегән уртак йорт,
Тигезлек, Иминлек — нигез нык!

Юк, буш сүз түгел бу — чынбарлык:
Юлларның ниндиен узмадык,
Читләргә без нәфес сузмадык,
Сузганны тукмадык — тузмадык.

Бирмәбез хәзер дә апрельнең
Саф җилен сөремгә бутарга,
Язларның кояшы нурына
Нейтрон ялкыны кушарга.

Җәмәгать, ишетми калмагыз:
Мәгарә ишеге ачыла!..»
Сагынып көтелгән бу бәйрәм —
Халкымның зур улы каршында:
Даһилар тудырган бу айда
Иманны яңартыйк тагын бер;
И күңел, халкыңның, Илеңнең,
Җиреңнең һәр даим хәлен бел!

## Халкым өчен

...Аерырга теләп Шигъриаттән,
Зинданнарга күпме япканнар,—
Тик шагыйрьләр музалары белән
Кавышырга җаен тапканнар.
Бу дуслыкның җимешләре булып,
Җырулары —
Җыр-уллары илгә кайтканнар.

...Бу якларның яшел яфрак исен,
Кошлар җыры тулы һавасын —
Табигатьнең назын
Калдырам да, мин булмәгә керәм.—
Мине кеше иткән халкым өчен
Сүзләрем бар җырга саласы.

Сөйгәнеңне озак күрми торсаң,
Сүзләр табылмаган шикелле,
Кәгазь йөзенә карап, уйга калам:
Ничек кенә үтемлерәк итеп,
Аңлатырга йөрәк хисемне?

...Халкым көткән сүзне моңыма төреп,
Яңгыратып әйталсам иде.
Якташларым янына җыруларым —
Җыр-улларым
Миннән алда кайталса иде...

## Алда — яшьлек көтә

Менә тагын мин — каен урманында,
Рәхәт тә соң шул чаңгы юлларында!

Йөземне кар кызымы алсулаткан?
Каршы ала агачлар кар-толыптан.

Эләгеп калган бер ботакка ал яулык...
Алга-алга! Анда — Мәхәббәт тавы.

Авыру, картлык артта калсын боегып —
Алда — яшьлек, көтә нурда коенып...

## Аккошны һәлак иткәннең...

И гомерем аккошы,
Күңелемнең яктысы,
Очкан чагыңда ашкынып,
Кем сиңа ук атты соң?!

Сагынсаң да һаваны,—
Канатларың яралы,
Очу тәмен белгәннәргә
Очмый яшәү ямандыр...

Ләкин нигә аучының
Йөзендә юк шатлыгы? —
Аккошны һәлак иткәннең
Кими күңел аклыгы...

●

Кешеләрдән кача,
диясездер бәлки минем хакта...
Ә мин кешеләрдән түгел,
Яман гадәтләрдән генә качам.
Качам төрле гайбәтләрдән,
күз буяудан, әләкләрдән —
чакмасыннар димен килеп арттан...

Шул гадәтем аркасында
күп вакыт ялгыз да калам,
ямансулыйм мин, моңланам.
Ләкин барыбер,
«Кеше дигән бөек затны
түбәнсеткән, йөзенә кызыллык китергән
бәндәләр арасында булмадым,
ваклыклардан читтә яшим», дип юанам.
Кешеләрдән качмыйм!
Мин —
Кешеләр эзләп барам...

●

Еллар сезне картайтмасын,
 япь-яшь кызлар,
картайсагыз, бу дөньяны
каплар бозлар.
Сагынырга сез булмагач,
күңел сызлар.

Сездән башка без — ир-атлар
дәрмансызлар.

Картаймагыз, картаймагыз,
яшьтәш кызлар!

## Кайтыгыз

Гөрләвекләр килеп уятты да,
Иделкәйдә шаулап акты боз.
Җылы якка киткән аккошларым,
Ник кайтмыйсыз инде, кайтыгыз.

Кайтыгыз сез: сабыйларга тәпи,
Ә яшьләргә алып мәхәббәт,
Сырхаулыга саулык китерегез,
Дөньяларга — ризык-бәрәкәт.

Кайтмый калганнарын көткәннәргә
Сагыну-моңнар алып кайтыгыз.
Сездән минем көткән нәрсәм шул ук:
Яңа җырлар алып кайтыгыз.

Ул җырларда — сабыйларга тәпи,
Яшьләр өчен булсын мәхәббәт,
Сырхау кеше сихәт алсын аннан,
Дөньяларга иңсен бәрәкәт...

Гөрләвекләр килеп уятуга
Иделкәйдә шаулап акты боз.
Җылы якка киткән аккошларым,
Бик сагындым сезне,
Кайтыгыз!..

# Ләис Зөлкарнәев

## Ядәч

Туа кеше. Әҗәл килә.
«Ядәчләшик,— ди,— әйдә.
Отсаң, мәңгелек буласың.
Отылсаң,— ди,— бигайбә!

Газиз җаның миңа була,
Ә тәнеңне җир коча».
Кеше риза. Өзелә бәхәс
Кендек белән берочтан.

Үсә кеше. Мирас ала —
Йола ала, хәситә...
Онытты, дип уйлый Әҗәл.
«Истә,— ди кеше,— истә!»

Һәм ала ул ил картыннан
Зирәклекне, җорлыкны.
Таудай саллы олпатлыкны,
Ала җиңелмәс рухны.

Бик күп еллар яши кеше
Һәм бер көнне, ниһаять,
Оныкларын чакыра ул
Әйтер өчен васыять.

Онытты, дип уйлый Әҗәл.
«Истә,— ди кеше,— истә.
Гомерең өзелсә дә, балам,
Көең өзелмәсен эчтә!»

Тән мәңгегә түгел икән.
Бетә хәтер, бетә хәл.
Соң сулышын ала кеше.
«Ядәч!»— кычкыра әҗәл.

Авыл зурлап җирли аны
Зират түренә, эчкә.
Онытты, дип уйлый әҗәл.
«Истә,— ди авыл,— истә!»

Җыруларын җырлый һаман
Гашыйклар хат көткәндә.
Әкиятен сөйли һаман
Малайлар ат көткәндә.

Тирән уйда утыра, ди,
Аптыраган, ди, Әҗәл.
Җанын алдым, тәнен алдым,—
Исән калды. Бу ни хәл?!

●

Көндезен дә, төнен дә
Пар күләгә төшә миннән,
Пар күләгә.

Уйга талам,— бер күләгәм
Башын ия гамь белән.
Озак тормас бу күләгә.
Тезләнүне белмәгәнгә,
Җиргә иңәр тән белән...

Йокы бирми бер күләгәм:
Ертып күкрәк пәрдәсен,
Кәгазьгә төшә, көйдерә.
Килмидер шул сүнәсе.
Җанымның күләгәсе...

Купты күңел — кабынды җил куакларда.
Мин очамын, янып оча яфраклар да.
Таны мине, аралап ал, аралап ал —
Яфрак та мин, җил-җиләс тә, җисмем барда...

Җиргә сыенып мин тынармын, җил дә тынар.
Салмак кына күмеп китәр онытылу — кар.
Күмсә дә кар — аралап ал, аралап ал,—
Туфракта мин, һавада мин — миндә җан бар...

## Мордар

Сейде. Ләкин сөю генә
Канәгатьләндермәде.
Урын тапмас булып купты
Җанның өермәләре!

Хәтта дөнья кысан иде.
Җанның даулы чаклары
Әйләндерде бар дөньяны!—
Әмма урын тапмады.

Тапмады җан җирдә урын,
Күкләргә караш ата.

Күкрәп-күкрәп дәшә күкләр:
Җирдә яшәү сафсата!

Монда иркен, ирек монда,
Монда бар да югары.
Җанны тулылыгы белән
Таный күк кануннары».

Мәңгелеккә мордар китте,
Күкрәгенә тотынып...
...Бәрә кылган офыкларга...—
Бәгыре калган онытылып...

## Тәрәзәдәге күбәләк

Гөлләр бии тыгыз җилдә.
Монда — күләгәләре...
Тәрәзәгә сарылдым мин —
Гөлбакча күбәләге.

Җибәрмиләр тәрәзәләр,
Җилпенәм җан көчемә.
Мыегым — яшь гөл муенын
Иркәләр өчен генә...
Канатларым — болыннарны
Гизәр өчен генә...

Баеп килә тәрәзәдә
Таҗларның ал яктысы.
Боегып калды өй гөле —
Болынның үги кызы.

Гөл телендә дәштем аңа:
— Син халәттәшем кебек...
Аңламады, туган телен
Белмәгән кеше кебек.

Кызганыйм соң кайсыбызны?
Үзем дә аның тиңе...
Канатымдай чуар язмыш,
Кая ташладың мине?
...Канатымдай чуар язмыш!
Кая ташладың мине...

Гөл таҗында җан бирәсе
Күбәләк идем. Менә,
Чәчәксез гөл, өнсез генә,
Яфрак яба өстемә...

# АЗЫК-ТӨЛЕК ПРОГРАММАСЫ — БӨТЕН ХАЛЫК ЭШЕ

Марсель Галиев

## «КЕЧЕ АРТЕК» ХУҖАЛАРЫ

*...Кадрларны эшлеклелек, принципиальлек, кимчелекләр белән килешмәүчәнлек рухында тәрбияләргә, эштә аларның инициативасын һәрьяклап үстерергә.*

(«1990 елга кадәрге чорга СССРның Азык-төлек программасы»ннан).



Кеше җирдә ни өчен яши?» — дигән мәңгелек сорауны арткарак чигереп, «Кеше җирдә ничек яши?» — дигән мәсьәләне алга куясы килә. Беренче карашка гади тоелган, әмма эчке мәгънәсе дәвамлы уйлануларга этәргән бу сорау миндә, кисәтүле чаң тавышыдай тармакланып, кайтавазын җуя алмыйча, күңелдә тагын-тагын кабатлана: ничек яшим соң әле мин? Ничек яши соң әле ул? Ничек яши соң әле алар?..

Кеше тормышта үзен гөлләр белән дә, үсеп утырган агачлар белән дә чагыштырып-тиңләп тормый, ул үзен бары тик әйләнә-тирәдәге бер үк максатка омтылган кешеләр белән генә янәшә куеп карый. Менә шунда ачыла инде күңелнең яшерен пәрдәләре — кем заяга үткән еллары өчен үкенү кичерә, кемдер, максатына ирешелгән белән генә канәгатьләнмичә, үзендә яңа омтылыш тоя, ә кемдер, дөньяга йөз чытып, үз-үзен аклар сәбәп эзли башлый. Ә гомер дигәнең һәркемгә бер генә бирелгән. Ни өчен вакыт бераүләргә зур эшләр кылырга җитә дә, икенче бераүләр өлгерми кала микән? Әллә соң вакыт агышының яраша алу хасияте бармы? Кулыннан эш килгәннәр аны иләштерә, буйсындыра аламы? Шулайдыр. Югыйсә, үзенә тигәннән артыгын эшли алучылар каян килер иде!

Мин гомерем буе әнә шулай вакытны буйсындыра алган, булган кешеләргә кызыгып яшәдем. Булган кеше дип, үз һөнәренә бирелгән, гаять тырыш кешене генә түгел, ә үз мөмкинлеге чиген дә узып, юкны бар итә, барны үстерә белгән кешеләр турында әйтәләр бездә.

Агачларга әле көз канаты кагылмаган, алар, җәйге хозурлыкның ямен җуярга теләмичә, әле һаман яшел килеш утыралар. Әмма сентябрь үзен барыбер сиздерә, урман өшкынлыгыннан исеп куйган җилдәме, юка яфракларының салкын яңгыр шавын хәтерләтеп шыбырдавындамы, сусыллыгын җуйган үләннәрнең коры кыштырдавындамы — каяндыр көз үзен искәртә, ул янәшәдә генә, яңа фасыл — кыш бусагасы төбендә җәнлек сыман посып ята.

Мин әле кайчан гына шау-гөр килеп торган лагерьда тын калган биналарга, итәкләрен җил шыбырдаткан палаткаларга карап торам. Җил моннан берничә дистә чакрымдагы Бөек Болгар ягыннан исә. Моңсу тынычлыкка ияләшә алмый торганда,

урман арасыннан ак яулыклы әби килеп чыга. Янәшәмә килеп баса да, исәнлек-саулык алышуга, туп-туры сорап куя:

— Бик ерактан килгән күренәсең. Әллә исәбең укытучы булып урнашыргамы?—ди.

— Теләк шулайрак иде,— дим мин, дөресен әйтергә кыймыйча; ак чырайлы, зәңгәр күзле әбидән йөземне читкә борам.

— Безнең Әнвәрнең эшкә алган кешеләре, гадәттә ипле, тәртипле булалар. Үзе дә бик уңган бала ул. Кара инде, буп-буш җиргә нәрсәләр салдырып куйды бит. Ун бала арасында үскән бик инсафлы егет ул!

Кыска гына вакыт эчендә үз гаилә тормышын да сөйләргә өлгәшкән әби, олы юл тузанын туздырып килгән машина тавышын ишетүгә, әллә кая гына юкка да чыкты. Урман бирде, урман алды үзен. Мин аның исемен дә сорый алмый калдым. «Болгар әби»,— дип уйлап куйдым эчемнән.

Минем әле Әнвәр Хуҗиәхмәтовны, мәктәп директоры буларак, турыдан-туры эш урынында беренче күрүем. «Нива» машинасыннан шактый озын буйлы, Гогольныкы сыман пөхтә ятып торган озын чәчле егет чыкты. Күзләрендә, йөз чалымнарында һаман шул сабыйлык чаткылары. Балалар дөньясын үз итеп, шулар арасында гел яңалыкка омтылып яшәгәнгә шулайдыр ул. Гомумән, әгәр кешенең эчке дөньясы белән тышкы дөньясы, теләкләре һәм эше тәңгәл килсә, канәгатьләнү тудырса, йөзе тиз генә үзгәрми, күрәсең.

Менә без «Кече Артек» исемен йөрткән хезмәт һәм ял лагерен карап йөрибез. Ни өчен хезмәт һәм ял лагере, ә пионер лагере дип кенә аталмый? Хикмәт шунда: бу лагерьда ял һәм хезмәт итү махсус план белән уйланып оештырылган. Быел монда өч смена буе, 1 нче һәм 10 нчы классларны да кертеп, барысы 296 бала ял иткән, эшкә катнашкан.

Өстәлләренә бизәкле клеенкалар җәелгән пөхтә ашханәдә «Намус тактасы» игътибарны җәлеп итә. Анда эше, тәртибе, үз-үзен тотышы белән дә һәркемгә үрнәк булырлык укучыларның фотолары тезелгән. Шунда ук «Әтиләр җире — безнең җир!» дигән стенд тора. Бу стендта — ата-аналарның һәм балаларның ял иткәндә һәм хезмәт вакытында төшкән рәсемнәре. Туган җиренә тугры булып калган, бәхетен шунда тапкан өлкән буын белән балалар арасындагы рухи бергәлек чагыла бу рәсемнәрдә.

Моннан биш-алты еллар элек бу урында беренче палаткалар корыла. Казан дәүләт университетын тәмамлагач, туган авылына укытучы булып кайткан Әнвәр Хуҗиәхмәтов (ул чакта Яңа Рәҗәп сигезьеллык мәктәбе) төрле кабинетларны шакып, шундый-шундый планнарым бар дип, олыдан кубып, буш сүз сөйләп йөрми, ә укучыларда дәрт-илһам кузгатып, конкрет шөгыльгә керешә. Беренче башлангыч... Беренче палаткалар... Ул чакта күпләр Әнвәр Хуҗиәхмәтовның бу энтузиазмына әле ышанмыйча, мыек астыннан көлеп кенә караганнардыр. Көйле генә барган көндәлек дәрес сәгатьләренә яңа мәшәкатьләр өстәләсен сизенгән кайбер укытучыларның йөзе караңгыланыбрак та киткәндер. Әмма беренче башлангыч, бернигә карамый, үзенә мәйдан сорый. Колхоз бүлеп биргән басуда көндезен эш кайный. Эштән бушаган арада — ял. Тын аланны җанландырып, музыка тавышы, укучы балаларның шат авазлары яңгырый, һәм бу авазлар, сөенечле хәбәргә әйләнеп, югары оешмаларга да барып җитә. Хыялны чынга әйләндерү, теләкне хуплау өчен, бу оешмаларның ишекләре киң ачыла. Нәкъ шушы урында, Куйбышев районы «Кызыл Йолдыз» колхозы идарәсе, Авыл хуҗалыгы работниклары профсоюзы райкомы һәм Яңа Рәҗәп урта мәктәбе дирекциясе тарафыннан «Кече Артек» хезмәт һәм ял лагере корыла башлый.

Мин затлы зәвык белән төзелгән йокы биналарын күздән кичерәм. Шунда ук — төсле телевизоры, кино күрсәтү аппаратурасы булган клуб, спорт мәйданчыклары. Уку үзәге дә лагерьда. Монда умартачы, терлекче һәм игенче һөнәренә өйрәтү дәресләре дә үтә икән.

Менә без лагерьның алма бакчасында. Укучылар монда 1416 төп төрле сортлы алмагач утыртканнар. Рәт-рәт сузылган агачлар арасында талгын җилдән күкчәчәкләр тирбәлә. Инде көз сулышын сизгән бал кортлары ялкау гына безелдәп очалар. Янә-

шәдә — умартачылары да укучылар булган умарталык. Быел аннан 372 килограмм бал суыртканнар.

Бакча тирәли, фонарьларны хәтерләтеп, сыерчык оялары тезелгән. Иң матур сыерчык оясына конкурс игълан ителүгә, бөтен мәктәп дәррәү эшкә тотына. Нәтиҗәдә, 542 сыерчык оясы ясалып, урманга таратыла. Кеше белән табигать арасындагы бәйләнеш, үзара ярдәмләшү, бала күңеленә үз хезмәте аша салынган бердәмлек күпере шушы мисалда гына да чагыла түгелме!

Куйбышев районы Яңа Рәҗәп урта мәктәбе базасында укыту-тәҗрибә комплексы оештырылган. Бу — күп компонентларны берләштергән, зур бер хуҗалык. Мәктәпнең «Колос» һәм «Нива» комбайннары бар. Комбайннарда киң профильле механизатор таныклыгы алган өлкән класс укучылары эшли. Тәҗрибә участогының һәр гектарыннан 28 әр центнер уңыш җыеп алганнар.

Мәктәпнең шулай ук бер йөк машинасы, җир эшкәртү агрегатлары, өч тракторы, ике аты бар.

1981 елда укучыларның производство бригадаларына үткәрелгән Бөтенроссия смотрында җиңеп чыккан иң яхшы ун бригада арасында партиябезнең: «Терлекчелеккә — удар хезмәт!»— дигән чакыруына беренчеләрдән булып кушылган Яңа Рәҗәп урта мәктәбе дә бар.

Бу төбәкнең җирләре уңдырышлылыгы ягыннан бик үк мактанырлык түгел. Колхозның баш агрономы Шәһит Исмәгыйлов җитәкчелегендә агротехника серләренә өйрәнгән укучылар үз участокларында тәҗрибәләр дә алып баралар. Мисал өчен, шикәр чөгендере утыртылган мәйданда дүрт төрле тәҗрибә үткәрелә. Беренче бүлемдә чөгендер орлыгы 1 центнерга 16 грамм исәбеннән бор эремәсе белән чылатылып утыртыла. Икенче бүлем молибден эремәсе белән ашлана (1 центнерга 35 грамм). Өченче бүлемдә туфрак бор һәм молибден белән баетыла. Дүртенче бүлемдә исә саф суда гына чылатылган орлык май уртасында утыртыла. Бор һәм молибденлы участокның гектарыннан 480 центнер күләмендә иң зур уңыш алынган. Нәкъ шушы төбәк туфрагына ярашлы дип табылган сый-ашлама микъдарының уңай нәтиҗәсе «Кызыл Йолдыз» колхозына да тәкъдим ителә.

Хезмәт һәм ял лагереның 195 гектарлы тәҗрибә участогында тагын бәрәңге, бодай, борчак игелә. Үз куллары белән утыртылган бакчадан карлыган, кура җиләге уңышы алына, яшелчә үстерелә, файдалы үләннәр җыела.

Тәҗрибә-терлекчелек комбинатында да колхозның баш зоотехнигы Касыйм Гыйззәтуллин җитәкчелегендә эш фәнни нигезгә куелган. Малларны үз вакытында һавага алып чыгу, яшенә һәм авырлыгына карап группаларга бүлү, азык рационын тулысынча бирү, һәртөрле мәгълүматларны, анализларны төгәл язып бару, режим саклау кебек терлек үрчетү һәм симертүдә мөһим чаралар һәр укучының ихтыяҗына әверелгән.

1982 нче елда бу комбинатта 88 нутрия, 652 куян, 74 дуңгыз үстерелеп хөкүмәткә тапшырылган. Укучылар көче белән әле тагын 58 сарык, 19 бозау карап үстерелә. Йөзләрчә килограмм җиләк-җимеш, яшелчә, файдалы үләннәр җыела.

21237 сумны тәшкил иткән еллык саф табыш мәктәп ихтыяҗларына тотыла: ашханәдә бушлай ашату, укучыларга кием-салым алу, уен кораллары, җиһазлар... Шушы хисаптан һәр укучыга «Яшь ленинчы» газетасы, «Ялкын» һәм 120 данә «Казан утлары» журналларына да яздырганнар.

Күңелләренә яхшы уку һәм хезмәт дәрте сеңгән яшь белгечләр үз казаннарында гына кайнамыйлар, башкалар кулланган ысулларны да өйрәнәләр. Мәктәптән 28 укучының Мәскәүдә Бөтенроссия хезмәт һәм ял лагеренда булып, айга якын тәҗрибә уртаклашуы, анда үткәрелгән уку, семинар, диспутларда катнашуы, эштәге яңа алымнарны өйрәнеп, үзләре ирешкәннәрне дә күрсәтә белеп кайтуы — ныклы нигезгә корылган бу комбинатның бүгенгесе һәм киләчәге киң карашлы җитәкчеләр, олыларча уйлый белгән яшь көчләр кулында икәнлеген искәртә.

1982 елда үзләре җитештергән продукция үрнәкләре белән катнашып, Яңа Рәҗәп мәктәбе — СССР Халык хуҗалыгы күргәзмәсе дипломы белән, мәктәп директоры Әнвәр Хуҗнәхмәтов һәм 14 укучы «Юному участнику ВДНХ СССР» медале белән бүләкләнде.

Менә без өйрәнү-тәҗрибә терлекчелек комбинатында. Тезелеп киткән читлек-

ләр арасында эшчән кыяфәтле укучылар кызыл күзле куяннарга ашарга салып йөриләр. Беренче карашка, кыяфәтсез генә тоелган нутрияләрне дә (тиресе затлы булганга, бәлки, табигать аларны котсыз яраткандыр) балалар, һәрберсенең холык-фигылен белеп, кадерләп карыйлар. Әнә бит, һәр читлек кырыендагы ак катыргыга матур-матур исемнәр язып тагылган: «Ут-күз», «Ялт-йолт», «Мыраужан»...

Бу мәктәптә укучылар, дәрестән соңгы буш вакытны кая куярга белмичә, трай тибеп йөрмиләр. Алар өчен буш вакыт юк. Уку — хезмәт — һөнәргә өйрәнү — ял һәм уеннар тәүлеклек расписаниегә сыйган.

— Ничек соң, укучылар барысына да өлгерәләрме, укытучылар зарланмыймы?— дип сорыйм мин Әнвәр Хуҗиәхмәтовтан.

— Яхшы укытучы өйгә эш калдырмый, ә яхшы укучы өй эшен мәктәптә бетереп кайта,— ди ул. Бу сүзләрдә, бәлки, хаклык бардыр. Чынлап та, эшең күп булса, вакыт үзе ярдәмгә килә, син аны каныңда, җаныңда тоя башлыйсың. Син — вакытка түгел, ә вакыт сиңа буйсына.

Мин Әнвәр Хуҗиәхмәтовның үз кул астындагы хезмәткәрләр белән мөгамәләсен күзәтәм. Күрсәтмә-приказ тоны аңа ят. Һәммә кешене үз урынында зур икәнен, шәхес икәнен танып, гомум эштә барыбыз да тигез, дигән сыман гади генә итеп сөйләшә, киңәшләшә белә. «Хезмәте барның хөрмәте бар»,— дигән мәкаль нәкъ менә шушында урынлыдыр да. Укучылар белән дә ул ерак ара калдырып, үзенең директорлыгын сиздереп сөйләшми. Кирәк икән, башларыннан сыйпап, җилкәсеннән кагып куя, китапча купшы вәгазь укып түгел, кешелекле, җанга ягымлы сүзләр табып, хәтта, шаяртып та ала. Көлгән чакта да, вәкарь саклап, иреннәрен газаплы тартыштырып көлми, рәхәтләнеп җәелеп, самими чаткылар уйнатып көлә. Үз эшенең бөтен нечкәлекләрен белгән, көченә, сәләтенә, дәрт-дәрманына ышанган кеше генә шулай көлә аладыр.

Вуз бетергәч, районнарның берсендә мәктәп директоры булып эшли башлаган бер танышымны мин Бауман урамында очраттым. Ул, тар күкрәген киереп, тавышын калынайтып, Казанга килгәч тә җитәкче роленнән чыгып җитә алмыйча сөйләшә башлады.

— Менә, тазарып булмый әле, көненә ике кило ит ашыйм югыйсә, ә корсак үсми... Солидность өчен анысы да кирәк,— диде ул һәм аның зарын хатыны да куәтләгәч, шаянлыктан ерак торган бу кешегә мин чын-чынлап гаҗәпсенгән идем. «Солидность өчен анысы да кирәк...»— бу сүзләр һич тә колагымнан китмәде. Мин аның эш урынында кешеләр белән ничек сөйләшүен, үз-үзен тотышын, рәвеш-кыяфәтен күз алдыма китерергә тырыштым. Гадәттә, кылган хезмәте бәләкәй кеше, гәүдәне утыртып, ясалма тавыш чыгарып, тышкы кабыгы белән ялтырарга, ялган эффект тудырырга омтыла. Бүгенге әдәпле, культуралы җитәкченең башкаларны кечерәйтеп буйсындыруы түгел, ә һәр шәхесне хөрмәтләп, үзендәге яхшы сыйфатлар мисалында тыңлата белүе мөһим.

Галстук тагып, дөрес сүз генә сөйләп, туфлиен кульяулык очы белән серткәләп йөрүче «әдәпле» эшлексезләр заманы күптән үткән, эш-гамәле сүзеннән аерылмаганны гына хөрмәтлиләр, шундыйларга ышаналар, югары бәялиләр. Шуңа күрә дә мин Әнвәр Хуҗиәхмәтовның затлы туфли башларының купшаклануын да кичерәм. Аңа отыры зурая барган мәктәп хуҗалыгын торгызу өчен көн-төн чабарга, гозерен йөрәгенә кысып, күн ишекләр төбендә чират торырга, күпме чакрымнарны узарга, кыскасы, сорый, таба, исбатлый белергә кирәк.

Яңа Рәҗәп авылы олы төзелешләрдән, зур заводлардан ерак урнашкан. Кояш йомгагы тәгәрәтерлек асфальт юллар да сузылмаган әле аңа. Мәктәп хуҗалыгы исә яңадан-яңа төзелешләр сорый, колачы киңәя, үсә бара.

Ак ташпулат мәктәп, тәрәзәләрендә чагылган эре таҗлы гөлләре, бакчасындагы яшеллеге белән, авыл уртасында үзенә бер бизәк булып балкып тора. Ак диварлар дәшми. Аларның тигез тезелгән һәр кирпеченә күпме кешенең кул җылысы, кайнар сулышы, күмәк авазлары сеңгән. Әгәр төзүчеләргә генә ышанып, кул кушырып торсаң, бу мәктәп, планда каралганча, 1983 нче елда салынып бетәр иде микән?.. Кирпечне мең бәла белән Ульяновск аша Казаннан кайтартып, төзүчеләргә ярдәм йөзен-

нән, бөтен укытучылар, укучылар коллективы өмәләр ясап, бердәм кубып тотынмасалар, әлеге якты тәрәзәләрдән менә ике ел инде укучыларның шат тавышы ишетелеп тормас иде. Җылы кабине:ын калдырып, кемдер алдан йөргәндә, кузгатып көч биргәндә генә коллектив бер йөрәк булып тибә башлый, һәм эш дигән күзгә күренмәс, авыр да, газаплы да нәрсәнең татлы нәтиҗәсе шунда күренә.

Классларда тәрбияви күргәзмә әсбаплары, төрле фәнгә багышланган кабинетлардагы җиһазлар искитмәле, хәтта, техниканың соңгы яңалыклары да монда килеп кергән. Нинди һөнәр сайларга телисең — рәхим ит! Рәт-рәт тезелеп торган тегү машиналары, токарь станоклары, фото-кино аппаратлары, кыйммәтле музыка кораллары (монда музыка мәктәбе филиалы эшли)... Кайсы түгәрәккә язылырга телисең — синең ихтыярда.

Елкылдап торган өр-яңа автобуска «Бөтенроссия смотрында җиңүчегә — ТАССР Куйбышев районы Яңа Рәҗәп мәктәбенә» дип, сәнгатьле хәрефләр белән язылып куелган. Бу зур бүләк һәммә укучыда горурлык хисе уятадыр. 1 сентябрьдә, укуның беренче көнендә, 1—3 нче класслар, шушы автобуска утырып, туган җирне өйрәнү экскурсиясенә баралар. Дөрес, һәр бала үзенең тәгәрәп-уйнап үскән тугайларын, җиләк җыйган урманнарын, җилләр көрмәкләшкән тауларын яхшы белә, мең кат күргәне бар. Әмма янәшәңдә бер тойгыга бирелгән иптәшләрең белән сәяхәт итү, укытучының гади генә нәрсәләрдән дә хикмәтләр чыгарып, ягымлы сөйләвен тыңлаганнан соң, туган як табигате, иген кырлары, ата-бабалар җире бала аңы өчен көтелмәгән яктан ачылып китә. Мондый гайре табигый дәреснең төбендә олы бер тәрбияви мәгънә ята.

Әйе, туган як ул — урман-кырлар, матур тугайлар, әрәмәле инешләр генә түгел икән, ул — тырыш кешеләрнең фидакарь хезмәте, омтылышы белән сакланып, үстерелеп, буыннан-буынга исән-имин тапшырыла килгән тормыш бишеге икән!

Бу мәктәптә эшкә дә, укыту-тәрбия мәсьәләсенә дә үзенә бер иҗади караш яши. Һәр чараны кызыклы, истә калдырырлык итеп оештыру гамәлгә кереп килә. Җәйге эшләр тәмамлангач, ата-аналарны да чакырып, лагерьда үткәрелгән уңыш бәйрәме укучылар хәтерендә җуелмас эзләр калдырадыр. Бу вакытка инде звенога бүленеп эшләгән һәр укучының хезмәт кенәгәсе тутырылган була. Тантаналы җыелыш, социалистик ярышта җиңүчеләрне бүләкләү (кайчак бүләккә 200 сумлык магнитофон да бирелә), балалар үзләре хәзерләгән ризыкларга конкурс, җыр-бию, күңелле уеннар, очкыннары йолдызларга үрелгән учак ягу — болар барысы да тантаналы истәлек булып, җир, эш кадерен белгән балаларны киләчәк хыяллары белән бәйли.

Мин хәтерлим: элек авылларда аерым һөнәр ияләре була торган иде. Әйтик, мич чыгаручы. Аның даны бу авылга гына түгел, тирә-якка да тарала. Ул чыгарган мич төтенне әйбәт суыра, кирпече тиз кыза, өй эчен дымландырмый. Әнә шундый мич чыгара белгән тылсым иясенә чират, мендәрле урын-түрне бушатып, аны көтеп алалар, хөрмәт итәләр. Бүтән берәүнең инде мич чыгарып карарга башына да килми, бу эшкә тотынырга кодрәте җитми. Балта остасы, тәрәзә рамы ясаучы, умарта караучы, алма үстерүче кебек һөнәр ияләре бармак белән генә санарлык, урамнарга ямь кертеп, гармун уйнаучы, фотога төшерүче дә аерым бер шәхеснең автоном шөгыле иде. Элек шулай иде...

Бүген ничек соң? Хәзер инде авылда ике кешенең берсе балта уйната, бурасын да бурап ташлый, мичен дә чыгара, рамын да үзе ясый, умарта да тота, гармун уйный белүчегә дә гаҗәпләнмиләр, хәтта, кайбер өйләргә, ишекләрне киң ачтырып, пианино да кереп утырган. Хикмәт нәрсәдә? Сәбәбе бик гади. Муллыкта яшәгән кешеләрдә элек затлы саналган һөнәрләрдән курку тойгысы бетте. Аларда: «Ә нигә моны мин дә булдырмаска тиеш?!» — дигән яхшы мәгънәдәге үҗәтлек, таваккаллек, уянды, яшеренеп яткан сәләтнең эшкә бары тик үзең тотынганда гына тоела торган ләззәтен сизделәр.

Әгәр мәктәптә ун ел буена бары тик укуны гына белеп, хезмәт тәҗрибәсе алмыйча, олы дөньяга каршына чыксаң, элекке куркуны ничек җиңә алыр идең икән?! Әнә шуны истә тотып, бүгенге мәктәпләрдә укыту методикасы белән бергә хезмәт культурасына өйрәтү бурычы да куелу бик табигый.

Яңа Рәҗәп урта мәктәбенең укыту-тәҗрибә комплексында теоретик белемне практика белән бәйләп алып баралар икән, соңыннан балаларга куян караучыдан башлап, шофер һәм киң профильле механизатор таныклыгына кадәр биреп чыгаралар икән, бу инде — мондагы педагоглар кешеләрне кечкенәдән үк җәмгыятькә бик кирәкле итеп тәрбияләләр, аларның сәләтен вакытында күреп алып, омтылышларына дөрес юнәлеш бирәләр дигән сүз.

«Киләчәктә кем булырга?» — дигән сорау яшь кеше күңелендә мәктәпне бетергәнче аерылгысыз юлдаш булып килә. Профессия сайлауда укытучының да, ата-ананың да йогынтысы булырга тиеш. Яшермик, кайбер ата-аналар, яшьлегемдә хыялланган минем максатка, ичмасам, балам ирешсен, дип, балага, аның сәләтенә, мөмкинлегенә бөтенләй чит-ят һөнәрне тагарга тырышалар. Шуңа күрә дә укытучылар коллективы һәр укучыны якыннан өйрәнеп, уку һәм хезмәт дәверендә аның асыл сыйфатларын ачарга тырыша.

Укыту-тәҗрибә комбинатының мөдире Миңҗиһан Сәйфетдинова мәсьәләгә болай карый.

— Кайбер укучыларның профессия сайлауда ялгышуы мәктәп белән авыл хуҗалыгы арасында бәйләнеш булмаудан килә. Безнең укыту-тәҗрибә комбинаты нәкъ менә шушы ике өлкәне якынайтырга тырыша, һәм инде ул уңай нәтиҗәләрен дә бирде,— ди ул.

Һәр уку елы башында 7—8 классларда: «Киләчәктә син кем булырга телисең?» — дигән сораулы анкета таратыла. Күпләрнең әле киләчәк юлын сайламаганлыгы, янсә икеләнүе, кайсыларының исә, ата-ана сүзенә карап, үз сәләтенә бөтенләй ятышмаган белгечлек турында хыяллануы ачыклана. Тату коллективта уртак максатка омтылып уку һәм эшләү хәлне үзгәртә. Һәр баланың холык-фигылен яхшы белгән укытучыларның шифалы йогынтысы, ата-аналар белән үтемле сөйләшүләр алып баруның нәтиҗәсе инде икенче елда шул ук сорау куелган анкеталарда ачык чагыла — җавапларда укучыларның киләчәк планнары төпле бер юнәлеш алганы сизелә, ә инде мәктәпне тәмамлаганда ул тагаен ачыклана.

1982 нче елда Яңа Рәҗәп унъеллык мәктәбен тәмамлаган 49 укучының алтысы — югары уку йортларына, уникесе — авыл хуҗалыгы техникумнарына, берсе — һөнәр училищесына кергән, калганнары, укуны читтән торып дәвам итәргә ниятләп, туган авылларында үз профессиясенә хас эш сайлаган.

Юк, кыйммәтле спорт мәйданчыклары, купшы культура сарайлары асфальт юллар салып кына яшьләрне авылда калдырып була диючеләр берьяклы уйлыйлар. Кешегә яшьтән үк дөрес тәрбия бирү, аны коллектив хезмәттә чыныктыру, үз эшеннән канәгатьләнү — сөенеч тойгысы алырлык итеп җитлектерү генә уңай нәтиҗәләр бирә. Үзе үстергән игеп, үзе үстергән агач тамырлары аша җиргә күңелләре белән береккәннәр, авылда калып, шунда бәхет табалар, эш белән бергә белемнәрен дә күтәрәләр. Күмәк хуҗалыкның байлыгын арттыручылар белемле яшьләр икән, югарыда әйтелгәннәрне булдыру да — алар кулында.

Яңа Рәҗәп мәктәбе укучылары әнә шул хакыйкатьне аңлап, рухи җитлегеп чыгалар. Мәктәп белән тыгыз бәйләнештә торучы, һәртөрле ярдәмне кызганмаучы «Кызыл Йолдыз» колхозы җитәкчеләре дә лаеклы алмашны үз итеп, ике куллап кабул итә беләләр.

Мәктәпнең укытучылар коллективы, нигездә, яшьләр. Уку һәм эш процессын ялыктырмаслык итеп оештыра белүче фантазиягә бай кешеләр. Нинди генә кызыклы чаралар уйлап табылмый монда: әнә бит, каникулга таралганда да, укучылар, сумкаларын күтәреп, тизрәк өйләренә чыгып чапмыйлар, тантаналы линейкага тезеләләр. Отряд советы председателе кулында — конвертлар. Һәр укучы тынын кысып көтә. Конвертларда олы бер сер ята. Менә отряд советы председателе конвертларны берәм-берәм ачып укый башлый. Анда — классларның өлгерешенә, хезмәткә уңышларына карап бер-берсен һич тә кабатламаган котлау сүзләре язылган икән...

Бу инде һәр классның, шулай ук һәммә укучының күңелен күтәрү, аерым игътибар күрсәтү, санлый һәм олылый белүнең кабатланмас бер үрнәге булып тора.

Хәер, каникулга таралсалар да, алар өчен мәктәп офык артында күмелеп калмый, комбинатта эш дәвам итә, классларда төрле үзешчән түгәрәкләр эшләп тора. Директор Әнвәр Хуҗиәхмәтов үзе «Яшь хәбәрчеләр», фото һәм кино сөючеләр түгәрәкләрен җитәкли. Яшь хәбәрчеләрнең мәкаләләрен район һәм өлкә газеталарына җибәрәләр, авыл радиосыннан укыйлар, шигырь, хикәяләрне түгәрәктә тикшерәләр, бәхәсләшәләр. Мәктәпнең фото сөючеләр оештырган күргәзмәне карагач, ничек инде «авыл матур уйлый» димисең: бер рәсемдә озынколак-куяннарны күтәреп, бәхетле елмаеп төшкән балалар. Алар шатлыгына җитди бер символ булып, артта плакат тора: «Күктә — кояш, җирдә икмәк мәңгелек!»

Укучы балалар эш һәм ял сәгатьләрен, спорт уеннарын, үзләре куйган спектакль һәм концертларны кинога төшерәләр, аннары, күмәкләшеп, ул фильмны карыйлар. Мәктәптәге ритм, шаулы тормыш һәр укучының күңелен үстерә, чын кеше булырга өйрәтә.

— Бездә пассив балалар юк, барысы да тырышлар,— ди Әнвәр Хуҗиәхмәтов. Аның эчке куанычын йөзендә чагылдырып әйткән сүзләренә һичшиксез ышанасың. Әнә бит, «Артек»ка бер путевка килгән, ул инде ике-өч көн буена, аны кемгә бирергә белми баш вата. Барысы да лаеклар, берсен дә читкә тибәреп булмый, әмма тырышлар арасыннан да тырышын барыбер сайлап алырга туры килә...

Әнвәр Хуҗиәхмәтов сигезенче класста укыганда үзе дә Кара диңгез буенда — «Артек»та булган. Шуңа охшашлы лагерьны туган авылында булдыру теләге аның шул вакытта ук бөреләнеп хыялына күчкән.

— Хәзергә безнең хезмәт һәм ял лагере «Кече Артек» дип атала. Бу әле башы гына. Киләчәктә... — һәм ул төзеләчәк яңа корпуслар, аттракционнар, спорт мәйданчыклары турында илһамланып, ышандыргыч дәлилләр белән сөйли башлый. Кулыннан эш килмәгән кеше моңа, коры хыял дип, күзен йомарга мөмкин.

Әнвәр күңелендә кайнаган хыял исә, тиз арада, бөтен педагогик коллективның тынгысыз эзләнүе рәвешендә укучы балаларга да күчә. Мәктәптә конкурс игълан ителә. Ял һәм хезмәт лагеренең макеты һәм киләчәктә авыл нинди булырга тиеш, диган тема буенча игълан ителгән конкурска укучылар йөзләгән макет әзерлиләр. Бөтен сәләтен, уй-фантазиясен эшкә җиккән яшь җилкенчәкләр агачтан, пенопласттан, кәгазьдән, пластилиннан — кыскасы, кул астындагы һәртөрле материалдан макетлар ясыйлар. Конкурста җиңеп чыгучылар макеты нигезендә авылда яңа йортлар да салына башлаган инде. «Кече Артек» лагере да, яшь энтузиастлар күрергә теләгәнчә, үзгәртеп корылачак.

Балалар фикерендәге безнең өчен өлкәннәр уйларга һәм эшләргә тиеш диган карашны үзгәртеп, аларның үз ихтыярына, уй-хыялына мөмкинлек бирү, аларны җитди мәсьәләләргә катнаштыру — Яңа Рәҗәп мәктәбе укытучыларының игътибарга алырлык кыю алымы.

Кеше үз гомерендә кимендә бер гөл һәм бер агач утыртып, тәрбияләп үстерергә тиеш. Шунда гына ул я ш ә е ш диган чиксез мәңгелеккә бәясез бер өлеш кертә ала. Яңа Рәҗәп мәктәбе укучыларының күпме гөл, күпме агач утыртканын санап бетерү мөмкин түгел. Шушы дәлил үзе генә дә аларның киләчәгенә өмет яктысы сирпи.

Еш кына, шәһәр газоннарында әле өлгереп тә җитмәгән, ачуташ кебек кыргый алмага үрелеп, агач ботакларын рәхимсез рәвештә сындыручы җилкуар малайларны да күрергә туры килә. Кайчак урманда, агачын төптән кисеп-аударып, шомырт, миләш җыючылар да очраштыргалый. Мондый мәрхәмәтсезлек каян килә? Шик юк ки, андый йөрәксезләр үз гомерләрендә бер генә агач та утыртып карамаганнар. Алар уенча, бу агач беркемнеке дә түгел... «Беркемнеке дә түгел... Минеке түгел» диган җәмгыять өчен ифрат зарарлы караш җәһәтеннән тагын бер мисалга тукталасым килә. Әйтик, балигъ булган, яшен яшәгән шофер элеваторга икмәк илтергә чыга. Ул машинасының әрҗәсен юньләп карамаган, ашлыгы коелып бара. Башка кешеләр,

юлда туктатып, кисәтү ясаганнан соң гына, ул, әрҗәдәге тишек-тошыкны рәтләп, яңадан кузгала. Гәрәбәдәй бөртекләрнең юлга коелып исраф ителгәнен үзе дә белә иде бит югыйсә, икмәкнең нинди авырлык белән үстерелгәнен дә белә иде! Хикмәт шунда — әлеге дә баягы «минеке түгел» дигән салкын битарафлыкта. Димәк, бу адәм мәктәп елларыннан ук бер җан булып типкән коллективта хезмәтнең ачысын-төчесен, ләззәтен татымаган, аның канына бер максатка омтылудан туган саф рух сеңмәгән.

Яңа Рәҗәп мәктәбенең укыту-тәҗрибә комбинатын карап йөргәндә (ә бит алар чын мәгънәсендә терлекчеләр, яшелчә, җиләк-җимеш, иген үстерүчеләр), укучыларның хуҗаларча «бу — безнең эш нәтиҗәсе бит» дигән якты караш, хезмәттән тәм табып йөрүләрен күзәткәч, миндә шундый уйлар туды. Киләчәктә укыту-тәҗрибә комбинатлары илнең бөтен мәктәпләрендә булдырылыр. Хезмәт һәм уку арасына әнә шундый ныклы күпер салыныр.

«Бу бит безнеке... шул ук вакытта минеке дә...» дигән төшенчәләр тәңгәл килгәндә, хезмәт рәхәте җанга тәрбия аша иңгәндә генә җәмгыятьтәге байлыкка саф мөнәсәбәт туа. Сакчыллык һәм кешеләргә мәрхәмәтле булу — шулай ук аерылгысыз янәшәлектә. «Безнеке һәм минеке дә...» дигән төшенчәләрнең бердәмлеге совет чынбарлыгында җитлеккән яңа кешенең иң асыл сыйфатыннан саналырга тиеш!


Кеше үзенең туган җирен күз карашына сыйдыра ала, ә туган илен, Ватанын күңеле белән иңли. Торган җирендә үзең үстергән гөлне, үзең үстергән агачны кадерләү, саклый белү исә — туган илеңне, Ватаныңны кадерләү һәм саклау кебек олы мәгънәгә барып тоташа.




## Мөнир Әһлиуллин

# ӨР-ЯҢА МӘСЬӘЛӘЛӘРНЕ ЧИШКӘНДӘ

ОЧЕРК



Җәүдәт Хәкимович Маннапов кырларны, фермаларны урап, колхоз идарәсенә кайтып кергәндә, төш якынлашып килә иде инде. Кабинетында ул көен дәфтәренә бүген теркәлгәннәрне тагын бер кат күздән кичерә башлады. Ишектә күренгән секретарь кыз, председательне уйларыннан аермыйм дигәндәй, әкрен генә түргә узып, өстәлгә калын гына папка куйды да кире борылды. Җәүдәт Хәкимович күзләрен көен дәфтәреннән аерды.

— Нәрсә бу?

Секретарь кыз, гаепле кеше сыман:

— Бу, ни инде... теге... нефтьчеләрнең хатыннарыннан гаризалар,— диде.

Җәүдәт Хәкимович папканы ачты, күзе иң өстәге гаризага төште. Бозау караучы Тәслия Саратхуҗинадан икән. «Нефтьче ирем Абдуллага «Сөләйнефть» идарәсе шәһәрдә квартира бирүе сәбәпле, колхоздан китәргә рөхсәт итүегезне сорыйм», дип язылган. Председатель авыр сулап куйды. Тәслияне яхшы белә ул. Башта сарыклар карады, аннары сыерлар сауды, хәзер бозаулар үстерә. Тәслиягә тапшырылган терлекләр өчен күңеле тыныч иде председательнең. Кем алыштырыр икән үзен? Икенче гариза сарык караучы Дәрига Җәләловадан иде. Калганнарын сыер савучы Нәкыя Кәримова, медсестра Рәйхана Хәйруллина язган... Председательнең маңгаена борчак-борчак тир бәреп чыкты, күзлек пыялалары парланды. Авылда яшәүче нефтьчеләргә Әлмәттә квартира бирелачәген белә иде ул, тик болай ук күп булыр дип башына да китермәгән иде: егерме бер гариза! Димәк, иртәгәдән авылдагы егерме бер йортның тәрәзәләре кадаклана, егерме бер йортта мал-туар бетерелә, колхозда эшләүче дистәләгән кеше чыгып китә. Алай гына да түгел, җирдә тәгәрәп үскән авылның киләчәге, өмете булган балалар да кими.

Җәүдәт Хәкимович телефон трубкасына үрелде. «Сөләйнефть» идарәсе начальнигына шалтыратты. Трубканы секретарь кыз алды.

— Виталий Александрович үзендәме?

— Хәзер генә кайтып керде. Тоташтырыйммы?

— Юк, рәхмәт. Аңа Фрунзе исемендәге колхоз председателе Маннапов киләчәк дип әйтегез әле. Чыгып китмәсен иде!..

Шофер, төш вакытында Әлмәттә тагын ни калган инде, дигәндәй күтәрелеп карады да, председательнең болытлы йөзен күргәч, сүзсез генә машинасын кабызды.

Җәүдәт Хәкимович каршылыклы уйларга чумды. «Сөләйнефть» идарәсенә барып кына нәрсә үзгәртеп була соң?! Авылда яшәүче нефтьчеләргә шәһәр квартиралары бирелгән, алар барыбер күчәчәкләр. Моңа кадәр дә китә тордылар, ләкин берьюлы

егерме бер гаиләнең авылдан чыгып киткәне юк иде әле. Председательне бу хәл чыгырыннан чыгарды...

«Сөләйнефть» идарәсе начальнигы Виталий Александрович Тагеев Җәүдәт Хәкимовичны ачык йөз белән каршылады.

— Рәхим ит, Җәүдәт Хәкимович! Күптән күренмисең. Шефларыңны оныттың...

— Аның каравы сез онытмыйсыз, тагын егерме бер терлекчебезне суырып аласыз.

— Ничек? Миңа терлекчеләр кирәкми. Аңлатыбрак сөйлагез әле, Җәүдәт Хәкимович?

— Аңлатасы юк. Безнең авылда яшәүче егерме бер нефтьчегә Әлмәттә квартира бирдеңме? Бирдең. Шул ук квартираларны авылда да төзеп булыр иде бит. Үзләре дә әйтеп торалар: бөтен уңайлыклары булган квартираны монда төзесәләр, авылдан һич китәсебез юк, диләр.

— Әһә, син менә нәрсә турында? Бусы инде, дускай, икенче мәсьәлә, әр-яңа мәсьәлә!

— Синең нефтьчеләрнең эше дә безнең колхоз җирендә үк бит. Син иртәгә үк аларны автобуска утыртып, безнең басуга китерәчәксең. Көн саен илле чакрымга автобус куачаксың. Ә аның хатынына нинди эш бирерсең? Җыештыручымы, вахтермы? Алар бит менә дигән терлекчеләр. Андыйларны уннарча ел буе хәзерләргә кирәк. Их!..

— Туктале, Җәүдәт Хәкимович, кызма. Беренчедән, йортларны кайда салу мәсьәләсен берләшмә планлаштыра. Мин аңлыйм, нефтьле җирдә иген игү бик мәшәкатьле. Ләкин без сезгә шактый ярдәм дә итәбез бит!

Җәүдәт Хәкимович дәшмәде. Шушы якларда туып-үскән, институт тәмамлап, туган колхозында — агроном, аннары председатель булып эшләгән кеше буларак, нефтьчеләрнең авылларга ярдәмен яхшы, бик яхшы белә ул. Әлмәт, Лениногорск, Баулы, Азнакай районнарының данын еракларга җибәрүчеләр нефтьчеләр булды. Чал Бөгелмә белән Алабуганы яңартучы да — нефть. Нефтьчеләр көче белән авылларга сөткәргечләр сузылды, өйләргә газ килеп керде. Авыллардагы бүгенге киң һәм якты мәктәпләрне, мәһабәт культура сарайларын салырга да нефтьчеләр булышты. Уннарча мең гектарда сугарулы көтүлекләрне, һәрберсендә унар мең терлек асрала торган комплексларны да нефтьчеләрдән башка төзү бик авыр булачак иде. Бу яклардагы кебек көзгедәй юлларны кем сузар иде? Нефтьчеләр ике мең ярым километр юл суздылар. Бу — колхоз-совхозлар экономикасы өчен дә файдалы: машиналар озакка түзә, транспорт чыгымнары арзанга төшә. Республиканың Буа, Чүпрәле, Тәтеш, Әгерҗе кебек районнары шоферлары нефть чыккан якларда яшәүче хезмәттәшләренә бик урынлы кызыгалар.

Сүз дә юк: нефть авылга күп нәрсә бирде. Ләкин авылдан шактый ала да ул. Колхоз-совхозларның уннарча мең гектар җире нефтьчеләр карамагына күчте. Йөзләгән, меңләгән егетләр колхозлардан нефтькә китте. Бу да авыл хуҗалыгы хезмәтен оештыруда яңа проблемалар тудырды. Буа һәм Чүпрәле, Балтач я Кукмара кебек авыл хуҗалыгы өстенлек иткән районнарда өстәлдәй тигез кырлар җәелеп ята. Игенче — биредәге җирләрнең тулы хуҗасы. Нефть чыга торган районнарда җир өсте электр линияләре белән чолгап алынган, асты — торбалар челтәре.

Басулардагы баганалар тирәсен чүп үләннәре каплап, игенченең үзәгенә үтә. Мондагы тиз азучан чүп үләнен бетерү өчен, багана тирәләрен кечкенә сабаннар белән дә сөрәләр, хәтта көрәк белән дә казыйлар. Шул урынга күпьеллык үлән дә чәчеп карыйлар. Ләкин багана төпләрендә кара солыча дигән иң зәһәр чүп үләне барыбер үсә, шуннан кырларга үрмәли бирә. Аңардан котылу өчен төрле хәйләләр коралар. Язгы чәчү барышын күзәткән сводкаларга күз салсаң, һәр елны диярлек бу яктагы районнар артта кала. Районның хуҗалык җитәкчеләре каты-каты шелтәләр ишетәләр. Игенче монысына да түзә, чөнки ул белә: бөртекләрне җир куенына иртә салсаң, басуны кара солыча басып китәчәк. Аннары уңышны көтмә инде син. Шуңа күрә игенче кара солычаның баш калкытуын көтә, аннары җирне культивацияли, шуннан соң гына чәчә башлый.

— Шулай да басуларыгызда ничәләп багана бар соң? — дип кызыксынам Җәүдәт Хәкимович Маннаповтан.

— Ун ел элек бер санаган идем. Ун мең чамасы иде. Аннан соң тагын арттылар инде...

Берничә ел элек Азнакай районының «Актүбә» совхозына Ростов өлкәсеннән ярдәмгә комбайнчылар килде. Шул чакта хәйран калган идек: ярдәмгә килгән көчле «Колос» комбайннары, авылдагы «СК-4» комбайннары белән чагыштырганда шактый аз суктырдылар. Сәбәпләре белән кызыксындык.

— Монда ничек эшләмәк кирәк?— диде ростовлылар бригадиры.— Кая карама — багана да торба. Борыла алмый интегәбез. Ике комбайныбыз, ургычларына тимер чыбык эләгеп, бөтенләй эштән чыкты. Менә бездә ул кырлар: тип-тигез, иге-чиге күренми! Хәер, бирәдәге егетләр әйбәт эшли, җайлашканнар...

Сүз дә юк, нефть игенчеләргә зур мәшәкатьләр тудырды. Авыл хуҗалыгы җирләре кими, уңдырышлы басуларда нефть манаралары, төрле биналар калка, торбалар өчен тирән чокырлар казыла. Әлмәт районында, мәсәлән, бер ел эчендә генә дә нефтьчеләргә 3282 гектар җир бүленгән. Кечерәк бер колхоз кадәр. Шуның 623 гектары нефть ихтыяҗы өчен бөтенләйгә бирелгән. Калганы берничә елдан, иген игәрлек хәлгә китерелеп, хуҗалыкларга кире кайтарылырга тиеш. Кайтарып бирелергә тиешле җир аркасында да игенче белән нефтьче арасында еш кына бәхәсләр туа әле.

Кайчак файдалану срогы үтә, ә нефтьчеләрнең эшләре тәгәлләнмәгән була. Басуны кабул итәргә баргач та, еш кына игенче аптырап кала: югандай күперәп торган уңдырышлы җир бала башы чаклы сары балчык кантарлары белән чуарланган була. Монда ничек иген икмәк кирәк?! Нефтьчеләр, эшкә тотынганчы, җирнең уңдырышлы катламын аерым урынга өеп куярга тиешләр. Әмма бу кагыйдә еш кына бозыла. Кара туфрак балчык белән катнаша. Җирнең иген үстерү сәләте нык кими. Шуңа күрә нефтьчеләрдә дә, төзүчеләрдә дә җиргә, игенчелеккә ихтирам тәрбияләү аеруча мөһим. Бу әлеге районнарда һаман да җитди проблема булып кала. КПСС Үзәк Комитетының 1982 елгы май Пленумында кабул ителгән Азык-төлек программасы үзәгендә җир турында кайгырту, аңардан рациональ файдалану ята. Бу мөһим эштән нефтьчеләр дә читтә тормыйлар, билгеле. Беренчедән, алар шул ук колхоз-совхоз басуларында нефть чыгаралар. Ә кирәк чакта алар җир сөрергә, ашлык җыярга да ярдәмгә киләләр.

«Ярдәм» сүзен телгә алганбыз икән, аны оештырудагы бер яңалыкка тукталырга кирәктер. Чөнки нефть районнарында үстерелә торган игеннең уңышы шактый дәрәҗәдә әлеге ярдәмгә дә бәйле. Менә уннарча ел рәттән инде, урак өсте җиттеме, колхоз-совхозларга нефтьчеләр килеп төшә. Аларның күбесе комбайннарда эшли. Моңа кадәр предприятиеләр колхоз-совхозларга механизаторлар җибәрәләр дә тынычланалар иде. Аларга комбайннар биреләме? Нефтьченең колхоз-совхозларда хезмәте, ялы ничек оештырылган? Нефтьче-механизаторлар ничек эшли? Мәсьәләнең бу ягы белән кызыксынып тормыйлар иде.

Соңгы вакытта районда урып-җыюда катнашучы комбайнчылар хезмәтен алдан ук оештыру юлларын эзли башладылар. Ел дәвамында районда һәр хуҗалыкка өстәмә рәвештә ничә механизатор кирәклеге ачыклана. Предприятиеләр исә авыл хуҗалыгында эшләрдәй кешеләрне сайлап куялар. Алар районның «Сельхозтехника» берләшмәсендә иген игү, комбайннарны эшләтү серләрен өйрәнәләр. Үткән елгы уңышны җыю өчен әзерлек барган чорда нефть районнарында 312 нефтьче һәм төзүче комбайнчы таныклыгы алып чыккан, техник ремонт үткәрү өчен 29 мастер-көйләүче дә әзерләнгән.

Колхоз-совхозлар үзләрендәге берничә комбайнны шеф предприятие карамагына тапшырып торалар. Шефлар аларны ремонтлыйлар, комбайнчылар белән тәэмин итәләр һәм уңыш җыюда катнашалар. Ел башында ук колхоз-совхозлардагы 460 комбайнның 240ы предприятиеләргә бирелгән. Урак өстендә 400 ләп нефтьче комбайнга утырган, кырыклап көйләүче, 100 дән артыгы шофер булып эшләгән.

Хәзер инде предприятиеләр үз комбайнчыларының авыллардагы хезмәтен, ялын, көнкүрешен оештыру турында да кайгырталар. Нефтьче механизаторлар барысы бер звенога оешып эшлиләр, нәтиҗәдә аларның җаваплылыгы арта, хезмәт дисциплинасы ныгый. Нәтиҗәне исәпләп карасалар — районнардагы 65 мең гектардагы бөртеклеләрнең 40 меңләп гектарын нефтьчеләр җыеп биргәннәр. Беренче карашка, болар — шатла-

нырлык күренешләр кебек. Табигый хәлме бу? Юк, әлбәттә. Уйлабрак карасаң, бу якларда игенче һөнәре эшче кулына күчеп бара. Тик алар игенчене тулысынча алыштыра аламы соң? Моңа уңай җавап бирү авыр.

Игенчелек, терлекчелек — бик нечкә һөнәр... Язгы чәчү, урак өсте, сугым вакыты, каз өмәләре җитсә, авыл кешесенең җаны чабышка әзерләнгән тулпар кебек ашкына башлый. Аңа бу эшләрнең һәммәсе кадерле, изге сыман. Ул, тук башаклар турында уйлап, көзен җир сөргән, кырга ашлама чыгарган, язын, йокы-ял белән исәпләшмичә, җир куенына бөртекләр салган. Чистай районының «Татарстан» колхозы комбайнчысы Хәбибулла Салахов, бу турыда сүз чыккач, болай диган иде:

— Утыз өченче тапкыр уракка чыгуым. Тик алар бер-берсенә охшамаган. Һәр елны, игеннәрнең хәленә карап, өстәмә җайланмалар кулланасың. Уракка утыз өч тапкыр төшсәм дә, ел саен туйга әзерләнгән кебек дулкынланам...

Бу — игенченең табигатенә бәйле психологик хакыйкать. Аны да исәпкә алмый булмый. Вакытлыча ярдәмгә килүчеләр бу хисне кичермиләр. Алар күңеленә үз һөнәре тамыр җибәргән. Нефтьче әле кичә генә девон тирәнлегенә омтыла иде. Бүген аның кулында — комбайн штурвалы. Аның авылдагы эшен тиз-тиз тәмамлап, кабат нефтькә юл ярасы килә, максаты башка аның. «Кичү» совхозының бодай кырында бер комбайн туктап калган иде. Шунда совхоз директоры Зәфәр Шәйдуллин белән нефтьче-комбайнчы арасында булып узган кыска гына әңгәмә әле дә онытылмый.

Совхоз директоры саламнан түшәк ясап сузылып яткан егеттән:

— Кайчан туктадыгыз?— дип сорады.

— Ике сәгатьләп бар инде, «полотно» өзелде...

— Әнә бит — машина! Полотно складта бар, ярты сәгать дигәндә, әйләнеп килгән булыр идең.

— Механик китерер әле...

Директорның ачыргалануы йөзенә чыкты.

— Их! Игенне игенче үстерсен дә, нефтьче үз нефтен үзе чыгарсын икән ул...

— Барысы да андый ваемсызлар түгел бит,— дидем мин.— Әнә «Елховнефть» идарәсеннән килгән Николай Кузнецов 10 мең центнердан артык ашлык суктырган!

— Николай башка,— диде директор.— Ул нефтькә киткәнче үк комбайнда эшләгән шул, аңарда — игенче каны...— Директор күңелендәгеен әйтеп салды.— Авылның бөтен хаҗәтен үз механизаторлары үтәргә тиеш. Моның өчен, минемчә, иң беренче чиратта, аларны шәһәрнекенә алыштыргысыз әйбәт йортлар, яхшы шартлар белән тәэмин итәргә кирәк!

Директор шулай уйлый. Совхоз үзәгендәге Кәләй авылы аның теләген тормышка ашырырга ашыккандай, берсеннән-берсе матур ап-ак ташпулатлар белән байый бара. Аларның һәрберсе икешәр гаиләгә исәпләнгән. Бөтен уңайлыклары булган бу өйләрдә иркен зал, йокы бүлмәләре, аш-су ягы бар. Газ, су кертелгән. Бәрәңге-яшелчә утыртыйм дисәң — бакчасы, терлек асрыйм дисәң, абзар — янәшәдә генә. Дирекция шундый йортлар тәкъдим итеп торганда яшьләр дә туган авылларында кала икән. Хәтта кайчандыр совхоздан чыгып китүчеләр дә әйләнеп кайта башлаган.

Фрунзе исемендәге колхозның да, «Нефтяник», «Чишмә» совхозларының да җитәкчеләре йортлар салдыра башлаган. Ләкин торак төзелешен киң колачлап алып барырга колхоз-совхозларның әлегә көчләре җитеп бетми.

Шуңа күрә бүген авылда яшәүче нефтьчеләр өчен дә торак йортларны авылда салдыру мәсьәләсе бөтен җитдилеге белән көн алдына килеп баса. Табигый ки, нефтьче һөнәре завод-фабрика эшчесеннән шактый аерыла: нефтьченең эше игенченеке кебек үк, ачык һавада, кырларда бара. Авыл басуларында берәүләр җир бораулыйлар, нефть суыра, икенчеләр икмәк үстерә.

Әлмәт районының Фрунзе исемендәге колхоз үзәген генә карыйк. Иртән авыл уртасындагы мәйдан автовокзалга охшап кала. Маңгайларына «Сөләйнефть», УБР, СМУ кебек сүзләр язылган автобуслар тезелеп киткән. Капкалар ачыла да ябыла: әле бер йорттан, әле икенчесеннән ир-егетләр чыгалар да үзләрен көтеп торган автобусларга юнәләләр. Фрунзе исемендәге колхозга караган Сөләй, Урсалыбаш, Михайловка авылларында гына да йөзгә якын кеше нефть эшенә бәйле. Әлмәт районы

предприятиеләрендәге эшчеләрнең 17 проценттан артыгы авылларда яши. Гадәттә, гаилә башлыгы нефтьче булса, аның хатыны, балалары колхоз-совхоз хуҗалыкларында эшлиләр. Мондый хәл гаилә хуҗалыгын алып бару өчен шактый уңайлы: нефтьче ир сменасын тутырып кайта, аның атнасына ике ял көне бар, димәк, йорт ихтыяҗлары турында кайгыртырга шактый вакыты кала. Гаилә членнары арасында колхоз-совхозда эшләүче дә булганлыктан, терлек азыгы хәзерләү җиңеләя. Шуңа да мондый гаиләләрдә мал-туарны күпләп асрыйлар, бәрәңге һәм яшелчә үстерәләр. Бу якларда дистәләгән еллар буе туган авылында торып нефть промыселында эшләгән, пенсиягә чыккач та шунда ук яшәүчеләр шактый.

Ләкин бу тормышның да үз кыенлыклары бар. Әйтик, нефтьченең йорты искерә. Яңасын салу зур мәшәкатьләргә бәйле. Нефтьче үзе эшли торган оешмасыннан квартира сорап гариза язарга мәҗбүр. Нефтьчеләрнең яңа йортлары исә Әлмәт, Лениногорск, Бөгелмә кебек шәһәрләрдә салына. Көннәрдән бер көнне нефтьчегә бер дигән квартира бирәләр. Шулай итеп үз хуҗалыгы белән авылда яшәгән гаилә шәһәргә күчеп китә. Бер ел элек «Сөләйнефть» идарәсе Әлмәттә 80 квартиралы йорт салган. һәм ул квартираларның барысына да диярлек авылларда яшәгән нефтьче гаиләләре кереп урнашкан. Әйткәнебезчә, шуларның егерме бере — Сөләй авылыннан.

Хәзер, колхоз-совхозларга кирәк чакта, нефтьчеләр җир сөрергә, игенне урыпҗыярга булышалар. Эшләр шушындый юнәлеш белән барса, бу якларда киләчәктә сыер савучыларны да шәһәрдән чакырырга туры килүе ихтимал.

Нефтьчеләр күп кенә авылларда менә дигән мәктәпләр, клублар салганнар иде. Тулы гаиләләр шәһәргә күчә башлагач, авыл мәктәпләрендә укырга — балалар, клубларда күңел ачарга яшьләр кими башлады.

Шәһәргә күчеп килгән нефтьчеләр исә хәзер көн саен автобусларга утырып уннарча километр ераклыктагы элек үзләре яшәгән авыл башындагы скважиналарга киләләр. Әйтик, «Ямашнефть» идарәсе — Әлмәттә, ә скважиналарының иң якын дигәне дә 50 километр ераклыкта. Бу идарә нефтьчеләре Әлмәт, Зәй, Чистай, Чирмешән, Түбән Кама районнарында эшлиләр. Идарәнең 130 нефтьче-операторы, скважиналары җир асты ремонтлау буенча 120 мастеры — барысы да диярлек, авылларда яши. Инде аларның кайберләре торак шартларын яхшыртуларын сорап гариза биргәннәр. «Ямашнефть» идарәсе начальнигы А. В. Мордвинцев, бу мәсьәләне ничек хәл итәргә җыенуларын сорагач:

— Безгә ел саен Әлмәттә ун квартира бирелә. Шулай ук Зәйдә дә яңа йорт өлгереп килә,— диде.— Нефтьчеләребез шунда яшәячәк. Дөрес, алар бездән яңа йортларны авылда салып бирүне сорыйлар. Ләкин безнең идарә төзү эшләре белән шөгыльләнми,— ди ул.— Квартираларны «Татнефть» берләшмәсе бүлә, ул әлегә шәһәрдә генә төзи.

Бу мәсьәләне кузгаткач, «Татнефть» берләшмәсенең җитәкчеләре:

— Киләчәктә дә төзелешне нигездә шәһәрдә алып барачакбыз. Авылларда йортлар салу безнең өчен файдалы түгел,— дип кырт кисте.— Анда газ үткәрү, канализация һәм су кертү өстәмә чыгымнар таләп итә...— диләр.

Мәсьәләгә икенче яктан карaганда, чыгымның кайда күбрәк икәнен ачыклау шактый катлаулана. Авылларда яшәүче нефтьче гаиләләре шәһәргә күчкәндә мал-туарларын бетерергә мәҗбүр булалар. Шуңа күрә хәзер нефтьле районндагы шәхси хуҗалыкларда терлекләр саны елдан-ел кими. Соңгы ун елда Әлмәт районы шәхси хуҗалыкларында мөгезле эре терлекләр — 6800, сарыклар — 25 мең, дуңгызлар 7 мең башка кимегән. Азык-төлек программасын хәл итүдә барлык резервлардан, шул исәптән шәхси хуҗалыклар мөмкинлекләреннән дә файдалануны яхшырту чараларын алга куя. Республикабызның нефть районнарында килеп туган әлеге житди мәсьәләне ничек чишеп була соң? Иң элек авылда яшәүче нефтьче гаиләләрен туган җирләрендә калдыру ягын карарга иде!

ТАССР Авыл хуҗалыгы министрлыгы һәм «Татнефть» берләшмәсе бу мәсьәләне өйрәнерләр, мөгаен. Бу районнар авылларында торак төзүдә колхоз-совхозлар һәм нефть оешмаларының көчләрен берләштерү әлеге проблеманы хәл итүдә мөһим адым булыр иде.

Тагын да алгарак чыгып карасак, нефть районнарында шәһәр яны авыл хуҗалыгы зонасы булдыру мәсьәләсе туачак. Безнең республикада моның матур үрнәге бар. Кыска гына вакыт эчендә КамАЗның авыл зонасы — Тукай районы булдырылды. Бу район Брежнев шәһәрен авыл хуҗалыгы продукциясе белән тулысынча диярлек тәэмин итә. Дөрес, нефтьчеләр үзләре дә бу юнәлештә кайбер эшләр башкаралар. Хәзер «Татнефть» берләшмәсенең биш совхозы һәм терлек симертү пунктлары бар. Бу совхозларда зур гына төзелешләр башлап җибәргәннәр. Ярдәмче хуҗалыклар шактый күп продукция дә бирә инде. Әлмәт районындагы «Нефтяник» совхозы бер ел эчендә 14 мең центнер сөт, 2360 центнер ит, 14 мең центнер яшелчә җитештергән.

Шулай да болар — мөһим эшнең башы гына әле. КПСС Үзәк Комитетының 1982 елгы май Пленумында куелган бурычлар мөмкинлекләре булган нефтьчеләрнең авылларда социаль үзгәрешләрне тормышка ашыруда тагын да активрак катнашуларын таләп итә. Шуңа да күптән түгел партиянең Әлмәт шәһәр комитеты пленумында бу турыда җитди сөйләшү булды. Нефтьчеләр адресына җитди тәнкыйть сүзләре әйтелде, авылда яшәүче нефтьче гаиләләре өчен йортлар, социаль культура объектлары төзергә кирәклеге бөтен кискенлеге белән куелды.

Күрәсең, бу сөйләшү нефтьчеләрне дә җитди уйландыргандыр. Пленумнан соң атна-ун көн үткәч тә, Фрунзе исемендәге юлхозга «Сөләйнефть» идарәсе начальнигы В. А. Тагеев килеп төште.

— Нәрсә, тагын авылда яшәүче нефтьчеләр гаиләсен шәһәргә күчәргә кодаларга килдеңме әллә?— дип каршылады аны колхоз председателе Җ. Х. Маннапов.

— Чәпчемә әле, председатель. Теге чактагы бәхәс безне дә уйга салды. Менә бөтен уңайлыклары булган һәрберсе икешәр квартиралы ике йортны сезнең авылда салырга җыенабыз...

— Егерме бер йортны алдыгыз, икесен саласыз. Аерма килеп чыга түгелме соң?..

— Быел икене, киләсе елга — дүртне... Төзелеш өчен урын карарга килүем. Әйдә, күрсәт әле! Эшне кайсы урында башларга икән...

Җәүдәт Хәкимовичның йөзенә елмаю йөгерде:

— Була ул! Безнең әллә кайчан билгеләп куйган урыныбыз бар. Үзебез дә шунда ике йорт сала башладык инде...

Игенче белән нефтьче сөйләшә-сөйләшә авыл кырыендагы буш мәйданга атладылар.

## УНБЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК: КЕШЕЛӘР ҺӘМ ЭШЛӘР

Равил Вәлиев

# КӨЧЛЕ АГЫМ

## Яңа вазифа



втомобиль җыю заводының диспетчерлык бүлеге начальнигы Анатолий Першко белән баш конвейер буйлап барабыз. Ул, монда килгәнче, Казан заводларының берсендә эшләгән. КамАЗда шундый җаваплы бүлекне җитәкли башлаганчы, берничә ел өлкән диспетчер булган. Шуңа күрә автомобиль рамына җитмеш позициядә беркетелә торган детальләрнең һәркайсын биш бармагыдай яхшы белә.

Ул китте санап Першко, ул китте санап һәртөрле шөйбе-шөрепләрне — очына һич чыгарлык түгел! Агач тамырлары кебек бөргәләнеп беткән нечкә көпшәләр генә дә, ачуым килмәгәе, йөздән артып китә икән бит! Боларның барысын да ничек истә тотып бетермәк кирәк?! Бигрәк тә конвейерда ике бозау га кибәк аерып бирә белми торган минем ише яңа кешегә?

Минем шулай иләс-миләс хәлдә торып калуымны сизепме, Першко әйтә куйды:

— Күз курка — кул эшли, дигән борынгылар. Конвейерга кергән һәр кеше бездә әнә шулай нульдән башлап җибәрә. Берәм-берәм тота-күтәрә торгач, хәтергә тиз сеңә алар...

«Монысы фәлән позиция, тегесе фәләненче пост...» дип, баш конвейер белән таныштырып барганда, Першко кинәт:

— Сиңа кайсы футбол командасының уены күбрәк ошый? — дип сорады.

— Футболның конвейер белән нинди уртаклыгы булсын ди инде, Анатолий Тихонович?

— Шулай да...

— Әлбәттә, Киев «Динамо»сы!

— Димәк, Владимир Бессоновның уены сиңа яхшы таныш?

— Таныш булмыйча!..— дидем мин, ниһаять, Першконың тел төбенә төшенә башлап.— Киев «Динамо»сы һәм СССР җыелма командасы уеннарында ул кына диспетчерлык вазифасын башкара.

— Менә, менә...— Першко ыспай гәүдәсенә бик тә килешеп торган куе зәңгәр костюмының төймәләрен чишеп җибәрде.— Мин боларны ни өчен әйтәм?.. Безнең эштә дә шулай: әгәр диспетчерлык хезмәте яхшы куелган булса, баш конвейер тоткарлыксыз хәрәкәт итәчәк. Ләкин, моңа карап кына кемнән дә булса мактау сүзләре көтәргә ашыкма! Алар, нигездә, җыючы слесарьларга эләгә... Әгәр дә инде кайсыдыр позициядә нинди дә булса деталь җитешмичә, конвейер туктап калса — баш очында күк күкрәп, яшен ятырый башлавын көт тә тор!

Егерме икенче позиция турысына килеп җиткәч, кулларын картлар кебек арт-ка куеп барган җиреннән, Першко кинәт тынды.

— Ярый, хәзергә җитеп торсын! — диде.— Эшли башлагач, якыннанрак таны-шырбыз. Ә хәзер завод директоры янына керик. Ул эшкә яңа урнашучы инженер-диспетчерларны үзе кабул итә. Тик кара аны: сүзеңне үлчәп сөйләш! Безнең Николай Митрофанович — кемнең кемлеген бер сүздән белә — кире борып чыгара күрмәсен!

Автомобиль җыю заводы директоры Мещеряковның эш кабинеты икәү икән: берсе — идарә аппараты урнашкан административ бинада, икенчесе — баш кон-вейерның үзендә. Каядыр ашыккан чагына туры килдек ахрысы — ул сүзне озын-га сузып тормады. Калку маңгайлы башын ия төшеп, алтынсу кысалы күзлеге астыннан сөзеп бер карап алды да:

— Аяклары ярыйсы озын күренә болай...— дип, гаризага имзасын салды.

Мин уйга калдым: диспетчер дигәнгә, гадәттә, ниндидер пульт каршындагы сигнал төймәләренә басып, телефоннан сөйләшеп утыручы кеше күз алдына ки-лә. Биредә аяклар кирәк икән, гел чабалар, күрәсең!

Директор бүлмәсеннән чыккач, Першко шырпы кабы яткан учын ачып җи-бәрде:

— Әйтик, менә бу кап — фәлән деталь булсын ди. Ул фәлән секундта, фәлән кадәрле күләмдә, фәлән төштә торырга тиеш! Кыскача гына аңлатканда, синең вазифаң — шул! — диде.

Мин, хәтердә калдырырга теләп, аның артыннан кабатлап куйдым:

— Фәлән деталь фәлән вакытта...

— Фәлән вакытта түгел! — диде Першко, шунда ук мине бүлдереп.— Фәлән минутта да түгел — ә нәкъ менә фәлән секундта!.. Бер минутта конвейер өч-дүрт метр китеп өлгерә. Детальләрне кирәгеннән элек илтеп куюның да файдасы юк, алар тыгынлык кына китереп чыгарачак. Шуңа күрә запас детальләрне махсус складларда тотабыз.

Першко, бераз сүзсез торды да уфтангандай әйтеп куйды:

— Әлегә баш конвейердагы эш тиешле таләпләрдән күп якларга тайпыла. Хә-ер, барысы да җитешсә, биредә диспетчерларның кирәге дә калмас иде. ЗИЛ бу-лып ЗИЛ да «өч Иван»нан тора диләр бит...

— Өч Иван?

— Әйе... Диспетчер, машина җыючы, контролер... Ягъни мәсәлән, озын аяк, өлгер кул, үткен күз!

— Ярый, өлгер кул белән үткен күз аңлашылсын да ди, Анатолий Тихонович! Тик ни өчен соң сезгер колак түгел — ә һаман озын аяк та озын аяк?

— Чөнки бездәге диспетчерлар әлегә йөгерәләр... Транспортка утырып, әлбәт-тә... Юкса, никадәрле генә кызу чапсаң да, безнең конвейерның бер башыннан икенчесенә тиз генә барып җитәрлек түгел!

## Бертуган Хөснетдиновлар

Икесе ике сменада эшләсәләр дә, алар баш конвейерда көн саен очрашмыйча калмыйлар үзләре. Чөнки, ни әйтсәң дә, бер участок кешеләре!

Бригадир Шәүкәт Хөснетдинов, сменасын тәгәлләп, өенә кайтып китәргә тор-ганда, энесе Җәүдәтнең баш конвейерга яңа килгән чагы була. Участок началь-нигы Җәүдәт Хөснетдинов кайтырга җыена башласа, эшкә абыйсы Шәүкәт килеп җитә.

Сменалар алышынган берничә минутлык вакыт арасында алар гапьләшеп ала-лар: Чистайда калган әти-әниләрдән хатлар киләме, гаиләдә хәлләр ничек, ба-лалар авырышмыйлармы... Үз сменаларында эшнең ничек баруы, автомобиль рам-нарына куела торган детальләрнең җиту-җитмәве хакында да сүзләр чыккалый.

Мин аларның сөйләшүләрендә ике туганның бер-берсенә хезмәт эстафетасын тапшыру һәм кабул итеп алуларын да күреп-ишетеп торгандай булам. Алар

үзара: «Конвейердан төшкән һәр автомобиль безнең куллар аша да үтә. Сынатмыйк, туган!» — диялордер төсле.

Тышкы кыяфәтләре әллә ни охшашмаган аларның. Шәүкәтнең гәүдәсе, буйдан бигрәк, аркылыга күбрәк алдырган. Җәүдәтнеке — киресенчә. Аерымлык бертуган Хөснетдиновларның холык чалымнарында да бар. Ачуы чыккан чакларда, бигрәк тә бу ачу кемнеңдер ваемсызлыгы белән бәйле очракларда, Шәүкәт тозлыборычлы сүз артыннан кесәгә керүчеләрдән түгел! Җәүдәте... әүлия дә әүлия — ул да әүлия! Ник бер кешегә авыр сүз әйтә алсын! Кирәк чакта Җәүдәт үзен тыңлаттыра белә. Югыйсә, эшләрсең баш конвейерда участок начальнигы булып! Ләкин Җәүдәтнең һәр сүзеннән аның гаять ипле һәм итәгатьле, кешеләргә карата тирән ихтирамлы һәм игътибарлы егет икәне күренеп тора.

Бу аерымлыкның сәбәпләре түбәндәгеләр белән аңлатылса кирәк: абый кеше буларак, Шәүкәт тормышның ачысын-төчесен күбрәк татыган. Җитмешенче еллар башында КамАЗга килеп төшкәч тә кыенлыкларны ул энесенә караганда күбрәк авыз иткән. Җәүдәт Казан химия-технология институтын тәмамлап чыкканда, КамАЗның беренче чираты сафка тапшырылган була инде. Башта аны Казандагы бер предприятиегә инженер итеп билгелиләр. Ләкин КамАЗдагы абыйсыннан көн аралаш диярлек үзләренә чакырып язылган хатлар ала башлагач, түзми: чемоданнарын тутыра да юлга чыга. Баш конвейерда берничә ай эшләүгә — «малосемейка»! Ванна-кухнясы кешеләр белән уртак булса да, бүлмә — аерым! Үз түбәң, үз куышың дигәндәй...

Әйе, Хөснетдиновлар тышкы кыяфәтләре белән дә, холыкларының кайнар яки тынычрак булуы ягыннан да бер-берләренә әллә ни охшамаганнар. Әмма эшкә мөнәсәбәтләре, КамАЗның баш конвейерында үзләренә йөкләнгән гаять җаваплы вазифаны башкару мәсьәләсенә килгәндә, алар — суйган да каплаган! — «бертуганнар»!

Шәүкәт Хөснетдиновның баш конвейердагы бүтән бригадирлардан аерылып торган бер гадәте бар. Көн саен смена азагында диспетчерлык пунктына керә дә, телефоннан шалтыратып, ул һава торышын билгеләүчеләрдән иртәгә көннең нинди булачагы турында белешә. Без инде Шәүкәтнең бу гадәтенә күптән ияләшеп беткәнбез — шуңа күрә еш кына аңа игътибар итеп тә тормыйбыз.

Әмма баш конвейер пульты каршында, Курбацкий кебек, теленә шайтан төкергән кеше бар чакка туры килсә — тиз генә котылырмын димә!

— Нишләптер, гел һава торышын сораша башладың әле...— дип куя ул, берни аңламаганга салышып.— Әллә кунак киләсе бармы, Шәүкәт?

Аны икенчесе куәтли:

— Кунак кына дигәнмени, Борис Иванович! Үзе юлга чыгарга җыенадыр, мөгаен. Верховный Совет депутаты булгач соң! Әле Казаны, әле Мәскәве чакырта дигәндәй...

Иртәгә булачак һава хәленең үзенә ни өчен кирәклеген алдан ук белеп торуыбыз, әлбәттә, Шәүкәткә яхшы мәгълүм. Шунлыктан ул, шаяртуга шаярту белән җавап кайтара да, җылы гына саубуллашып, өенә кайтып китә.

Бер карасаң, эш ыгы-зыгысына күмелеп калмыйча, кешеләр өчен хафалануы белән Шәүкәт Хөснетдинов никадәр хаклы! Кеше кәефенең еш кына һава хәленә бәйле рәвештә үзгәреп торуы күптән исбат ителгән бит! Үзе җитәкләгән комсомол-яшьләр коллективындагы һәр егет һәм кызның ни сулаганын яхшы белгән бригадир, көн ничек булуга карап, иртәгә кемнең ниндирәк кәеф белән киләчәген алдан ук чамалый алачак. Шунлыктан кешеләр йөрәгенә юлны ул, башкалар белән чагыштырганда, тизрәк табачак.

Әлегә проекттагы куәтенә эшләп китә алмаган КамАЗның бүгенге таләпләреннән чыгып караганда, билгеле, бу бик кечкенә нәрсәдәй тоелырга да мөмкин. Ләкин төгәл ритмны яраткан баш конвейерда һәр мөмкинлек, барыннан да бигрәк, кешенең шатлык-хәсрәте Хөснетдиновның күңел түрендә исәптә тора.

Тольятти автомобиль заводында конвейер эшчесенең күңелен өйрәнә торган махсус лаборатория дә оештырылды. Аның игътибарыннан кеше тормышының бер

генә мизгеле дә читтә калмый. Бүгенге фәнни-техник революция заманы шуны таләп итә. Хәер, бу турыда соңыннанрак...

Шәүкәт Хөснетдинов бригадасы баш конвейерның диспетчерлык үзәге урнашкан егерме икенче позициясендә эшли. Шуңа күрә аның һәр адымын, һәр хәрәкәтен без уч төбендәгедәй яхшы күреп торабыз.

Кайсы бригада ниндирәк коллектив икәнен беләсең килсә, аны баш конвейер туктап торган минутларда күзәт икән! Берәүләр, буш вакыт әләгүгә, ял итеп алу ягын карыйлар. Шәүкәт бригадасында башка тәртип: әнә, рамнарны йөзтүбән әйләндереп торучы Таня Енизиркина яңа «КамАЗ»ларга ябыштырып җибәрү өчен запас биркалар әзерли башлады. Әнә, үз позициясендәге ике гайковертны берләштереп, елына дүрт йөз сумлык экономия ясаган Илгиз Жангиров һаман шул «пистолет»лары янында кайнаша. Пөхтә киенеп йөрергә яратучы Әзһәр Сәйфуллин деталь салынган әрҗәләрне тигез рәткә тезеп маташа. Фәүзия Сабирова бригада бүлмәсенең тәрәзәсен чистарта. Беренче «КамАЗ»ны җыюда катнашкан Николай Назаров, тагын нинди эш калды икән дигән сыман, конвейер буйлап акрын гына әрле-бирле йөреп тора. Шәүкәт Хөснетдинов үзе нишли? Мондый чакта аның кулында, гадәттә, автомобиль рамына беркетелә торган ниндидер авыр бер деталь була. Шуны чөя-чөя (Чистай авыл хуҗалыгы техникумында укыган елларында Шәүкәт хәтта республика чемпионы булган!) ул буыннарын бераз яздырып ала. Мондый чакта ул янәшәсендәге иптәшләрен дә тик тотмый, үзе белән бергә физик күнегүләр ясарга мәҗбүр итә.

— Әлегә баш конвейерда эшләү ул хәтле авыр түгелдер, Шәүкәт, ә? — дидем мин аңа бервакыт.— Деталь җитешмичә, ул туктап торса, ял итеп алырга җае бар.

— Киресенчә! — диде Шәүкәт, минем белән килешмичә.— Эш ритмына кереп киткән генә буласың, конвейер туктап кала, эч поша башлый. Бераздан тагын кызу ритмга көйләнергә кирәк... Болай тизрәк ардыра. Шуңа күрә без, конвейер туктап торганда да берәр шөгыль табарга, ритмнан чыкмаска тырышабыз.

Шәүкәт Хөснетдинов бригадасы кешеләренең берсен мактап, икенчесен яманларлык түгел. Әмма: «Бу коллективның иң оста җыючысы кем?» — дип сорасалар, мин, һич икеләнеп тормыйча: «Шәүкәт үзе!» — дип әйтер идем.

Шәүкәт Хөснетдиновка, безнең каршыда гына эшләгәч, телефон трубкасына үрелеп мәшәкатьләнүнең дә кирәге юк. Иркенрәк чагы булса, кирәкле детален сорап, ул диспетчерлар янына үзе килеп керә. Ашыгырга туры килгәндә, пыяла будка каршысыннан узып барышлый, дефицит болты яки гайкасы белән тәрәзә пыяласын гына шакып үтә. Башка чакта Шәүкәт, үз бригадасы белән иңгә-иң торып, әлеге моментта кайда авыр һәм җаваплырак,— шунда басып автомобиль җыя.

Менә тагын кемдер тәрәзә пыялабызны чиртеп узды. Кемдер дип... Шәүкәттән бүтән кем булсын инде! Үтеннеч аңлашылсын өчен, ул кирәкле детальнең санын да күрсәтә иде. Бу юлы исә, башыбызны күтәреп карасак, Шәүкәтебездән җилләр искән!

Ул арада янәшәдә генә, чәлпәрәмә килеп, пыяла ватылган тавыш ишетелде. Диспетчер Харисов белән бергә бүлмәдән атылып чыксак, ни күрик: егерменче позиция каршындагы газлы су аппараты янына бер пикап килеп туктаган. Аның шоферы, мыскыллы елмаеп, читтәрәк басып тора. Тирә-юнь стакан ватыклары белән тулган.

Бу аппаратның суы беткән икән, пикап шоферының моңа ачуы чыккан да стаканны идәнгә бәргән. Үзе китеп тә бармакчы! Каршысына юан гәүдәле Шәүкәт чыгып басмаган булса, күздән дә югалачак иде ул. Шофер Шәүкәтне яхшы белә булып чыкты:

— Атлы кешенең җәяүлегә кайчан юл биргәне бар? — диде ул.— Кит юлдан, бригадир!

— Гаебең булгач, бирерсең! — диде Шәүкәт, һәр сүзен теше арасыннан гына кысып чыгарып.— Син чәчкән ул стакан ватыкларын Гөләп җыңги җыеп алырга тиешме әллә?

— Җыештыручылар бар лабаса! Вакыты җиткәч, килер дә себереп алыр!

— Я хәзер үк пыяла ватыкларын җыеп аласың, я...

Шәүкәтнең ике потлы гер хәтле йодрыгын күргәч, шоферга:

«Синең бригада территориясе дә түгел ич! Кем өчен шулай тырышасың?..» — дип сөйләнә-сөйләнә, су аппараты тирәсен җыештырудан башка чара калмады. Шәүкәт исә автомобиль җыя иде инде.

Аларга машиналардагы электр үткәргечләрен монтажлау бурычы тапшырылган, димәк, мондагы җыючылар намусына яңа машинаның яктырту һәм сигнал бирү приборлары бәйле.

Менә Шәүкәт кул көче ярдәмендә эшли торган йөк күчергечкә менеп басты да, бер аягы белән этә-этә, үзенә кирәкле детальләр артыннан янәшәдәге складка китеп барды. Бу минутларда мин Шәүкәтнең тормыш юлы турында уйлап куйдым...

Чистай шәһәренең күршесендә генә, Кама автомобиль гиганты салына башлау турындагы хәбәрне Шәүкәт беренче мәртәбә хәрби хезмәттә чагында ишетә.

Туган авылы Тубылгыга кайтып төшкәндә исә авылдагы кыр эшләренең нәкъ кызып килгән вакыты була. Урып-җыю техникасында эшләргә кеше җитми. Шунлыктан, КамАЗ төзелешенә китүне беразга чигереп, Шәүкәт комбайнга утыра. Аңа ярдәмче итеп, авылның бер дигән чибәр кызын билгелиләр. Тиздән аларны Тубылгыда булачак «гаилә экипажы» дип йөртә башлыйлар. Һәм ялгышмыйлар!

Көзен, игеннәр җыелып беткәч, алар туй ясыйлар. 1971 елның азагында яшь гаилә Бөтенсоюз удар төзелешенә килеп төшә. Бу вакытта Чаллының кырмыска күчедәй гөҗләп торган чагы була. Яшәргә — торак, йөрергә — урам җитми! Шәүкәтләр иске шәһәрнең бер агач өендә буш почмак табып, фатирга керәләр. Эшкә урнашып йөргәндә, Шәүкәт сабакташ егетен очрата һәм аның янына «Спецстрой» идарәсенә керә, мастер булып эшли башлый.

Шәүкәтнең күңел түрендә йөрткән төп хыялы башка була: Баш конвейерга басып, автомобильләр җыю! Шул хыял аны, ашкындырып, туган Тубылгысыннан КамАЗга алып килә, шул хыял аңа төзелеш башланып киткәндәге беренче кыенлыкларга бирешмәскә булыша.

Шәһәр, завод, автомобиль! Аларның һәркайсында Шәүкәтнең дә хәләл өлеше бар. Бүгенге конвейерда каска киеп эшләгән слесарьларны күрү сәер тоелыр иде. Чөнки баш өсләренә бары тик күзләрне иркәли торган неон нурлар гына коелган, минутына кырыкмаса-кырык мәртәбә бөгелә-бөгелә детальләр беркетүче автомобиль җыючыларга аның сукыр бер тиенгә дә кирәге юк!

Әмма беренче көннәрдә эшне Шәүкәтләргә лимон төсле сары каскалар өләшеп чыгудан башлап җибәрәләр. Бик өләшмәс идең дә — өстә монтажлау бара әле, көлтә-көлтә чаткылар ява. Аларның эше беткәнне көтеп торып булмый, чөнки «Беренче «КамАЗ»ларны КПССның XXV съездына өлгертергә!» дигән вәгъдә бирелгән. Һәм 1976 елның 16 февралендә — съезд ачылыр алдыннан, беренче «КамАЗ»лар конвейердан төшә. Тагын берничә көннән ул автомобильләр, Кама буенда яуланган зур хезмәт җиңүенең ышандыргыч шаһитлары булып, Мәскәүдәге Кызыл Мәйданга барып басалар. Бу җиңү уңае белән уздырылган тантаналы митингта, үзләрен танытып өлгергән алдынгылар арасында, Шәүкәт Хөснетдинов та була.

Кырык кешелек бригадага җитәкчелек итә башлавының беренче көннәреннән үк Шәүкәт Хөснетдинов үзләре ирешергә тиешле: «бригада — берәү өчен, берәү — бригада өчен!» дигән төп максатны билгели. Социалистик җәмгыять тормышының төп кагыйдәләреннән саналган бу девиз баш конвейердагы эш принципларына ифрат дәрәҗәдә туры килә.

Ул бригадада җаваплылыкның артуына, кешеләр арасындагы дуслык һәм хезмәт дисциплинасының тагын да ныгуына китерә. Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллинны үз коллективларына почетлы слесарь-җыючы итеп кабул итү, аның нормасын да үтәп барган өчен түләнергә тиешле хезмәт хакын даими төстә Тынычлык фондына җибәреп тору, Брежнев шәһәрендәге утыз бишенче мәктәпнең 6 «Г» классы укучылары белән шефлык мөнәсәбәтләре урнаштыру — барысы да шул якты максаттан чыгып эшләнә.

Дус коллектив булып тупланып җиткән бригада тиздән берсеннән-берсе куа-

нычлырак хезмәт җиңүләре яулый башлый. Беренче җитди уңышка 1977 елның азагында ирешелә. Әлеге елны ул, Бөтенсоюз социалистик ярышында җиңеп чыгып, «СССР Автомобиль промышленносте министрлыгының иң яхшы бригадасы» дигән исемгә лаек була.

Бригаданың Хезмәт Даны бүлмәсе бар. Монда СССРның очучы-космонавтлары Гречко һәм Губарев кул куйган диплом һәм галәмдә булып кайткан вымпел эленеп тора. Дистәләгән Мактау грамоталары, «Бөек Октябрьның 60 еллыгы исемендәге бригада», «ВЛКСМның 60 еллыгы исемендәге коллектив», «КПССның XXVI съезды исемендәге бригада» таныклыклары, «Молодой коммунист» журналы биргән «Кызыл канәфер» призы... Ә КПССның шәһәр комитеты тапшырган истәлек байрагы, комачы белән бөтен стенаны тутырып, Хезмәт Даны бүлмәсенә аерым бер ямь өсти.

КамАЗның беренче һәм икенче чиратлары сафка тапшырылу уңаеннан, Шәүкәт Хөснетдинов үзе «Хезмәттәге батырлык өчен» медале, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде.

Шәүкәт сораган болтларны күтәреп, диспетчер Харисов та кайтып җитте.

— Ашыгыч заказың үтәлде, коллега!

— Рәхмәт инде! — Шәүкәт аның кулын кысты.

Харисов, эшне беткәнгә санап, берничә адым китәргә дә өлгермәде:

— Бу ни бу?! — дигән гаҗәпләнүле тавышны ишеткәч, янә артына борылырга мәҗбүр булды.

— Нәрсә инде тагын?

— Ялгыш деталь алып килгәнсең бит, коллега!

— Булма-ас...

— Менә... Син алып килгән бу детальдә бер генә тишек, безгә кирәкле болтта андый тишекләр икәү булырга тиеш!

— Каян табыйм ди мин сиңа икенче тишекне? Заводта, үзең беләсең, тишек атлы деталь ясамыйлар.— Харисов болтларны яңадан әрҗә төбенә ыргытты.— Ятсыннар шунда — ашарга сорамыйлар!

— Юк инде, коллега: үзең алып килгәнсең икән — үзең үк алып та китәсең, шасси участогында көтеп торалардыр үзләрен...

— Кирәк икән — мин аларга минутында йөзне табып бирәм! — диде горурлыгына көч килә башлаган Харисов.— Шәүкәт, кеше көлдермик, Рафис абзаңның әле үзе китергән детальне позициядән кире алып киткәне булмады!

Харисов дөрес әйтә иде: баш конвейерга, ялгышып, ниндидер кирәкмәгән деталь алып килү безнең диспетчерлык эшендә иң зур гөнаһлардан санала. Бу, бердән, детальләрне белеп бетермәүне күрсәтсә, икенчедән, әлеге «үги» эшләнмәләрне киредән үз урынына илтеп куюның мәшәкате бик күп. Аннары... бергә эшләүче иптәшләрең алдында хурлыгы ни тора!

Ә кире беткән Шәүкәт:

— Әйдә, әйдә... Күп сүз — юк сүз, ди. Әрҗә төбеннән болтларыңны ал да — яхшы чакта сыпырт моннан! — дип, гел үз туксанын туксанлап торуын белә.

— Синең, Шәүкәт, әллә бер шөребең бушый башлаган инде?

— Кемнеке бушагандыр — белгән юк әле монда!

Нишләсен мескен Харисовыбыз! Аңа, горурлыгын җиңеп, әлеге болтларны шасси участогына илтеп куярга һәм Шәүкәт Хөснетдинов бригадасына аларның яңаларын — ике тишеклеләрен китереп бирергә туры килде.

Смена азагы иде.

Дефицит детальләр язылган исемлеген тотып, диспетчерлык үзәгенә икенче участок начальнигы Җәүдәт Хөснетдинов килеп керде. Баш диспетчер Ганевичның телефоннан сөйләшеп бетергәнен сабыр гына көтеп торды да, ул ашыгыч кирәк булган детальләрен әйтеп яздырырга кереште: «...фәләненче бәйләм — ун данә, төгәненче кронштейн — егерме...»

Бүтәннәр, смена тәмамланып килгән мондый минутларда, тизрәк эш урынын рәткә кертә, өйгә кайтырга җыена башлый. Ә аңа әнә деталь кирәк!

Икенче участок начальнигының әлеге гадәтен яхшы белгән Ганевич Җәүдәт сораган детальләрне кәгазь битенә теркәп куйды. Аннары, бу турыда сөйләшүне беткәнгә санап, тагын телефонына ябышты. Ганевичны үзе таләп иткән детальләр хакында белешер өчен шалтырата дип өметләнгән иде булса кирәк Җәүдәт. Сүзнең башка нәрсә тирәсендә баруын аңлагач, түземсезләнеп, тагын сорады:

— Ә безгә... Безгә кайчан булачак соң, Виктор Владимирович?

Хәйләкәр Ганевич, электр үткәргечләренең кирәклеге турында әле яңа гына ишеткән кешедәй сәерсенеп:

— Синдә ничә комплект калды? — диде.

— Унау гына!

Ганевич ялт итеп сәгатенә карап алды һәм:

— Унау! Димәк, синең сменага җитеп ашкан!

— Минем сменага җитсен дә ди, ә безне алыштыручыларга ни кала?

Ганевич, ниһаять, колагыннан телефон трубкасын алды да урындыгы-ние белән Җәүдәт Хәснетдиновка таба борылды:

— Карап-карап торам да, гаҗәпләнеп, тагын бер мәртәбә карап куям: бигрәк тә сәер кеше инде син, Хәмитеч! Үз сменасының гына яхшы эшләве җитмәгән, бүтән смена өчен дә эче поша аның!..

— Яңа смена башланып киткәч кенә, конвейер туктап торсынмы?

Җәүдәт Хәснетдиновтан коры вәгъдә биреп кенә котылып булмауны Ганевич яхшы аңлый иде, әлбәттә. Тик смена тәмамланып килгәнгә, пикаплар һәм электрокаралар инде үз участокларына китеп беткән. Дежур пикапка утырып, үзе генә китәр иде — конвейер пультын ялгыз калдырырга ярамый.

— Әллә үзең генә барып кайтасыңмы, Хәмитеч?

— Пикап булса — ник бармаска? Барам, әлбәттә!

Ганевич, сынагандай, тагын сәгатенә карап алды.

— Смена тәгәлләнергә нибары биш минут! Складка барып кайту өчен, кимендә ярты сәгать кирәк, өеңә соңга калып кайтырга туры киләчәк инде, Хәмитеч!

— Таптыгыз сүз! Конвейер гына туктап тормасын!..

Ганевич, конвейер микрофонын алып, бер кычкырган иде — кайдадыр складтагы биек әрҗәләр арасында яшеренеп торган җиреннән атылып чыкты да, дежур пикап пыяла будканың ишеге турысына килеп тә туктады.

Тагын ярты сәгатьтән, абыйлы-энеле Хәснетдиновлар икәүләшеп әле яңа гына Җәүдәт китереп җиткергән электр үткәргечләрен егерме икенче позициягә бушата башлаганнар иде инде.

# Ун минутлык тәнәфес

КамАЗның баш конвейеры белән өч сменада өч кеше җитәкчелек итә. Холыкфигыльләре буенча да, эшне оештыру ягыннан да алар бер-берсенә һич тә охшаш түгелләр.

Виктор Яковлевич Смоляков — табигате белән кайнар җанлы кеше. Аны үзенең төп эш урыны булган баш конвейер пультында сирәк очратасың. Берәр позициядә аз гына тоткарлык килеп туса, һөҗүмгә ташланган атлы гаскәр командиры кебек, ул хәзер шунда чыгып йөгерә! Ләкин баш конвейер — җитмеш буынлы! Мондый «кавалеристлар ысулы» белән никадәрле генә кара тиргә батып чапсаң да, минуты-секундында дигәндәй, аның бөтен позицияләренә өлгерү мөмкин түгел.

Владимир Михайлович Шугаев исә — Смоляковның нәкъ капма-каршысы. Шактый яшь бу егетне баш конвейер пультыннан тиз генә аерып алырмын димә! Аның бер кулында гел микрофон, икенчесендә телефон трубкасы булыр. Ул, шулар аша эш йөртеп, күбрәк участок начальникларын һәм мастерларны йөгертә. Кыскасы, Шугаев — фәнни-техник революция тудырган бүгенге көн белгече!

Сәгыйть Шәйхуллович Кашапов конвейер пультында утырырга да, ашыгыч эш килеп чыкса — позицияләргә барып килергә дә өлгерә.

Смоляков, бигрәк тә Шугаев җитәкләгән сменалар бер көнне график заданиесен арттырып үтәсәләр, икенчесендә тиешле күләмдәге автомобильләрне җыеп өлгертә алмаулары да бик мөмкин. Кашапов сменасында исә, график буенча ничә машина җыю каралса, конвейердан нәкъ шул кадәрле төшә.

Кашапов, КамАЗга килгәнче, Тольяттидагы Идел автомобиль заводында эшләгән. Бу предприятиедә исә промышленность белән идарә итүнең иң нәтиҗәле ысуллары кулланылу яхшы мәгълүм. Брежнев шәһәре автомобильчеләре аларны, әлегә бик акрынлык белән булса да, файдалана баралар.

Кашапов бүген ВАЗ тәҗрибәсеннән тагын бер «эксперимент» ясап алды. Ай азагы. Баш конвейерның алны-ялны белмичә, иң зур тизлек белән хәрәкәт иткән чагы. Һәр минут исәптә.

Сәгыйть Шәйхуллович — мәшәкатьнең үзәгендә, пульт микрофонын алып, бөтен конвейерга бик сәер белдерү ясады:

— Смена начальнигы Кашапов сөйли. Баш конвейерда ун минутлык тәнәфес игълан ителә! Кабатлыйм: ун минутлык тәнәфес!

Ашыга-кабалана автомобиль җыеп яткан слесарьлар, ялгыш ишетмибезме дигәндәй, конвейер пульты урнашкан якка борылып карадылар. Ул арада смена начальнигы чакыртып китергән пикап-буфетлар позициядән-позициягә кайнар чәй һәм кофе таратып йөри башлады. Автомобиль җыючылар, смена уртасында беренче мәртәбә игълан ителгән бу кыска вакытлы ялны хуплап, кул чаба башладылар.

Бу — бөтен завод тарихында, баш конвейер эшләгән чакта яңгыраган беренче кул чабулар иде. Диспетчерларның берсе: «Карагыз әле, эшлисе булмагач — ничек сөенәләр!» — дип куйды.

Кашапов аңардан:

— Кирәкле детальләрне китереп җиткермәвегез аркасында, баш конвейер туктаса, ник кул чапмыйлар соң? Эшсез торган ачудан, автомобиль җыючыларның күзләре маңгайларына сикереп менгән була.— Кашапов тыныч кына елмая иде.— Проектта каралган куәт белән эшли башлагач, баш конвейерда һәр ике сәгать саен автомобиль җыючыларга ун минутлык тәнәфес булачак. ВАЗдагы кебек...

Тольятти шәһәреннән килеп эшли башлаган Кузнецов фамилияле инженер:

— Сез эргономиклар лабораториясе керткән яңалыкны әйтәсезме, Сәгыйть Шәйдуллович? — дип сорады.

— Әлбәттә, эргономикасыз булмый монда.

Безнең күбебез өчен болар беренче мәртәбә ишетелгән ят сүзләр иде. Кашаповка төрле яктан сораулар яудырырга керештек.

Сәгыйть Шәйхуллович ялындырып маташмады, кыскача гына итеп, илебездә беренче мәртәбә Тольятти автомобильчеләре тарафыннан сынап каралган гаять кызыклы һәм мөһим тәҗрибә турында сөйләп бирде.

Бу сөйләшүдән соң озак та үтмәде, минем үземә дә күршедәге Идел автомобиль заводында командировкада булып кайтырга туры килде. Һәм мин тольяттилылар тәҗрибәсенең нинди зур әһәмияткә ия икәнлегенә үз күзләрем белән күреп ышандым.

## Киләчәк бүген туа

Җитмешенче еллар башында нигезе салынган КамАЗны Идел автомобиль заводының тагын да куәтлерәк туганы диярга мөмкин.

КамАЗның бик күп объектлары Идел автомобиль заводы тәҗрибәсен файдаланып төзелделәр. Көн үткән саен, ике арадагы бәйләнеш ныгыганнан-ныгый барды. Брежнев гигантының күп кенә эшчеләре Тольяттида өйрәнеп кайттылар. КамАЗның беренче чираты сафка баскан гаять тынгысыз көннәрдә, ВАЗ инженерлары, Кама буенда яшәп иң җаваплы участокларга шефлык иттеләр.

Безнең баш конвейердан автомобильләр төшә башлагач та тольяттилылар ярдәм итүдән туктамадылар. КамАЗда даими эшләргә үзләренең иң яхшы кадрларын җибәрделәр.

Тольятти автомобиль заводы конвейер системасын куллланудагы кыенлыклар белән дә беренче булып очрашты. Бу проблемаларның иң җитдие — конвейерда кешеләрнең еш алмашынып торуы. Дөрес, бирелә эшләү искиткеч мактаулы! Әмма бик авыр да. Хикмәт шунда: фән-техника казанышлары кулланылган автомобиль гигантының бердәнбер бу цехында барлык операцияләр диярлек кул көче ярдәмендә башкарыла. Әшеңне күпме генә яратсаң да, көн саен кабатланып торган бер үк хезмәт тиздән туйдыра-ялыктыра башлый. Кеше бер ел түзә, ике ел... Һәм көннәрдән бер көнне, эштән китү турындагы гаризасын язып, кадрлар бүлегенә юнәлә.

Капитал илләрендә конвейерларда аеруча авырга туры килә: башка эш эзләп китәрләр иде, бөтенләй хезмәтсез каласың... Шулай да кешеләр барыбер китә. Швециянең атаклы автомобиль фирмасы «Вольво» конвейерында эшләүчеләрнең, мәсәлән, ел саен егерме проценттан артыгы алмашынып тора.

Тольятти заводында бу күрсәткеч күп мәртәбә түбәнрәк. Әмсезлек куркынычы бөтенләй булмаган шартларда да ник болай соң? Мондый четерекле мәсьәләне вазлылар ничек чишкән соң?

Конвейердагы кешеләрнең еш алмашынып торуына чик кую белән Тольятти автозаводында, беренчеләрдән булып, аның элекке техник директоры Евгений Артемович Башинжагян (Хәзер — СССР автомобиль промышленносте министрының беренче урынбасары!) шөгыльләнә башлый. Башка илләрдәге бик күп автомобиль заводларында танышып-йөреп кайткач, ул шундый фикергә килә: нигә социалистик ил генә бирә алган мөмкинлекләрне эшкә җигеп карамаска?!

Күп тә үтми, Башинжагян тәкъдиме белән, Тольятти автозаводында кешенең бүгенге заман производствосы шартларында эшләү мөмкинлекләрен өйрәнүче эргономиклар лабораториясе оештырыла. Югары белемле врач Виктор Степанович Мацук җитәкчелек иткән бу лабораториядә, нигездә, тәҗрибәле медиклар, психологлар эшли. Аның төп максаты конвейердагы хезмәт шартларын җиңеләйтүгә юнәлдерелгән.

Моңа ирешү өчен Идел автомобиль заводының баш конвейерында һәр хезмәт иртәсе, эргономиклар тәкъдиме нигезендә, алдан төзелгән ярты сәгатьлек махсус музыкаль программа тапшыру белән башлана. Йөрәккә ятышлы, талгын көйне тыңлый-тыңлый, кешеләр эш урыннарына килеп басалар. Музыка кинәт тынып кала. Радио аша дикторның ягымлы тавышы ишетелә:

— Хәерле иртә, иптәшләр! Сезне яңа смена башлану белән тәбрик итәбез, күтәренке һәм шат күңел белән эшләп, хезмәт уңышларына ирешүегезне телибез! Баш конвейер кузгалып китәргә ярты минут калды.

Тагын — музыка. Ләкин инде ул хәзер бөтенләй икенче төрле: игътибар сорый торган, өндәүле музыка! Һәркем алдан ук белеп тора: эшкә һәр секундта әзер булырга кирәк! Бу инде бирелә гадәткә әверелгән. Музыкаль заставка уйналып бетүгә, тагын диктор тавышы ишетелә. Бу юлы инде ул җитди, боерулы төстә яңгырый:

— Башладык!

Баш конвейер зур тизлек белән кузгалып китми. Хәтта, талгын музыка тәэсирендә, аның кайчан хәрәкәткә килүен күрми-сизми дә каласың! Ул салмак кына шуыша башлый. Бу шулай ук завод эргономиклары тәкъдиме буенча эшләнә. Чөнки, тикшеренүләр күрсәткәнчә, кешенең физик халәте төрле вакытта төрлечә: эшкә яңа тотынган минутларда кешегә шактый кыен икән. Тулы көчкә эшли башлау өчен, аңа кимендә утыз минут кирәк. Шунлыктан конвейерны смена башыннан ук зур тизлек белән хәрәкәт иттерү автомобиль җыючыларда киеренкелек тудыруы мөмкин.

Беравз үткәч, талгын музыканы диктор тавышы бүлә.

— Баш конвейерның тизлеге — минутына дүрт метр!

Бусы — кешеләрне юату, тынычландыру өчен!

Смена башланып, нәкъ ярты сәгатьтән соң, тагын диктор тавышы яңгырый:

— Баш конвейерга тиешле тизлек бирелде! Уңышлы эш телибез сезгә иптәшләр!

Музыка тынып кала. Көндезге ялга кадәрле инде ул бүтән яңгырамаячак.

Диктор тавышы да башка ишетелмәячәк. Беренче смена тәмамланырга егерме минут калгач, конвейерның тизлеге кабат киметелә. Чөнки өйләренә кайтып китәр алдыннан, акрынрак ритм белән эшләттереп, кешеләрне бераз «ял» иттереп алырга кирәк. Кичке смена азагында исә баш конвейер соңгы сәгатьтә гел акрынайтылган тизлек белән хәрәкәт итә. Икенче смена төнге унбердә генә төгәлләнә. Кешеләрне арыган-алҗыган хәлләрендә кайтарып җибәрергә һич кенә дә ярамый. Югыйсә, эргономиклар фикеренчә, аларның автобуста кайтып барганда, юктан гына ярсып китеп, тавыш чыгарулары, өйләрендә йокыга китә алмый ятулары мөмкин икән.

Кешенең хезмәт җитештерүчәнлеге төрле сәгатьләрдә генә түгел, атнаның төрле көннәрендә дә төрлечә булучан. Әйтик, бу яктан караганда, сишәмбе, чәршәмбе һәм пәнҗешәмбе иң «әйбәт» көннәрдән санала. Дүшәмбедә исә кеше әле ял рәхәтлекләреннән арынып бетмәгән була. Җомга җитсә, атна буе арыганлык үзен сиздерә, өстәвенә, алдагы ял көне дә күңелне «кытыклап» тора башлый.

Эргономиклар беренче карашка бик вак булып күренгән бу мәсьәләләрне дә уңай хәл итү юлларын тапканнар: дүшәмбе һәм җомгада музыканың дәртлесе, марш ритмнарындагысы тапшырыла.

Боларга тагын безнең КамАЗда беренче мәртәбә Кашапов сынап караган «эксперимент»ны ике сәгать үткән саен, кешеләрне ун минут ял иттереп алуны да өстәсәң!..

Тольятти эргономиклары өйрәнгән мәсьәләләр болар белән генә дә чикләнми. Әйтик, эшчеләрнең буйлары мәсьәләсен алыйк. Бер караганда, моның баш конвейер белән нинди бәйләнеше булсын ди инде? Эргономиклар моның бик мөһим нәрсә икәнлеген раслый. Шасси җыю участогына кыскарак буйлы, кабина кебек биегрәк нәрсәләр урнаштырыла башлагач, озын гәүдәле кешеләр таләп ителә. Бу шартлар үтәлмәсә, җыючылар кирәгеннән артык арыйлар. Эшкә яңа кабул ителүчеләр өчен, завод эргономиклары тарафыннан антропологик тәкъдимнәр системасы булдырылган. Кадрлар бүлеге хезмәткәрләре аны төгәл үтиләр.

Идел автомобиль заводының баш конвейеры белән танышып йөргән көннәрдә мин тагын шуңа игътибар иттем: иртәнге смена башланып, ярты сәгать чамасы үтүгә, позицияләрне «тәгәрмәчле буфет»лар әйләнеп чыга. Арты ябулы пикапларга утырган ак калфаклы кызлар чәй һәм бутерброд сатып йөри. Бусы да эргономиклар кушуы буенча эшләнә. Чөнки иртән эшкә ашамыйча чыгып чабу очраклары да булгалый.

Тольятти эргономиклары тагын мөһим бер яңалыкны тормышка ашырганнар: баш конвейердан төшкән яңа автомобильләрне складларга илтүне баштарак егетләр башкарган. Ян якларына «перегон» дип кенә язылган әлеге автомобильләрнең, маршруттан тайпылып, тиешле урынга еш кына тоткарланып килү, хәтта кайчакларда юл йөрү кагыйдәләрен бозу очраклары да булгалаган. Хәзер исә, беренче карашка гына җиңел тоелган, чынында, бик җаваплы бу эшне бирёдә бары тик кызлар гына башкара. Чөнки алар, тәҗрибә күрсәткәнчә, егетләргә караганда, игътибарлырак та, ышанычлы да икән.

## Утны сүндерүче ут

Эргономиклар тарафыннан башкарылган эш нәтиҗәсендә Идел автомобиль заводының баш конвейерында кешеләрнең алмашынуы шактый кимеде. Әмма барлык кыенлыклар да хәл ителмәгән әле. Шулардан иң үзәккә үткәне — башкарыла торган операцияләрнең гел бер төрле булуыдыр, мөгаен.

Бу проблеманы хезмәткә түләүнең Идел автомобиль заводында киң кулланыла торган прогрессив алымын кертү юлы белән азмы-күпме җиңеләйтеп була. Күбрәк төрле детальләрне беркетергә өйрәнгән саен, профессиональ осталык өчен түләнә торган өстәмә хак та арта бара. Шунлыктан баш конвейерда эшләүчеләр күбрәк операцияләрне үзләштерергә тырышалар. Бу хәл бригада эчендә эш урыннарын алыштыргаларга, хезмәтнең бертөрлелегеннән котылып торырга мөмкинлек бирә.

Эш урыннарын еш алмаштырырга исә конвейерның кырыс законнары моны «рөхсәт» итми: операция никадәр остарак, тизрәк башкарылса, конвейерга шул кадәр яхшырак! Моңа кешенең бер позициядә мөмкин чаклы озаграк эшләве белән генә ирешергә мөмкин.

Баш конвейерда эшләүнең тагын бер кыенлыгы бар. Баш конвейерда эшли башлаган яшь кеше баштарак әле бу турыда җитәрлек уйлап та бетермәскә мөмкин. Беренче айларда аны биредә көн саен диярлек туктап тормаган кино һәм фотоаппаратлар чыжылдавы, телевизион камералар җемелдәве, күзләрне камаштырырлык дәрәҗәдә балкып янган рампа утлары мавыктыра. Ләкин вакыт уза тора. Берничә ел үтүгә, конвейерда эшләүче әлеге яшь иптәшнең дә күзләре ачылып өлгерә. Бүтән цехларда, бүтән корпусларда кая карама — катлаулы автоматика да электроника! Акчасын да күрәп алалар. Ә баш конвейер дигәннәрендә иртән дә шул бер үк эш, кичен дә шул бер үк эш! Өстәвенә, акчасын да алай бик кесә тутырып бирергә (уртача разряд белән эшләүче слесарь-җыючының айлык хезмәт хакы ике йөз сумнан артмый!) атлыгып тормыйлар. Кеше уйлый башлый: эшләмәде түгел, эшләде, күрмәде түгел, күрде — яхшы чакта, бүтән цехка күчеп котылуың хәерле...

Баш конвейерда эшләүче һәр кешенең диярлек язмышы менә шулайрак тәмамлана. Нишләргә соң? Бергәләшеп уйлаша торгач, Идел автомобиль заводында бу проблеманы хәл итүнең дә җае табыла. Тольятти автомобильчеләре ирешкән бу могҗиза урман янгынын сүндерүне хәтерләтә. Су сиптереп кенә аны сүндереп өлгерергә мөмкин түгел! Бу хәвефле очракта тәҗрибәле янгынчылар, бераз алгарак китәләр дә, агачларны кисеп, ачык урын әзерлиләр. Аннары утка каршы ут яндырып җибәрәләр. Ике хәтәр көч маңгайга-маңгай килеп бәрелешкәч, башта чыккан зур янгынның икенче янгыннан калган буш аралыкны сикереп үтәргә хәленнән килми.

Идел автомобиль заводында беренче эш итеп, беренче карашка никадәрле генә сәер тоелмасын, берләшмәнең бүтән цехларына килгән югары квалификацияле эшчеләрне кабул итүдән туктыйлар. Мондый белгечләр заводның үзендә — баш конвейерда берничә ел эшләп «арыган» слесарь-җыючылардан әзерләнә. Алар, билгеле бер вакытка исәпләнгән кечкә курсларда укып, завод өчен гаять кирәкле һөнәргә өйрәнәләр. Аннары, баш конвейер белән хушлашып, күптән күзләрен кызыктырган цехка күчеп китәләр.

Баш конвейерның бушап калган позицияләренә яшь эшчеләр (слесарь-җыючы һөнәрен үзләштерү өчен, озак вакыт кирәк түгел!) кабул ителә. Эшкә алганда, аларны киләчәктә нәрсә көткәнен шулай ук җентекләп аңлаталар: иң әүвәл баш конвейерда тирләп-пешеп автомобильләр җыячак ул, бераз иләшә төшкәч, рәхим ит — берьеллык кечкә курслар, аннары — булачак даими эш урынында практика үтү. Баш конвейерда эшли башлавына ике-өч ел узгач, бүтән цехка күчеп китәсең, кулыңда — югары квалификация, яхшы хезмәт хакы булачак.

Кешеләрне болай атлаган саен әвеш-тәвеш китереп торуның төп эшкә — югары класслы машиналар җитештерүгә зыяны тимиме соң? Болай уйларга берничә нигез юк. Хикмәт кешеләрнең алышынуында түгел, ничек китүендә.

Хәзерге китүләр — бөтенләй икенче, алдан планлаштырып, оешкан төстә китү, кайту өчен китү. Икенче төрле әйткәндә, утка каршы ут яндыру бу.

## Сораулар, сораулар...

Идел автомобиль заводындагы баш конвейердан хәзер һәр минут саен — 3, сәгатенә — 180, тәүлегенә — 2500, елына 700 000 җиңел автомобиль килеп чыга. Биредә тыгыз ритм белән эшләү тайпылышсыз кагыйдәгә әверелгән.

Бездә, КамАЗда ничек?

Унберенче бишьеллык азагында КамАЗның баш конвейерын проектта каралган куәт белән эшләтә башлау күздә тотыла. Аннары без ел саен 150 000 йөк автомобиле бирәчәкбез.

Ләкин нигә соң күршеләрдә тупланган алдынгы тәҗрибәне бүгеннән үк файдалана башламаска? Тольятти эргономиклары кушканнарга бүгеннән үк якыная башламаска?

Ярый, баш конвейерның тизлеген смена башы һәм азакларында киметергә мөмкин дә булмасын ди. Конвейер смена уртасында да туктый-туктый кешеләрнең ачуын китереп бетерә: графикта каралган бурычны үтәми ярамый. Югыйсә, ай азагы җиткәч, баш конвейерда «бөек штурм» башланачак — кешеләргә хәтта ял көннәре белән дә исәпләшеп торырга туры килмәячәк!

Ә менә эш башында музыка яңгыратып алу? КамАЗның баш конвейерында, көндезге һәм кичке ял сәгатьләрендә, колакларны туйдырып бетергән бер үк көйләр генә бирелә. Чөнки бу хакта ныгытып уйлап караган кеше юк!.. Сүз уңаенда әйтик, Тольятти эргономиклары ял сәгатьләрендә музыка уйнатуга аяк терәп каршы торалар. Завод шау-шуыннан арыган кеше кимендә кырык минут тынлыкта калып ял итәргә тиеш икән. Музыка фәкать эш башланып китәр алдыннан гына файдалы.

Смена башланыр алдыннан кешеләргә хәерле иртә, хәерле эш сәгатьләре теләүнең ни авырлыгы бар? КамАЗның баш конвейерындагы радио әле бик сирәк телгә килә. Анда да сүз саннар һәм терминнар белән тулган була.

Баш конвейерны, галәмгә кораб очырткан кебек, кимүгә барган минутларны саный-саный, «Башладык» командасы белән җибәрү кыенмы? Безгә әле үз эшләгән урының өчен горурлык хисләре уята торган бу алымны кертүләрен көтәргә генә кала.

Һәм, ахыр килеп, иң мөһиме, иң әһәмиятлесе — Идел автомобиль заводындагы кебек, «утка каршы ут үрләтү» алымын үзләштерү. КамАЗның баш конвейерындагы кешеләр, үкенечкә каршы, вокзалдагы кебек алышынып тора.

Сораулар, сораулар... күңелне күптәннән тырнап килгән әлеге сорауларның һич иге-чиге булмастыр кебек!

Ләкин мин ышанам, минем ышанасым килә: Чаллыда гасыр гиганты төзелә башлаган беренче көннәрдән алып, күршедәге Тольятти тәҗрибәсеннән бик теләп һәм уңышлы файдаланган камазлылар, хәлиткеч этап җиткәч кенә, сынатып тормаслар. Килер шундый вакыт — илебез автомобильчеләренең чын башкаласы булып әверелгән Брежнев шәһәренә, КамАЗ тәҗрибәсен өйрәнү өчен, вазлылар һәм бүтәннәр үзләре агыла башларлар әле.

Әйе, бу шулай булачак! Бу шулай булырга тиеш! Моңа ирешү өчен, бүгенге көндәлек мәшәкатьләрдән югарырак күтәрелеп, карашны ераккарак ташлый белү генә кирәк. Киләчәкнең үз җае белән якынлашуын көтеп тормыйча! Вакытны узып!

*Брежнев-Тольятти-Брежнев*

# ИБРАҺИМ НУРУЛЛИНГА 60 ЯШЬ



*Язучы һәм галим Ибраһим Нуруллинның әдәбият фәнендәге беренче адымнары ук Тукай иҗатын өйрәнүдән башланган иде. Шагыйрьнең эстетик карашларын ачуга багышланган беренче хезмәте кандидатлык диссертациясе рәвешендә язылды, әлеге теманы яктырткан мәкаләләре 1956 һәм 1964 елларда аерым китап булып дөнья күрде. XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы татар әдәбиятында реализм үсешен өйрәнү нәтиҗәсендә И. Нуруллин филология фәннәре буенча докторлык диссертациясе яклады.*

*Тукай шәхесе һәм иҗаты И. Нуруллинны язучы буларак та илһамландырды. Аның Тукай турындагы хикәяләре һәм пьесалары киң катлам укучылар игътибарын җәлеп итте. Бер яктан, татар халкының сөекле шагыйре һәм ул яшәгән чор әдәбияты турында этрафлы фәнни хезмәтләр, икенче яктан, Тукайның җанлы образын гәүдәләндерүче әдәби әсәрләр иҗат иткән галим һәм әдип, ниһаять, «Атаклы кешеләр тормышы» (ЖЗЛ) сериясе өчен зур китап язды. Мәскәүдә (1977) һәм Казанда (1979) басылып чыккан «Габдулла Тукай» әсәре әдәбиятыбызда вакыйга буларак кабул ителде һәм бәя алды. Китапта бөек шагыйрьнең әдәби һәм гражданлык батырлыгы бай фактик материалга нигезләнеп ачыла. Шагыйрьнең садә һәм гади җанын аңларга омтылу, аның иҗатын, шәхесен һәм мохитын җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә барлыкка килгән бу хезмәт югары бүләккә — Татарстан АССРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.*

*Ибраһим Нуруллин — әдәбиятыбызның катлаулы һәм актуаль мәсьәләләрен еш кына беренчеләрдән булып күтәреп чыгучы актив һәм принципиаль тәнкыйтьче. Аның мәкаләләре фәнни-теоретик нигез ныклыгы, эстетик һәм социологик анализ үткенлеге белән әдәби хәрәкәткә сизелерлек тәэсир ясап килә. Җентекле анализны канатландырып килүче полемик рух тәнкыйтьчегә инде кабул ителгән караш һәм концепцияләрне дә кабат тикшерү, үз фикерен ышандырырлык итеп дәлилләргә омтылу мөмкинлеге бирә. Аның күп кенә тәнкыйть мәкаләләре, вакыт сынавын үтеп, бүген дә актуаль яңгырашларын югалтмыйлар.*

*И. Нуруллин — танылган әдәбият белгече дә. Аның гыйльми хезмәтләрендә әдәбиятның конкрет күренешләрен анализлау белән киң колачлы гомумиләштерүләр, әдәби-тарихи материал белән теоретик сөземтәләр бергә үрелеп бара. Әлеге хезмәтләр эстетик критерийлар төгәллеге, фикернең үткен һәм дәлилле булуы, профессиональ анализ осталыгы белән аерылып тора.*

*Татар әдәбиятында тәнкыйди реализм мәсьәләләре һәм XX йөз башы татар әдәбияты тарихы буенча зур монографияләре белән танылган галим һәм тәнкыйтьче үзенең хезмәтләрендә методология проблемаларына зур игътибар бирә, халыкчанлык һәм партиялелек, социалистик реализм принципларын раслый, әсәрләрнең идея югарылыгы һәм художество эшләнеше камиллеген яклап көрәшә.*

*Филология фәннәре докторы И. Нуруллин Казан дәүләт университеты профессоры буларак та, мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен күп санлы дәреслекләр һәм методик кулланмалар авторы буларак та зур һәм игелекле эш башкара.*

*60 яше тулган көннәрне тынгысыз хезмәттә каршылаучы галим һәм тәнкыйтьчегә яңа иҗат уңышлары, нык сәламәтлек телибез.*

Ибраһим Нуруллин

# КИЛӘЧӘККӘ КАРАП

Соңгы еллардагы әдәби тәнкыйть чыгышлары белән танышканда, «хәрәкәттәге эстетика»бызның үсеш юллары турында уйланганда, еш кына бизмән-критерийларны яңадан тикшереп карау, төшенчәләрнең чикләрен тәгаенләү ихтыяҗы туа. Нәрсә ул тәнкыйть? Аның асылы һәм үзенчәлеге нидән гыйбарәт? Чикләре кайдан узә? Кемгә адреслана?

Моның белән мин әдәби тәнкыйтьнең методологик мәсьәләләре хәл ителмәгән дип әйтергә җыенмыйм. Пушкин, Белинский, Чернышевский һәм Добролюбов заманнарында ук инде әлеге сорауларга нигезле һәм анык җавап бирелгән, төшенчәләрнең чикләре билгеләнгән. Әмма, уен кагыйдәләре буенча сызылган сызыклар тапталып беткәч, малайлар арасында бәхәс, кычкырыш, үпкәләшү башланган кебек, без дә еш кына классиклар сызган сызыкны шәйләмичә, алар кулланган критерийларны оныта төшеп сөйләшәбез һәм дөрес нәтиҗәгә килә алмыйч аптырыйбыз.

Гади генә мисал китерик. Даими сүгелеп килгән тәнкыйтьне, әйдә, күңеле булсын дип, мактарга тиеш табылса, дәлил өчен, менә бит Г. Халитның «Революция тудырган геройлар»ы, менә М. Хәсәновның «Галимҗан Ибраһимов»ы, менә И. Нуруллинның «XX йөз башы татар әдәбияты» китабы дип, монографияләр санарга керешәләр. Әнә ничек әдәби тәнкыйть белән әдәбият тарихы арасындагы чик бозылды! Тәнкыйтьне әдәбият теориясе белән тәңгәл куйю очраклары да булып тора.

Әдәби тәнкыйтьнең асылы һәм үзенчәлеге мәсьәләсенә кире кайткалау, күренә ки, эш юктан гына эшләнә торган нәрсә түгел. Тәнкыйтьнең бурычы һәм кемгә адреслануы мәсьәләсенә килгәндә дә, шул ук хәл. Бүген дә әле әдәби тәнкыйть минем өчен, мине мактау, минем иҗатымны пропагандалау өчен яши дип, чын күңелдән ышанучы авторлар байтак. Моннан берничә ел элек «Литературная газета»ның «Тәнкыйтьче ничек һәм кем өчен яза?» дигән рубрика астында махсус дискуссия уздыруы да очраклы хәл булмады.

Русның революцион-демократ тәнкыйтьчеләре алдында мондый сорау тормаган. Алар тәнкыйтьнең төп бурычын китап укучылар массасын идея-эстетик яктан тәрбияләүдә күргәннәр. Бүтәнчә була да алмый. Тәнкыйть мәкаләләрен унар мең, йөзәр мең тиражлы журнал яисә газета аша тарату үзе үк шул турыда сөйли. Тәнкыйтьнең тикшерү объекты — бүгенге көн әдәбияты, бүгенге әдәби процесс. «Кыйссаи Йосыф» турындагы фәнни мәкалә яисә Ф. Әмирханның сатирасына багышланган хезмәт, билгеле инде, әдәби тәнкыйть кысасының тышында кала.

Тәнкыйтьнең үзенчәлеге тагын шунда: ул әсәрне, язучы иҗатын яисә әдәби процессны бербөтен итеп тикшерә. «Фәлән әсәрнең сюжет-композиция үзенчәлеге» яки «фәлән әсәрдә пространство һәм вакыт проблемасы» кебек темаларга «фәнчә» язылган мәкаләләрне әдәбият теориясе дип карау дөресрәк булыр. Әдәби тәнкыйть классикларының мирасы бу яктан да гыйбрәтле. Аларда, әйтик, «Иван Никитин шигырьләре» яисә «1846 елда рус әдәбияты» тибындагы хезмәт булса да, «Фәләннең поэзиясендә тавыш семантикасы» яисә «Фәлән романда полифонизм» кебек темаларга язылган мәкаләләрне тапмассыз.

Бербөтен итеп анализлау — мәсьәләнең бер ягы. Икенче һәм тагын да әһәмиятлерәк ягы нинди максат белән, нинди бурыч куеп анализлауга кайтып кала. Революцион демократ һәм марксист тәнкыйтьчеләр, шулай ук соңгырак заманнар тәнкыйтенең танылган вәкилләре тәҗрибәсе безгә болай ди: тәнкыйтьтә иң мөһиме әсәрнең төп мәгънәсен, күтәргән проблемасын ачу, тормыштагы нинди процесс, нинди тенденцияләр йогынтысында мәйданга килүен аңлатып бирү һәм әдәби процесста нинди урын тотуын билгеләү. Икенче төрле әйткәндә, әсәрне яисә язучы иҗатын чынбарлык белән чагыштырып тикшерү, ул гына да түгел, әдәби әсәр мисалында тормышның үзендә бара торган катлаулы процессларны аңларга ярдәм итү. Кыска-

сы, әдәби тәнкыйтьнең төп бурычы — конкрет әдәби күренешләрне тормыш һәм әдәбият контекстында аңлатып бирү.

Әйе, бу башлыча, социологик анализ, һәм ул чын мәгънәсендәге әдәби тәнкыйтьтә әйдәүче роль уйный. Дөрес, Белинский иҗатында әле эстетик анализ зуррак урын тоткан. Чөнки, Чернышевский сүзләре белән әйтсәк, ул «...үз эшен әр-яңадан башларга тиеш иде; барыннан да элек, ул безгә әдәбиятның, тәнкыйтьнең, журналның, поэзия һәм башкаларның нәрсә икәнлеген аңлатып бирергә тиеш булды». Чернышевскийның үзендә, шулай ук Добролюбов һәм Писарев мәкаләләрендә инде социологик анализ беренче планга чыкты. Н. А. Добролюбов фикеренчә, мәсәлән, әдәби тәнкыйтьнең бурычы — «...алдан уйланган идея һәм бурычларны авторга такмыйча, әдәби әсәр нигезендә **тормышның үзендәге күренешләр** (ассызык минеке — И. Н.) турында фикер йөртү».

Татар әдәби тәнкыйте дә үз эшен әнә шулай башлаган иде. Аның яралуында һәм бик тиз үсеп китүендә, бөек рус тәнкыйтьчеләре белән беррәттән, «Тәрҗеман» газетасының да күпмедер роль уйнаганлыгын әйтмәсәк, гаделсезлек булыр. Татар телендә әле көндәлек матбугат юк чакта, тәнкыйть өлкәсендә ат уйнатачак каләм ияләре нәкъ менә шушы газетадан мәгънәви азык һәм гыйбрәт алдылар. «Тәрҗеман»-да күп санлы рецензияләрдән тыш, тәнкыйтькә, аның асылы, үзенчәлеге һәм төп принципларына махсус багышланган озын мәкалә бар. Автор Көнбатыш Европада өстенлек алган «эстетик» һәм Россиядә үсеп киткән «социологик» тәнкыйтькә чагыштырма бәя бирә дә түбәндәгечә нәтиҗә ясый: «Мөселманнар тормышындагы әдәби һәм көндәлек яшәеш күренешләрен бәяләүдә, Европаныкына караганда, рус тәнкыйтенең принциплары кулайрак һәм файдалырак» («Тәрҗеман», 1896, 7 (1). 1905 елдан соң аякка баскан татар демократик тәнкыйте беренче адымнарда ук «әдәби әсәр нигезендә тормышның үзендәге күренешләр турында фикер йөртү» кебек, рус тәнкыйте принципларын тормышка ашыра башлады. Г. Тукай, мәсәлән, М. Гафуриның «Хәмитнең хаяте» повестена язган рецензиясендә, әсәрнең үз эчендә казынудан бигрәк, мәдрәсә баскычларын үткән яшьләрне фаҗигале язмышка дучар иткән социаль, милли, дини һәм рухи сәбәпләрне ачып бирә. «Ачлык кушты» исемле пьесага багышланган рецензиясенең уртасына кадәр Ф. Әмирхан Россиядә кабатланып тора торган ачлыкның социаль-сыйнфый сәбәпләре турында сүз алып бара. Алга таба ул, әсәрнең идея-художество кимчелекләрен күрсәткәннән соң, татар әдәбиятының үсеш перспективасын күзаллый һәм кыска гына итеп тәнкыйди реализм методының асылын аңлата. Бу рецензия әсәрне тормыш һәм әдәбият контекстында карауның матур үрнәге булып тора. Җ. Вәлидинең күп кенә мәкалә һәм рецензияләре турында да шуларны әйтергә мөмкин.

Егерменче һәм утызынчы елларда Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти һәм Г. Гали социологик һәм эстетик анализ берлегән саклап язылган байтак хезмәтләр бирделәр. Бераз соңрак әдәбиятка килгән Г. Кашшаф, Г. Халит, Л. Җәләй һәм Х. Хәйри мәкаләләре арасыннан да шундый тәнкыйть үрнәкләрен табарга мөмкин. Соңгы еллар әдәби тәнкыйтен җигелеп тарта торган Р. Мостафин һәм Ф. Мусинда да, яшьләрдән М. Вәлиев һәм Р. Мөхәммәдиевтә дә бар алар. Р. Мөхәммәдиевнең кыска гына бер мәкаләсе, мәсәлән, истә калган. Ә. Еникинең «Тынычлану» хикәясе уңае белән язылган иде ул. Тәнкыйтьче, яшь профессор Шәйхиев образы белән бәйле рәвештә, укучының игътибарын тормыштагы зарарлы күренешләрнең берсенә юнәлткән һәм ул күренешкә исем дә биргән иде: шәйхиевщина.

Әйе, болар бар. Әмма бүгенге тәнкыйтебез җитди генә кимчелекләрдән дә азат түгел. Шулардан иң зурысы — әсәрне, язучы иҗатын янсә әдәби процессны әдәбиятның үз кабыгы эчендә генә тикшерү булса кирәк. Рецензия икән, күпчелек очракта әсәрнең сюжетын сөйлибез, кайбер персонажларына характеристика биргәндәй итәбез, композиция һәм тел-стиль кимчелекләрен өстән-өстән генә саныйбыз да, бетте-китте. Язучы иҗатына багышланган мәкаләдә еш кына язганнарының эчтәлеген сөйләү, тематик үсеше һәм осталыгының арта баруы турында шактый гомуми сүзләр әйтү белән чикләнәбез.

Кайбер укучыларның, бигрәк тә каләмдәш дусларның килешеп җитмәүләре мөмкин. Янәсе, безнең мәкаләләрдә социология кирәгеннән артык, сәнгатьчәлеккә исә

игътибар юк, эстетик анализ юк. Чынлыкта исә нәкъ киресенчә. Эстетик анализ дигәнне әсәрнең үзен генә тикшерү, язучының алым һәм чаралары, тел-стиле турында фикер йөртү дип аңласак, начармы, яхшымы, бусы бар. Чын мәгънәсендәге социологик анализ исә, күреп үткәнебезчә, сирәк кунак.

Революцион-демократ тәнкыйтьчеләргә кайтыйк. Бармы аларның мәкаләләрендә эстетик анализ? Әлбәттә, бар! Беренчедән, алар тормыштагы тенденцияләр белән аваздаш идеяне әсәрнең **үз тукымасын** анализлаудан чыгаралар. Икенчедән, шул идеягә «эшли», шул идеяне сәнгатьчә гәүдәләндерә торган компонентларны ачу белән бергә, аңа «эшләми», ул идеяне укучы аңына җиткерүгә комачаулый торганнарын күрсәтеп бирәләр. Менә мондый эстетик анализ өстә җәйрәп ятмый.

Социологик һәм эстетик анализның табигый берлеге,— менә шул җитми безнең күп кенә мәкалә һәм рецензияләргә.

Әдәби тәнкыйтьнең үзенә генә хас сыйфатлары турында сөйләшкәндә, аның форма һәм стиль үзенчәлекләрен дә читләтеп үтеп булмый. Укучыга адресланганга күрә, аның үзенеке генә булган жанрлары, алым-чаралары һәм теле бар. Бу яктан ул фән белән матур әдәбият арасында тора дисәк, шаять ялгышмабыз. Хакыйкатьне эзләү һәм дәлилләү ягыннан ул — фән, фикерне укучыга җиткерү чаралары ягыннан — әдәбиятнең бер төре. Һәрхәлдә шулай булырга тиеш. Тик бер фикерне ассызыклап әйтергә кирәк: тәнкыйть мәкаләсен мавыктыргыч итә торган төп сыйфат шулай да тел-сурәт бизәкләре түгел, бәлки фикернең тирәнлеге һәм яңалыгы.

Тәнкыйть белән әдәбиятның үзара мөнәсәбәте мәсьәләсенә килик.

Күп дистә еллар инде менә тәнкыйтьчеләрне үз вазифаларын тиешенчә үтәмәүдә, тәнкыйтьне артта калуда гаепләп киләләр. Сорау туа: кемнән яисә нәрсәдән артта кала соң ул? Билгеле инде, әдәбиятның үзеннән — проза, поэзия һәм драматургиядән артта калуы күздә тотыла. Шактый еллар элек бер язучы, үз тапкырлыгына үзе сокланып, болай дигән иде: проза, поэзия һәм драматургия атакага киткәндә, тәнкыйть обозда кала.

Ләкин мәсьәләне принцип төсендә куйсак, әдәбият күз күреме юл китеп, тәнкыйтьнең утырып калуы да, һәм, киресенчә, соңгысы алга сикереп, әдәбиятның артта сөйрәлүе дә мөмкин түгел, дигән нәтиҗәгә килербез. Чөнки алар, Сиам игезәкләре кебек, бер-берсенә тоташкан, бер-берсенә берекkән. Пушкинда ук мондый фикер бар: «Тәнкыйтьнең хәл-әхвәле үзе ук әдәбиятның җитлегү дәрәҗәсен күрсәтә». Заманында Г. Ибраһимов романнарыннан һәм хикәя-повестьларыннан Г. Нигъмәти кебек сәләтле тәнкыйтьчеләрнең үсеп чыкканын искә төшерик. Ш. Камал, Һ. Такташ, М. Җәлил, И. Гази, Г. Бәширов, М. Әмир, Ф. Хөсни кебек әдип-шагыйрьләр иҗатының әллә никадәр монография, китап һәм мәкаләләрне мәйданга китерүе шулай ук очраклы хәл түгел. Һәм, гомумән, чын мәгънәсендә проблемалы әсәр дөньяга чыктымы, тәнкыйть шунда ук җанланып китә. Ә. Еникинең «Саз чәчәге», «Йөрәк сере», «Рәшә» повестьлары, А. Расихның «Язгы авазлар» һәм «Ике буйдак» романнары, С. Батталның «Сигезенчесе кем?» һәм Р. Төхфәтуллинның «Авылдашым Нәби» повестьлары дөньяга чыккан вакытларны хәтерлик.

Әдәби тәнкыйтьнең артта калуы турында сүз бара икән, моны әдәбияттан түгел, бәлки тормышның үзеннән, тормыш куйган таләпләрдән артта калу дип аңларга кирәк.

Хәер, тәнкыйть әдәбиятның үзеннән дә беразартарак калырга мөмкин. Кызганычка каршы, гадәттә шулай була да. Чөнки, ни әйтсәң дә, әдәбиятның әлеге өч төре белән чагыштырганда, тәнкыйтькә талантлар азрак килә. Килгәннәре дә әдәбият тарихына яисә әдәбиятның үзенә китү җаен карыйлар. Моңа исә сәбәпләр җитәрлек.

Беренчедән, тәнкыйтьче хезмәте мораль һәм материаль яктан ничектер түбәнрәк бәяләнә. Уртакул прозаик яки шагыйрь, мәсәлән, яхшы тәнкыйтьчегә караганда дәрәҗәлерәк санала. Шагыйрь яисә прозаикның һәр язганы, вакытлы матбугат аша үтеп, китапка әверелсә, яңадан-яңа басмалары дөнья күрсә, тәнкыйтьче язганнарның ихтимал, уннан тугыз өлеше бер күренә дә, үз эшен эшләп, газета-журнал төпләмәләрендә торып кала.

Икенчедән, тәнкыйтьче, мактау сүзен сирәк ишеткәне хәлдә, әр-хур эчендә яшәргә мәҗбүр. Чөнки ул, чын сәнгать әсәрләренең иҗтимагый һәм эстетик кыйм-

мәтен ачу юнәлешендә төп эшен башкару белән бергә, Авгий абзарын чистарту кебек, бик үк рәхәт булмаган икенче бурычны да үтәргә тиеш. Туры әйткән — туганына ярамаган, диләр. Талантлы каләм ияләре арасында тәнкыйтьне өнәп бетермәүчеләр очраса да, тәнкыйтьчегә таш күбрәк уртакул язучылар ягыннан оча. Андыйлар әдәбиятка һәрвакыт күпләп килгәннәр. Хәтта рәтләп гонорар түләнмәгән заманнарда да... Ә бит революцион-демократик тәнкыйть «әйтергә теләгәне дөрес, җитмәсә, китабын үз хисабына бастырып чыгарган, тимик инде» дип, мондый авторларның башыннан сыйпамаган. Белинский, мәсәлән, әдәбиятның үсеше хакына уртакул авторларның уртакул әсәрләренә юлбарыс кебек ташланган. Тукай, Ф. Әмирхан һәм Г. Ибраһимов та аяп тормаганнар.

Хәзер исә тоташ грамоталылык заманы. Язучының эш шартлары да начар түгел: менә сиңа гонорар, иҗат йорты, хөрмәт һәм дан... Табигый, әдәбиятка уртакул сәләтлеләр дә, хәтта таланттан мәхрүм булганнар да агылып киләләр.

Безнең бүгенге тәнкыйть, әлеге ташлардан башын күптерүдән куркыпмы, артык кыюсыз, артык юаш. Хәер, икеләнеп калдырырлык сәбәпләр дә юк түгел. Уртакул авторлар да безнең язучылар, кесәләрендә билет, бер-берсенә бик нык берекКәннәр, тавышлары көр. Тәнкыйть, диләр, объектив булырга, иптәшләрчә булырга тиеш. Принципиаль тәнкыйтьчене күсәк куллануда гаепләүләр. Үзләре кыйнныйлар, үзләре каравыл кычкыралар. Хәтере калган авторларны яклаучылар да табылса, тәнкыйтьченең хәле бөтенләй мөшкелләнә.

Югарыда телгә алынган язучының чагыштыруын үзгәртеп, мин болай дияр идем: юк, чын тәнкыйтьчеләр үзләре теләп обозда калмыйлар, аларны еш кына **калдыралар,** атакага китүчеләрнең хур булуы ихтималын күрмәсеннәр өчен, обоз арбасына бәйләп калдыралар.

Әйтелгәннәрдән шундый нәтиҗә чыга: әдәби тәнкыйть, тормыш куйган таләпләргә дөрес җавап бирсен өчен, әдәбияттан бер карыш та артта калмыйча, аның белән бер аяктан атлап барырга тиеш.

Әмма мәсьәләнең болай куелышы белән кайберәүләрнең килешмәве мөмкин. Чынлап та, тәнкыйтьнең бурычын һәм мөмкинлеген чикләү түгелме бу? Әдәбияттагы уңышларны һәм кимчелекләрне барлап һәм теркәп кенә утырса, аннан ни файда?

Язучылардан чынлап та еш кына «тәнкыйть, әдәбиятны әйдәп алдан барырга тиеш!» дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Мондый таләпне әдәбият теориясенә адреслау дөресрәк булса да, тәнкыйть уңае белән дә ул игътибарга лаек. «Алдан барырга тиеш» дигәнне язучыларга иҗат буенча сабак бирү яисә әдәбиятның иртәгәсе турында трактат язу дип түгел, бәлки **киләчәккә карап** эш итү дигән мәгънәдә аңласак, андый бурычны тәнкыйтькә дә йөкләргә мөмкин һәм кирәк.

Әдәбиятта катлаулы һәм каршылыклы процесс бара. Сирәгрәк булса да, күтәргән мәсьәләсе һәм шул мәсьәләнең сәнгатьчә гәүдәләнеше белән **яңа, оригиналь** әсәрләр туа.

Сәнгатьчә ачыш булган һәм әдәбиятның иртәгәге көнен билгеләп торган шундый әсәрне тәнкыйтьче кенә-сәгате белән күреп алырга һәм, иҗтимагый-эстетик кыйммәтен ачып биреп, укучылар массасының һәм әдәбият җәмәгатьчелегенең игътибарын шуңа юнәлтергә тиеш.

Тәнкыйть тарихында моның үрнәкләре булмады түгел. «Яшь йөрәкләр», «Безнең көннәр», «Тирән тамырлар» романнары турында тирән эчтәлекле мәкаләләр язган Г. Нигъмәтине кабат искә төшерик. Беренчеләрдән булып Һ. Такташ поэзиясенең үзенчәлеген ачып бирган Г. Галине хәтерлик. Татар әдәбиятының «юл баганалары» булган «Язгы җилләр», «Намус», «Онытылмас еллар» кебек романнар шулай ук лаеклы бәяләрен алдылар. Х. Туфан, М. Җәлил һәм С. Хәким кебек шагыйрьләрнең поэзия тарихындагы урыннарын билгеләүгә зур өлеш керткән Р. Мостафин хезмәтләрен дә рәхмәт белән искә алмый мөмкин түгел. Әмма еш кына безнең тәнкыйть әдәбиятка яңалык алып килгән әсәрне яисә язучыны укучылар һәм җәмәгатьчелек тарафыннан кабул ителгәч кенә күреп ала. Күрми уздырган чаклары да булгалый. Мисал эзләп ерак барасы юк: менә С. Баттал. Беркемгә дә охшамаган талантлы шагыйрь, гаять үзенчәлекле прозаик. Бармы аның турында төпле тәнкыйть? «Баштан үткәннәр» исемле автобиографик повестен, мәсәлән, мин дә, оятыма каршы, бик

соңгарып укыдым. М. Кәримнең «Озын-озак балачак» повестена тиң торырлык әсәр язгач икән ләбаса безнең С. Баттал!

Яисә менә Н. Фәттахның «Әтил суы ака торур» романы. Узгынчы рецензияләрдән башка тәнкыйть күрмәде бугай ул. Мәгълүм булганча, татар совет әдәбияты тарихи жанр белән бик үк мактана алмый. XIX йөз ахыры һәм XX йөз башыннан ерак китә алганыбыз юк. Ә Н. Фәттах әсәрендә — Болгар дәүләте чоры, «Сызгыра торган уклар» романының беренче китабында — тагын да борынгырак тарих! Язучының шәхес буларак үзенчәлеге белән генә бәйләнгән феноменмы бу, әллә татар халкының милләт буларак үсеше тудырган ихтыяҗның чагылышымы? Әнә шул сорауга әдәби тәнкыйтьтән бүтән кем җавап бирсен?

Әдәбиятны алга әйдәүче әсәрләр белән беррәттән — берәүгә дә сер түгел,— карап торышка чын сәнгатьтән аерылып тормый торган башка төр әсәрләр дә дөньяга чыккалый. Укучыларны да җәлеп итәләр, авторлары да мактала. Болар алдан юл ярып баручыларның яктысын чагылдырып ялтырыйлар, икенче төрле әйткәндә, моңарчы күтәрелгән тема һәм идеяләрне, моңарчы табылган алым һәм чараларны үзгәртеп кабатлыйлар. Бу типтагы әсәрләр, күпмедер файдалы эш башкарып, иртәме, соңмы, игътибардан төшеп калачаклар, онытылачаклар. Тәнкыйтьче, әнә шул «икенчел» (вторичный) әсәрләрнең «үз үлемнәре белән киткәннәрен» көтеп тормыйча, бүген үк, хәзер үк «кемлекләрен» төшендерергә, чын сәнгать әсәрләреннән аермаларын күрсәтеп бирергә тиеш. Бу да — киләчәккә карап эш итү.

Әмма монда да безнең тәнкыйть бик үк өлгерлек күрсәтми. Рецензияләү практикасы һәм еллык күзәтүләр әлеге ике тип әсәрләрне еш кына тигезләүгә китерә. Объектив булам дип, чын сәнгать әсәреннән кимчелекләр, ә «икенчел» әсәрдән уңай яклар эзләп язганда, бүтәнчә була да алмый.

Партия Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карары татар совет тәнкыйтенә дә бәрәкәтле йогынты ясаган иде. Эшлекле төс алды ул, тирәнәйде, уңышларга карата сизгеррәк, кимчелекләргә карата кырысрак булып китте. Бәхәс һәм дискуссияләр гамәлгә керде. Әдәби тәнкыйтьнең «палитрасы» да байый төште, жанрлары төрләнә башлады.

Әмма соңгы дүрт-биш елда тәнкыйтьтә сүлпәнәю сизелә башлады. Бәхәс кимеде, мактау һәм макташулар арта төште, як-якка каранып, ул-бу булмагае дип эш итү яңадан гамәлгә керде. Сәбәп, күрәсең, атта да, тәртәдә дә. Без карарның күп кенә мөһим күрсәтмәләрен оныта төштек шикелле. Тәнкыйть әдәби хәрәкәттә үзенең паеклы урынын алсын, тормыш куйган таләпләргә җавап бирсен өчен, тәнкыйть арбасының сөйрәлебрәк баруына китергән объектив һәм субъектив сәбәпләрне бетерү турында уйланырга кирәк. Атны камчылау белән генә, белмим, эш чыгар микән. Солы белән ку, ди бит халык...

Әхсән Баянов

# ЗАМАНДАШЛАРЫМ

Замандаш.

Заман кешеләрен сурәтләү.

Бу сүз, бу теләк телләрдә еш кабатлана. Доклад һәм чыгышларда, газета һәм журнал битләрендә, әдәбият-сәнгать хакындагы күп санлы язмаларда төрләнә торгач, ул гадәти сүзгә дә әйләнеп китә. Без әсәрләрдә заман тормышының күбрәк күренүен таләп итәбез. Бу, әлбәттә, законлы теләк, хаклы таләп. Тик аның стереотипка әйләнүе генә хәерсез. Чөнки гадәткә әйләнгән чакырулар үзләренә тартым тәссез әсәрләр, схемага корылган образлар барлыкка китерәләр.

Замандаш — минем дә төп героем. Үткәннәр турында язганда да, барыбер, бүгенге көн кешесе минем баш героем булып кала. Ул еш кына үткәннәр белән сөйләшә, киңәшә, бәхәсләшә. Үткәннән калган үрнәкләр дә, гыйбрәтләр дә бүгенге көнгә һәм киләчәккә хезмәт итә бит.

Безнең заман герое. Кем соң ул? Нинди кеше? Гомумән, болай берләштереп әйтергә ярыймы? Кешеләрнең һәркайсы бит конкрет — абстракт төшенчә түгел. Алар әсәрләргә дә төрлечә килеп керә. Аларның үзләренә генә хас сыйфатлары бар. Шул ук вакытта уртак сыйфатлары да юк түгел. Мин шул уртаклыклар һәм аерымлыклар хакында еш уйланам.

Кеше — җирдәге матди һәм рухи культураны иҗат итүче. Аның дөньяга һәм бүтән шәхесләргә мөнәсәбәте, хезмәткә, фикерләүгә, әхлакый тойгыларга һәм эстетик кичерешләргә сәләте — тарихи-социаль яшәеш дәвамында барлыкка килә һәм формалаша. Замандаш хакында фикер йөрткәндә, без әнә шул параметрларны да истә тотарга тиеш булабыз.

Икенче яктан алып караганда, кешедәге сәләт, әхлак, җаваплылык һәм табигый үзенчәлекләр шәхесләр төрлелеге өчен чикләнмәгән мөмкинлекләр тудыра. Әдәбиятка, сәнгатькә дә тормыш һәм кешеләр гаҗәеп дәрәҗәдә төрле булып килеп керәләр. Бу төрлелекне теориядә һәркем таный. Ләкин, яшерен-батырын түгел, практикада моның киресе белән дә бик еш очрашабыз. Күз алдыбызда төрле хәлләр булды һәм була тора. Безнең алга:

— Пантюхов минем фамилиям! — дип, күкрәк киереп килеп чыккан типлар да бар. Алар да — безнең замандашлар. Эстрада сәнгатенең күренекле вәкиле Аркадий Райкин сурәтләп күрсәткән бу адәм төрле оешмаларда җитәкчелек иткән. Фәнни институтта эшләгән чагында ул бер галимне үз бүлмәсенә чакырып кертә дә:

— Сез бүгенге көндә нәрсә белән шөгыльләнәсез? — дип, сорауны кабыргасы белән куя.

— Без бүгенгесе көндә ярымүткәргечләр белән шөгыльләнәбез, — ди аңа тегесе.

Пантюхов җитәкчелекнең тәнкыйтьтән башланганын белә һәм нәкъ баягыча кыюлык белән:

— Шул гомер буе ярымүткәргечләр белән азапланасыз. Бу вакыт эчендә тулы үткәргечләргә күчәргә дә бик вакыт иде инде! — ди һәм каты шелтә белдерә.

Пантюхов аннан соң төрле тармакларда җитәкчелек итеп ала. Ләкин аңа табанын тиз ялтыратырга туры килә.

Ә менә әдәбиятта ул озагракка тукталды, ахрысы...

Ни өчен болай дим, чөнки безгә еш кына сәер сүзләр ишетергә туры килә:

— Социалистик реализм әсәрләре өчен шартлы алымнар куллану гөнаһлы — тормыштагы хәл нәкъ булган рәвешендә генә әсәргә кереп утырырга тиеш!

Тиеш һәм вәссәлам!

Кызганычка каршы, мондый фикерләр матбугат битләренә дә үтеп керәләр.

Әйе, кызганычка каршы, Пантюхов та безнең замандаш...

Ләкин безнең иҗат методыбыз, иҗатта торган юнәлешләребез күптөрле теорияләр, карашлар һөҗүмен кичерә һәм җиңә килә. Чыннан да, инде мәсьәлә тәмам ачык, бөтенесе бик гади кебек. Фәнни нигезләрнең ныклыгын әсәрләрне иҗат итүчеләр дә, бәя бирүчеләр дә тигез дәрәҗәдә таныйлар һәм күрәләр. Тик практикада бәхәсләр мәңгелек, күрәсең.

«Казан утлары» битләрендә башланып киткән геройлар һәм проблемалар хакындагы әңгәмә дә әнә шул мәңгелек бәхәснең дәвам итүен раслыйдыр.

Заман һәм халык көткән, үзебез теләгән характерларны без сурәтли алабызмы? Бүгенге татар прозасында ниндирәк геройлар иҗат ителә? Биредә дә җаваплар күп төрле булырга мөмкин икән. Беренче мәкаләләр әнә шуны күрсәтә. Беренче булып сүз алган А. Гыйләҗев: «Тынычлану зарарлы!» — дип аваз сала. Булганнар белән канәгатьләнеп, тыныч кына яшәүнең зыянлы булуы хакындагы фикер, әлбәттә, адәм баласына күптәннән билгеле. Бүгенге көндә кайбер уңышларыбызның булуы, әмма аларның тагын да зуррак булырга тиешлеге, әдәбиятыбызның гомумсоюз мәйданына кыюрак чыгарга һәм ныклырак урын алырга тиешлеге дә яңа бурыч түгел. Иң мөһиме — бәхәсле түгел. Ул бурыч социалистик милләтләрнең үсеш процессында һәм яшәешебезнең объектив бер законы рәвешендә барлыкка килде.

Әлеге мәкалә авторы бу законлы күренешне кемнәндер бик кайнар рәвештә яклаган һәм саклаган төслерәк итеп күрсәткән. Р. Мостафин да мәкаләнең төп юнәлешен шул кысадан чыкмыйча тирәнәйтә генә төшкән.

Әйе, хәзер союз киңлегенә чыгу факты әсәрләргә бәя биргәндә иң мөһим критерийларның берсенә әверелде. Әсәрләрнең үзәк матбугатта чыгуы, бәя алуы, танылуы — ул инде шактый югары зәвыкларга һәм таләпләргә җавап бирү дигән сүз. Әмма бу урында кайбер искәрмәләр ясау шулай ук кирәк. Үзәк матбугатта чыгу төрлечә бара, һәм анда төрле дәрәҗәдәге әсәрләрнең басылуы да ихтимал. Тәнкыйть күзенә дә аерым очракта иң әйбәте түгел, ә аннан калышрагы тап булырга мөмкин. Иң яхшы әсәрнең читтә калуы шулай ук булмаслык хәл түгел. Кайсыбер язучы әсәренең чыгу факты белән канәгатьләнә һәм алар хакында фикер оештыруны, тәнкыйтьчеләр арасында дус-иш булдырырга тырышуны түбәнлек дип саный. Ә кем өчендер, андый дуслар — горурлык, дәрәҗә!

Менә шундый бик күп сәбәпләр тоташканга күрә, кайбер яхшы әсәрләрнең тиешле яңгыраш ала алмавы, минемчә, һич тә кеше ышанмаслык нәрсә түгел. Бездә мондый мисаллар күп булды. Шуларга тагын классиканы да өстисе килә. Безнең Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, һ. Такташ кебек әдипләрне дә ил алдында бөтен зурлыклары белән күрсәтә алганыбыз юк әле. Күрсәтә башладык кына бугай. Ләкин шуңа карап, без аларның бөеклегенә шик белдерергә тиешме? Юк. Бу язучылар минемчә дөнья масштабында да югалып калмый торганнардыр.

Әдәбиятны зур дөньяга күрсәтү, чыгару ысуллары байтак. Ләкин без алардан тулысынча файдалана алмыйбыз. Бу мәгънәдә ныклы план нигезендә эшләсәк кенә, без проблеманы дөрес хәл итә алырбыз.

Критерийларның буталчыклыгы гомум әдәбият үсеше өчен шактый зарар китерә. Беренче мәкалә авторы да теге яки бу язучыга бәя биргәндә, бары тик үз теләгенә, үз мәнфәгатенә генә буйсына. Ул, Ч. Айтматов романындагы манкорт образыннан файдаланып: «Без хәтерсезләр» дигән фикерне әйтә. Ә икенче урында, бу фикерне нәкъ кирегә әйләндереп: «Гореф-гадәтләребезне, милли мөнәсәбәтләрне, йорт-көнкүреш хәлләрен, кием-салымны, йолаларны тирәнтен әдәбиятта беркетеп калучы

олы зат!»— дип язучы М. Мәһдиевне мактый. Аннары: «Халыкчан язучыбыз татар халкы вәкилләрен нәкъ булгандагы кебек итеп... тормышның бөтен тармакларында милли характерлары белән бирә белде... Халыкның үзенә хас булган күпме эчкерсезлек, никадәр сафлык бар бу повесть юлларында!»— дип бөлдерә ул.

Эчкерсезлек һәм сафлыкны бер конкрет милләт сыйфаты гына түгеллеген җәя эчендә искә төшерик тә төп искәрмәне әйтик: мәкалә авторына кирәкмәгән төштә безнең хәтеребез юк иде, аңа кирәге чыккач, ул куәтләгә үк әйләнде һәм күбәйде.

Мәкалә авторы яза: «...авторларның заманны аңлый алулары, заман кешеләрен җитәкли алырлык көчле рухлы булулары зарур! Ә уртача иҗат кешеләреннән ни көтәргә мөмкин соң?»

Әйе, биредә ике сорт язучылар теркәлә: талантлылар һәм уртачалар (көчсез рухлылар). «Тынычлану зарарлы!»— дигән мәкаләнең төп мәгънәсе дә әнә шунда булып кала. Мәкалә авторы, әдәби хәрәкәткә үз биеклегеннән күз атып, мәгърурәнә хөкемдарлык кыла: «Бүгенге көн прозасыннан,— ди ул,— мин өч кешенең — Ә. Еникинең, М. Мәһдиевнең, Нурихан Фәттахның әсәрләрен генә кайта-кайта укыйм».

Мондый ысуллар белән эш иткәндә, үз фикеремне укучы хөкеме дәрәҗәсенә күтәрергә минем дә җаем бар. Ләкин андыйны кабул итә алмыйм. Кулымда ышанычлы социологик күзәтү документлары булса гына, укучы исеменнән сөйләргә кыюлыгым җитәр иде. Нишлисең, принциплар икенче төрле. Бәлки иң ышанычлы яклаучы да шул принциптыр.

Күренекле язучы И. Гази вафатына берничә ай гына калган вакытта принципларның бозылуы һәм иҗат мәсьәләләренең кунак-кунак уйнап хәл ителүенә, бәяләрнең хәйләкәрлегенә карата бик борчылып, ачынып сөйләгән иде. Вакытсыз үлем комачауламаган булса, бу хәлне фаш итүгә ул үзеннән өлеш тә керткән булыр иде, әлбәттә. Ләкин өлгерә алмады. Хәзер күрәш тагын да кыенлашты. Объективлыкның кимүе әнә шуның белән аңлатыла да. Кайберәүләрнең, әсәре бик үк рәтле булмаса да, гадәт буенча макталулары, билгеле бер позициягә ирешкәч, обойма дигән аты чыккан исемлеккә ныклы теркәлгәч, тынычланулары принциплар гаделсезлеге белән ныгытыла. Шулай итеп, анализ дигән нәрсәнең дәрәҗәсе югала һәм, әле сүз барган мәкаләдәгечә, принципсыз бәя, риторика дөрли.

Юк, авторлар белән түгел, әсәрләр белән, беренче чиратта әсәрләр белән эш итәргә кирәк. Бәяне дә, авторга карап, әсәренә түгел, ә бары тик әсәрләргә генә бирергә кирәк. Әсәре әйбәт булган кеше үзе дә ким-хур булмас.

Тәнкыйтьнең бурычы — әдәбият тарихындагы һәм бүгенге барча байлыкларның бөтен перспективасын күз алдына тоткан хәлдә, яхшысын-яманын өйрәнү, тикшерү, үсеш яки тайпылыш тенденцияләрен тоеп, төпкел агымнарны табып, яңа, чын, матур сыйфатлар өчен көрәшү, аларга юл ачу. Чын тәнкыйтьчене мин шундый көрәшче итеп күз алдына китерәм. Ә хәзергә безнең тәнкыйть әдәби хәрәкәт кырында башкалар сызып әзерләгән буразналарны гына тырнайтә... Тырнаю аркасында туфракны балчык кумгәч, усал кыланудан да һич файда юк — үсеш, уңыш барыбер шәп түгел...

Баланың гел башына сугып: «Үс, үс!»— дип кычкырсаң да, үсми, эшкә дә өйрәнми — миңгерәүләнә генә. Тиргәүләр болай да җитәрлек, без болай да шактый миңгерәүләндек инде. Хәзер хаталарны төзәтсәк тә, язык түгелдер. Вакланууларны кимәтә төшеп, җирдә биосфераны саклаган кебек, иҗади атмосфераны саклау хакында күбрәк кайгыртсак, минемчә, моның чын уңышлар өчен йогынтысы куәтлерәк булыр иде.

Әдәбиятта җитди тикшеренү эшләрен «пик»лар белән мавыгу ыгы-зыгысына кайтарып калдыру — матур шөгыль түгел. Артык мәшәкать. Чөнки бүген иң биек тау дигәннең, акбурлы токымнардан гыйбарәт булып, башка заманда ямьсез чокырга әверелүе бар бит.

Т. Галиуллин һәм Ф. Галимуллин мәкаләләреннән язучы иҗатына табигый мәрхәмәт сизелеп тора, аларның күп кенә фикерләре белән ризалашасы да килә. Мәгәр, уйлый төшкәч, бәхәсле моментлар да табыла. Т. Галиуллин мәкаләсендәге күзәтү, әсәрләрне исәпкә алу яман эш булмаса да, фәнни сөйләшү барышында теге яки бу әсәргә яхшы яки начар билгесе кую белән генә чикләнү, минемчә, эшнең әле башы гына. Дөресен әйткәндә, бүгенге укучы бу эшне үзе дә үти ала һәм объективлык

аркасында аның бәяләре хәтта дөресрәк тә була. Тәнкыйтьче исә укучы үти алмаганрак эшне башкарса, моның файдасы да, мәртәбәсе дә зуррак булыр иде.

Язучының «үз темасы» хакындагы тезисны да ачыграк куярга мөмкин иде. Аны фетишка әверелдерү үсешкә хезмәт итә алмас. Билгеле, аерым язучы теге яки бу темага гомер буе тугры калса, моның өчен аны тәнкыйтьләмәскә кирәк. Ләкин мактау да артык, чөнки сыйфатны тема хәл итми бит. Белер-белмәс килеш теләсә нинг темага ташланган халтурачыны искә алмасак, тирәнлеккә хилафлык китермичә, дөньяны киңрәк хәлендә күргән язучыны тиргәмәү хәерле. Шулай ук терминның мәгънәләрен исәпкә алсак та зыян итмәс. Мисал өчен әйткәндә, мин үзем авыл темасы, шәһәр темасы дип, аларны аерып сөйләшергә яратмыйм. Минем караш һәм уй юнәлешен кеше күңелендәге, социаль психологиядәге күренешләр билгели.

Әлбәттә, образ һәм характер теге яки бу тирәлектә матдиләшә. Конкрет җирлектә (авылда, шәһәрдә) сурәт ителә. Әмма җирлек дигәнебез икәү (бәлки тагын да күбрәк) булып чыкса, вакыйгалар барышында ике урындагы тормыш бергә кушылса, бу минем участок түгел дип, язучы шып туктарга, урамның икенче ягында гына эшләнеп яткан җинаятькә яки шатлыклы манзарага күз йомарга тиешлеме? Әлбәттә, алай түгел.

Минем гомеремнең, мәсәлән, өчтән бер өлеше авылда, өчтән ике өлеше калада узды. Темаларның аралашуы да асылда шуннан килә дип уйлыйм. Аннары, күп кенә еллар буе газета корреспонденты булып эшләгәндә, Казан һәм нефть районнарындагы төзелешләрнең әчесен-төчесен күрергә туры килде. Газеталардан артып калган тәҗрибә шигырь һәм поэмаларга, драма әсәрләренә, аннары романнарга тоташкан һәм күчкән икән, мин моны табигый хәл дип саныйм.

Кеше үзе белгәнне, күңеле ятканны, йөрәгендә тулышканны язса гына, башкалар тоярлык һәм күз алдына китерерлек сурәтләр иҗат итә ала. Ф. Галимуллин белән бары тик шул мәгънәдә генә килешергә мөмкин.

Ә гомумән алганда, каушарга кирәкмидер. Г. Ибраһимов һәм Ш. Камал кебек классикларыбыз иҗаты, М. Әмирнең «Агыйдел», Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек», И. Газиның «Онытылмас еллар» кебек роман һәм повестьлары киләчәгебез өчен ныклы база булып тора. Ул Ә. Еникиның «Рәшә», «Әйтелмәгән васыят», Ш. Маннурның «Агымсуларга карап» кебек әсәрләре белән ныгытыла. Әдәбиятыбыз әлеге сөйләшүнең үзәгендә торырга лаек булган урта буын язучылар әсәрләре аша яңа сыйфатларга ирешә. Бу һәм башка әсәрләр хакында тыныч тавыш белән эшлекле рәвештә сөйләшергә мөмкин.

Безнең максатыбыз — татар совет әдәбиятын үстерү юлы белән гомумсовет әдәбиятын баету. Моңа ирешү өчен комачау иткән кимчелекләр, аларны бетерү ысуллары хакында арттырып җибәрүләрсез, селтәнүләр һәм буталуларсыз гына конкрет мисаллар, детальләр нигезендә киңәшергә кирәк.

Мин үзем соңгы вакытта әсәрләрдәге геройларның масштабы, характер тирәнлеге турында уйланам. Гыйбрәт яки үрнәк булып халык телендә йөрерлек образлар күрәсем һәм язасым килә. Теләк тормышка ашмаслык та түгел кебек. Бу яктан Ч. Айтматовның «Ак пароход» повесте һәм соңгы романы эре һәм тере характерлар сурәтләнеше белән офыкларыбызны чынлап та киңәйтте.

Замандашлар.

Алар идеал дәрәҗәсендә түгелләр. Әмма мин алар белән яшим: бәхет тоям, алданам, кайгырам, көләм, елыйм, көрәшәм. Үз сәләтемчә һәм үз ысулларым белән.

Замандашларым — геройларым: батырлар һәм куркаклар, ихлас күңеллеләр, икейөзлеләр һ. б., һ. б. Мин алар турында уйланам. Мин алар турында язам.

## Фәиз Зөлкарнәев

# ЧАКМА ЧАКМЫЙ УТ ЧЫКМЫЙ

Хакыйкать бәхәстә, әңгәмәдә ачыклана дип исәпләгән борынгы греклар. Ә бәхәс, билгеле, карашлар төрлелегеннән килеп чыга...

Сөйләшүне башлап җибәрүчеләр, А. Гыйләҗев белән Р. Мостафин, бүгенге татар прозасындагы хәлләрнең торышын икесе дә бертөсле бәяләде: прозабыз артта кала! Шул ук вакытта аларның проблеманы аңлаудагы аерымлыклары да күренде. Мәсьәләгә якын килү аларның икесендә ике төрлерәк. Ә башка мәкаләләрнең авторлары, минемчә, гомуми картинага әллә ни яңалык өстәмәделәр, аны конкретлаштыра гына төштеләр.

Шулай итеп, димәк, ике караш... Төрледән-төрле әдәби күренешләр, геройлар, язмышлар дөньясында адашмыйча йөри алуларына ышанып, мин дә аларга ярдәм. һәм — ни гаҗәп! — тора-бара бу ике караш минем күңелемдә үзара сөйләшә, хәтта бәхәсләшә үк башладылар...

I. Прозабызга нәрсә җитми икән, дип баш ватаргамы?! Эзләнергә, казынырга яратучы кеше кимчелекләрне әллә ничаклы табып куя ала! Шулардан котылу өчен нинди чара кирәк икәнен әйтү читенрәк, авыррак. Әйтү белән генә дә хәл җиңеләйми әле. Проблеманы, ахыр чиктә, бары иҗат кына — бүгенге язучыларның хезмәте, таланты хәл итә.

II. Әгәр ул бихисап кимчелекләр «бер агач яфраклары» булып чыкса? Ягъни алар бер зур сәбәпнең нәтиҗәләре булсалар? Мондый очракта һәр яфракны ачыклаудан, тасмерләүдән элек, кәүсәсен, тамырын табу мөһимрәктер бит. Бу инде язучыларыбызның талант дәрәҗәләрен билгеләү, шуның буенча аларны төркемнәргә бүлгәләү генә түгел. Бу — барыннан да элек һәр әдәби күренешнең иҗтимагый асылын аңларга омтылу, әдәбият белән тормыш арасындагы бәйләнешләрне барлау.

I. Минә без дә сүзебезне, башкалар кебек үк, шушы ике нәрсәне ачыклаудан башладык: бер якта — үзенең иҗат мөмкинлекләре белән язучы тора; икенче якта — әдәби күренешләр, әсәрләр...

II. Миңа калса, бу сөйләшүдә беренче як дикъкатьне күбрәк җәлеп итте бугай. А. Гыйләҗевның талантка саграк мөгамәлә дәгъвалап, шәхесләрне уртага алып сөйләшә башлавына ирделәр, димме. Ә шәхесләр турында сөйләшкәндә еш кына объективлык таләбе сангә сугылмый, «ошый-ошамый» принцибы өскә калка. Тәнкыйтьче Р. Мостафинның биредә субъективизм чаткыларын төсмерләве бер дә юкка түгел. А. Гыйләҗевның күренекле язучыларыбыз Г. Бәширов, Г. Ахунов, Ә. Баяновлар иҗатын күрмәмешкә салышуын башкача аңлап булмый.

I. Хикмәт монда субъективизмда гына димәс идем мин. Бер үк нәтиҗә ясауларына да карамастан, А. Гыйләҗев белән Р. Мостафинның мәсьәләгә якын килүләре ике төрле. Р. Мостафин үрешелгәннәр югарылыгыннан бүгенге әдәбият мәйданына күз сала. Татар прозасының киләчәге аның өчен серле «кара әрҗә» кебегрәк. Ул әсәрләргә карап кына фикер йөртә, язучыларның дөнья әдәбияты дәрәҗәсендәге повесть, романнар язарга сәләтлеме-түгелме икәне турындагы уйларга бирелеп тормый. А. Гыйләҗев исә, әйтерсең лә, безнең проза уңларга тиешле биеклекләрдән торып карый. Аның күз күреме ераграк, караш перспективасы киңрәк, таләпләре зуррак. Ул, Р. Мостафин сыман, төп игътибарын үткәндәгенең дәвамы булган бүгенгегә түгел, ә бәлки киләчәккә нигез була алырлык бүгенгегә юнәлтә. Язучыларның, димәк, прозабызның да, иҗади мөмкинлекләрен тоемларга омтыла. Бу караш-мөнәсәбәт принципи рәвешен алганда кайбер язучыларыбызның иҗаты игътибар үзәгеннән читтәрәк калуы табигый. Шулай ук М. Галиев кебек әлегә берничә генә җитди әсәр иҗат итәргә өлгергән яшь авторларга аның ни өчен күбрәк өмет баглавы да аңлашыла. Дөрес, киләчәкне күзаллаганда кеше бик үк объектив һәм

хаклы булып бетә алмыйдыр. Тормыш бит шахмат уены түгел, барысын да алдан әйтеп кую кыен. Шуңадыр, күрәсең, Р. Мостафин күрәзәлек итүдән баш тарта. Ул үзенчә бәхәссез саналган мәгълүм фактларга гына таяна. Ләкин менә шул фактлар мине сагайтты да инде. Әйтик, ул, И. Гази, Ә. Еникиләрнең повесть-хикәяләре русча яңгырый алмадылар, ди һәм гүя шуның белән әлеге язучыларга хөкем чыгара. Аларның русча яңгырый алмаулары белән мин дә килешәм. Ләкин мәкаләне укыганда, автор бөтенсоюз әдәбияты әсәрләре белән әлеге әсәрләрнең үзләрен түгел, аларның тәрҗемәләрен чагыштыра кебек тоела миңа. Аның: «Монда гаеп тәрҗемәнең сыйфатында гынамы, әллә бу әсәрләрнең ниндидер эчкәрге, тирәндә яткан үзлекләрендәме?» — дигән сүзләре аптырашта калдыра. Оригиналның асыл сыйфатларын белмәгән, аның тәэсир көчен татымаган кеше генә моны әйтә ала иҗ. Р. Мостафинның факт дигәне артефакт түгел микән, дим мин. Артефакт — димәк, ялгыш аңлаңылган күренеш.

II. Димәк, Сезгә А. Гыйләҗев позициясе якынрак икән. Бәлки, Сез аның «аккумулятор теориясен» дә яклыйсыздыр әле? Ул Э. Касыймов, Ш. Хөсәенов, Х. Хәйруллин кебек язучылар хакында чак кына, комнары коелып беткән инде, дими. Шулай ук аның бүтән кайбер язучыларны да инде үз сүзен әйткән, тукталырга тиешле язучы итеп каравы сизелә. Янәсе, табигать һәр кешегә билгеле бер күләмдә генә иҗат егәрлеге бирә. Шул көч-куәт бетүгә, имеш, кеше шәхес буларак йомшара, чүгә башлый...

I. Табигатьнең һәр кешегә талантны, рух көчен төрле күләмдә, төрле дәрәҗәдә бирүенә мин дә ышанам анысы. Ләкин ул көч нәкъ менә А. Гыйләҗев әйткән конкрет әсәрдә, конкрет вакытта исраф булып бетүенә генә ышану кыен. Фикере гомуми алганда дөрес булса да, ул артык катгыйлеге белән хаталана шикелле.

II. Аның күп кенә язучыларга чыгарган «хөкем карары»ннан фатализм исе аңкый. Нигә килмәскә тиеш әле язучыга «икенче сулыш» — күңел ренессансы? Ерактан эзлисе юк. Үз-үзен җиңеп, илле яшен тутырганнан соң күтәрелеп китә алган шагыйрь Н. Арсланов бар бездә. А. Гыйләҗев кагыйдәдән чыгарылма кебегрәк әйтеп узган Б. Рәхмәт бар. Дөрес, әгәр язучы үткәннәр учагы җылысында гына җылынып утырса — элек язылган әсәрләре белән хозурланып, алардан канәгать булып яшәсә, аңардан иҗади яңарыш көтү урынсыз. Андыйлар да юк түгелдер, билгеле. Ләкин дөнья турында, яшәеш турында өзлексез уйланып, борчылып, җанын туктаусыз эшләтеп, рухи эзләнүләрендә һаман саен тирәнгәрәк керә барган әдипләребез дә җитәрлек иҗ әле! Алыйк Г. Ахуновны, Т. Миңнуллинны, М. Мәһдиевне, М. Юнысны, ниһаять, А. Гыйләҗевның үзен...

I. Кешене аккумуляторга тиңлибез икән, аны кабаттан корып булу мөмкинлеген дә истән чыгармыйк,— тел төбегездә шушы фикер ята төсле. М. Юнысның «Биектә калу» повесте турында сөйләгәндә А. Гыйләҗев сүз уңаеннан әйтеп үтә: «Безнең тәнкыйтьчеләр әсәрне күрә алмадылар, тирәнтен анализлап укучының күңел офыкларын киңәйтмәделәр, әсәр басылды, күзгә күренде һәм онытылды. Ә ул безнең көрәш коралына әйләнергә хаклы әсәр иде бит!» Иҗат кешесенә яңа дәрт өстәрлек хәлме менә бу? Күрми калу — бер хәл. Бездә күрмәскә теләү дигән чир дә юк микән әле? Күрә торып күрергә теләмәү. Х. Сарьянның «Бер ананың биш улы» повесте белән шулай булмады микән? Әсәрнең проблематикасын шактый тарайтып, әһәмиятен кечерәйтеп күрсәткән бер рецензиядән башка (анда әсәрнең төп темасы итеп эчкечелекнең тамырларын ачу атала) мәрхүм язучының ул әсәре турында сүз дә әйтелмәде бит. Ә повесть соңгы еллар прозасында вакыйга булырлык әсәр иде. Күтәргән проблемалары белән дә, камил эшләнеше белән дә.

II. Ә нигә «иде» дип сөйләргә? Ул әле дә шундый. Әсәр хакында фикер әйтергә, аңа бәя бирергә, аны шәрехләргә беркайчан да соң түгел, минемчә. Соң түгел — әгәр ул чыннан да әйбәт әсәр булса. Газет мәкаләсен генә ул көнендә укып барырга кирәк. Ә сәнгать әсәренең тузганак гомере генә яшәмәвен онытмыйк без!

I. Юк шул, соңга калуыбыз да бик мөмкин. Тимерне кызуында сугарга кирәк, дип тикмәгә генә әйтми халык.

Сүз тәнкыйтькә кагылган икән инде, күңелемдә күптәннән бирле йөргән бер борчуны әйтми булдыра алмыйм. «Казан утлары» журналы битләрендә аның үзендә дөнья күргән әсәрләргә язылган рецензияләрнең басылганын һич хәтерләмим мин. Әдәби әсәрне һәр яклап бәяләрлек, аңа тирән үтеп керә алырдай, тәфсилләп үз фи-

кереңне әйтеп бирерлек мәкалә яки рецензия өчен көндәлек газета бите генә гаять кысан бит! Нәфис телле, тәфсилле рецензия журнал яки әдәби газета битен сорый, шуңа гына «сыя» ул. «Казан утлары»ннан башка бездә андый журнал юк. Димәк, журнал үз битләрендә басылган әсәрләр турында укучылар игътибары сүрелгәнче үк язылган рецензияләр бирүдән курыкмаска тиеш. Хәтта әсәр белән рецензияне бер үк санда урнаштырган очракта да файдадан башка берни дә булмас.

II. Бездә бит язучының иҗаты, әсәрләре хакында берәр вакыйга яки дата уңае белән генә язу гадәткә кергән. Юбилярларга багышланган мактау-мадригаллар кыспрыклавы астында чын әдәби тәнкыйтькә урын да калмый. Бездә хәзер әдәбияттагы күренешләр, аның сыйфатлары, проблемалары турында түгел, ә әдәбияттагы шәхесләр турында язу өстенлек итә. Иҗат портретлары, күзәтүләр (алар да күп чагында төрле әдипләрнең исемнәрен санап чыгудан узмыйлар) һәм рецензияләр... Гомуми картина хакында, аның эчке структур сыйфатлары хакында исә сүз сирәк әйтелә. Төп игътибар ул структураның аерым элементларына гына юнәлтелгән. Комплекслы күзаллау, анализ юк.

I. Мин моны әдәби тәнкыйтьнең генә «чире» димәс идем. Әдәбиятыбызның гомуми кимчелеге ул. Бөтенесен колачларлык, үз күңеленә сыйдырырлык, А. Гыйләҗевча әйткәндә, «күп сыйдырышлы» шәхесләр җитмәүдәндер инде анысы. Х. Туфанга тиң, аның кебек, күңел бөтенлеге, олылыгы белән аерылып, бер баш калкып торган шәхесләр җитми ахры бездә. Каршылыклы чорыбыз чагылышы булган каршылыклы күңелләргә без бай. Ләкин андый шәхесләр шул каршылыклар арасында изаланудан котылып, шуларны үзләре өчен хәл итеп, шулардан өстен булып, үсеп китә алмыйлар. Минемчә, алар шулай үз-үзләрен җиңгәннән соң гына безнең бүгенге тормышыбызны үз аңнарында гомумиләштерү, яшәеш җепләренең барысын бергә үз күңелләрендә төйнәү сәләтенә ия булачаклар.

II. Безнең прозаның күтәрелеп китә алмыйча җәфалануының сәбәбе аның үзендә генәдер дип уйлау бик үк дөрес булмас иде. Сәнгать — ул бит катлаулы күренеш, күп компонентлы күренеш. Сәнгать төрләре арасындагы бәйләнешләр, аларның булу-булмавы, ныклыгы да үз ролен уйный монда. Балтик буе республикаларының, кыргыз, казакъ, рус прозаларының көчәеп китүенә аларда нык үсеш алган кино сәнгате дә шифалы һәм куәтле йогынты ясады дип уйлыйм мин. Мәсәлән, В. Шукшин иҗаты. Аның әсәрләре үзенчәлеген әдәбият һәм кино сәнгатенә бәйләнешеннән башка аңлап булыр иде микән? Юктыр, мөгаен. Яисә менә Ч. Айтматов, Н. Думбадзе, В. Быков әсәрләре. Алар буенча күпме фильм куелды! Тикмәгә түгел бит бу! Димәк, аларның иҗаты кай ягы беләндер кино сәнгатенә якын, димәк, алар кино сәнгате йогынтысын кичергән, иҗатларына шуннан файда таба алганнар. Кино сәнгатенең әдәбиятка шифалы йогынтысы хакында ул язучылар үзләре үк әйтәләр. Шуның өстенә тагын мөстәкыйль яшәү хокукына ия киносценарий, телесценарий жанрлары да бар ич әле. Башка милләтләрдә ул жанрлар үсә, әдәбиятка кино сәнгатенә хас фикерләү рәвеше алып килә, сәнгать чараларының яңа синтезы туа. Талантны аны тормыш белән, төрле шәхесләр белән ныклы бәйләнештә булу, аралашу үстерә. Бусы — мәгълүм канун. Шулай булгач, нигә әле бу канун әдәбият дигән феноменга да карамаска тиеш, ди? Сәнгатьне генә түгел, теләсә кайсы бүтән системаны ал — аның да үсеш дәрәҗәсен структур өлешләре арасындагы бәйләнешләрнең күплеге, ныклыгы билгели.

I. Сәнгать — әлбәттә, шәхестән өстен торган объектив чынлык. Аның үз закончалыклары бар. Әмма, барыбер, биредә иҗади шәхеснең ролен киметеп карарга ярамый. Чөнки көчле шәхес, талант барысын да аңлау, тою югарылыгына күтәрелә.

Бая башлаган фикеремә кайтып, кайбер прозаиклар иҗатында чагылыш тапкан бер күренешкә тукталмакчы булам. М. Мәһдиев иҗатының иң характерлы сыйфаты итеп тәнкыйтьче Ф. Миңнуллин яшьлекне сагыну хисен атады. Мәсьәләгә шигърирәк карарга тырышкан очракта, әлбәттә, яшьлекне сагыну мотивларын да табарга мөмкиндер. Игътибар итик: урта буын прозаиклар авылның хәзерге урбанизация серемена пычранмаган чагын — 40—50 нче еллар авылын язалар. Аның саф әхлагын, матур гореф-гадәтләрен сагыналар. Мәсәлән, Х. Сарьян, М. Мәһдиев ул чордагы авылда эчкечелек булмавына басым ясыйлар, аракының авылда кайчан күренә башлавын төгәл хәтерлиләр. Х. Сарьян элеккеге авыл кешесендә кумәк тормышка, бердәмлеккә ихтыяҗ зуррак булуын искәрә, шушы күркәм сыйфатның хәзер кими баруын тоеп

сызлана. Кыскасы, мондый «сагыну» — гомумән алганда, бөтенсоюз әдәби тәнкыйте кат-кат тәкрарлаган «авыл прозасы»ның төп үзлеге. Ә проблемага шәхес мәсьәләсе аша карасак, тагы бер «сагыну» ачылып китәр. Хәзерге каршылыклы заманның каршылыклы кешеләреннән гаҗиз булган прозаның, бөтен күңелле натуралар эзләп, якын тарихка мөрәҗәгать итүе түгелме соң бу? Г. Ахуновның «Чиклавек төше», Х. Сарьянның «Бер ананың биш улы», М. Мәһдиевнең «Кеше китә — җыры кала», М. Юнысның «Биектә калу» повестьларында нәкъ менә шундый кешеләр тасвирлана бит...

II. Димәк, язучылар бүгенге көн тормышыннан андый кешеләрне я таба алмаганнар, я... аларны аңлый алмаганнар.

I. Бүгенге прозадагы тагы бер кызыклы күренешне искәрмичә, аның асылын аңларга тырышмыйча ярамый. Хәзерге әсәрләрдә үзәк урынны алып торучы карт яки карчык образлары күбәйде. Элеккерәк чорга әйләнеп карасак, гомумән, һәр чор прозасы өчен характерлы геройлар булганын күрербез. Мәсәлән, рус әдәбиятында кайчандыр үзәк герой гади эшче иде, шуннан соң «эшлекле кешеләр» туды, аннары — «читтән килгән кеше», ахырда «сәер кешеләр» пәйда булды. Тәнкыйтьче А. Бучис та шуңа охшаш хәлләрне сөйли: «Литва прозасында элегрәк халык акылының гәүдәләнеше булып патриархаль карт йөрде, аннан соң «сәер кешеләр» китте...» Игътибар белән карасак, ул «патриархаль карт»ны үзебезнең әдәбияттан да табарбыз. Әдәби әсәрләрдә артык еш очрый башлап, штампка әйләнгәч, заманында тәнкыйть утына эләккән «ил карты» образы ул. «Ил карты» ул чакта, үзәк фигура ук булмаса да, игътибарга лаек һәр әсәрнең мәҗбүри образы кебегрәк иде. Сугыштан соңгы әдәбиятта калкып чыкты бугай ул, төрле кыяфәтләргә кереп — я карт булып, я карчык булып — озак вакытлар яшәде, онытылып торгандай да тоелды. Һәм менә соңгы елларның проза әсәрләрендә кабаттан картлар, карчыклар ишәеп китте. Хәзерге «ил карты» — күпчелек очракта үзәк геройларның берсе. Ә. Баяновның «Төлке тоту кыен түгел» повестенда — Карт, Х. Сарьянның «Бер ананың биш улы» повестенда — Мәһисәрвәр ана, А. Гыйләҗевның «Әтәч менгән читәнгә» повестенда — Хәйретдин агай, М. Мәһдиевнең соңгы повестенда — Кәшфи абзый, М. Галиевнең «Ерак урман авазы» повестенда — Иләмән карт (исеме дә нинди бит!), Ә. Гаффар, С. Шәмси, Н. Гыйматдинова хикәяләрендәге әбиләр, бабайлар...

II. Боларга өстәп тагын драматург Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасын, поэзиядән Р. Мингалимның «Ике авыл арасы» поэмасын, күп кенә шагыйрьләрнең буыннар бәйләнешенә, тарихи мираска багышланган шигырьләрен әйтер идем. Ягъни бу бер прозага гына хас күренеш түгел, ул безнең бөтен әдәбиятны колачлаган. Хәтта сынлы сәнгатькә, нәкыш сәнгатенә дә үтеп кергән. Р. Нигъмәтуллинаның «Дөньялар имин булсын» дигән скульптура композициясендәге, Ф. Гыймаевның «Әбигә хат килде» картинасындагы үзәк образларда да төсмерлим мин аны.

I. Рәссам Ф. Гыймаев, прозаиклар М. Галиев, Ә. Гаффар, С. Шәмси, Н. Гыйматдинова — яшьләр. Аларның әсәрләрендә җентекләп, мәхәббәт белән сурәтләнгән карт яисә карчык образын күрү башта сәер тоелырга мөмкин. Янәсе, ниндидер бер шаукым гына түгел микән?.. Ләкин уйлыйк әле: яшьләр әлеге «ил карты»ннан рухи байлыкларны, халык әхлагын кабул итеп алучылар, лабаса. Күрәсең, алар үзләренә нинди мирас калуын төгәл белергә телиләр.

Бу күренешнең яшьләр иҗатында да урын алуы шактый мәгънәле. «Ил карты», минемчә, үткәннәр белән мавыгудан түгел, элеккеге кешеләрнең рухи матурлыгын, бөтенлеген сагынып сагышланудан да түгел, ә бүгенге көнне, бүгенге кешеләрне ныграк аңларга теләүдән кабат игътибар үзәгенә килеп керде бугай. Әйе, гаҗәпләнмәгез, бу бер яктан үткәннән нәрсә мирас калганын ачыклау булса, икенче яктан — бүгенге көн кешесен тирәнрәк аңларга тырышу нәтиҗәсе. Аңлау өчен чагыштырып карарга кирәк бит. «Ил карты» хәзерге заман кешесен аңларга тырышып уйланууларның, эзләнүләрнең башында тора, димәк.

II. Менә без Сезнең белән заман герое мәсьәләсенә дә килеп җиттек. Р. Мостафин: «...прозабызның тагы бер җитди кимчелеге — зур характерларның, замандашларыбызның күренекле матур образларының булмавы...» — дип яза. Шулай, бүгенге проза үзенең чын һәм зур героен таба алганы юк әле. Кайбер әсәрләрдә, әйтик, Ш. Бикчуринның «Каты токым» романында, аны бераз шәйләргә мөмкин кебек, тик ул Р. Мостафин әйткән «күренекле герой» түгел әле.

Урбанизация — хәзерге чорның төп билгеләреннән берсе. Җәмгыятебезнең бөтен катламнарын да колачлаган бу процесс үз геройларын һәм антигеройларын тудыра. Антигеройларны безнең язучылар инде сиземлиләр булса кирәк. Яңалыкның иң элек кимчелекле яклары күзгә чалынучан бит. Сатирик характердагы яисә тискәре типларны фаш итүгә юнәлтелгән башка төр әсәрләрнең күбәюе шуны аңлата. Ләкин, хәзерге проза заман героеның тирәсендә генә чуала әле. Бер иш әсәрләр бүгенге көн героена капма-каршы сыйфатлы кешеләрне фаш итү характерында. Әйтик, А. Гыйләҗевның «Мең чакрым юл», «Әтәч менгән читәнгә», В. Нуруллинның «Һәлакәт», Т. Миңнуллинның «Хәсән Вәгыйзович» дигән повестьлары... Боларның үзәгендә — тискәре типлар. Икенче төр әсәрләрдә, бая әйткәнебезчә, «ил карты»ның заманча интерпретациясе күренә. Авторлар гүя хәзерге тормыш күтәреп чыгарган тискәре күренешләргә, типларга узган чорның уңай образларын каршы куялар.

I. Ә кем соң ул — бүгенге заман герое?

II. Минемчә, ул — кичәге авыл кешесе. Теләмәсә дә, хәтта җаны-тәне белән карышса да, урбанизация ташкыны аны туып үскән җиреннән алып киткән. Шуннан котыла алмыйча, җанына терәк эзләп, рухи эзләнүләренең бер читеннән икенчесенә ташланучы, асты-өстә актарылгандай тоелган тормышта, газапланып, үзенә урын эзләүче, ахыр чиктә аны табучы кеше. Ул — бүгенге көн Одиссее. Мәсәлән, безнең Татарстанда Брежнев, Түбән Кама кебек шәһәрләр тирәсендәге берәр авылдан китеп, тормыш дулкыннары стихиясенә ташланган шундый берәр Одиссей әле булса үзенең Гомерын көтә торгандыр...

Без, гадәттә, заман герое дип, бүгенге тормыш уртасында калкып торучы, аны киләчәккә әйдәүче зур һәм көчле шәхесне күз алдына китерәбез. Ә гади кеше күңелендәге зурлыкны, аның каршылыклы кичерешләрендә чагылучы, башка беркайда да, берничек тә күрергә мөмкин булмаган мәгънә тирәнлеген әлегә без төсмерли алмыйбыз. Ул кеше, туган авылын ташлап, шәһәргә тикмәгә генә китми бит. Бер караганда, аны моңа тормыш мәҗбүр итә сыман, икенче карасаң, аны шәһәргә үз ихтыяҗы, омтылышлары да тарта. Аның эш-гамәлләренең диалектикасы шушында. Бу аны җәмгыятебезнең аеруча хәрәкәтчән, һәртөрле яңалыкка һәм фаҗигага аеруча сизгер бер кисәкчәсе итә.

I. Һәм мин дә өстәп куйыйм: үзенең әхлакый тотнаклыгы белән мәгълүм «ил карты» образының әдәбиятка кабаттан кайту сәбәбе менә шул типның артык динамик булуында түгел микән әле? Ягъни, шулай итеп, бүгенге прозада әһәмиятле урын билгән «ил карты» образының асылы тагы да ныграк ачыла. Рухи тормыш сферасындагы көчләр тигезлеген саклау зарурлыгы «уяткан» икән аны! Әдәбиятыбызда шундый сизелерлек үзгәрешләр китереп чыгарырга сәләтле икән инде, димәк, заманыбызның Сез күрсәткән ул героен, аның әһәмиятен берничек тә инкяр итеп булмый. Әдәбиятта ул үзенә урын даулый, һәм аның дәгъвасы җитди.

II. Бүгенге прозаның төп герое мәсьәләсенә билгеле бер дәрәҗәдә бәйле булган тагы бер проблемага тукталыйк. Төп геройда, бигрәк тә заман героен чагылдырган образда, бүгенге көн рухына туры килә торган идеал гәүдәләндерелә. Әсәрдә шул идеал яктысы төшкән проблемалар бирелә. Ул идеал, проблемаларның чишелеше кемнәрне кызыксындыра соң? Әсәрнең укучысы кем? Ягъни, биредә укучы мәсьәләсе күтәрелеп чыга. Әгәр һәммә язучының иҗатын күздән кичереп, шушы хакта уйлансак, гомуми нәтиҗә әллә ни бәхәсле булмас: прозаикларыбыз авыл укучысы өчен яза. Аларның тормышка мөнәсәбәтләрендәге, фикерләү рәвешендәге, телләрендәге «авыллык» әллә каян сизелеп тора. Моңа калса, безнең прозада патриархальлек төсмере сакланган тормыш идеалы өстенлек ала. Бу күзәтүгә тагын икенчесен дә өстәргә мөмкин: прозаикларыбызның әсәрләрен нигездә авылда укыйлар. Шәһәрдәге укучыларның да күбесе — авыл балалары...

Димәк, җәмгыятебез хәзергедәй кискен структур үзгәрешләргә дучар булган бер вакытта, әлеге фактларны күз уңында тоткан хәлдә, В. И. Ленинның: киләчәкне крестьяннар сыйныфы түгел, ә эшчеләр сыйныфы билгеләячәк, дигән мәгълүм фикерен искә төшереп уйланасы нәрсәләр күп әле.

Республикабыз шәһәрләрендә соңгы унбиш-егерме ел эчендә авылдан күчеп килгән бер миллионнан артык кеше яши. Безнең язучылар яратып һәм белеп яза торган авыл тормышын әлегә онытмаган, авыл белән бәйләнешен әлегә өзмәгән бер

миллионнан артык кеше дигән сүз бу. Миңа калса, татар әдәбиятының укучылары мәсьәләсен бүген әнә шулар хәл итә. Татар прозасы бүген бу бер миллионның рухи ихтыяҗларына җавап бирерлек хәлдәме? Ягъни безнең әдәбият халкыбызның әлеге өлешен йогынты сферасында тота алырмы, югалтмасмы ул аны? Әдәбиятның язмышы укучылары язмышына бәйле ич.

I. Язмыш дигәннән, бер вакыйгга сөйлим әле. Өч яшьлек кызым бар минем. Бер кичтә, кәгазьләремне өстәлгә җәйләп таратып эшкә утырганымны күргәч, яныма йөгереп килде: «Әти! Миңа рәсем яса. Өй яса!» — ди. Өй рәсемен ясап бирдем мин моңа. Койма артында алма агачлары, ишегалдында мәэмәе да бар. Мәэмәй бик охшады кызыма, ләкин өй рәсемен яратмады бит. Ни өчен икәнен аңлатып бирсә, бала да булмас иде ул. «Алай түгел!» — дип кенә әйтә. Карандашларын сайлый-сайлый, үзе рәсем ясарга керешә. Хәзер инде аның «өе» белән мин риза түгел. «Өймени бу? Багана ич»,— дим. Сабырлык сакларга тырышып, тагын кулыма карандаш алам. Кызым тагын канәгать түгел. Ахырда миңа үпкәләп, карандашларын, альбомын күтәреп, әнисе янына, аңардан рәсем ясатырга китеп барды. Ул көнне бу вакыйганың асылы турында уйладым. Бары, берничә көннән соң гына, троллейбус тәрәзәсеннән көзге юеш урамга, ундүртәр катлы биек шәрә йортларга караштырып, эшкә барган чагымда гына кинәт исемә төште. Һәм мин кычкырып көлеп җибәрдем, үземнән көлдем. Мин бит, беркатлы авыл диванасы, аңа авыл өе рәсемен ясаганмын! Өй төшенчәсе минем күңелдә әле һаман авылча икән бит! Дүрт яше дә тулмаган шәһәр баласы каян белсен синең авыл өеңне! Авыл бит аның өчен — күз алдына китереп булмас ераклыктагы тәмле каймак, бал, вареньелар гына ашап гомер итүче әби белән бабай авылы. Мин ясаган алмагачлы, мәэмәйле өй дә — бабай өе бит. Ә биредә өйләр әнә нинди: егермешәр, ундүртәр катлы! Шуңа күрә дә бала уҗәтләнеп, биек шәһәр өйләренең сурәтләрен кәгазьгә тезгән икән. Ә мин багана дип уйлаганмын. Кызыма мин соңрак авыл өе рәсемен ясарга өйрәттем, әлбәттә. Ләкин ул — аның өчен барыбер «бабай өе» генә...

Шәһәр белән авыл арасындагы аерма, барыннан да элек, күңелләр арасындагы аерма икән бит. Һәм яңа шәһәрләрдә яшәүче өлкән буын белән яшьләр, аталар белән балалар арасындагы аерма да шәһәр белән авыл аермасына тиң икән. Биредә буыннар бәйләнешендәге киеренкелекне тоймый мөмкин түгел. Менә шундый киеренкелек, тора-бара, өзеклеккә әйләнмәсме? Борынгылар әйткән бит: «Бер күчену ярты януга тиң»,— дигәннәр. Халыкның авылдан шәһәргә күченүе дә югалтуларсыз гына бармый. Мондый шартларда әдәбиятның, сәнгатьнең коммуникатив һәм тәрбияви әһәмияте тагын да арта, традицияләр күчемлелеген тәэмин итү бурычы зурая, авырая. Авырая, чөнки әдәбият белән укучы арасындагы бәйләнеш яңа шартларга куеп сынала.

II. Брежнев шәһәрендә, Түбән Камада, Әлмәттә, Казанда бүгенге көндә менә шушындый проблема яши, үзенең чишелешен көтә. Ә чишелеш бер генә: язучылар, иң кимендә, шәһәрләшеп килүче әлеге кешеләрнең күңелендәге, иҗтимагый аңындагы үзгәреш-күчешләрне күз уңыннан җибәрмәскә тырышырга тиешләр. Аларны алдан ук чамалап, сизенеп, барысына алдан әзер торырга тиешләр.

I. Әйе, һәр укучы әдәби әсәрдән үзе турында, дөнья турында моңарчы белмәгән яңа мәгълүмат, яңа тәэсир алырга тели. Француз язучысы Арман Лану: «Әдәбият — ул яңалыкны аңлау»,— ди... Ә безнең әле яңа кешеләрне, аларның күңел ихтыяҗларын тиешенчә аңлый алганыбыз юк...

Борынгыларның инде без онытып килә торган матур бер гадәте булган. Кунакны каршылап, исәнлек-саулык сорашканнан соң иң элек: «Ни хәбәр?» — дип кызыксынганнар. Яңа хәбәр әйтә алган кешегә зур ихтирам күрсәтелгән, аның урыны түрдә булган.

Бүгенге көн әдәбиятыбыз әсәрләреннән күпмесенең урыны шулай түрдә икән?..

Авыл кешесенең шәһәргә күченүе, крестьянның эшчегә әйләнүе темасы егерменче гасыр татар прозасы яралганнан бирле үзләштерелеп килә. Бер карасаң, бу өлкәдә әллә никадәр байлык туплаганбыз, традициябез җитәрлек: Ш. Камал, Һ. Такташ, К. Нәҗми, Г. Әпсәләмов... Икенче карасаң, үзеңне барыбер ярык тагарак алдында утыргандайрак хис итәсең: чөнки заман герое юк әдәбиятта!

II. Аеруча интенсив урбанизация процессы барган Брежневта, Әлмәттә Язучылар

союзы бүлекләре бер дә юкка оештырылмагандыр. Укучы заман турындагы иң яңа сүзне дә шул шәһәрләрдә яшәүче язучылардан көтәргә хаклы.

Р. Вәлиевнең «Иске сәгать дөрес йөри» повесте «урбинизация казанын», шул «казанда» кайнаучы кичәге авыл кешесе күңелен азга гына булса да яктыртып алуы белән әһәмиятле. Әсәр авторның чор таләбен, социаль заказны дөрес тоеп иҗат итүен күрсәтә. Повестьның рухы, хикәяләү рәвеше дә «авылча»дан шактый үзгә. Минемчә, Р. Вәлиевнең бу әсәре — без кагылган проблеманы хәл итү юлында уңышлы адым.

I. Р. Вәлиевнең повесте прозабызда шактый урын алган бер кимчелекне дә (кимчелек дими хәл юк, чөнки прозаикларыбыз бу сыйфатны бик сирәк очракта гына әсәрләренең дәрәҗәсен күтәрерлек казанышка әйләндерә алалар) ачык күрсәтте. Повестьта хәрәкәт аз, динамик киеренкелек җитенкерәми. Хәрәкәттән баш тарту, сюжет ярлылыгы, гадәттә, эчке монологны үстерүгә китерә. Әсәрдә сүз күбәя, төрле «фәлсәфәләр» куера. Р. Вәлиев тә сюжет йомшаклыгын фикер хәрәкәте белән капларга тырыша. Эчке монолог геройның бай күңелен, әһәмиятле тирән уйларын, көчле кичерешләрен чагылдырса бер хәл әле. Әгәр ул аның бары тик күңел сайлыгын, кабыргаларын санарлык ябык фәлсәфәсен ачу өчен генә хезмәт итсә? Ул чагында әсәр төбәнәя дә куя. Психологизмны үстерү белән мавыгып, соңгы елларда прозаиклар әсәрдәге хәрәкәткә игътибарны киметтеләр. Р. Вәлиев тә югалткан. Аның повестенда шәһәрнең кайбер типларын танып-белү җәһәтеннән шактый әһәмиятле характерлар табасың. Ләкин тоташтан һәр персонаж фәлсәфә сатарга тотынгач, беренче карашка уңайлы һәм бик күпне әйтергә мөмкинлек бирер сыман тоелган алым авторга «аю хезмәте» күрсәтә: әсәрнең табигыйлеге, ышандыру көче кими.

М. Мәһдиев тә, хәрәкәткә караганда, статик күренешләрне яратыбрак тасвирлый. Әсәрнең бүлекләре бер-берсе белән аз бәйләнгән була, яисә алар арасында берниндн дә бәйләнеш тоймыйсың. Шуңа күрә андагы вакыйгаларны, геройларны истә калдыру читен. Җебе өзелгән сәйләннәр кебек алар, хәтердән коелалар да бетәләр.

II. М. Мәһдиев стиле — прозабызда яңа күренеш, катлаулы күренеш.

Совет кино сәнгатенә нигез салучыларның берсе, аның теоретигы Д. Вертов, фильмнарының бербөтен фикере юк, дип үзенә бәйләнүчеләргә: «...тысяча собранных фактов, если только увидеть заключенный в них ритм и понять связь отдельных частей, как, например, звуковых пассажей, дают общую мелодию, которая — вместе с конкретным содержанием сцен — и раскрывает смысл произведений»,— дип җавап биргән. А. Гыйләҗев та: «М. Мәһдиевнең беренче карашка сюжетсыз кебек күренгән әсәрләрендә өзелмәс моң бар»,— ди. Моңның булуы әсәрне бербөтен итә. Аерым детальләр, төсләр истә калмаска да мөмкин, әмма гомуми картина күз алдында кала, онытылмый.

М. Мәһдиев стилен мин мозаикага тиңләр идем. Аның «Каз канаты», «Торналар төшкән җирдә» исемле әсәрләрендә сугыштан соңгы авылның гомуми картинасы нәкъ менә мозаика алымы белән ясала.

Бу алымның традициясе безнең әдәбиятта күптәннән килә. Ләкин ул моңа кадәр поэзиядә генә хакимлек итә иде. Көнчыгыш поэзиясендә, мәсәлән, көнбатыш халыкларының фикерне һәм хисне үсештә, хәрәкәттә сурәтләүче поэзиясеннән аермалы буларак, фикерне һәм хисне бер шигырь эчендә бүлеп-бүлеп, өлешләп бирү хас булган. Шушы традиция безнең хәзерге поэзиядә яңа бер дәрәҗәдә, баскычта яңарды. Ул әйтерсең, бер шигырь кысасы эченнән чыгып, бөтен поэзияне иңләде. Хикмәтле сүз әйтү формасындагы дүртьюллыклар, парчалар, борынгы фәрд жанрын хәтерләтүче икеюллыклар, кечкенә генә халәт сурәтен бирә алган шигъри этюдлар. Төрле медитацияләр... Алар кай яклары беләндер үзара охшашлар. Вакыты белән башы-ахыры булмаган озын бер әсәрне укыйсың сыман да тоела. Әйтерсең шигырьләр түгел, күз алдында төрле төстәге вак кына пыяла кыйпылчыклары җемелдәшә, төсләре кушыла һәм шунда шагыйрь күңеленең образын төсмерлисең...

Күрәсең, шушы алым хәзер прозага да үтеп керә.

I. Әдәби күренешнең асылын аңлатмый бу. Хикмәт әдәби әсәрләрдә динамика кимүгә бәйле.

Барысы да 60 нчы елларда башланды шикелле. И. Юзеевның «Язылмаган поэма», Р. Фәйзуллинның «Кәрәшчеләр» поэмаларыннан башлап лиро-эпик жанрларда сю-

жетсызлык сыйфаты үсеп китте. Поэзиядән акрынлап хәрәкәт-динамиканың китүен канунлаштыру, шул хәлне абсолютлаштыру тора-бара фрагментарлык үсүгә, борынгы традицияләр яңарып, мозаика алымының куәтләнүенә шартлар тудырды. Хәзер, тирәнгәрәк карасак, бүгенге поэзиядә фрагментарлык көчәюенең сәбәбе — әдәбиятта рухи хәрәкәтнең сүлпәнәюеннән, фикер полюслары арасындагы киеренкелек йомшарудан икәнен чамаларга була.

Соңгы елларда ни өчен безнең бер генә проза әсәре дә бөтенсоюз мәйданында яңгыраш таба алмады? Шул ук вакытта Т. Миңнуллин, Д. Вәлиев, И. Юзеев кебек драматургларның драмалары илебез сәхнәләрендә бара? Бу сорауга җавап гади. Драматургия динамикасыз бөтенләй яши алмый, бушсүзлелекне күтәрми. Шуңа күрә дә аңа әдәбиятыбызга ябырылган әлеге шаукым кагылмады, шуңа да ул үз позицияләрен бирмәде, һаман алга баруында булды.

Р. Мостафин стиль, образлылык ягыннан әллә ни балкый алмаган Г. Әпсәләмов әсәрләренең укучылар арасында бик популяр булуына аптырый. Г. Әпсәләмов нәкъ менә сюжетны оста кора белүе белән аерылып тора. Аның һәр әсәре нинди дә булса берәр киеренке, катлаулы конфликт тирәсенә укмашкан, вакыйгалары тыгыз, образлары — көчле характерлар. Ягъни ул әсәр өчен сюжетның нәрсә икәнен нык белгән, аның әсәрне оештыру, бербөтен итү көчен ачык аңлап иҗат иткән. Үз эшенең остасы булган ул. Укучылар исә аңа рәхмәт белән җавап кайтара. Ә без шуңа гаҗәпләнәбез. Чөнки хәрәкәт-динамикага тиешле игътибар җитмәү — бүгенге әдәбиятыбыздагы гомуми шаукым, без аңа күнегеп киләбез. Сирәк талантлар гына аңа бирешми.

Катлаулы чорда, каршылыклы чорда яшибез, дип әйтергә яратабыз. Ә менә чорыбызның төп конфликтын чагылдырган тирән коллизияләрне үз эченә алган, чорыбызның көчле характерларын «чәкәштергән» колачлы эпик әсәрләр турында әлегә хыялланабыз гына...

II. Дөрес искәрдегез, чорыбызга лаек катлаулы вакыйгаларны чагылдырган, аның эчке динамикасын киң колач белән күрсәтә алган әсәрләр бездә әлегә юк.

Тормышны кабул итүдәге колачлылык, тирәнлек — әлбәттә, талант, күңел үткерлеге эше. Ләкин ул гына да түгел... Т. Миңнуллинның «Хәсән Вагыйзович» повестен укыгач, уйга калдым. Бүгенге проза үзенчәлекле динамик характерларны, үзенә күрә ачыш саналырлык образларны бөтенләй таба алмый дип булмый икән! Т. Миңнуллин повестендагы төп герой үзе генә дә ни тора! Әсәрнең ахыры, дөрес, образ логикасына бик үк ярашып бетми, бераз ясалмарак, ашыгычрак, ләкин шуңа да карамастан, ул тәэсир итә. Моның төп сәбәбе — А. Гыйләҗевча әйтсәк, «когоритлы кара герой»! Әмма шушы героен, бу ачышын язучы нәрсә әйтү өчен файдаланган соң? Менә шундый типлар да яши, дип укучыны искәртү өчен генәме? Геройның көче, масштабы белән чагыштырганда артык кечкенә вазифа түгелме соң бу? Менә шуны уйлыйсың да, прозаның, әдәбиятның без әле генә сүз алып барган олы сыйфатлары, аларның мөһимлеге ничектер тоныкланып кала төсле. Сүз дә юк, ачык сыйфатларга ия образ булу, әлбәттә, әсәрне бизи, аның сәнгатьчәлеген арттыра. Ләкин сюжет та, характер да язучы кулындагы чара гына бит, аларны бирү әдәбиятның үзмаксаты түгел. Аларның вазифасы — гомумиләштерү, укучыны яшәеш, тормыш турында нинди дә булса зур, мөһим нәтиҗәгә китерү. Ә язучының зур гомумиләштерүләр биеклегенә күтәрелә алуы аның талантыннан башка тагын философик әзерлек дәрәҗәсе белән дә билгеләнә.

Мин еш кына менә нәрсә күзәтәм. «Литературная газета»ның соңгы битләренең берсендә сан саен диярлек нинди дә булса берәр чит ил язучысы белән әңгәмә урнаштырыла. Билгеле, анда күренекле язучыларга гына сүз бирелә. Алар, үз әсәрләре турында сүз башласалар, барыннан да элек аның идеясе, философик нигезе турында сөйлиләр. Иҗатның төп мәсьәләсе итеп шул карала. Калганнары исә — күрәсең, осталык, техника эше. Ч. Айтматов та үз әсәрен аңлатып кына чыгудан ерак тора, ул күбрәк үзенең идея-эстетик эзләнүләре, үзен борчыган әхлакый, фәлсәфи мәсьәләләр турында сөйли.

Ә безнең язучылар сүз алса?.. Алар мәгълүм мәзәктәге күзе күрмәгән кеше кебегрәк: филнең аякларын, койрыгын, борынын таныйлар, ә үзен тулы итеп күрмиләр. Әсәрнең теле, стиле турында алар рәхәтләнеп сөйләшәләр, аерым бер сүзне куллану үзенчәлекләре, аның мәгънә төсмерләре турында тәфсилләп мәкалә язалар.

Образлар, характерлар турында да кызыклы гына фикерләр ишетергә мөмкин. Әсәрнең тематикасы, идеясе турында да сүз әйтеп куйгалыйлар. Ләкин шуннан артыгын көтмә инде.

I. Ч. Айтматов кебекләр — әлбәттә, зур язучылар. Вак мәсьәләләр турында сөйләшү, бәлки, аларга килешмидер дә. Ләкин безгә дә бит гел генә вакланып яшәргә димәгәндер. Р. Мостафин әйткәнчә, «гасырыбызның әхлакый һәм фәлсәфи эзләнүләре югарылыгында хәрәкәт итәргә» өйрәнергә вакыттыр! Үз заманында Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар»ы, Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы, Г. Бәшировның «Намус»ы чор таләпләре югарылыгында язылган әсәрләр булган. Хәтта еракка карыйсы да түгел. 60 нчы елларда безнең поэзия күтәрелеш кичерде. Моның сәбәбе, минемчә, ул чор кузгаткан әхлакый, фәлсәфи проблемаларны шагыйрьләрнең нәкъ вакытында күтәреп ала һәм тиешенчә яктырта алуларында булды. Шәхес һәм җәмгыять, шәхес һәм вакыт кебек төшенчәләр турында уйлану безнең поэзия өчен бик нәтиҗәле булды. «Фәлсәфи поэзия» дигән термин да юкка гына шул чакта тумады...

II. Р. Мостафин тәрҗемә ителгән һәм Мәскәүгә җибәрелгән проза китапларының еш кына борып кайтарылуын әйтә. Бу хәлнең төп сәбәбе, мөгаен, ул әсәрләрнең сәнгатьчә эшләнеше начар булуда да, композиция көпшәклегендә дә түгел, ә барыннан да элек аларда сәнгать әсәренә кирәкле философик тирәнлек булмауда.

I. Алай ук катгый хөкем йөртү дөрес микән? Мин, мәсәлән, Х. Сарьянның «Бер ананың биш улы» повестен, М. Юнысның соңгы ике повестен, Н. Фәттахның «Сызгыра торган уклар» романын шактый җентекләп эзерләнгән философик базалы әсәрләр дип саныйм.

II. Әсәрнең философик базасы һәм чорның фәлсәфи эзләнүләре югарылыгында иҗат итү — икесе ике яссылыктагы мәсьәләләр, аларны чагыштырып булмый. Ләкин икесе дә тиң дәрәҗәдә мөһимнәр. һәм, әлбәттә, прозабызның фәлсәфи тирәнлеге, яңалыгы турында сүз кузгатабыз икән, искәрмичә дә ярамый: бу безнең прозаның иң авырткан төше. Бүгенге прозадагы хәлләрнең торышы турындагы бу сөйләшүне башлап җибәрүчеләр нәкъ шуңа тикмәгә генә игътибар итмәделәр. Л. Толстой сүзләре китерелеп, язучының сурәтләү предметына мөнәсәбәте нәкъ үзенчә һәм ихлас булуы мөһим икәнлеге дә әйтелде, язучының тормышны аңлауга яңалык кертергә тиеш икәнлеге дә искәртелде.

I. Безгә дә, мөгаен, сүзебезне шушында тәмамларга кирәктер. Өлкән язучыбыз Әмирхан ага Еники яшьләр белән бер әңгәмәсендә: «Зур әдип әзер хакыйкать белән яши алмый, ул аңа үз зиһене белән ирешә»,— дигән иде. Прозаикларга безнең теләгебез булсын ул. Шул ук әдипнең: «Талантлы кеше кыю булганда гына чын мәгънәсендә талантлы әсәр иҗат итә ала»,— дигән сүзләре дә күңелгә кереп калган. Дөньяны, тормышны кабул итүдә кыюлык, фикерләүдә кыюлык! Язучы хакыйкатьне тормыштан никадәр тирәнрәк һәм кыюрак чумырып алса, аның әсәре шулкадәр зуррак гомумиләштерү көченә ия булачак, ул шуның кадәр күбрәк кешегә үз һәм газиз булачак.

# АК БУРАНДА ТУГАН ШИГЪРИЯТ

*Шагыйрь Рәдиф Гатауллинның яңа җыентыгын укыгач*[1]

Әгәр чынлап та әдәбиятта «Мәхәббәтнең Мәҗнүн премиясе» булдырылса һәм ул премиягә шагыйрь Рәдиф Гатауллин кандидатурасы тәкъдим ителсә, мин аны яклап чыгыш ясаудан тыелып кала алмас идем. Һәм сүземне сәнгатьнең мәңгелек объектларыннан берсе — Мәхәббәт хисе һәм аның сәнгатьтә иң нык чагылышы булган мәхәббәт лирикасы турындагы уйлануларымнан башлар идем.

Рәдиф Гатауллин иҗаты турында сүз чыкса, кайчакта шактый сәер фикерләр ишетергә туры килә: «Әлбәттә, аның төп темасы — мәхәббәт», «Шул мәхәббәт лирикасыннан да ары үсә алмаячак ул...» Шушы ук фикерләр матбугат битләрендә дә күренгәләде.

Әйе, нәкъ шулай: мәхәббәт лирикасына кадәр үсә алу турында түгел, «мәхәббәт лирикасыннан ары үсә алмау» хакында сүз барды.

...Хәзер, менә шушы мәлдә бөтен җир шарында ничә кешенең алдында ачык шигырь китабы икән? Кемнәр, кайсы битен ачты икән ул китапның? Галәмдәге йөзләгән спутниклардан шуны тикшереп карыйсы иде дә процентлап исәпләп чыгарасы иде... Хәер, бу исәпләүләрнең мәхәббәт лирикасы файдасына булачагына шикләнергә дә кирәкмидер.

Шулай да, мәхәббәт лирикасына карата сәер мөнәсәбәт бар. Димәк, шагыйрь Рәдиф Гатауллинның «Мәҗнүн премиясенә тәкъдим ителгән кандидатурасын» һичшиксез якларга кирәк.

Башладык.

Гадәттә, «Фәлән шагыйрь фәләненче елларда поэзиягә килде», дип әйтелә. Димәк, логика таләп иткәнчә, килгән елы булгач, аның поэзиядә яшәгән, эшләгән һәм, ниһаять, киткән елы да булырга тиеш. Ләкин «фәлән шагыйрь фәләненче елны поэзиядән китте», дигән сүзләрне укыганыбыз да, ишеткәнебез дә юк. Поэзиягә килә алган кеше китә алмый. Поэзиягә гомерең буена, бер туктамыйча килергә генә мөмкин.

Шуңа күрә, «шагыйрь Рәдиф Гатауллин поэзиягә 60 нчы елларда килә башлады»,— дип сүзгә керешү дөресрәк булыр.

Һәр уңышлы шигырь — поэзиягә килү.

Һәр уңышсыз шигырь... Хәер, шигырьнең уңышсызы булмый.

Гомерең буена поэзиягә килә алу — иҗади бәхет. Бу бәхет — барлык бәхетләргә бәхет.

Көрәш мәйданында шагыйрьнең әһәмиятен, гражданин буларак кыйблясын, иманын аңлау өчен иң элек аның интим хисләрен аңларга кирәктер. Тагын да төгәлрәк әйткәндә, шагыйрьнең җиһанга, яшәешкә, социаль халәткә карата мөнәсәбәте иң әүвәле мәхәббәт лирикасында тамырлана. Мәхәббәттән башка нәфрәт барлыкка килә алмый. Мәхәббәт — беренчел. Шигъри сүз соклanудан, гаҗәпләнүдән һәм, ниһаять, яратудан ярала түгелме соң?

Күңел түрендә, бәгырь үзәгендә яралган саф хис, нәфис хис, гүзәл хис... Нигә соң кеше аны шунда — үз җанында гына яшереп сакламый? Нигә ул аны кәгазьгә төшерергә, кешегә ишеттерергә, китаплар итеп дөньяга чыгарырга һәм хәтта сәхнәләргә чыгып укырга җөрьәт итә соң? Саф хисләренә хыянәт итү түгелме соң бу? Күңелнең серләр пәрдәсен ачарга нинди көч, нинди хикмәт мәҗбүр итә шагыйрьне?

«Аллага шөкер, мәхәббәт — һәркемнең яшерен эше» — шагыйрьнең әнә шул яшерен хисләре турында язганнарын укыганда без һич тә чит кеше хатын ачып укыган сыман уңайсызлану, оялу кичермибез ләбаса! Киресенчә, шул ук тойгылар кайнарлыгыннан үзебез дә кабынабыз, үкенәбез, борчылабыз, куанабыз... Серләр пәрдәсен ачуның хикмәте нәкъ менә шундадыр, күрәсең: укучының, тыңлаучының рухиятенә, хиссиятенә карата булган ышанычтадыр ул. Шул ышаныч булмаса, кешелекнең бөек сәнгать үрнәкләре, җан кергән мәрмәр сыннарга, тере төсләргә күчкән полотноларга, утлы сулыштан кабынган сүзләргә әверелмичә, һәр талант иясенең күңел түрендә генә яшәп, дөньядан китеп барыр иде.

Менә өч шигырь. Өч мәхәббәт шигыре.

[1] Гатауллин Рәдиф. Йөрәк сөйли. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1982.

Яшерен хисләр, яшерен өмет, яшерен яну. «Көт син мине» (К. Симонов), «Юксыну» (С. Хәким), «Фатыймам» (М. Әмир)... Һәрберсе бер йөрәктән чыккан бу гаҗәеп дәрәҗәдәге ихлас, моңлы сүзләр мәңләгән авторлы җырларга әверелгән. Меңләгән автор — меңләгән ышаныч, меңләгән өмет, меңләгән моң. Иң катгый приказлардан, иң ныклы бастионнардан көчлерәк сүзләр. «Ура!» авазыдай канатландыргыч, кодрәтле сүзләр. Гражданлык вазифасы әнә шунда. «Ирләр булыйк!» шигырен миң нәкъ шул исемлектә санар идем.

Кеше гомере дөньяга нечкә җеп белән генә бәйләп куелган, диләр. Бу дәрес икән, ул җепнең ныклыгы аңа мәхәббәтнең күпме үрелүенә бәйле.

Күптән түгел генә Башкортстан китап нәшрияты гаять кызыклы бер китап чыгарды. «Мәхәббәт китабы» дип атала ул. Анда Башкортстан шагыйрьләренең мәхәббәт турында язылган иң әйбәт шигырьләре тупланган. Гаҗәеп китап! Әгәр дә дөньяда шигъри сүз туган көннән алып бүгенгегә кадәр иҗат ителгән мәхәббәт шигырьләрен бергә җыйсаң, нинди бөек дәреслек барлыкка килер иде. Кешелекнең күңел тарихы дәреслеге. Әйтик, Борынгы заман Күңел тарихы, Яңа заман Күңел тарихы, СССР халыклары Күңел тарихы...

Бәлки, бу дәреслекләр тикшерелгән, төгәл мәгълүматлар белән эш итүче кайбер фәнни чыганакларга караганда көчлерәк тә, гыйбрәтлерәк тә булыр иде.

Бүгенге чорда, бүгенге йөрәкләрдә яңарган иске мәхәббәт татар совет поэзиясенең бүгенге вәкиле Рәдиф Гатауллин шигырьләрендә аерата яңа көч, яңа талпыныш белән яңгырый алган икән, бу — шагыйрьнең иҗади бәхете.

Сөю һәм романтика... Мостай ага Кәримнең бер шигырендә шундый юл бар: «Сөю сүнсә, кеше үлә». Кешенең күңел тарихы тәҗрибәсеннән, газаплы тәҗрибәдән чыгып әйтелгән гаять тирән сүзләр... Гомер җебенең ныклыгы мәхәббәткә бәйле.

Сибгат Хәкимнең Рәдиф Гатауллин иҗаты турында әйткән фикерләре искә төшә: «Яңа утраулар — шигырь утраулары эзли яшь шагыйрь... Каядыр ерак сәяхәтләргә, ерак диңгезләргә омтылу гомумән аның иҗатына хас сыйфат. Поэзия утраулары, мәхәббәт утраулары дияр идем мин аларны. Аларда — яшьлек романтикасы, мәхәббәт романтикасы... Шигырьгә канатлар кирәк, ялкын, хис кирәк, ул югарыга, яктыга омтылсын. Шигырьнең табигате, рухы шундый. Ләкин нигезе тормышта... Җырга җыр кирәк, якты кирәк, зур омтылышлар, янулар кирәк. Рәдиф Гатауллинның шигырьләренең характерын күз алдында тотып, мин өстәп Такташча романтика дияр идем... Романтикага канатларны тормыш үзе куйсын, шул канатлар күтәрә шигырьне».

Рәдиф Гатауллин поэзиясендә заман яшь кешесенең гаять киеренке кичерешләр белән кайнап торган күңеле бик күп төрле яклары белән чагылыш тапты. Нинди булып күз алдына килә соң ул яшь кеше?

Үзенең бөтен табигате белән бунтарь, һәм халкы алдында үзен җаваплы тойган көрәшче шәхес ул. Дөньядагы һәр авазны, һәр сулышны йөрәгенә гаять якын кабул итә торган шәхес, мәхәббәте һәм нәфрәте белән көчле, горур шәхес. Ул яшь кеше үзенең нинди катлаулы заманда, потенциаль катаклизмнар һәр адымда сагалап торган чорда яшәгәнлеген бик яхшы аңлый, кисәтә, чаң кага, көрәшергә чакыра.

Шагыйрьнең барлык шигырьләрен рәттән укып чыкканда бу яшь кеше образы — замандашыбыз образы тагын да калкурак булып күренә. Хәтта ул шигырьләрне һәм поэмаларны әнә шул замандашыбызның көндәлеге яки чордашларына атап язган хатлары итеп тә аңлатырга була. Ул яшь кеше кайда гына булмасын — туган авылы Марстамы, яки Ык буйларындамы, Уфада яки Казандамы, яисә Лондонда һәм Париждамы — Тукайлардан калган җитди миссиясен аңлаган хәлдә, һәр күренешкә карата үзенең шигъри хөкемен чыгара һәм мәхәббәте яки нәфрәте хакында ачыктан-ачык сөйләр өчен гражданлык трибунасына күтәрелә.

Шуңа күрә, бу кешенең кичерешләрен «мәхәббәт лирикасы» дип кенә атау бик аз, әлбәттә.

Әйе, Хәсән Туфан әйткәнчә, шигъриятнең ике канаты да ныклы булырга тиеш — мәхәббәт һәм нәфрәт канатлары...

Бу бунтарь рух шагыйрьдә аның рухи укытучылары Такташ, Байрон йогынтысында тәрбияләнгән.

Рәдиф Гатауллин, гомумән, зур шигъри мәктәп үткән, бөтендөнья классикасын тирәнтен белгән шагыйрь. Шуңа күрә шигырьләрдә дә «бөек исемнәр» вакыты-вакыты белән күбәебрәк китә. Ләкин бу, русча әйткәндә, «литературщина» булып яңгырамый. Күңелне борчыган сорауларга җавап эзләгәндә, бәхәсләшкәндә, киңәшкәндә шагыйрь аларга мөрәҗәгать итә. Дөрес, әдәби зәвыгың тиешле югарылыкта булмаганда, исемнәр белән мавыгуның чыннан да «литературщина»га китерүе бик мөмкин. Ләкин Р. Гатауллинга интеллектуаль ориентация ярдәм итә, һәм ул «бөек исемнәр» шагыйрь өчен абындыргыч каршылыкка түгел, үзенчә бер маякка, уй һәм кичереш объектына әверелә.

Форма үзенчәлеге, әлбәттә, фикер үзенчәлегеннән килә. Р. Гатауллинның саф һәм иркен яңгырашлы шигырь формасына укучы инде күптән күнекте, ияләште, яратып өлгерде. М. Светлов әйтмешли, гел бер үк калып «иждевениесендә» яшәүче шагыйрьләр дә бар. Рәдиф Гатауллин үзенең шигъри формасын эзләгәндә Назыйм Хикмәткә таянды бугай. Аның кырык шигырьдән торган «Егерме дүрт йолдыз һәм унҗиде диңгез» циклы әнә шул хакта сөйли. Бу шигырьләрнең ритмик яктан иркен сулышлы булулары һич тә йөгәнсезлектән түгел. Ритмик иркенлек барыбер шигъри төзелеш кануннарының төгәл үтәлешен таләп итә. Ритмик иркенлек фикер, хис иркенлеген тәэмин итә.

Р. Гатауллинның «Ирләр булыйк!» исемле китабына язган кереш сүздә Әхсән Баянов болай дигән иде: «Һәр шагыйрь кебек үк, Рәдиф Гатауллин да һаман үзгәрә. Шигырьләренең стиле, тематикасы төрләнә... Гражданлык тойгылары, интереслар һәм фикерләр, элеккечә үтә күренмәле булу белән бергә, инде катлаулырак һәм тирәнрәк тәҗрибәләрне сиздерәләр. Иң кыйммәтлесе — чәчелгән фикерләр бөтенлеккә кайталар».

Әйе, Рәдиф Гатауллинның әдәби герое шагыйрь белән бергә шигъри дөньяга аяк басты, гашыйк булды, ялгышты, эзләде. Югалтты, тапты... һәрдаим якты идеалларга омтылган йөрәге аны ерак юлларга алып китте, чыныктырды, ир итте. Һәм бүген инде ул — гомер уртасында... «Гөл керфеге тибрәнүгә мөкиббән» гашыйк малай инде ир булды. Ләкин сынаулар тукталмый икән, алар туктаусыз дәвам итә икән. «Гашыйк малай» инде үз буыны өчен генә түгел, үзеннән соң килгән буыннар өчен дә җавап тота.

Югыйсә, бу яшьтә инде тәҗрибә дә җитәрлек, дусларның һәм дошманнарның кем икәнлеге дә ачык, максатлар да тәгаен билгеле сыман... Ләкин йөрәк һаман эзләнә... Димәк, табигый ки, тагын югалтулар, ялгышлар да һәм ачыш-табышлар да булачак. Яңа ялгышлар, яңа табышлар... Романтиканың табигате шундый. Без дә шагыйрь белән бергә ялгышлар өчен үкенәчәкбез, табышлар өчен сөенәчәкбез.

Рәдиф Гатауллин шигъриятен, хисләренең сафлыгын һәм давыллы булуын күздә тотып, «ак буранда туган шигърият» дип әйтергә мөмкин булыр иде.

Якты талант кешеләргә һәрвакыт шатлык китерә. Синең белән бер үк чорда яшәүче якты күңелле, дөньяга мәхәббәт гашыйк кешеләрнең яшәвен тоюдан да зуррак тагын нинди куаныч булсын!

**ЗӨЛФӘТ.**

# ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ...

## БИЕКЛЕККӘ ЧАКЫРУ

Кызыклы, әйбәт шигырьләргә юлыккан саен, мин бер нәрсәгә ныграк ышана барам: кеше күңелен, андагы рухи тетрәнүләрне шагыйрьләр иҗаты аша гына тирәнтен өйрәнеп буладыр сыман. Кардиограмма тасмасындагы сызыкларга карап, без йөрәкнең тибешен, эшчәнлеген бәяли алабыз. Шигырьләр дә — шул ук кардиограмма лабаса, анда да күңел хәрәкәте, күңел тирбәнешләре акка кара белән уелган. Ул тирбәнешләр никадәр куәтле һәм актив булса, аларның безгә тәэсир көче дә шулкадәр зуррак.

Яхшы шигырь безне ни өчен шундук үзенә суырып ала? Чөнки бу — бай рухлы, югары яшәешле күңел белән очрашу. Андый очрашулар укучыда һәрвакыт якты тойгы, шатлык хисе калдыра. «Казан утлары» журналының 1981 елгы 9 нчы санында яшь шагыйрә Асия Минһаҗеваның шигырьләр циклы басылып чыккан иде. Күңелдә зур өметләр уятты бу исем. Ниһаять, журналның быелгы март санында шагыйрә белән яңадан очрашу. Анда да Асиянең бер бәйләм яңа шигырьләре. Әлеге шигырьләр белән танышып чыкканнан соң, кеше күңелен шагыйрьләр иҗаты аша гына ныклап өйрәнеп буладыр, дигән фикерем тагын да ныгыды минем.

Асия Минһаҗеваның шигырьләре кайягы белән үзенә җәлеп итә соң? Бу сорауга мин: заманчалыгы, образлылыгы, көтелмәгән фикер-хисләре белән дип җавап бирер идем. «Биогамма» дигән шигырьдә бу сыйфатларның һәммәсе бергә кушылып китә алган:

> **Кем геннары тынгы бирми миңа,**
> **Кем хисләре көйләп эндәшә?**

Дулкын тота күңел локаторы,
Биотоклар нидер сөйләшә.

Менә нинди ул бүгенге шәхес күңеленең мөлдерәмә халәте! Әлеге юлларда бик күп нәрсәләрне — гасырлар багланышын да, җан һәм фикер тәңгәллеген дә, кеше рухының мәңгелеген дә төсмерләргә була.

Үткәннәр янсә киләчәк турында язамы, яшь шагыйрәнең шигырьләрендә — бүгенге көн кешесенең уйланулары, гамьнәре, борчулары. Юк, декларатив кычкыру, матур сүзләр сөйләү түгел, ә актив уйлану болар. Автор үзенең сөйлисе сүзен нык уйлап, җиренә җиткереп, образлы телдә әйтергә тырыша. Авторның каләме, археолог пәкеседәй, катлам-катлам яткан тарих төпкелләренә дә кереп китә:

Дөнья яралган көннәрдә
Тарих ак төстә булган.

Образлар әнә шулай кырыс матурлыгы белән сискәндереп куя. Автор озынга сузып, тәфсилләп тормый, ул укучының актив һәм ассоциатив фикерләвенә ышана.

Асия Минһаҗева күп кенә шигырьләрендә үзен иркен хис итә, вакыт һәм пространство барьерларын җиңел атлап чыга, масштаблылыкка омтыла. Аның фикерне маңгайга бәреп әйтмәве куандыра. Әйтик, сугыш һәм тынычлык турындагы уйларын ул табигатькә, болытлар агышына күчерә, шуңа күрә бу урында шигырьнең үз исеме белән «Кирәкми!» дип чаң кагып алу да бик җитә.

Вакыт агышы, еллар агышы да үзеннән-үзе аның шигырьләренә саркып керә:

Булса да безнең өчен тик
Егерме дүрт сәгатьле,

Вакыт — талант. Әлләниләр
Тудырырга сәләтле!

Вакытның талант булуы да сискәндерде мине. Ә бит уйлап карасаң, бу дөрес, чөнки вакыт — без ул. Таң калырлык пирамидаларны һәм шәһәрләрне дә без иҗат иттек. Иң гади ташбалтаны һәм... атом бомбасын да без — кешеләр — уйлап таптык. Менә бүген җир шарының киләчәге язмыш тәлинкәсенә салынган: кайсы як басар — аек акылмы, әллә акылсызлыкмы? Вакыт, «Хиросима күперендә катып калган күләгә» булып, кешелекне әнә шул хакта искәртергә, кисәтергә тели...

Шулай итеп, чынбарлыктагы гап-гади детальләр яшь шагыйрә шигырьләрен укыганда зур политик яңгыраш ала. Ә бит поэзиядә публицистик яңгырашка ирешү ансат эш түгел. Асия моны яхшы аңлый булса кирәк. Публицистик агым аның иҗатына шаулап, актарылып түгел, ә бәлки салмак тонда һәм үтемле, мәгънәле штрихлар рәвешендә килеп керә.

Поэзиягә берәү дә җиңел юл белән килми. Асия Минһаҗеваның әле юл башында торган чагы. Шуңа күрә иҗатта тәҗрибә җитмәү үзен сиздерә икән, бусы да бик табигый хәл. Кайчак авторның максаты, позициясе, теләк-ниятләре томан эчендәрәк күмелеп кала. Кайсыбер шигырьләрендә эзлеклелек җитмәү, фикернең очын-очка ялгап бетермәү кебек кимчелекләр дә күзгә ташлана. Ләкин без аның уңышлы шигырьләренә ышаныйк. Чөнки ул — үсәсе, потенциаль мөмкинлекләре зур булган шагыйрә. Табигать биргән сәләтен даими үстереп, баетып, тәрбияләп торганда ул әле безне кеше күңеленең яңадан-яңа биеклекләренә сәяхәткә алып чыгар.

РАШАТ НИЗАМИЕВ.

**Рәфыйк Нәфиков,**
тарих фәннәре докторы

# ИҢ БӨЕК МАКСАТ

Соңгы берничә елда безгә Габдулла Тукай һәм аның даирәсенең эшчәнлегенә кагылышлы моңарчы билгеле булмаган документлар белән танышырга туры килде. Аларның байтагы «Казан утлары»ның 1980 елгы унберенче, 1981 елгы тугызынчы саннарында басылган мәкаләләрдә күрсәтелеп, журнал укучыларында кызыксыну уяткан иде. Яңа табылган мәгълүматларның бер өлеше шулай ук рус телендә басылган һәм царизмга каршы яшерен революцион көрәш сәхифәләренә багышланган «Революцион подполье серләре» исемле китапка да керде (Казан, КДУ нәшрияты, 1981 ел).

Менә шушыларны искә алып һәм моңарчы беркайда да басылмаган кайбер материалларның әһәмиятен күздә тотып, укучыларга әлеге сериядән өченче мәкаләне тәкъдим итәргә булдык. Ул мәгълүматлар беренче рус революциясе елларында Уральскида чыгып килгән басмаларда хезмәттәшлек иткән, Г. Тукайга якын торып, басма сүз белән царизмга каршы көрәшкән кешеләрнең исемнәрен, шул көрәштә башка халыкларның да алдынгы карашлы яшьләре катнашуын тагын да ачыклый төшү мөмкинлеге бирә. (Алар арасында иҗтимагый эшчәнлекне Казанда һәм Уральскида соңрак елларда да дәвам иттергән, давыллы 1917 елда большевиклар партиясе сафында көрәшкән кешеләр дә бар.)

Шулай ук Габдулла Тукай һәм Камил Мотыйгый-Төхфәтуллинның, соңрак исә Казан демократик һәм большевистик матбугатының патша властьлары агенты, 1890 елларда ук рус матбугаты битләрендә җинаятьче-уголовник буларак фаш ителгән Ә. Сәйдәшевкә каршы алып барган көрәше хакында сөйләүче материаллар да игътибарга лаек дип уйлыйбыз: ә Г. Тукайның әле Урал якларында яшәгән чорында ук Казан белән тоткан элемтәләре, шагыйрьнең Казандагы яшәеш обстановкасы, аның даирәсендә булган, полиция белән жандармерия күзәтүеннән һәм эзәрлекләүләреннән җәфа чиккән кешеләр тормышына нисбәтле мәгълүматлар исә аеруча әһәмиятле.

Бернинди кысу-эзәрлекләүләр, куркыту-янаулар да бу кешеләрне рус иптәшләре белән иңгә-иң торып фидакарьләрчә көрәшүдән, самодержавиене фаш итү һәм хезмәт иясе массаларын патриотизм, халыклар дуслыгы рухында тәрбияләү эшчәнлегеннән туктата алмый. Бөек рус культурасы казанышларыннан рухлануда, илкүләм-россиякүләм фикер йөртү һәм иң авыр чорда да илнең кыю гражданнары булып калуда татар революцион демократларының иң күркәм сыйфатлары чагыла. Аларның иң алдынгылары чын интернационалистлар, бөтенроссия масштабында фикерләүче шәхесләр булып күтәрелделәр. Әнә шул югарылыктан торып, татар революцион демократлары царизмның әшәкелекләрен, Пуришкевич кебек түбән җаннарны, кадетларның һәм мөселман иттифакчыларының татлы ялганнарын һичбер куркусыз фаш иттеләр. Г. Тукайның «Китмибез» шигыре әнә шундый кара көчләргә каршы юнәлдерелгән, Россия социал-демократиясе көрәшенә аваздаш килгән чыгыш иде. Россия прогрессив көчләренең политик көрәш мәйданындагы бу кыю авазларны В. И. Ленин зур кызыксыну белән күзәтеп бара,— моны без аның язмаларыннан күрәбез. Безнең эзләнүләр, табышлар бүтән тикшеренүчеләрне дә архивларда бу чор документларын эзләү эшен дәвам иттерүгә дәртләндерер дип ышанасы килә. Күп гомер узган булса

да, барысы да югалып бетмәгән, илебез халыкларының сыйнфый азатлык көрәше тарихын яктыртучы мөһим мәгълүматлар табыла һәм табылачак әле.

*
* *

Уральскида чыккан «Яңа тормыш» газетасына «Инсанлар тормышы» исемле мәкаләне кем язды икән? Автор исеме урынына «Х. А.» инициалларын гына куйган. Борын заманда да, хәзер дә кешелек җәмгыятендә бер-берсенә капма-каршы сыйнфлар яшәп килә, дип яза автор. Элгәре еристократия булган булса, хәзер исә аның исеме башкачарак — буржуалар. Өскә «буржуалар, капиталистлар акча капчыклары менеп утырганнар» («Яңа тормыш», 1908 ел, 24 март). Мәкалә турыдан-туры социал-демократик рух белән сугарылган. Аның соңында «ахыры булачак» дип вәгъдә ителгән булса да, ул басыла алмый кала. Өлкәнең хәрби губернаторы генерал-лейтенант Родзянко нәкъ менә «Инсанлар тормышы» мәкаләсен бастырып чыгарган өчен газетаны яптыра. Генералның әмере белән ул рус теленә тәрҗемә ителә, аннары Петербургтагы баш цензура комитетында каралып, «котырткыч» рухтагы мәкалә дип табыла (ЦГИАЛ, 776 фонд, 21 тасвирлама, II кисәк, 270 эш, 7, 8, 10 кәгазьләр). Прогрессив матбугат органын яптыру губернаторларның кулыннан килсә дә, алар кешеләр күңелендә кабынган хөррият утын сүндерә, Уральскида Г. Тукай чәчкән орлыкларны себереп түгә алмый.

«Яңа тормыш» газетасының барлык саннарын тәфсилләп күздән үткәрү кирәк (алар «фаш итү әйберләре» сыйфатында өлешчә Казан губернасы жандарм идарәсе фондында, өлешчә ЦГИАЛдагы Баш цензура идарәсе фондында саклана). Ни дисәң дә, ул — Г. Тукайның тырышлыгы белән дөньяга килгән һәм ул үзе Уральскидан киткәннән соң да яшәвен дәвам иттергән газета.

Ленинградта Салтыков-Щедрин исемендәге дәүләт китапханәсенең кульязмалар бүлегендә беренче рус революциясе елларында Уральск шәһәрендә «татар партиясе» яшәп килүе хакында әләк кәгазе-белдермә өлешчә сакланып калган. Документның бу өлешендә әлеге «партиянең» (әлбәттә, бу сүзне туры мәгънәсендә түгел, ә группа, агым мәгънәсендә аңларга кирәк) членнары да, оештыручыларның исемнәре дә юк. Анда К. Мотыйгый-Төхфәтуллин һәм Г. Тукай тарафыннан чыгарыла торган «Фикер» газетасы турында сүз бара.

Биредә «Фикер» газетасының «кыргыз-татар» (ягъни казах-татар) газетасы дип аталуы мөһим. Белдермәдә газета битләрендә казах авторлары мәкаләләренең басылуы, газетаның аерым саннары, андагы кайбер мәкаләләрнең даладагы авылларда таралуы әйтелә. Шуның өстәвенә, редакциянең аерым сәхифәләр бастырып, шулар белән казах шәкертләрен далага җибәрү фактлары хәбәр ителә. Шулар арасыннан Ипмагамбетов фамилиясе (соңыннан ул большевик, Көнбатыш Казахстанда Совет властен урнаштыру өчен актив көрәшче.— Р. Н.) күрсәтелә (Салтыков-Щедрин исемендәге дәүләт китапханәсе кульязмалар бүлеге. 1072 фонд, 15 том, 271 бит).

Мондый фактлар Г. Тукай һәм аның Уральск шәһәрендәге эшчәнлеге хакында безнең белгәннәребезне киңәйтә һәм тирәнәйтә. Шагыйрьнең Уральскидагы дуслары, алдынгы яшьләр 1916 елда шәһәрдә «Дуслык» дип исемләнгән музыка түгәрәге оештыралар. Бу түгәрәктә алар музыка кoралларында уйнарга өйрәнеп кенә калмыйлар, белемнәрен дә күтәрәләр. (Бу максат белән алар үз китапханәләрен булдыралар. Бездә «Дуслык» түгәрәге мөһере басылган берничә китап саклана.) Шушы түгәрәктә үскән кешеләр, Совет властен яклап, гражданнар сугышында актив катнашалар. 1919 елда Уральск шәһәре оборонасында, шулай ук ак поляклар, алаш-урдачылар, басмачыларга каршы сугышалар. (Бу хакта аерым язып чыгарга, түгәрәк членнарының 1916 һәм 1917 елда төшкән фоторәсеме белән таныштырырга мөмкин булыр иде.)

«Фикер» газетасының даирәсе, анда кемнәрнең хезмәттәшлек итүе хакындагы мәгълүматлар Г. Тукайның Казан университеты студентлары А. Имамбаев һәм И. Кашкинбаев белән үзара мөнәсәбәтен ачыклау мәсьәләсен дә алга куя. Боларның яшерен революцион көрәштә катнашулары, Х. Ямашевның дусты Г. Коләхметов белән танышлыклары, большевик Х. Ямашев фатирында булулары архив документлары

нигезендә исбат ителгән иде («Революцион подполье серләре» дигән китапта). Хәзер исә И. Кашкинбаевның әле Казанга укырга килгәнче, Урал гаскәри һөнәр училищесында укыган чагында ук, укучыларның революцион социал-демократик оешмасында катнашучылар (Е. Ларин, М. Беньяминович һ. б.) белән бәйләнештә булуы ачыкланды[1].

Уральскида ниләр эшләгәнне Казанда белеп торганнар. «Казанский телеграф» битләрендә, Уральскида тиздән «Әлгасрелҗәдид» исемендәге татарча беренче журнал басыла башлаячак, дип хәбәр ителә (1905 ел, 1 декабрь саны). «Әлгасрелҗәдид»не Казанда да, Уфада да, Оренбургта да күтәрешергә вәгъдә биреп, каләм ияләре хуплап каршы алганнар. Ул татар, башкорт, казахлар арасында яклау тапкан. Бу шул ук вакытта яшь шагыйрь Г. Тукайның хезмәтен тану да иде. Чөнки, шиксез ки, Уральскида ул татар телендәге барлык газета-журналларны оештыручы һәм аларның төп әдәби хезмәткәре булган.

Уральск шәһәрендәге татарча басмалар хакында «Казанский телеграфта» чыккан белдерү Г. Тукай һәм аның даирәсенә кагылышлы булган беренче хәбәр түгел.

Газеталарда басылган материаллардан күренгәнчә, Уральск белән Казан арасында без әйткән мәгънәдәге элемтә алданрак урнашкан. Большевиклар органы булган «Волжский листок» газетасы 1905 елның апрелендә ук инде «Уралец» газетасының 147 санында басылган бер мәкаләне телгә ала. «Ишанлык һәм аның нәтиҗәләре» дигән мәкалә авторы «бер мөселман кешесенең» «Уралец»та дөнья күргән әлеге шул мәкаләсен таяныч итеп алып, шуңардан файдаланып яза («Волжский листок», 1905 ел, 9 апрель саны). Шул ук елның 20 маенда «Волжский листок» газетасы «Яшь татарин» имзасы белән бер хәбәр урнаштыра. Автор биредә Ә. Сәйдәшевнең мөселман хатын-кызлары һәм шәригать законнарына багышланган мәкаләсенә каршы чыга. «Яшь татарин» кыю рәвештә хатын-кызлар турындагы шәригать законнарын һәм аларны яклаучыларның реакцион асылын фаш итә. «Тормыш алга бара һәм аны буйлы чапан җиңе белән каплап, бәйләп кую мөмкин түгел... Дөньядагы бер генә алдынгы халыкта да кол хатын-кызлар юк»,— дип яза ул («Волжский листок», 1905 ел, 20 май саны).

Һәм менә шушыларга яңа фактлар килеп ялгана. Большевистик рухтагы «Казанский дневник» газетасы «Фикер»нең редакторы һәм нәшире К. Төхфәтуллинның, консерватив татар газетасы «Бәянелхак» нәшире Ә. Сәйдәшевкә матбугат битләрендә яла ягуда гаепләнеп, округ суды тарафыннан Казанга чакырылуын хәбәр итә. К. Мотыйгый суд гыйбрәтле булачак, анда дини мәсьәләләр күтәреләчәк, дип белдерде, диелә («Дневник Казани», 1907 ел, 11 март саны).

Әлеге суд материалларын архивтан эзләп табарга теләвебез табигый иде, чөнки бу эш карагруһчы Әхмәтҗан Сәйдәшевнең, К. Төхфәтуллиннан бигрәк, Г. Тукайга каршы көрәшүен күрсәтә. Һәм менә шунда безгә бик күңелсез хәлгә тап булырга туры килде. Дәүләт архивының тасвирламасы буенча (390 фонд — округ суды) Төхфәтуллинга караган бер генә дә түгел, ике эш: 1906 ел, 2490 эш һәм 1908 ел, 2997 эш (70 кәгазь) теркәлгән булган. Никадәрле документ, күпме мәгълүмат, катнашкан кешеләрнең исемнәре, күрсәтмәләре һ. б. фактик материал. Булган, җитмеш ел буе сакланган. Ә 1981 елны, безнең килердән берничә атна гына элек, әлеге эшләрне «вакыты үткән»гә санап, акт белән юк иткәннәр. Әлбәттә, бүтән төрле саклау берәмлекләренә мәйдан булдыру өчен шулай эшләгәннәр. Округ суды эшләренә карата мондый саксызлык бик кызганыч. Революция һәм милли азатлык хәрәкәте тарихына аз гына кагылышлы булган материалларга карата да бик сак караш кирәк. Әлеге процесс турында кайбер өзек-өзек мәгълүматларның 1405 фондта (ЦГИАЛ, Юстиция министрлыгы) сакланып калган булуы ихтимал.

Архивларга хөрмәт ничаклы зур булмасын, тикшеренүче алар белән генә яшәми. Тарих ул төрле формаларда саклана. Алдыбызда 1905 ел революциясе чорында чыккан газеталар. Алар күп төрле, чуар эчтәлекле, әмма һәрберсенең тоткан юнәлеше

---

[1] ЦГИАЛ, 733 ф., 166 тасв., 809 эш, 76 кәгазь; Татарстан дәүләт архивы, 199 ф. 1 тасв., 1692 эш, 295 кәгазь. Кашкинбаев Лонщенск өязе, Курапл волосте, 3 нче номерлы авылдан. 1891 елда туган. Урал реаль училищесында 1903 елдан 1910 елга кадәр укыган. (Татарстан дәүләт архивы, 977 ф., 40506 эш.)

1905 елның җәендә Г. Тукай, далага дип, аңа этап бармаганмы икән? Шулай ук шагыйрьнең 1912 елны Троицкига сәфәрен шушы күзлектән тикшерәсе иде. Биредә ул Г. Коләхметовның дусты А. Имамбаев белән очрашмаганмы?

бар. Бер-берсеннән уздырырга тырышып, үзара сөнге-ук атышып, төрле вакыйгалардан хәбәр бирәләр.

Кадетларның «Казанский вечер» газетасында, мәсәлән Ә. Сәйдәшевнең «Фикер» газетасы белән судлашуы хакында хәбәр бар (1907 ел, 18 май саны). Анда «әле шушы көннәрдә» генә округ судының присяжный заседательләр катнашыннан башка гына үткән бер утырышында (бусы, шиксез ки, суд процедурасын бозу иде) Уральскида чыга торган татар газетасы редакторы һәм нашире Төхфәтуллинны яла ягуда гаепләү эше каралуы хакында әйтелә.

«Бу эшне кузгатуга Төхфәтуллинның үз газетасында Сәйдәшевкә каршы «Алай-болай» исемле мәкалә һәм бер шигырь бастырып чыгаруы сәбәп булды,— дип яза газета.— Мәкаләдә һәм шигырьдә Сәйдәшев, «карыны ачкач, шаригать, иман сатарга тотынган, соңыннан унике мең сум акча чәлдерү өчен Әхмәт бай белән судлашкан, бу 12 меңне алгач, әле тагын рус аллавытларына сатылып, «Бәянелбатыйль»ны, ягъни «ялган сөйләүче»не (Сәйдәшев чыгара торган «Бәянел-хак» газетасын ул әнә шулай дип йөртә) чыгару өчен алардан да шуның кадәре сумма алган, диелә». Алга табан Сәйдәшевнең вексель ерткан өчен төрмәдә утырып чыгуы әйтелгән. Сәйдәшев, усал ният белән яла ягуда гаепләп, үзенең поверенный кешесе аша Төхфәтуллинга закон буенча җәза бирүне таләп иткән. Төхфәтуллинның судтагы яклаучысы исә аны акларга омтылып һәм әлеге мәкаләләрдә яла юклыгын күрсәтеп, заманында Сәйдәшевнең сәүдә кенәгәсеннән бер язуны ертып алып яшергәнлеге өчен гаепләнүен белдерә, төрмәгә ябылуын раслый торган документларны күрсәтә. Әмма Сәйдәшевнең поверенный кешесе раславынча, Сәйдәшев әлеге уголовный эш буенча присяжный заседательләр тарафыннан акланган булып чыга. Шушылардан соң округ суды Төхфәтуллинны гаепле табып, аны ун көнгә полиция участогына ябылуга хөкем итә («Казанский вечер», 1907 ел, 18 май).

Газетада чагылган бу хәбәрләр, безнең бәхеткә каршы, архив документлары белән дә раслана. Әлеге вакыйгага мөнәсәбәтле ике архив чыганагы юк ителгән дип әйткән идек инде. Ул шулай, ләкин эзләнүләр нәтиҗәсендә без тагын бер архив «эше»нә юлыктык (ТАССР үзәк дәүләт архивы, 41 фонд, 2 тасв., 2513 эш, 1907—1908 еллар, 88 битта). Анда тагын кайбер нәрсәләр ачыла. Әхмәтҗан Сәйдәшев үзенең гаризасында «Алай-болай» мәкаләсенең һәм шигырьнең авторлары да судта гаепләнергә тиеш дип яза. Редактор аларның исемен вә тора торган урыннарын да күрсәтсен, ди, эшне тизләтер өчен булса кирәк, Тукай әсәрләренең тәрҗемәсен дә судка тапшыра Сәйдәшев. Ләкин аның мәкерле сорауларына җавап булмый, Тукайны дошманнарга ачмыйлар.

Хөкем вакытында Сәйдәшевнең 1897 елны судка тартылуы да искә алына. Ул вакытта, 1897 елда, суд аның урлауларын ачыклый (ТАССР үзәк дәүләт архивы, 41 фонд, 2 тасв., 2271 эш, 9, 11, 95 кәгазьләр), ә менә 1907 елда башкача нәтиҗә ясый.

Биредә әһәмиятлесе шул, Г. Тукай җибәргән уклар тиешле урынына тигән, Сәйдәшев нәкъ менә аңа, аның язганнарына каршы күтәрелә, чөнки «Алай-болай» дип исемләнгән мәкалә Тукайныкы, һәм ул «Фикер» газетасының 1906 ел 3 нче һәм 21 июль саннарында «Биик усал» имзасы белән басылып чыккан. К. Мотыйгый-Төхфәтуллин җаваплылыкны үз өстенә ала һәм судта хезмәттәше Г. Тукай исемен атамый. «Казанский вечер» газетасында урнаштырылган әлеге кыска гына хәбәрдән үк Сәйдәшевнең уголовник икәнлеге аңлашыла. Присяжный заседательләрнең аңа карата шартлы төстә аклау карары чыгарулары Сәйдәшевнең җинаятен, бурыч таныкламасын ертып ташлау фактын юкка чыгармый. Газетадагы хәбәрдә «Алай-болай» мәкаләсенең эчтәлеге төгәл үк яктыртылмаган. Бу сатирик мәкаләдә Г. Тукай Сәйдәшевнең, миллионер Ә. Хөсәеновтан унике мең сум акча дәгъвалап, судлашып йөрүе хакында яза. Бу чыннан да булган хәл. Казан сәүдәгәре Ә. Сәйдәшевнең «Бәянел-хак»ны чыгару өчен рус аллавытларыннан тагын унике мең сум акча алуына ишарә итү дә дөреслеккә туры килә: ул үзенең карагруһчыл эшчәнлеге һәм доносчылыгы өчен патша казнасыннан яшерен алган акчалардан файдалана.

Төхфәтуллинга гаеп ташларга маташу нигезсез булып чыга: газета хәбәрендә дә, һәм, ихтимал, суд карарында да мәсьәлә дөрес яктыртылмый. «Казанский вечер»да күренгән информация буенча фикер йөрткәндә, соңыннан ул карар расланмаган һәм көченә кермәгән, бер уйдырма булып кына калган. Г. Тукай үзенең фельетоннарында

юкка гына Ә. Сәйдәшевне әхләкый гарип зат, әлифбадан ары узалмаган надан һәм томана баш, коткы таратып, пычрак ягып йөрүче погромчы итеп сурәтләми[1].

Югарыда әйтелгәннәрне Казанның рус матбугаты, шул исәптән социал-демократик матбугат органнарында чыккан материаллар белән янәшә куеп карыйк. «Нәрсәнең намуслы һәм нәрсәнең намуссыз булуы хакында безгә һәрхәлдә Сәйдәшев әфәнде мораль укымасын иде»,— дип яза «Волжский листок» газетасы 1907 елның 12 сентябрендә. Шул ук газетаның 25 сентябрь санында Г. Камалның «Бәянел-хак»ны ялган хәбәрләр таратуы өчен судка тартырга җыенуы хакында әйтелә.

Яңа табылган фактлар карагруһчы, царизмның сатлык агенты Ә. Сәйдәшевнең большевиклар белән тарткалашуын да раслыйлар. Аның улы М. Сәйдәшев, мәсәлән, «Редакциягә хат» язып, «Волжский листок»ның 474 номерында басылган бер мәкаләгә каршы чыга («Казанский вечер», 1907 ел, 7 сентябрь саны). Ә. Сәйдәшев үзе дә шундый рухтагы «хат» яза (шунда ук, 10 сентябрь саны). Үзләрен «демократлар» дип күрсәтергә яратучы кадетлар большевистик матбугатка каршы көрәшә, пычрак җанлы сәүдәгәрләрне файдаланудан да тартынмыйлар.

Ә. Сәйдәшев пыяла заводы хуҗасы, комсыз һәм әхлаксыз кеше буларак та күптән инде яманаты чыккан кеше була. Аның ерткычлыгы хакында Г. Лопатинның танышы революционер А. Дудкин язып чыга («Северный вестник», 1890 ел, 6 сан.) Бу исем шулай ук профессор Н. П. Загоскинга да билгеле. Ул бозык татар байлары һәм сәүдәгәрләре Х., У. (аларның фамилияләре тулысынча бирелми) һәм Әхмәтҗан Сәйдәшевләрнең татар кызы Миңнегөл Ш-ваны мыскыл итүләрен сөйли. Алар кызны алдалап, «туй мәҗлесе» үткәргән булалар, әлеге Сәйдәшевләрнең берсе аңа «өйләнә», ә аннары ташлап калдыра. Эшне судта караган вакытта никах таныклыгының ялган булуы беленә. («Волжский вестник», ценз. экз., 48 нче сан, 1892 ел, 23 февраль саны). Г. Камалның «Уйнаш» пьесасы сюжетына да шушы вакыйга алынган булырга мөмкин.

Әлеге фактлар самодержавиегә һәм татар милләтчеләренә каршы көрәштә, революцион демократларның һәм большевикларның бергә хәрәкәт итүләрен, Г. Тукай һәм аның дусларының социал-демократлар белән бердәмлеген бик ачык күрсәтә, яшәп килүче стройга каршы көрәштә азатлык хәрәкәтенең төрле буыннары арасындагы дәвамлылык хакында сөйли.

Уральскиның прогрессив матбугаты органнарының Казан белән тоткан элемтәләренә караган яңа фактлар ачыклана тора. К. Мотыйгый-Төхфәтуллин Казанга килгәч, 1907 елдан РСДРП члены М. Дулат-Али туганнары квартирасында туктый. Уральскидан Казанга киткәндә, Г. Тукайга да шул ук адрес бирелгән була. Димәк, фәнни эзләнүләрне дәвам иттергәндә, Г. Тукайның М. Дулат-Али аша Х. Ямашев белән танышлыгының ничек башлануын ачыклау мөмкинлеге туа. Шагыйрьнең М. Дулат-Али белән дуслыгы исә билгеле.

К. Мотыйгый-Төхфәтуллинга килгәндә, яңа, прогрессив татар матбугаты органнарының беренче редакторларыннан берсе, Совет властен урнаштыру һәм ныгыту өчен актив көрәшчеләрдән булган, 1917 елда Смольныйда В. И. Ленин җитәкчелегендә һәм Д. Рид белән берлектә эшләгән ул шәхеснең тормышы һәм эшчәнлеге аерым тикшеренүне сорый. Аның биографиясеннән безнең темабызга якын бер күренекле һәм мөһим фактны әйтеп китәргә мөмкин. РСДРПның Уральск шәһәр комитеты 1908 елда «Яик» исеме астында көндәлек газета чыгаруны планлаштыра, аны «Уралец» газетасының элекке нашире К. Мотыйгый-Төхфәтуллин типографиясендә бастыру күздә тотыла («1907—1914 елларда Казахстанда эшчеләр һәм аграр хәрәкәт». Документлар һәм материаллар җыентыгы. Төзүчеләр: Ф. Н. Киреев, Ф. И. Колодин. Казахстан дәүләт нәшрияты, Алма-Ата, 1957 ел, 87—89 битләр.)

Революцион демократларга реакция елларында патша охранкасының өзлексез күзәтүе астында эшләргә туры килде. Аларның барлык әсәрләре, хәтта легаль рәвештә бастырып чыгару өчен билгеләнгәннәре дә, махсус цензорлар күзеннән үт-

[1] Мәсәлән, Г. Тукайның «Ялкаулык, яки җиңел кәсеп» («Фикер», 1906 ел, 25 июнь саны), «Погром» (1906 ел, 10 июль саны) һәм башка мәкаләләре. Мәгълүм булганча, Г. Тукайны, Төхфәтуллиннар гаиләсен, газета редакциясен карагруһчыларның Сәйдәшев һәм Уральск байлары коткысы белән оештырылган һөҗүменнән бары типография эшчеләре генә саклап кала.

кәрелә, тикшерелә. Ә легаль мөмкинлекләрдән файдаланып, ачык кичәләрдә катнашулары, публика алдындагы чыгышлары полиция һәм жандармерия органнарында шик уятә, җентекләп күзәтеп барыла. Үткән спектакльләр һәм концертлар, аларга кемнәрнең килүе, үзара очрашып сөйләшүләр, кемнең кем белән таныш булуы, дусишләре, чолганышы хакында махсус агентлар отчет язып торалар. Нииндидер могҗиза белән архивта сакланып калган берничә документны күрсәтеп үтик. 1909 елның 11 октябрендә «Шәрык клубы» бинасында «музыка кичәсе булу билгеләнгән», дип хәбәр итә Казандагы жандармерия идарәсенә полиция членнары[1]. Кичәнең булу-булмавы хакында хәбәр юк. Шулай ук кичәләр әзерләнүе турында әлеге адресатка хәбәрләр туктаусыз килеп тора. Мәсәлән, әдәби-музыкаль кичәләрнең 1909 елның 18 октябрендә, 1, 8, 11 ноябрендә һәм башка көннәрдә булачагы әйтелә. Боларга «клуб әгъзалары» һәм «аларның рекомендациясе буенча» чит кешеләр дә кертеләчәк, диелә[2]. Күрәсең, «Шәрык клубы»нда андый кичәләрне атнага бер тапкыр үткәрү гадәткә кергәндер.

Дәүләт архивында безгә 1909 елның соңгы айлары, 1910 ел башында үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәләрнең дүртесенең программаларын очратырга туры килде. Боларда дүрт дистәгә якын татар халык көе күрсәтелгән. Шулар арасында һәркемгә таныш көй исемнәре белән бергә сирәк яңгырый торган, онытылган исемнәр дә бар. Мәсәлән, «Иске Троицки», «Кисмәк асты», «Зәйнулла», «Ягкуп», «Мирфаиз», «Акчун», «Җомга», «Шәмсиҗиһан», «Әхмәт солдат», «Калфагым бар, шәлем юк», «Гайса макарҗә» һ. б. Исемнәре буенча инде аңлашылып бетми торган номерлар да күрсәтелә, мәсәлән, «Казан калаларында», «Шарманка тасвирлары» (155, 219, 238, 242 кәгазьләр). Концертларда рус халык җырлары, композиторларның әсәрләре, опереттаралардан өзекләр башкарыла. Рус җырларыннан тыш, татар башкаручылары башкорт, казах, үзбәк көйләреннән дә иркен файдаланалар. Концертларда төп урынны халык моңнары алып тора. Шунсыз мөмкин дә булмый, профессиональ иҗат җимешләре әлә аз, булса да, жандармерия киртәләре аша аны сәхнәгә алып чыгу мөмкин түгел. Ә халыкның һәркайда җырланган җыр-көйләрен тыя алмыйсың, шул ук вакытта алар максатка да җавап бирә, халык һәм аның шагыйрьләре, җырчылары, уй-теләкләренең бердәмлеген чагылдыра. Эстетик дәрәҗәләре ягыннан исә көйләр югары таләпләргә җавап бирерлек, клубка йөрүче рус тамашачылары да, аларны тыңлап, чын күңелдән соклануларын белдерәләр. Клубта киң публика өчен лекцияләр үткәрүгә дә шактый игътибар бирелгән. Мәсәлән, 1909 елның 12 февралендә Г. Әхмәров «Казан тарихы» буенча лекция укый. Лекциянең дәвамы рәсми тоткарлыклар аркасында шул елның 29 октябрена гына игълан ителә.

Г. Тукай үзе дә шушы клубта халык әдәбиятына багышланган мәшһүр лекциясен укый. Әле Уральск шәһәрендә яшәгән елларында ук дәртләнеп әдәби-музыкаль кичәләр оештырышып йөргән шагыйрь Казанда да «Шәрык клубы» эшчәнлеген күңеленә якын алып, аңа юнәлеш биреп торучылардан берсе була. Ул халыкның иң яхшы идеалларына, аның өметләренә дәрт өстәп, аларны үстереп, алдынгы традицияләренең дәвамчанлыгын кайгыртып яши һәм көрәшә, иҗаты белән халык поэзиясен алга әйдәп бара, хезмәт ияләрен якты киләчәк өчен көрәшкә рухландыра һәм юнәлтә.

Патша самодержавиесе ялчылары Г. Тукайның татар тормышындагы бу ролен аңламый калмаганнар. Моны түбәндәге бер документ бик ачык күрсәтә. Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитеты Габдулла Тукаевның шигырь мәҗмугаларыннан берсенә (1908 ел) карата Петербургтагы Баш Идарәгә 1911 елның 26 ноябрендә М. Пинегин кулы белән бер документ җибәрә. Казан чиновниклары җыентык авторының «Китмибез» шигыре өчен Җәзалар турындагы Уложениенең 1034 статьясы 3 пункты, «Хөррият хакында» шигыре өчен Уголовный Уложениенең 129 статьясы 2 пункты, «Тавыш хакында» шигыре өчен («турыдан-туры эшчеләрне көрәшкә чакыручы» әсәр буларак) Уголовный Уложениенең 129 статьясы 6 пункты, «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр» шигыре өчен шул ук статья һәм пункт буенча гаепле

[1] ТАССР дәүләт архивы, 199 ф., 1 тасв., 1714 эш, 119 кәгазь.
[2] Шунда ук, 136, 162, 176, 189 кәгазьләр.

булуын күрсәтеп, әлеге җыентыкка арест салуны, Г. Тукайны суд хөкеменә тарттыруны үтенәләр. Шигырьләрне русчага Н. Ф. Катанов тәрҗемә иткән [1].

Боларның барысы өчен нинә ел утыру тиеш булды икән соң? Г. Тукай төрмәдән дә чыга алмаган булыр иде. Ә ул бу вакытта каты авыру инде. Әлеге «эш» 1911 елның декабренда да дәвам иттерелә. Казандагы суд палатасы гаепләү статьялары белән килешми, кәгазьләр исә 1912 елның апрелендә дә йөри тора [2].

Шушындый авыр шартларда да Г. Тукай оптимист булып кала. Ул бүтән халыкларның да алдынгы вәкилләрен бердәм эшләргә чакыра. Әлбәттә инде, Г. Тукай һәм аның көрәштәшләренең эшчәнлегенә төрле киртәләр салына, алар кара исемлекләргә теркәлә, даими күзәтү астына алына. «Шәрык клубы» әгъзалары артыннан, мәсәлән, Казан губернасы жандарм идарәсе хезмәткәре, «Житель» кушаматлы кеше шымчылык итә. Аның хезмәтенең нәтиҗәләре белән Идел буе охранный бүлеген җитәкләүче Саратов жандармерия идарәсе начальнигы да кызыксынып тора [3].

Бөтенроссия шагыйре Г. Тукайны бөтен тулылыгы һәм бөеклеге белән күз алдына китерү өчен, галимнәребезгә шагыйрь эшчәнлегенең колачын, Россия империясе хезмәтендәге учреждениеләрнең аны күзәтү буенча алып барган эш нәтиҗәләрен һәрьяклап тикшерергә кирәктер дип уйлыйбыз.

1909 елда Казан губерна идарәсе хөкүмәткә каршы эш итүдә шикләнеп Әхмәтҗан Мостафин белән Ш. Шәрәф өстеннән язышу алып бара, алар өстеннән яшерен полиция күзәтүе урнаштырыла [4]. Жандарм идарәсе начальнигы 1908 елның 26 сентябрендә үк Казан губернаторына язган яшертен хатында «Сабах» китап кибетендәге татар басмалары арасында легаль булмаган брошюралар бар, «моннан башка исә әлеге магазинның конторкасы янында чынаякта партия работниклары язу калдыралар», дип хәбәр итә [5].

Тәртип сагында торучыларның моннан соңгы гамәлләре гаҗәеп «нәзакәтлелеге» белән аерылып тора. Әлеге кибет урнашкан Ш. Казаков йортына цензор Н. И. Ашмарин белән бергә полиция чиновникларыннан комиссия килеп төшә. Кибеттәге китапларны актарып чыгалар, әлеге конторка чынаягындагы хатларны ачып тикшерәләр, әмма «гаепләрлек нәрсәләр таба алмыйлар». Хатларны русчага профессор Н. Ф. Катанов тәрҗемә итә [6]. Шикле китаплар да күренми, шуның белән хәвефле «эш» тә ябыла.

Тикшерелгән хатларның берсендә «Әминов берәз вакыттан соң кайтып җитәчәк», дигән юллар игътибарны җәлеп итә [7]. Сүз биредә Х. Ямашев яшәгән квартира хуҗасы М. З. Әминов хакында бара булса кирәк. Ямашевның аны Оренбургтан Уфага типография җиһазларын күчерү өчен җибәрүе билгеле. Документлардан күренүенчә, «Сабах» кибете аша Н. Думави һәм башка язучылар, шулай ук ул чорда Х. Ямашев белән аралашкан татар эсерлары да хат алышкан [8]. Бу елларда алар большевиклардан йөз чөерми, ә большевиклар исә царизмга каршы көрәштә, вакытлыча гына булса да, эсерлар белән бер блокта барудан өркмиләр: алар әдипләргә, артистларга һәм укытучыларга большевистик идеяләр йогынтысын җиткерергә омтылалар. Бу чорда, мәсәлән, Новый клуб бинасында уртак тырышлык белән спектакльләр кую очраклары булган, алардан алынган акчаның сөргенгә җибәрелгән большевиклар файдасына тотылуы да мәгълүм [9].

1911 елның 21 гыйнварында Новый клуб залында эшчеләрнең судоходный җәмгыяте рус һәм татар публикасы өчен кичә үткәрә. Әлеге җәмгыять җитәкчеләре арасында большевиклар булуы мәгълүм. Шушы кичәдә Г. Тукай да катнаша, сәхнәдә үз шигырь-

---

[1] ЦГИАЛ, 776 ф., 21 тасв., 260 эш, 2—3 кәгазь.
[2] Шунда ук, 8, 9 кәгазьләр.
[3] ТАССР дәүләт архивы, 199 ф., 1 тасв., 2065 эш, 17 кәгазь.
[4] ТАССР дәүләт архивы, 199 ф., 1 тасв., 606 эш, 75 кәгазь.
[5] Шунда ук, 1483 эш, 60 кәгазь.
[6] Шунда ук, 1483 эш, 67 об., 68—70 кәгазьләр.
[7] Шунда ук, 1483 эш, 1 тасв., 76 об. кәгазь.
[8] ТАССР дәүләт архивы, 199 ф., 1483 эш, 72 кәгазь.
[9] Шунда ук, 65 кәгазь. Казан жандармерия идарәсе агентурасы ярдәмендә төзелгән исемлектә алфавит буенча Г. Ибраһимовның якын иптәшләреннән берсе Х. Әбүзәров, Х. Ямашев түгәрәге члены студент Ю. Бикбов, М. Вахитовның якын кардәше И. Казаков, драматург Г. Камал, шагыйрь Дәрдмәнд, большевик Х. Ямашев һ. б. бар. Кара: ТАССР дәүләт архивы, 199 ф., 1 тасв., 3715 эш.

ләрен укый, М. Вахитовның якын иптәшләреннән булган Р. Габитова һ. б. лар була. («Йолдыз», 1911 ел, 18 январь саны.)

Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Г. Коләхметовлар Россиянең чын патриотлары булarak хезмәт итә халкын гомумроссия колачы белән фикер йөртергә өйрәттеләр, аны коллыктан азат уртак Ватан рухында тәрбияләделәр; алар шушы ук максатларда иң алдынгы рус һәм дөнья классиклары әсәрләрен һәрьяклап пропагандаларга тырыштылар.

Л. Н. Толстойның тууына 80 ел тулу уңае белән Казаннан җибәрелгән телеграммаларда күп кенә таныш фамилияләр: М. П. Четвергова (Казан буенча аны В. И. Ленин яхшы белә), Н. Е. Федосеевның иптәшләреннән булган П. А. Голубев, РСДРПның Казан комитеты члены А. Пинкевич һ. б. игътибарны җәлеп итә. Шулар белән рәттән биредә Г. Тукайның танышлары һәм хезмәттәшләре Г. Шәрәф, Х. Әбүзәров, Х. Ямашевның дусты А. Мостафин, Казанда революцион хәрәкәттә катнашкан әзербайҗан студенты М.- И. Сеидовны күрәбез [1]. Телеграммадагы шактый фамилияне тануы читен, кайберләре кыскартып, берничә гарәп хәрефе белән генә язылган. Әлбәттә, телеграммаларның барысы да безгә килеп җитмәгән. Л. Толстойның замандашлары билгеләп үткәнчә, Казан мөселманнары, барлык тыюларга да карамастан, бөек каләм иясе адресына ике йөзләп кешенең кулы куелган котлау телеграммасы җибәргәннәр.

Безнең алда яткан телеграммага өч йөз кеше кул куйган. Аның тексты зур түгел. «Ясная Поляндан ишетелгән сүз озак еллар инде дөньякүләм әһәмияткә ия. Аңарга бик күп төрле караштагы торучы һәм төрле милләт кешеләре колак сала,— дип язалар казанлылар.— һәм безгә,— рус чынбарлыгының кырыс шартларында яшәүчеләргә,— ул сүз аеруча якын һәм кадерле. һәрчак туры һәм кискен ул сүздә без кеше яшәешенең мәгънәсен эзләүче кыю һәм тугры фикер гәүдәләнешен күрәбез.

Кайбер чакта Сезнең белән килешеп бетмичә дә, күп вакыт исә хаклык, яхшылык һәм матурлык идеалларының яңача тасвирлануына шатланып, без һәрвакыт рус җиренең бөек язучысы тавышына тирән ихтирам белән күңел сала килдек...» [2].

Казаннан җибәрелгән бу котлау хаты либералларның купшы тәбрикләреннән аерылып тора. Монда бөек язучыны югары бәяләү белән бергә аның философиясе белән килешмәүче социал-демократларның тәэсире ачык сизелә. Шул ук вакытта телеграмма марксистлар белән революцион демократларны берләштерүче уртак фикергә нигезләнгән, һәм иң әһәмиятлесе дә әнә шунда. Казан большевиклары шушы нигездә үз байраклары астына башка милләтләрнең демократик эшлеклеләрен дә җәлеп итә белделәр.

һәртөрле эзәрлекләүләр, полиция киртәләренә карамастан, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал һ. б.ларның эшчәнлеге Х. Ямашев, В. А. Александров кебек большевикларның көрәше белән янәшә эздән бара. 1912—1913 елларда да жандармнар шул ук «Сабах», «Юл» китап нәшриятлары, «Мәктәп» журналы эшчәнлеген зарарлы дип санавын дәвам иттерәләр. Шунысы аеруча характерлы: ахыр чиктә патша чиновниклары азчылык милләтләр арасында «социалистлар һәм интернационалистлар тибы» барлыкка килде дип таныrga мәҗбүр булдылар [3]. Мондый нәтиҗә чынлыкта милли төбәкләрдә патша самодержавиесе тоткан политиканың йөзтүбән мәталүен күрсәтә иде.

Татар революцион демократларының азатлык көрәше сәхифәләрен тикшергәндә аларның рус һәм татар буржуазиясе партиясе — кадетлар һәм аларның бер тармагы «Мөселман иттифакы»на мөнәсәбәте дә бик ачык күренә.

Бу партиянең Казандагы эшлеклеләре Идел буе халыкларының күтәрелеп килүче азатлык хәрәкәтен үз йогынтысы астына алу өчен аз тырышмыйлар. Мәсәлән, 1907 елның 9 гыйнварында татарларның Новый клубта үткән кичәсен алар күзне камаштырырлык «йолдызлар парады» итеп оештыралар. «Мөселманнар» алдында конститу-

---

[1] М. — И. Сеидов университет студенты П. Х. Орлов һәм башкалар белән бергә сугышчан дружинада тора, кулга алына. Ул шулай ук Х. Ямашев даирәсеннән Р. Маликов белән якын элемтәдә була. ТАССР дәүләт архивы, 199 ф., 1 тасв., 1211 эш, 190—192 кәгазьләр, 2065 эш, 31 кәгазь.

[2] Мәскәүдәге Л. Н. Толстой музей-йорты архивы, 302 ф., 3 тасв., 1108 сакл. бер.

[3] ТАССР дәүләт архивы, 199 ф., 1 тасв., 2293 эш, 48 кәгазь.

цион-демократия партиясенең Казан секциясе җитәкчесе чыгыш ясый. Шуларның берсе — Бабушкин үзенең сүзен панисламизм һәм пантюркизмны байрак итеп алган «Мөселман иттифакы» партиясен мактап башлый. Иттифакчыларны ул, кадетлар шикелле үк, аерым сыйныфлардан югары торучы партия дип күрсәтергә тырыша. Аның фикеренчә, социал-демократлар, имеш, бары тик эшчеләр интересларын, ә эсерлар исә крестьян мәнфәгатьләрен генә кайгырта. Шуңа күрә, дип нәтиҗә ясый оратор, «мөселманнар тик кадетлар белән генә килешә ала» («Казанский вечер», 1907 ел, 15 январь саны). Кичәдә иттифакчыларның җитәкчеләре Алкин, Акчурин, Апанаевлар да чыгыш ясый. Ә инде большевиклар вәкиле Г. Сәйфетдинов сүз алгач, демократия өчен «җан атучы» кадетлар аның авызын томаларга ашыга. Үзен халык азатлыгы партиясе дип атап йөртүче кадетларның органы «Казанский вечер» бу хакта бер җөмлә язу белән чикләнә. «Г. Сәйфетдинов татарча сөйли башлый, ләкин председатель тарафыннан туктатылып, эстрададан залга төшә» (1907 ел, 16 январь саны).

«Казанский вечер» газетасы большевиклар белән даими рәвештә көрәшеп килә. Аның редакторы һәм нашире Н. Гусев еш кына большевикларга каршы рухта язылган мәкаләләр урнаштыра, Бичура атлы бераүнең халык көрәшчеләренә яла ягa торган шапшак язмаларын бастыра (мәсәлән, 1907 ел, 30 январь саны). Рус кадетлары авазына «Казан мөхбире» кебек татар буржуаз газета органнары кушыла. 1907 елның 21 сентябрь санындагы баш мәкаләдә бу газета Дәүләт думасына «иң лаеклы», бөтен милләт исеменнән сөйләрлек кешеләрне сайларга өнди. Газета партиялелекне гомумән инкарь иткән булып, аны уртак эшкә комачаулык итә, гади һәм кечкенә таләпләрне дә эшкә ашырырга ирек бирми торган бер нәрсә, дип ышандырырга тырыша. Татар буржуаз теоретикларының дөньяны революцион үзгәртеп коруны инкарь иткән мондый чыгышлары беренче чиратта большевикларга каршы юнәлдерелгән иде. Халык революцион идеяләрне кабул итәрлек дәрәҗәгә үсеп җитмәгән дигән дәлилне алга сөрүләре белән, татар буржуасы вәкилләре буржуаз катлауларның сыйнфый чикләнгәнлеген, аларның фикер гариплеген бөтен халыкка аудармакчы, халык интереслары өчен көрәшне мөселман мәктәпләренә ярым-йорты реформа ясау кебек чаралар белән чикләмәкче булдылар. Г. Тукай, Ф. Әмирхан исә — партиясезлек, сыйныфлардан өстенлек лозунглары артына яшеренеп, халыкны милли һәм дини нигездә берләшергә чакыручыларның чын йөзләрен аяусыз фаш иттеләр.

Кадетларның матбугат органнары «объектив» күренергә теләп, кайчак үзләренең тар максатларына сыешмый һәм алар теләгәннән киңрәк иҗтимагый яңгыраш ала торган хәбәрләр дә бастыралар, ягъни массаларны дулкынландыра торган үткен мәсьәләләргә кагылып, тозны «артыграк салып» җибәрәләр. «Казанский вечер» газетасында, мәсәлән, татар революционерларының яшерен типографиясе, учительская школа укучылары Моратов, Вәлиуллин һ. б. ларның социаль-демократик эчтәлекле прокламацияләр басуы (1907 ел, 30 май саны), Казанда хөкүмәт рөхсәтеннән башка шәкертләрнең съезд җыюлары (1907 ел, 17 май) турындагы хәбәрләр игътибарга лаек. Бу җәһәттән, «Казанский вечер» газетасының Дәүләт думасында уку-укыту мәсьәләләре буенча барган бәхәсләр турындагы материаллары да кызыклы. 1907 елның 8 май санында социал-демократ Мәхмүдов чыгышының язмасы бирелә. Россиядә хөкем сөрүче бюрократияне гаепләп, ул шундый саннар китерә: «...Закавказьеда полиция асрау өчен дәүләт 5 миллион сум, ә халык мәгарифе ихтыяҗларына 114 мең сум акча тота... Җирле тәрмәләрне карауга, этап повинностена ел саен 102646 сум, ә халык мәгарифенә 114 мең сум сарыф итә». Берничә ел мәктәптә укытучы булып эшләгән Вознесенский фамилияле бераү хөкүмәткә шундый ук гаеп ташлый. Мәктәпләрдә тарих урынына монастырьлар тарихы укытыла, алардан Некрасов кебек иң яхшы рус язучылары куыла, ди ул һәм болай дәвам иттерә: «хөкүмәт мәктәпләрдә укытучылардан бигрәк жандармнарны күрергә тели... Җирле халыкның нәфрәтен уятып, ирексездән «руслаштыру»ны гамәлгә ашыручы рус укытучысының хәлен күз алдына китерегез. Без укытучылар түгел, мәгарифне алга әйдәүчеләр түгел,— ә газаплаучылар, балаларның күңелен гарипләндерүчеләр...» (шунда ук).

Менә шушындый кызу атмосфера, туп-туры патшаның үзенә, аның карагруһчыларына каршы юнәлдерелгән нәфрәтле тәнкыйть ачыктан-ачык гауга китереп чыгара. Бу хакта газета болай дип хәбәр итә: «К. Хәсәнов (халык социалисты) Дәүләт думасын Уфа губернасындагы русча башкорт мәктәпләре хәле белән таныштырырга

тырышты. Ораторның чыгышы вакытында... Пуришкевич, Келеповский һәм Сазоновичлар шау-шу оештырдылар, шуның аркасында утырыш ябылды»,— ди (шунда ук).

Биредә К. Г. Хәсәнов хакында бер-ике сүз әйтеп үтәргә кирәк. Ул профессиясе буенча укытучы, трудовиклар партиясендә торган. Икенче Дәүләт думасы эшен игътибар белән күзәтеп барган В. И. Ленин аның 1907 ел, 16 май утырышындагы чыгышын билгеләп үтә. «Депутат Хәсәнов (Уфа губ.) башкортлар исеменнән хөкүмәтнең 2 миллион дисәтинә җирне талап алуын искә төшерә һәм бу җирләрне «кире тартып алуны» таләп итә». Суллар аның бу сүзләренә кул чаба, ә уңнар — Пуришкевич һәм К°, урындыкларыннан сикереп торып, йодрыкларын төйнәп, Төркиягә китегез, дип кычкыра-кычкыра ораторга ташланалар.

В. И. Ленин Думада депутат Б. Каратаевның да (Урал өлкәсе) чыгышын язып ала. Каратаев казах хезмәт ияләрен үз җирләреннән кысрыклау хакында сөйли.

Менә шул чакта Г. Тукайның җавабы бөтен илгә яңгырый — эчтәлеге белән дә, формасы белән дә камил шигыре «Китмибез» басылып чыга: «Иң бөек максат безем — хөр мәмләкәт, хөр Русия!» Б. Каратаевка килгәндә, Г. Тукай аның белән шәхси таныш була. Нәкъ менә Уральск матбугатында «Казах халкының рус халкына хаты» беренче тапкыр дөнья күрә, соңыннан аны большевистик «Урал» газетасы кабат баса, һәм ул бөтен Россиягә диярлек тарала.

Г. Тукайның уклары патшага һәм аның иярченнәренә юнәлдерелә, аларның халыкка каршы политикасын нәфрәт белән фаш итә. Шушы революцион адымында аның пролетар революционерлар белән бердәмлеге, бөтенроссия шагыйре буларак колачы чагыла.

Кайда да булса бүтән урында түгел, ә император сараендагы киңәшмәдә Павлов дигән бераү, беренче чиратта крестьяннарны күздә тотып, болай ди: «Грамоталы яки хәтта аз-маз укый белүчеләрне дә рухи яктан бозылган, хак юлдан яздырылган кешеләр итеп санарга кирәк... Болар инде кибәк». «Инородецлар» турында князь Нарышкин: «Минем фикеремчә, аларны андый хокуктан (сүз Думага сайлау турында бара) мәхрүм итәргә кирәк. Бу элемент тулысынча ышанычсыз һәм шуңа күрә киләчәк Дума өчен зарарлы»[1]. Патша моңа «Ризалашам» дип язып куя.

Радищевтан башлап, Россиянең иң алдынгы кешеләре менә шул явызлыкларга каршы күтәреләләр. Алардан эстафетаны кабул итеп алган Г. Тукай халык өчен, хезмәт кешеләренең җирдәге яшәү хокукы өчен көрәшә. Тикшеренүче П. А. Зайончковский царизмның һәм великодержавный милләтчелекнең руслаштыру политикасы XIX йөзнең 80—90 нчы елларыннан (татарларга карата исә 60 нчы еллардан дип әйтергә мөмкин — Р. Н.) башлап, «аеруча тыелгысыз сугышчан формалар ала», «бөек рус рәвешенә җавап бирмәгән һәр нәрсә эзәрлекләнә; немецлар, поляклар, финнәр, еврейләр, мөселманнар килешүгә һәм күмәк хезмәткә бернинди шанс калдырмыйча Россиянең дошманнары итеп игълан ителәләр», дип язуы белән хаклы иде[2].

Россиянең эшчеләр сыйныфы, большевиклар партиясе карагруһчылыкка каршы көрәшне җитәкләүчеләр булды. Алар белән янәшәдә, аларның куәтле йогынтысы астында изелгән халыкларның иң алдынгы вәкилләре үз эшчәнлекләрен башлап җибәрделәр.

Тукай әнә шуларның берсе иде.

---

[1] Цитаталар М. К. Касимовның «Егерме өч баскыч түбән табан» китабыннан алынды. М., «Мысль», 1978, 117 бит.

[2] Зайончковский П. А. XIX гасыр ахырында Россия самодержавиесе. М., «Мысль», 1970, 117 бит.

# БАЛАЧАК ИСТӘЛЕГЕ

Казан өендәге[1] сәке өстендә ашап утырабыз. Вакыт кичкырын. Шул чакта Сәгыйть абый Рәмиев килеп керде. Әтием:

— Бүген бик соңга калып кайттың, әйдә, ашарга утыр,— дип әйтүгә ул:

— Рәхмәт, минем ашыйсым килми. Габдулла Тукаев белән гостиницада без ашадык та, эчтек тә,— дип җавап кайтарды.

Әтием белән Сәгыйть абый арасындагы сүзләрне бик кызыксынып тыңлап утыра торгач, мин шуны аңладым: без, балалар, бергә кушылып җырлый торган «Туган тел» җырын язган Габдулла Тукай исемле кеше Казаннан Астраханьга килгән, хәзер ниндидер мөсафирханәдә яши икән.

Тукайның мөсафирханәдә яшәвен ишеткәч, әтием:

— Ник син аны туп-туры безгә алып килмәдең? Астрахань татарларының өендә шундый кешегә урын табылмас дип уйладыңмы әллә? — дип, Сәгыйть абыйны бераз шелтәләп алды.

Сәгыйть абый акланырга теләп булса кирәк:

— Үзегез уйлап карагыз, Давыт ага! Ничек итеп сездән рөхсәт сорамыйча-нитмичә кунак алып кайтыйм икән? Мин бит сезнең өйдә үзем дә кунак. Икенче ел инде чын мәгънәсендә кунак булып яшим! Кешедә оят дигән нәрсә булырга тиеш бит! — диде.

Әти кулын гына селтәде:

— Ташла әле ул сүзләреңне, Сәгыйтьҗан! Бу өйдә син чит кеше дә, кунак та түгел. Син үз кеше, гаиләбез әгъзасы! Сиңа сүзем шул: Габдулла әфәндене әллә нинди чит кешеләр арасында тилмертмә, өйгә алып кайт! Теләсә, синең бүлмәдә бергәләп яшәрсез, яки, әнә, чарлакта бик әйбәт ике бүлмә буш тора. Теләсә, шунда торсын. Үзең беләсең, минем юлдаш[2] аш-суга оста. Җаны теләгәнен пешереп алдына куяр. Кирәк булса, (әтием бармагы белән миңа күрсәтте) кызыбыз даладагы казакълардан һәр көнне кымыз алып кайтыр.

Ул вакыттагы сөйләшү әнә шулайрак хәтердә калган.

Әтинең хөр фикерле кешеләр белән аралашуы юкка түгел, билгеле. Ул бигрәк тә Н. Нариманов белән танышканнан соң драма түгәрәге оештыруда, әдәби-музыкаль кичәләр үткәрүдә, спектакльләр куюда актив катнаша иде. Хәтта әнигә Астрахань хатын-кызлары арасында беренче булып, сәхнәгә чыгарга да юл ачты ул. Ел саен «Тәрҗеман», «Йолдыз» газеталарын, «Шура», «Аң » журналларын алдырып укый иде.

Тукайның мөсафирханәдән безнең өйгә кайчан күчеп килгәнен хәтерләмим. Ул чакта әле мин сигез яшьтә генә идем. Шулай да, кояш көч алып кыздыра башламаган вакыт булгандыр дип уйлыйм, чөнки аның өстендә күгелҗем зәңгәр шинельме, пальтомы сыман бер нәрсә, башында, кашына чаклы басып кигән фуражка иде. Габдулла Тукай чарлактагы ике бүлмәне яратса да, анда торырга теләмәде. Сәгыйть абый янына урнашты. Бүген, бик күп еллар узганнан соң, мин Тукайның бездә кунак булган көннәрен бер-бер артлы тасвир итә алмыйм, әлбәттә. Ул көннәрнең аерым күренешләре хәзер күз алдымда өзек-өзек кенә булып җанланалар. Менә шул күренешләрнең берсе:

«Идел» газетасы редакциясенең ял көне, ягъни җомга көн булгандыр дип уйлыйм, чөнки Сәгыйть абый иртәнге чәйдән соң эшкә китмәде. Ул китмәгәч, Тукай абый да өйдән чыкмады. Икесе дә залда утырып калдылар. Мин, әниләр бүлмәсенең ишек пәрдәсе арасыннан борынымны тыгып: «Сәгыйть абый, гадәтенчә, трюмо алдына басып, шигырьләрен укымасмы, Тукай абый да аңа кушылмасмы икән?» — дигән өмет белән карап торам. Алар үзара сөйләшүләрен дәвам итәләр. Күпмедер вакыт узды. Ә мин һаман ишек төбендә, пәрдә арасында...

---

[1] Казан өе — Астраханьда аш пешерә торган бүлмәне яки өйне «казан өе» дип атыйлар. Русчадан — кухня.
[2] Әти әниемә, исеме белән әйтмичә, «юлдаш» дип эндәшә иде.

Ниһаять Сәгыйть абый урыныннан кузгалды, көзге алдына килеп басты. Болай да кабарып торган куе, озын чәчләрен куллары белән тагын да кабарта төшеп, уң аягы белән алгарак басты да «Таң вакыты»н тантаналы тавыш белән сөйли башлады. Мин ул вакытта Сәгыйть абыйның күп шигырьләрен үзеннән ишетеп ятлаган идем. Аның һәрбер хәрәкәте матур, тавышы көр, ягымлы булып тоела иде миңа. Инде Тукай абый да үз шигырьләрен сөйли башлар дип, сабырсызлык белән көтсәм дә, ул утырган урыныннан кузгалмады, фәкать:

— Артист син, Сәгыйтҗан, артист! — дию белән генә чикләнде. Аннары, бераз уйланып торганнан соң, дусларча елмаеп дәвам итте:

— Сине сәхнәдә карчыклар ролен уйный диләр. Имеш, син, сәхнәгә уң аягың белән аксап кереп, сул аягың белән аксап чыгып китәсең икән. Шулаймы? — диде һәм бик рәхәтләнеп көлде. Сәгыйть абый да аңа кушылып көлеп җибәрде:

— Сиңа бу турыда да сөйләп өлгерделәрмени инде?!

— Сөйләмичә! Кызык ич! Сәгыйть аксак карчыклар ролен уйнаганда кайсы аягы аксаганын оныта икән!

Алар шулай көлешә-көлешә залдан чыгып, Сәгыйть абый бүлмәсенә кереп киттеләр.

Менә тагын бер күренеш: безнең өйдәге зал. Идәнгә келәм җәелгән. Келәм өстенә әнинәм белән Тукай абый утырганнар. Аларның алдында минем төрле төскә буялган ашыкларым[1] сибелеп ята. Әнинәм Тукай абыйны «Әлчә-дахан» уенына өйрәтә.

— Ашыкның менә бу тишекле ягына «чек» диләр, ә менә бу кабарыбрак торган ягына «бек» диләр. Инде менә бу тар, кыйгачланып уелган ягына «әлчә» дип, ә шундый ук тар, ләкин тигез ягын «дахан» дип әйтәләр...

Тукай абый әнинәмнең сүзләрен бик дикъкать белән тыңлый. Кулындагы ашыкның дүрт ягын әйләндереп «бек, чек, әлчә, дахан» — дип кабатлый.

Бу уен, бер урында гына утырып уйнаганы өчендер, Тукай абыйга кызыксыз күренде ахрысы. Әнинәгә карап:

— Әйдә, һаҗәр ханым, ишегалдына чыгып, шунда рәхәтләнеп уйныйк әле! — дип, келәм өстендәге ашыкларны кесәсенә тыкты да, миңа:

— Ә син, кыз малай, ашыкларыңны тартмасы белән алып чык! — диде.

Мин ишегалдына чыкканда ул, уен өчен кирәк булган сызыкларны җиргә сызып, кесәсендәге ашыкларны тиешле урынга тезеп куйган иде инде. Мине күргәч, кулымнан тартманы алып, ашыклар арасыннан үзенә сага эзли башлады. Минем ике сагам бар иде. Тукай абый аларның икесен ике кулына алып, кайсы яхшырак икән дип, авырлыкларын үлчәгәндәй сынап, караштыргалап торды, җирдәге ашыкларга тезәп бер-бер артлы атып та карады. Ниһаять, кызылга буялганын сайлап алды. Бусы чыннан да авыррак та, ныграк та иде.

Уен озакка сузылды. Ара-тирә әнинәмнең:

— Сагаңны сызыктан бер адым алга чыгып аттың бит! Алай ярамый! — дигән сүзе, янса: — Бик хәрәмләшәсең син, Габдулла әфәнде! Алай булса мин уйнамыйм! — дигән тавышы ишетелеп китә иде.

Тукай абый моңа каршы рәхәтләнеп көлә дә:

— Аның кызыгы да шунда! — дип кенә җавап кайтара иде.

Әтием бер көнне Тукай, Сәгыйть һәм туганнан-туганы Вәлит[2] абыйлар белән бөтен гаиләбезне, моторлы көймәгә утыртып, пикникка алып чыкты.

Көн матур, җылы. Аудармa елгасы иркенләп, тулып ага. Зурлар үзара сөйләшәләр, көлешәләр. Әнинәм ара-тирә кулына кыңгыраулы Саратов гармунын алып, уйнап җибәрә. Сәгыйть абый белән Тукай абый гармунга кушылып җырлыйлар. Шул вакытта Тукай абыйның йомшак матур тавыш белән җырлаган бер җыры хәтеремдә калган. Моның сәбәбе, бәлки, җырдагы сүзләрнең мәгънәсе миңа аңлашылмаганга күрәдер. Җырның сүзләре болай иде:

Башымдагы чабатамның сиксән сигез серкәсе;
Бу дөньяда шөһрәт алды Бадигъ мәзин күркәсе.

---

[1] Ашык — кучы.
[2] Вәлит Алиевның Габдулла Тукай турындагы истәлеге «Тукай турында замандашлары» (1960 ел) һәм «Тукай турында хатирәләр» (1976 ел) дигән җыентыкларда басылып чыкты.

Бу җырда мине иң аптыратканы нинди дер серкәле чабатаның Тукай абыйның башына менеп утыруы иде. Хәзер аның башында чабата юк ич! Ул хәзер сөлгене башына чалма кебек итеп урап куйган ич!

Әтием яр буендагы бер бакчада шашлык пешерергә әзерләнә башлады. Бу эшне ул үзе эшли, берәүгә дә тапшырмый. Яшь сарык итен бер күләмдә кисәкләп турый, тозлап, борычлап, суганлап, лимон, яки нар сыгынтысы белән бергә, шампурларга тезгәнчә бер-ике сәгатькә томалап «дәмләргә» — талдырырга куя. Шул арада Тукай абый белән әнннәм, бер читкәрәк китеп, тагын ашык уйный башладылар.

Әнннәм:

— Күреп торам ич! Бу ашыкны син бармагың белән төртеп, сызыкның ар ягына чыгардың — дип Тукай абыйга үпкәләгән була.

Сәгыйть абый кычкырып көлә:

— Син, һаҗәр ханым, киракмәгәнгә ачуланма. Аның бармагы якынлашу белән, ашыклар үзләреннән-үзләре сикерешә башлыйлар! — ди.

Мин ышанырга да, ышанмаска да белмим. Башта миңа да ашык сызык өстендә яткандай күренгән иде. Ләкин Сәгыйть абый кебек олы кеше әйткәч, Тукай абыйның бармакларында ашыкларны үзләренә тарта торган магнит кебек нинди дә булса бер көч бардыр, бәлки? «Әнә, өйдәге ике кайчының берсе инәне үзенә тартып ала, ә икенчесе тартып алмый»,— дип уйлап, мин шикләнеп тә куйдым.

Габдулла Тукайның Казанга кайтып китүенә байтак вакыт үткәннән соң, хат ташучы безгә, хәзергечә әйткәндә, бандероль китереп тапшырды. Ул көнне әтиемнең эштән кайтып бандерольне ачканын сабырсызлык белән көтеп алдык. Аның эчендә өч китап булып, аларның исеме «Мияубикә» иде. Боларның берсе — «Гайшә туташка» (миннән ике яшькә олы апам), икенчесенә — минем шуклыгымны искә алыптыр — «Кыз малайга», өченчесенә «Давыт улы Сөләйман егеткә» дип язылган. Китапның һәрбер бите мәче сурәте белән башлана иде. Соңыннан Сәгыйть абыйдан ишеткәнемчә, бу «Мияубикә»нең рәсемнәрен, Габдулла Тукай Калмык базары дигән авылда Шәһит Гайфиләрдә кунакта чагында Шәһит абый ясаган икән. Китаптагы рәсемнәрне күргәч үк, әнннәмнең дә:

— Менә бу песи Нурбиби[1] мәчесенең нәкъ үзгенәсе! — дигәне хәтеремдә.

Астраханьнан китәр алдыннан Тукайга багышланган кичә үткәрелүе, томан аша гына булса да, күңел түрендә тора. Ул көн спектакль куелдымы, әллә әдәби-музыкаль кичә булдымы? Кызганычка каршы, аны бик ачыклап әйтә алмыйм. Тик бу турыда уйлаган чакта Сәгыйть абыйның:

— Ишеттегезме? Зөлкарнәй: «Ни сәбәптән җир йөзендә тәңгә — мунча, җаңга — юк?!» диясе урынга: «Ни сәбәптән җир йөзендә җаңга — мунча, тәңгә — юк?!» — дип әйтте бит! — дигәне исемә төшә. Һәм кышкы театр залының уң кырыенда утырган Габдулла Тукай менә хәзер дә күз алдымда.

**ГӨЛСЕМ МӨХӘММӘДОВА.**

# ТУКАЙ ТРОИЦК ШӘҺӘРЕНДӘ

Габдулла Тукайның Троицк шәһәренә баруы турында сүз башлар алдыннан шагыйрьне кунакка чакырып Казанга махсус килгән Габдрахман хәзрәт хакында берничә сүз әйтеп китү кирәк булыр.

Кем ул Габдрахман хәзрәт, һәм муллаларны яратмаган Тукайга бу хәзрәтнең ни дәхеле бар?

Танылган драматург Әхмәт Таҗетдиновның бертуган абыйсы булган бу кешенең муллалыгы «динем өчен түгел, көнем өчен» генә булып, ул укымышлылыгы, әдәбият-

[1] Нурбиби — Шәһит Гайфиның тормыш иптәше.

ка бер тиклем якынлыгы белән фанатик муллалардан аерыла һәм бик кулкә астен тора.

Аннан соң Габдрахман Рахманкуловның Тукай турында кайгыртуы татар поэзиясенә булган олы мәхәббәтеннән булса кирәк. Шагыйрьнең авырганлыгын ишетүгә, ул Казанга килә һәм аның белән берничә тапкыр очрашып сөйләшә, чәйләп утыра. Менә шул очрашуларда ул Троицк кымызы сыйфатының Уфаныкына карaганда шифалырак, сихәтлерәк булуын исбатлап, шагыйрьне Троицкига барырга күндерә. Дөрес, ул Тукайны үзе белән алып кайта алмый, ләкин шагыйрь яз көне Троицк шәһәренә барырга вәгъдә бирә.

1912 елның 14 апрелендә дуслары шагыйрьне «Фультон» исемен йөрткән пароходка утыртып Самара шәһәренә озаталар. Аннан ул Уфага килә, бирeдән Петербургка, Петербургтан тагын Уфага, Уфадан Троицкига китә. Һәм Тукай 1912 елның май аенда Троицк шәһәренә, Г. Рахманкуловка килеп төшә.

Шагыйрьнең Троицк шәһәренә килү көннәре үзе язган хатлар белән дә раслана. 1912 елның 11 маенда «Ялт-йолт» журналы редакторы Әхмәт Урманчеевка Уфадан язган хатында ул «Шушы көннәрдә Троицкига китәсе булып торам» дип белдерә дә хат язу өчен аңа Габдрахман Рахманкулов адресын күрсәтә. Ә инде икенче көнне Петербургта чыга торган «Нур» газетасы хезмәткәре, журналист Кәбир Бәкергә 12 майда җибәргән хатында «Тиздән Троицкига китам» ди дә, аңа да шул ук адресны бирә.

Димәк, Тукай Троицкига 14—15 май тирәләрендә килгән булып чыга.

Ә менә «Ил» газетасының 1914 ел 2 апрель санында басылган М. Гафури истәлегендә Тукайның Петербургтан кире Уфага һәм Уфадан Троицкига китүе алданрак күрсәтелә. Ул истәлектә: «Г. Тукай Петербургтагы сәфәрендә унбиш көн чамасы йөреп, апрельнең 18 ләрендә тәкрар[1] Уфага кайтты» һәм «Бер һәфтә[2]гә якын торып, әүвәлдәге карары буенча, кымыз эчәр өчен Троицкига китте»[3],— диелә.

М. Гафури күрсәтүе буенча Г. Тукай Троицкига (18 апрель бер һәфтә) апрель ахырларында, май башларында килгән була.

Тукай хатларындагы һәм Гафури истәлегендәге саннар арасында аерма барлыкка килә. Минемчә, ул аерма хатларның да һәм истәлекнең дә төрле елларда каткат күчерелеп басылган чакларында көннәрнең кайберләре иске стильдә калдырылып, башкалары яңача бирелүеннән киләдер. Хатлардагы көннәр яңа стильдә алынган дип фараз итсәк, Гафури күрсәткән көнгә якынлашабыз. Дөрес, бирeдә дә өч-дүрт көнлек аерма кала. Аны шагыйрьнең башта бер һәфтәдән китам дип карар кылып та, берничә көнгә соңлап китү ихтималы белән дә аңлатып була.

Шагыйрь үзенең Троицк шәһәренә килүен истәлекләр рәвешендә язылган «Мәкаләи махсуса» исемле язмасының икенче кисәгендә түбәндәгечә сурәтли:

«Бер заман таң аткан, кояш күтәрелгән. Мине вагонда берәү уята. Поездда бер кеше дә калмаган. Буп-буш.

— Габдулла әфәнде Сезме?

— Мин.

— Мин Габдрахман мулладан, алырга килдем.

Чыгып, атка утырдым. Шәһәргә киттем. Габдрахман хәзрәткә барып кердем. Нәкъ аш вакыты. Аштан соң... гакыйбәт[4] авызга кымыз тидe. Мине кымыз өчен Уфага бару фикереннән кайтаручы вә андагы кымызның җәгълилеген[5] сөйләүче вә яз көне кымыз эчәргә үзенә чакырып вәгъдә алып китүче ушбу Габдрахман хәзрәт иде. Троицкида берничә көн[6] торгач, сахрага, шәһәрдән егерме биш чакрым җиргә киттем. Анда хәзрәт тарафыннан... Миңа махсус чатыр тегелде... Эштән чыккан мин

---

[1] Тәкрар — яңадан.
[2] Һәфтә — атна.
[3] 1914 елда «Ил»дә, 1941 елда «М. Гафури әсәрләре»ндә басылган истәлектән китерелгән бу сүзләр бирeдә 1960 елда «Тукай турында замандашлары» җыентыгында, ягъни өченче тапкыр басылган тексттан алынды.
[4] Гакыйбәт — ахырда.
[5] Җәгълилеген — ясалмалылыгын.
[6] Бирeдә «Габдулла Тукай» альбомының 130 нчы битендәге Г. Рахманкулов йорты төшерелгән фото астындагы текстка төзәтмә кертү сорала. Бу йортта Тукай «бер кич кенә кунып чыкмый», ә үзе язганча, берничә көн яши. Җәйләүдән шәһәргә кайтып йөргән көннәрендә дә шушы йортта тора.

бичара ахры бер рәхәткә, тынычлыкка барып егылдым... Әүвәл «бисмиллаһи» дип... чишенеп ташладым. Коры степь (дала) һавасы. Сөт, каймак, теләсәң коен, әле генә сауган саф кымыз. Бүген генә суйган ит. Бөтен нәрсә табигый, бөтен нәрсә алдаусыз».

Һәм язмасының ахырында шагыйрь үз сүзләренең дәреслеген исбатларга теләгәндәй, ант итү рәвешендә «Валлаһи» исеме белән бер шигырен дә өстәп куя:

**Валлаһи, и валлаһи, и валлаһи,**
**Бәхте барлар кырда җәйли, валлаһи!**

**Ак күмәч берлән ашарлык саф һава,**
**Җир яшел, кошлар да сайрый, валлаһи!**

Шагыйрь үзенең табигать кочагында яшәвенә шатланып бетә алмый. «Мәгариф» басмасының хуҗасы Гыйльметдин Шәрәфкә язган хатында ул: «...хәлем яхшы, казакъ бае шикелле, иткә тук, кымызга гарык... һәр тараф сахра. Авыруым, тагы яңалары башланмаса, бетә инде»— дип яза.

Г. Рахманкулов Тукайга һәрьяклап (дәвалану, ял итү һәм иҗат өчен) тулы шартлар тудырырга тырышкан. Аның чатырына кереп, борчып йөрүләр тыелган. Олы улының истәлеге буенча шагыйрь янына бары Габдрахманның энесе Әхмәт белән Вәли исемле Борһан авыл, башкортына гына теләсә кайсы вакытта, керү рөхсәт ителгән.

Троицк теле белән әйткәндә, «оста пешекчеләр» — «Җиде балалы Заһидә» кушаматлы абыстай белән аның Хәдичә исемле кызы Тукайны кадерле кунакларга гына пешерелә торган тәмле ашлар белән сыйлыйлар.

Шушы Хәдичә апаның улы ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, күренекле архитектор Р. Мортазин әнисенең сөйләгәннәрен исенә төшереп, шагыйрьнең аеруча куллама белән тозлыклы ит ашларын яратып ашаганын, кымызны баштарак дару эчкәндәй өнәмичәрәк, авырлык белән эчкәнен, ә инде күнегеп киткәннән соң көненә бер чирек, чирек ярым[1] эчә башлавын һәм күзгә күренеп тәс керә, тәзәлүгә таба барганын әйтә.

Чәйгә, ашка дәшкән урыннар күп булса да шагыйрь кунакка йөрүдән баш тарткан, табигать кочагында, тынычлыкта яшәүне артык күргән. Чакырылган җиргә барган тәкъдирдә дә сайлап кына, күңеленә хуш килгән кешеләргә генә барган.

Әйтик, ул җәйләүдән кайтып Хәкимҗан Бакировларда куна, шәһәрнең могътәбәр зыялылары булган Габдрахман Әхмәров белән Зариф Рахманкулов дачасына барып берничә көн торып кайта, мәшһүр җырчы Мирфәйзә Бабаҗанов йортында да кунак була. Г. Әхмәров һәм З. Рахманкуловлар дачасына баруыннан бик канәгать булып, ошатып кайтуы турында җәйләүгә кайткач аш пешерүче Хәдичә апага да сөйли. Ә инде Әхмәров кызларының «Туган тел», «Милли моңнар», «Эштән чыгарылган татар кызына» кебек үзенең шигырьләрен халык көйләренә салып җырлаулары Тукайга көчле тәэсир ясый.

Шагыйрь җәмәгать урыннарында да була. «Сәнаигъ нәфисәне тәрвиҗ итү җәмгыяте»[2] әгъзалары белән очраша һәм берничә тапкыр соңыннан галим буларак танылган Габдулла Шанасыйның туганы Газиз Ибраһимовның «Хезмәт» исеме белән аталган китап кибетендә була. Вакытында бу кибет мондагы бердәнбер мәдәният учагы булып саналган. Хәзерге Октябрь урамындагы 86 нчы йортның аскы катына урнашкан бу кибетнең бер почмагы «уку залы» вазифасын үтәгән, өстәл өстенә газета-журналлар һәм яңа чыккан китаплар куелган. Бу «уку залына» Троицкида укыган елларында еш кына М. Гафури да килеп йөргән, биредә Дәрдмәнд тә, С. Рәмиев тә, Ш. Бабич та, С. Кудаш та булганнар...

Кайбер истәлекләргә караганда, Г. Тукай асылда Г. Рахманкуловның йорт китапханәсеннән файдаланган булса кирәк. Әйтүләренә караганда ул бик бай булган һәм күпләрне кызыксындырган, үзенә тарткан. Бу китапханәдә үз вакытында Габдрахман

---

[1] Хәзерге үлчәү белән бер чирektә — өч литр.
[2] Нәфис сәнгатьне үстерү җәмгыяте.

Сагъди дә, үсмер елларында Галимҗан Ибраһимов та була. Олы әдипнең анасы Хәсәнә апа да, атасы Гыйрфан абзый да[1] ара-тирә монда килгәләп йөргәннәр һәм үзләре белән кечкенә Галимҗанны да алганнар.

Әнә шул рәвешчә, халкыбызның бөек шагыйре Троицкида өч ай чамасы яшәгәннән соң, Казанга кайтып китә. Үз сүзләре белән әйткәндә «...Шәһәр смрадыннан[2], завод агуыннан, бозык һавадан качып... арбадан пароходка, пароходтан поездга күчә-күчә эштән чыккан...» алҗыган, сәламәтлеге дә какшаган Тукай фәкать Троицкига килеп кенә рәхәтлеккә чума, җан тынычлыгы таба, хәтта сәламәтлеге дә яхшыргандай була. Троицк шәһәренә килүеннән бик тә мәмнүн[3] булуы турында «Мәкаләи махсуса» язмасының беренче кисәгендә: «Троицкида эш шәп... Терелермен кебек. Терелсәм, әллә нәрсәләр язармын әле»,— дигән сүзләр бар.

Габдрахман Рахманкулов җәйләвеннән Тукай күңеле күтәрелеп, шатланып, тагы да килергә вәгъдә биреп китсә дә, Троицкига бүтән бара алмый.

**ШӘРИФ РАХМАНКУЛОВ.**

# ТАПШЫРЫЛМЫЙ КАЛГАН БҮЛӘК

Габдулла Тукайның шәхси китапханәсе булганмы? Булган, әлбәттә. Һәр каләм иясе кебек, шагыйрь үзенең басылып чыккан әсәрләрен җыеп барган, шуның өстенә аңа дуслары, каләмдәшләре, замандашлары үз китапларын бүләк итә торганнар. Профессор И. Нуруллин мәкаләләрендә Тукайның шәхси китапханәсендә сакланган шундый ике китап күрсәтелә. Габдулла Тукай күренекле демократик татар наширләре Әхмәтгәрәй Хәсәни, бертуган Әхмәдуллиннар, бертуган Шәрәфләр белән дус булган, алар шагыйрьгә үзләре бастырган китапларны бүләк итеп килгәннәр...

Тукайның шәхси китапханәсе, мөгаен, зур булмагандыр. Бөек шагыйрьнең тору өчен үз почмагы юк, бер номердан икенче номерга күчеп, миһманханәдә яшәгән кешенең бар байлыгы аның чемоданнарына сыярга тиеш. Димәк, Тукай иң яраткан, иң кирәк тапкан китапларын гына үзе белән йөртә, саклый алган. Менә шушы кечкенә генә шәхси китапханәсе сакланып калса, һич югында анда нинди китаплар булуы гына ачыкланса да, шагыйрь турында мәгълүматыбыз ни дәрәҗәдә киңәер иде!

Тукай вафат булгач, аның әйберләрен чыгарып ташламаганнар бит, кайсыдыр якыны әдипнең әйберләре белән китапларын да хөрмәтләп саклаган булырга тиеш. И. Нуруллинның эзләнүләреннән күренгәнчә, тора-бара ул китаплар төрле кулларга таралганнар. Димәк, шулай да алар тулысынча юкка чыкмаганнар!

Әлегәчә табылган ике китапка бүген Тукай исеме белән бәйләнгән тагын бер китапны өсти алабыз. Ул — Казан дәүләт университетының Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә «Т-958» шифры белән саклanучы, бөек рус язучысы Л. Н. Толстойның 1913 елда Казанда басылган «Хаҗи Морат» дигән тарихи хикәясе; басманың үзендәгечә әйткәндә, «Кавказ таулары арасында шәех Шамилнең Русия хөкүмәте илә сугышуы тарихыннан бер әсарлы хикәядер». Ул атаклы татар китап осталары Әхмәдуллиннарның «Өмид» типографиясендә басылган. Китапның нашире — Оренбургтагы «Белек» көтепханәсе. Демократик юнәлешле, уку-укыту буенча дөньяви дәреслекләр бастырган, татар һәм рус әдәбиятларын пропагандалауда шактый эшләр башкарган бу кооператив нәшрияты оештыручыларның берсе Мәхмүт Галәү (Мәрҗани) булуы мәгълүм. Толстойның «Хаҗи Морат»ын да татар теленә ул тәрҗемә иткән.

---

[1] Г. Ибраһимовның әтисе Троицк шәһәрендә тумаса да, шунда Троицк кызы Хәсәнәгә өйләнеп, гаилә тормышы корып җибәрә һәм озак еллар Г. Рахманкулов мәдрәсәсендә укыта.
[2] Смрад — сасылык, сөрем, төтен.
[3] Мәмнүн — бик тә шат, бик тә риза.

Китапның титул битенә «Татар социал шуралар җөмһүрияте мәркәз шәрык көтепханәсе музее» дигән мөһер басылган. Бу аның әлеге «Мәркәз шәрык китапханәсе»ннән Татарстан дәүләт китапханәсе аша, соңгысының китап фонды белән бергә, университет китапханәсенә килеп керүен күрсәтә.

Титул бите башында матур каллиграфия белән: «Мәдрәсәи Мөхәммәдия шәкертләре тарафыннан бөек шагыйребез Тукаевка ядкяр. $19\frac{4}{4}13$»,— дип язылган. Датага игътибар итик: 1913 елның дүртенче апреле. Ә Тукай икенче апрельдә кичке 8 сәгать 15 минутта дөнья куйган. Димәк, бу китап шагыйрь кулына барып җитәргә өлгермәгән.

Инде Тукайның вафаты бөтен Казанга гына мәгълүм булмыйча, ерак авылларга барып ишетелгән вакытта — дүртенче апрель көнне аңа шундый багышлама язу аңлашылмый. Масьәлә монда башкачарак булырга тиеш. Иң соң дигәндә, мөгаен, икенче апрель көнне «Мөхәммәдия» шәкертләре, сөекле шагыйрьләренең хәлен белү өчен, Клячкин больницасына барырга сүз куешалар һәм, шунда аңа бүләк итү максаты белән, әлеге китапны табып, махсус багышлама язалар. Язылу датасы итеп үзләре барачак көнне күрсәтәләр...

Бүләк итәлергә тиешле китапның тагын бер үзенчәлеге игътибарны үзенә тарта. «Хаҗи Морат»ның әлеге нөсхәсе калын, шома, яхшы кәгазьгә басылган. Бу басманың китапханәләрдә сакланган башка даналәре бөтенләй икенче, соргылт, юка газета кәгазенә басылган. Шушы фактны, шәкертләр үзләре басмаханәгә килеп, әсәрне яхшы кәгазьгә бастырып алганнардыр, дип кенә аңлатырга мөмкин. Шуны да искә алырга кирәк, бу китап ул вакытта әле сатуга чыгып өлгермәгән була. Цензор документлары буенча аны дөньяга чыгару өчен рөхсәт апрель ахырында гына бирелә. Әлеге фактның икенче ягы да бар. Шәкертләр Тукайга бүләк итәргә теләсә нинди әсәрне түгел, ә Л. Н. Толстойның әле дөньяга чыгып та җитмәгән китабын сайлаганнар. Бу инде Тукайның бөек рус әдибенә булган мәхәббәтен белеп, шуны искә алып эшләнгән. Яраткан әдибенең иң гүзәл әсәрләреннән берсен бүләк итү шагыйрь өчен сөенеч буласын шәкертләр яхшы белгәннәр.

Шәкертләр багышламасында Тукай «Бөек шагыйребез» дип аталган. Моңа чаклы шагыйрьгә әнә шундый зур, дөрес бәя бирелгәне булдымы икән әле?! Тукайны татар шәкертләре бөек шагыйрь буларак та, шәкертләрнең яклаучысы буларак та хөрмәт иткәннәр, яратканнар. Татар мәдәниятенә күп зыялылар биргән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләренең шушы ядкярне әзерләве турында, бәлки, ишетеп белүчеләр дә табылыр әле. Тукайның шәхси китапханәсендәге аерым китапларның саклануы бу өлкәдә эзләнүләр яңа уңышларга китерер дигән өметне дә көчәйтә.

ӘБРАР КӘРИМУЛЛИН,
филология фәннәре докторы.

Әнүр Исмәгыйлев

# ЖАНР АНЫКЛЫГЫ ҺӘМ ТОРМЫШ ДӨРЕСЛЕГЕ

Сәнгать тарихында һәм теориясендә төрле бәхәсләр уяткан күренешләр аз түгел. Без шуларның берсенә — драматургның иҗади уй-нияте һәм тормыш материалына мөнәсәбәте белән турыдан-туры бәйләнгән жанр төшенчәсенә тукталырга уйлыйбыз.

«Зифа» комедиясе беренче мәртәбә сәхнәгә куелгач, аның турында сүз күп булды. Берәүләр аны драма дип кабул иттеләр һәм комедияле ягын тәнкыйтьләделәр, ә икенче берәүләр комедия ягыннан тикшереп, әсәрнең драматик ягын кире кактылар. «Зифа» турындагы тәнкыйть мәкаләләре дә, әсәрнең үзе кебек үк, каршылыклы иде. Ләкин бүген «Зифа» турында элек әйтелгәннәр раслауга, төзәтелүгә яки кире кагуга да мохтаҗ түгел. Алар үз заманында ук нигездә дөрес һәм урынлы иде. Бу әсәрдә ике жанр — драма белән комедия бергә үрелгән һәм шул ук вакытта әсәрдә ике жанр хасиятләре бер-берләрен кискен кире кагып яшиләр. Комедия билгеләре драма эчендә эреп бетә алмыйча, су өстендәге май таплары кебек, драматик күзгедә аерым-ачык булып күренеп торалар. Аның комедия өлешен әнә шул драмасы яктылыгына куеп, ә драма өлешен комедиясе яктылыгында карарга кирәк, ниһаять, аларның берсен икенчесеннән аерып алырга кирәк.

Сүз дә юк, «Зифа» — талантлы каләм белән язылган, ләкин ике жанрлы булып туган әсәр. Комедиялелек белән драмалылык авторның сурәтле фикерендә үк бер-берләре эчендә яралганнар, әсәрдә сурәтләнгән тормыш кисәгенең эчендә үк бергә береккәннәр. Ягъни комедиялелек белән драмалылык — әсәрдә сурәтләнгән бер үк тормыш хәленең аерылгысыз ике ягы.

Әлбәттә, тормыш комедия-трагедияләргә бүленмәгән. Тормышны иҗади чагылдыручы драматургия әсәрләре генә төрле жанрларга карый. Драматургик жанрларның һәркайсысы тормышка үз күзлеге аша карый белә, вакыйганың үз хокукына буйсынган сыйфатын гына сайлап алып, сурәтле чагылдыра ала. Тормыш күпкырлы, күп сыйфатлы. Драматургия тормыш каршылыгының бер-берсен соң дәрәҗәдә кире кагучы очракларын сайлап алып сурәтләргә ярата. Ул тормыш вакыйгасының сул ягын хурласа да, уң ягын мактаса да — укучы теләкләренә хуш килгән ягын хуплау ниятеннән хурлый һәм мактый. Чөнки иҗади вакыйга — мөнәсәбәтле тормыш. Тормыш вакыйгасына мөнәсәбәтнең эчтәлеге жанрлылыкны билгели.

Туфан Миңнуллинның «Нигез ташлары»нда, мәсәлән, тормышның гадәти «тыныч» агышыннан зур булмаган бер вакыйга алынган. Ләкин драматург аны сул ягыннан күреп сурәтли. Сурәтләнгән вакыйгада кискен бәрелеш тә, авыз тутырып сөйләрлек комедия конфликты да, нык әшәке, тискәре характерлар да юк. Ләкин көндәлек тормышның сикәлтәләрсез агышында гадәтилектән тискәре якка тайпылыш бар һәм шул тайпылышның табигатендә комедиялелек ята. Әнә шул комедияле хәлне язучы драматургик формада чагылдырып күрсәтә белгән. Тормышның бу хәлендә кискен каршылык юк. Хәтта әсәр сурәтләнгән каршылыкны балаларны телеграмма суга-суга

авылга чакыртып кайтармыйча да хәл итеп булыр иде кебек. Чөнки әлеге тискәрелек ата куңелендә генә конфликт төсе алган, анда бутәннәр өчен авыз тутырып дәгъвалашырлык идея каршылыгы юк. Балалар өчен, мәсәлән, бу гадәти хәл булып кына күренә, һәм алар шул нигездә ата белән конфликтлашырга җыенмыйлар да. Авылдашың белән очрашкан исәнлек-саулык сорашу гадәтен оныту, борын чөю, үз тынычлыгыңны гына кайгыртып яшәү, җае чыкканда салгалап йөрү, җае чыкканда дәүләт малына кул сузу кебек хәлләрдә кайберәүләр өчен тавыш күтәрерлек начарлыклар да да күренми кебек, ә ата күңеле бутәннәр күнегә башлаган андый хәлләрне гафу итә алмый. Аның өчен — гаделлек, кешеләр белән матур мөгамәлә генә гадәти хәл. Үзе ианып яшәгән гадәтилектән читкә тайпылуларны ул аяусыз фаш итә. «Нигез ташлары» әсәрендәге комедиялелек әнә шунда ята. Атадан кала бутәннәр өчен бу әсәрдә конфликт та, комедиялелек тә юк. Әсәрнең бутән персонажлары ата белән малайлары арасында туган чатак хәлгә турыдан-туры мөнәсәбәттә яшәп, үз характерларын тулы ача алмаганнар.

Туфан Миңнуллин ыгы-зыгылы тормыш «ваклыкларын» да иҗтимагый мөһим сыйфатлары белән әйләндереп яктырта белә. «Нигез ташлары» комедиясендә дә драматург көндәлек тормышта еш очрый торган, беренче карашка күнегелә башлаган вак-төяк мәсьәләләрнең укучыга иҗтимагый әһәмиятле якларын ачып күрсәтә алган, уйландырырлык итеп шул мәсьәләләргә укучының игътибарын юнәлтә белгән. Бәлки тормышның бу кисәген драматургик иҗади формада түгел, ә проза әсәрендә сурәтләргә кирәк булгандыр? Хикәяләү рәвешендә сурәтләгәндә, әлеге тормыш вакыйгасының эчке табигатенә хас психологик нечкәлекләренә тирәнрәк үтеп керергә мөмкинлек арта төшмәс идеме? Ләкин язучы бу вакыйгада драматургик форманы күтәрә алырлык конфликт күргән һәм карап торуга кечкенә генә хәлне зур осталык белән сурәтләп бирә алган.

Эчтәлеген сөйли башласаң, ул вакыйгалар хәтта драматургик хәлгә охшамаган да кебек. Алар искиткеч гади, искиткеч гадәти һәм тормышчан, шул ук вакытта чын, иҗади матур, ышандыра торган итеп сурәтләнгәннәр. Моның өстенә комедия җор һәм тапкыр гади тел белән язылган. Ләкин җор тел генә әсәрнең жанрын комедия итә алмый. «Нигез ташлары»нда гади вакыйгалар нигезендәге идея-тематик үзәк комедияле, әсәрнең пафосы комедияле.

Аерым персонажлардан эзли башласаң, бәлки бу әсәрдә чын мәгънәсендәге тискәре характерны табуы да читен булыр. Дөрес, атаның өченче улы — склад мөдире булып эшли торганы — салгаларга ярата, өч курс укыгач, институтын да ташлаган, хатыны белән дә этле-мырлы тора, өстәвенә, караклык юлына да баскан. Ләкин әсәрдә әлеге тискәрелекләрнең берсе дә комедияле көлү аша фаш ителмәгәннәр, киресенчә, әсәрдә ул малай көлке булудан бигрәк мескен, мещан бәхетеннән тәм табып, шатлыксыз, кәефсез гомер кичерә торган бер мәхлук җан. Ата да, йомры сүзле шаян кеше булуына карамастан, комедия персонажы түгел. Әсәр Гарифулла картны шәп, акыллы, зирәк агай, гаделлек сакчысы итеп тәкъдим итә. Комедиялелек — уңай геройның тормыштагы тискәре күренешләрне, хирыс теләкләрне фаш итүендә, әсәргә йөкләнгән төп вазифаның характерында, холкында, табигатендә, иҗади проблемасында. Бу әсәр эчке рухы белән — комедия, идея-тематик эчтәлеге, күтәргән проблемасы һәм ул проблеманы хәл итү рәвеше белән — комедия. Комедиялелек гел авыз күтәреп көлү генә дигән сүз түгел, ул җитди тәнкыйть формасында да булырга мөмкин.

Тормышның һәр күренеш-вакыйгасы күпкырлы, күпсыйфатлы. Ә ул сыйфатлар әсәрдә мөнәсәбәт, ягъни идея аша гына ачылып яши алалар. Идея-тематик үзгә мәгънәләр чынбарлыкның эзлекле бер вакыйгасында табигый берләшкән булырга мөмкин. Ләкин аны түкми-чәчми күчерү драматургик жанрны тарката, драматургик иҗади форманы сүтә.

Тормышның үзендә аерылгысыз укмашып яшәгән мәгънәләр аларга кеше күзе төшкәч кенә үзенчәлекле төсмер алалар. Иҗат әнә шул мәгънәләрне гомумиләштерә, һәркайсына үзенчәлекле иҗади форма аша сурәтле чагылыш бирә. Юкса, әгәр комедия тормышның түкми-чәчми күчереп алынган бер кисәге булса, анда я дистәләгән әйбәт кешеләр арасында чуртым да кыра алмыйча каңгырып ялгыз тискәре мәхлук чуалып йөрер, я булмаса бер төркем әшәке бәндәләр арасында бер әйбәт

кеше адашып калыр иде. Беренче очракта язучы әлеге бер сыңар сантыйның комедиясен иҗат итә алмас, икенче очракта шул ук бер сыңар әйбәт кешенең драмасы табигый килеп чыкмас иде. Тормыш чынлыгын саклыйм дип, комедия үз жанр кысасына тормышны бөтен сыйфатлары берлегендә сыйдыра алмый.

Шушы күзлектән чыгып караганда, конфликтсызлык «теориясе» хөкем сөргән чорга туры килгән комедияләрнең язмышы тагы да ачыграк аңлашыла. Ул заманнарда иҗат ителгән кайсы гына комедияне кулга алма — аларның һәркайсысында унунбиш акыллы бәндә арасында бер «тискәре» киреләнеп йөри. Һәм ул әсәрләрнең барысында да акыллы башлар тискәреләнеп йөргән шул киребеткәнне үзләре кебек үк әйбәт кеше итү эше белән мәшгульләр. Теге «тискәре» киреләнеп йөри бирә, ә акыллы башлар аңа үгет-нәсихәт укый тора. «Тискәре» үз теләкләрен тормышка ашыру юлларын эзләр иде, көрәшер иде, теләкләренә каршы төшүчеләр белән конфликтка килеп бетәр иде... Ләкин, беренчедән, аның бүтәннәр белән якалашырлык төпле теләге юк: нәрсәгәдер киреләнгән дә — вәссәлам! Икенчедән, ул барыбер үзенең хаксыз икәнлеген белә. Дөресрәге, ул сыңар киребеткәннең дисталәгән әйбәт кешеләр арасында киреләнеп йөрүе ахырда ни белән бетәсен язучы үзе дә әйбәт сизә, тормышта алай булмаганын күреп тора, һәм «тискәре»не бүтәннәр белән низагка кертүдән, укучы теләкләре белән идея каршылыгына китерүдән үзе дә кача. Юкса, «комедия» языла алмыйча калачак. Чынлап уйлап карасаң, безнең чор комедия герое әле күптән түгел генә үзен чын күңеленнән хаклы дип санап, үз теләкләренә каршы төшүчеләр белән чын күңеленнән «хаклык» дәгъвалый башлады ул. Тискәре герой үз хаклыгына чын күңеленнән инанып, идеал белән көрәшә башлаганга күрә укучы аңардан көлә, аны фаш итә башлады. Комедия герое илленче елларның ахырына кадәр диярлек борынын да күрсәтергә базмыйча качып яткан икән ул. Ә төрле сәбәпләр аркасында вакыт-вакыт киреләнеп йөргән үз ишләребезне без комедия герое дип белеп, аларга үгет-нәсихәт укыганбыз, тәүфыйкка китереп йөргәнбез.

Юныс Әминевнең «Язылмаган законнар»ы белән Нәкый Исәнбәтнең «Зифа»сы — илленче елларда иҗат ителсә дә — ул заман драматургия кануннарыннан аерылырга өлгергән әсәрләр. Әлеге әсәрләрнең үз конфликтлары бар, һәм хәтта берәр генә дә түгел — икешәр: икесендә дә ир белән хатын һәм тискәреләр белән уңайлар арасында.

Шулай да төп хикмәт — заман таләбендә. Ә таләптән эстетик нормага исә бер генә адым. Талантларны заман таләпләре тудыра, талантларны заман теориясе үз кысасы эчендә фикер йөртергә мәҗбүр итә. Тарихтан билгеле булганча, драматургиянең классицизм чоры Буало кагыйдәсенә сыешырга тырыша торгач, тормышчанлыкны корбан итүгә кадәр барып җитә. Россия җирлегендә туган «югары стиль», «түбән стиль» таләпләре заманын искә төшерик. Хәер, тарихта мондый мисаллар буа буарлык. Зур талант иясенең иҗаты да, аерым «теория»ләрнең тар кысасына сыеп бетәргә тырыша торгач, тормыш чынлыгыннан ераклаша башлап, әсәрнең жанр аныклыгын да таркауландырырга мәҗбүр итә.

«Зифа» комедиясе 20 нче елларда ук инде менә дигән сатирик әсәрләр иҗат иткән талантлы әдип каләме белән язылган. Ләкин, ничек кенә булмасын, «теория» таләбенә сыешырга тырышу әлеге әсәрдә дә үзен сиздерә — «Зифа» жанрлыгы ягыннан да драма кысасы эчендә язылган комедия булып туа, автор әсәрнең фаш итү пафосын Зифаның үрнәклегә яктылыгында ачып, комедияне «теория» алдында «акларга» тырыша. Үз заманында бу әсәр турында сүз күп булуы да, нигездә, әнә шуның белән бәйле. Комедия турында сүз әйтергә сусаган тәнкыйть өчен «Зифа» беренче карлыгач булып тоелды.

«Язылмаган законнар»ны автор үзе «драма» дип тамгалап дөньяга чыгарды. «Зифа» белән чагыштырганда, бераз йомшаграк эшләнгәнгәдерме, бүтән берәр сәбәп аркасындамы, ул «Зифа» кебек үк күп сөйләшүләргә тап була алмый калды.

Бу әсәрләрнең икесе дә үз вакыты өчен җиңү иде. Алар тормыш кисәгенең бормалы чагын, кискен каршылыкта яшәгән турларын тотып алганнар. Вакыйгаларның көндәлек тормыш-көнкүрештән алынып сурәтләнгән булулары бу әсәрләрнең жанр рухларын трагедия-сатира түгел, ә бәлки драма-юмористик комедия генә итә ала.

Ләкин «Зифа»да тормыш вакыйгасының тискәре табигатен тирәнтен фаш итү урыны-урыны белән сатира дәрәҗәсенә үстерелә алган. Әсәрнең сатирик рухы Эсмеральда фатирында барган күренештә үзен аеруча нык сиздерә. Шул ук вакытта ике әсәрдә дә, тормыш чынлыгына тугрылыклы калырга теләп, сурәтләнгән вакыйгадагы диалектик бөтенлекне ике яклап та күрсәтергә омтылу бар. Бер үк тормыш хәле драматик һәм комедияле сыйфатлары аша сурәтле ачыла, нәтиҗәдә, бер үк әсәр ике жанрлы, ике проблемалы, ике конфликтлы булып туа. Алар бер-берсенә бөтенләй битараф проблема-конфликтлар түгел, бер үк тормыш вакыйгасының үзгә мөнәсәбәтләр аша сурәтле ачылган каршылыклы яклары. Шуңа күрә әсәр ике темалы һәм ике идеяле. Ләкин драматургик әсәр кискен каршылыклы вакыйганы әле уң ягыннан, әле сул ягыннан торып «чиратлаштырып» сурәтли алмый. Андый очракта әсәрнең драматургик иҗади формасы таркала, үсешнең, хәрәкәтнең кискенлеге җимерелә, жанр тотрыклылыгы кими.

«Зифа» комедияле тормыш вакыйгасын сурәтли, шул ук вакытта комедияле хәлнең Зифа өчен яшәгән драматик ягын да ачмакчы була. Сурәтләнгән урынында, куелган тормыш тирәлеге эчендә әлеге вакыйга иң элек комедияле ягы белән күзгә ташлана, шуңа күрә драматург үзе дә комедияле проблеманы алгы планга алып хәл итәргә мәҗбүр. «Зифа»да драма белән комедия бер-берсеннән аерылып, көчләреннән килгән чамада мөстәкыйль жанрлар буларак яши. Бер үк вакыйганың үзгә жанрлы сыйфат үзенчәлекләре бер әсәр эчендә, Сиам игезәкләре кебек бер-берләренә берегеп үсәргә мәҗбүрләр. Автор драматик проблеманы комедияле ягыннан аерып алырга, драматик һәм комедияле проблемаларның икесен ике тигезләмәгә куеп хәл итәргә тырышканга күрә, бер әсәр эчендәге ике жанр — драма һәм комедия чагыштырмача җиңел «сүтелә».

«Язылмаган законнар»да исә автор, табигате белән комедияле тормыш хәлен Фәридә, Хөббиҗамал һәм Шәйхенурларның үзләрендә яшәгән драматик ягы аша күреп хәл итә. Биредә комедиялелекне драмадан аерып алуы читен. Шуңа күрә, нәтиҗәдә «Язылмаган законнар» драма-комедия түгел, ә бәлки драматик комедия жанрында туа.

Укучыга мәгълүм, бу әсәрләрнең темалары тиңдәш, хәл итәсе төп мәсьәләләре аваздаш, вакыйгалар эзлеклелеге охшаш, тик авторларның иҗади мәсьәләгә карашларында, ягъни идеядә бераз үзгәлек бар да әсәрләренә куйган жанрлык тамгалары гына икесенең ике төрле.

Моңа тикле әйбәт кенә эшләп йөргән алдынгы ир, бер заман шулай җае чыгып, мещанлык чибәрлегенә абына да, гомер иткән уңган-булган хатынына хыянәт итә. Эш тирәнгә китә башлагач, ир үзенең адашканлыгын аңлый, үкенә. Тик соң инде, буласы булган — гаилә җимерелгән, кискән икмәкне кире ябыштыруы җиңел түгел. Сикәлтәле тормыш юллары кичеп, шулай да ир белән хатын аңлашалар, килешәләр һәм шуның белән бу әсәрләр тәмам була. Ике әсәрнең дә сюжет кысаларындагы уртаклыкны күрү кыен түгел, ул әле сөйләгәннәрдән гыйбарәт. Бик гади, күп кабатланган өчпочмак. Бу сюжетта, мөгаен, драма гына язарга мөмкиндер. Чибәр, тугры, әйбәт хатын драмасын. Һәр ике әсәрдә бу драмалылык үзгәрәк буяулар аша ачыла. Шул ук вакытта, әлеге сюжет сызыгы белән янәшәдә үк, сөйләнгән хәлләргә турыдан-туры буйсынмаучы икенче вакыйгалар эзлеклелеге бар.

Бу әсәрләр тормыш дөреслеген сакламаган дип кем әйтә алыр? Аларның икесендә дә вакыйгалар нәкъ тормышның үзендәгечә бәйләнешкән, берсе икенчесеннән эзлекле һәм логик рәвештә үсеп чыкканнар, чын, ышандыралар, һич «бәйләнерлек» түгел. Нәкъ тормыштагыча — ике әсәрдә дә бер төркем юньсезләр белән бер төркем әйбәт кешеләр үзара низаглашып яшиләр. «Зифа»да — бер якта тискәреләр төркеме, ә икенче якта ир хатыны Зифа белән балалар, һәм тагы алар тирәсендә тормыш фоны ясап йөрүче, үз характер йөзләреннән мәхрүм берничә бөртек эпизодик персонаж бар. Капма-каршы ике төркем уртасында башыннан әхлаксызлык җилләп бетмәгән шәп кеше Айдар адашып йөри. «Язылмаган законнар»да ир хатыны Фәридә белән бер төркем бик акыллы, әйбәт кешеләр ике юньсез хатынны җиңә алмыйча азапланалар. Монда да бер-берсенә каршы төркемнәр урталыгында мещанлык чибәрлегенә кызыккан шәп тракторчы Шәйхенур адашып калган. Шулай итеп, ике әсәрдә дә сюжет эчендә сюжет туды. Гаиләне төзәтү юлында, бу мәсьәләләргә караштa,

тискәреләр үз мөнәсәбәтләрен белгертеп, чын йөзләрен ача башладылар. Икенче сюжетның да үз темасы, үз идеясе, үз конфликты, хәл итәсе проблемасы бар. Шулай итеп, драматик сюжетлар эчендә комедияле сюжетлар яши башлады. Хәзер бу әсәрләргә, бер яктан ир белән хатын арасындагы низагны хәл итәргә, ә икенче яктан, тискәрелекләрне, гаилә татулыгын җимерүгә алып килгән юньсезлекләрне фашларга, мещанлык пәрәнҗәсен ертырга, тормыш чатаклыкларыннан көләргә, әшәкелекләрне мәсхәрә итәргә кирәк булды.

Драматургиядә һәр жанр тормыш тукымасыннан үз эзен, үз төсен сайлап алып сурәтли, икенче жанр ачыклыйсы фикерне әйтүгә алынмый. Ул әнә шул үз юлын югалтмаганда, үз эзеннән туры барганда гына тормыш дөреслеген иҗади хакыйкать дәрәҗәсенә күтәреп чагылдыруга ирешә ала. Ә бу очракларда бер әсәр өстенә ике жанр вазифасы йөкләмәделәрме икән дигән шик туа. Бу әсәрләрнең иҗади җавап эзләгән төп сораулары нинди? Ул сорау әлеге әсәрләрнең сюжеты үзәненнән буйданбуйга тотрыклы эз калдырып сузылганмы? Бу әсәрләр гаилә татулыгын, ир белән хатынның гаиләгә үзгә карашларын, мәхәббәт мәсьәләсен хәл итүне төп бурычлары итеп алганнармы, әллә гаилә мәсьәләсенә тискәре карашларны — мещанлык, икейөзлелек, бюрократлык кебек әшәкелекләрне фаш итүне үз өсләренә йөкләгәннәрме? Юкса, болар икесе ике тема, икесе ике проблема. Бер үк драматургик әсәр ике теманы, үз сюжет тотрыклыгын таркатмыйча гына, тигез җиңеллек белән ахыргача хәл итеп чыга алмый. Бер сюжет кысасында алар икесе ике мөстәкыйль проблема булып түгел, нәкъ тормыштагыча — берсе икенчесенә буйсынган төстә, икенчесе беренчесеннән чыгарма буларак яшәгән очракта гына хәл ителә алалар. Ә әлеге әсәрләрдә ул проблемалар бер-берсенә буйсынмыйча, янәшә яшиләр, сюжет кысаларында үзара чиратлашып сурәтләнәләр һәм чиратлашып хәл ителәләр. Аерма тик шунда — бу ике әсәрдә ул проблемаларның комедияле булганнары калку итеп сурәтләнгән, ә драматик рухтагылары тоныклана төшеп, арткы планда калган. Чөнки бер үзәккә ике проблема сыймый, һәр әсәрнең үзәге берәү генә була. Шулай булгач, бу әсәрләрнең төп жанрлыкларын да аларның калкурак итеп сурәтләнгән идея-проблематик сызыгына карап билгеләргә кирәктер.

Сүз уңаенда гына булса да әйтеп үтәсе килә. Гамир Насрыйның илленче елларда язылган «Кушнарат» комедиясе шулай ук ике проблемалы әсәр иде. Ләкин «Кушнарат»та ул проблемалар, «Зифа» белән «Язылмаган законнар»дагы кебек, аралашып, чиратлашып килми, аларның берсе тәмам иҗади хәл ителеп бетә дә шуннан соң гына икенчесе башланып китә. Шулай итеп, «Кушнарат» урта бер җирендә кушу билгесе куелган куш сюжетлы, ике жанрлы ике әсәр булып чыккан.

Әлбәттә, бу әсәрләрдә тормыш проблемаларының куелышы да, ул проблемаларның сәнгатьчә хәл ителү камиллеге, жанр аныклыклары төрле дәрәҗәдә, төрле иҗади югарылыкта хәл ителгән. «Зифа»ның драматик сызыгын аның комедиялелегеннән чагыштырмача җиңел аерып алып булса, «Язылмаган законнар»да ул төсләр ешрак чиратлашалар, бер-берләренә якынрак керешүләре нәтиҗәсендә мөстәкыйль аныклыкларын җуя төшәләр, конкретлыкларын югалталар, жанр ачыклыгын бераз тоныкландыра төшәләр.

Белгәнебезчә, бу ике әсәрдә дә ир белән хатын арасындагы низаг беренче пәрдәдә үк туа, үсә, куера да, нигездә, драма жанры рухында хәл ителә. Ике гаилә да җимерелде — аларның төп конфликтлары шул урында бетте. Ләкин ике әсәрдә дә әлеге драмага алып килгән сәбәпләрне эзләү һәм фаш итү башлана. Шуңа күрәдер инде, ике әсәрдә дә комедиялелек драманы каплап китә.

«Зифа»ның жанрын үзе үк «комедия» дип билгеләгән автор әсәрен үрнәк герой исеме белән атый.

Драматургия тарихында күпчелек трагедияләр төп геройлары исеме белән аталган. Чөнки трагедияләрнең барысы да уңай геройларының фаҗигале язмышларын сурәтли. Ә комедиянең үз сюжет кысасында яшәгән уңай герой исеме белән аталуы еш кына жанрның исемен үз җисеменә каршы куя.

Бу әсәрдә дә шул хәлне күрәбез. Драматург акыллы, уңган хатынның тугрылыгын күрсәтергә теләп һәм әсәрен аның исеме белән атый, ә әсәрнең үзәккә алынган, иҗади хәл итәсе проблемасы — тугрылыкка, гаделлеккә, уңганлыкка аяк чалучы мещанлыкны фаш итү, ягъни иҗади проблема комедия жанрын таләп итә. Әсәрнең исеме

жанр атамасы белән каршылыкка килә. Комедия жанры сюжет кысасына уңай характерны керттеме — әсәрнең исемен дә шул үрнәк геройның исеме белән атарга мәҗбүр була. Шулай итеп, жанрлык каршылыгы «Зифа» әсәренең исеменнән үк башланып китә.

Юныс Әминовның «Язылмаган законнар»ы искелек калдыкларын фаш итү проблемасын уздкка ала. Димәк, ул, беренче чиратта, тискәрелекнең көлке ягын яктыртуга, искелек күренешенең иҗтимагый зарарын фаш итүгә, проблемасының иң элек комедияле асылын ачуга төп игътибарын юнәлтергә тиеш иде кебек. Әлбәттә, әшәкелек белән идеалның көрәше гел көлке генә булып тормый. Кыскасы, комедиянең тирән кичерешләрдән азат булып, гел көлкедән генә торырга тиешлеген яклау дөрес булмас иде. Ләкин әсәрнең жанр аныклыгындагы төгәлсезлекләрне мондый сылтаулар белән аңлатып булмый. Чөнки «Язылмаган законнар» комедия генә түгел. Аның сюжет кысасында тискәре характерларның асыл табигатьләре, барыннан да бигрәк көлке булса да, әсәрдә әшәкелекне, тискәрелекне гаепләүгә, фаш итүгә караганда, ул юньсезләр китергән авыр кичерешләр калкурак сурәтләнә. «Зифа»да Айдар, үз хатасын таныгач, тискәрелек белән җиң сызганып көрәшә, ә «Язылмаган законнар»да Шәйхенур тискәреләр белән конфликтка килүдән кача, автор аны ялгышларына үкендереп, тамашачыдан кызгандырттыра. Сыкрау-сыктау, җәлләттерү әсәрдә күпчелек урын били, көлеп гаепләүне күз яше каплап китә башлый, мелодрама мотивлары күбрәк урын ала. Әсәр хәтта исеме белән дә драматик түгел, ә комедияле мәсьәләне хәл итүгә ишарәли. Искелекне көлеп хөкем итү законы — язылмаган закон ул.

Әйе, автор бу әсәрен «драма» дип атаса да, аны драма дип әйтеп булмый. Билгеле, авыз тутырып «комедия» дип әйтүе дә читен. Бәлки ул драматик яки мелодраматик комедиядер? Автор әсәрдә сурәтләнгән тормышның хәсрәтле ягына басым ясап, уздкка алган проблеманың ачыклыгына зыян китергән.

Шушы уңай белән янә кызыклы бер фактны искә төшерәсе килә. 1957 елның 31 маенда Мәскәүдә үткәреләчәк декада алдыннан драматурглар, тәнкыйтьчеләр, кино һәм театр сәнгате белгечләре катнашы белән татар драматургларының әсәрләрен тикшерү була. Секциядә, бүтән авторларның кайбер әсәрләре белән беррәттән, Юныс Әминовның «Язылмаган законнар»ына да тукталып үтәләр. Пьеса турында әйтелгән фикерләрне кыскартып биргән мәкаләдә мондый юллар бар: «...Автор пьесаның жанрын ачык билгеләмәгән, әле алай гына да түгел, пьеса кырт киселеп урталай бүленә: беренче яртысы — драма, икенчесе — комедия». («Совет әдәбияты», 1957, 8 нче сан, 118 бит). Тәнкыйтьчегә мондый сүзләрне әйтергә әсәрдә җирлек, әлбәттә, бар. Ләкин бу әсәр, «Кушнарат» кебек кырт кисеп, икегә бүленмәгән. Аның беренче драматик яртысын комедиялелек озата бара, ә икенче комедияле яртысына драматик тойгылар сибелгән.

Жанр чикләрен билгеләгәндә, «Зифа» һәм «Язылмаган законнар» адресына әйтелгән сүзләр аларның драматургик кыйммәтен түбәнәйтү йөзеннән түгел, билгеле. Әлеге әсәрләрнең, жанр аныклыгы мәсьәләсен ачыклаганда күтәреп сөйләшеп булмаган, бүтән шактый күп уңышлы яклары да бар. Бу — беренчедән. Ә икенчедән, мелодраматик комедияләр дә — әдәбиятның тулы хокуклы жанрлары. Ләкин, яшерен-батырын түгел, жанр аныклыгы — ул иҗади камиллекнең көзгесе, сурәтле чагылган тормышның дөреслеге, әсәрнең хакыйкатькә мөмкин кадәр якын килү билгесе. Әсәрдә сурәтләнә торган тормыш вакыйгаларына иҗтимагый югарылыктан торып идея-эстетик бәя бирә белү һәр художникның изге бурычы. Автор, үз ихтыярына буйсындырып, комедия битәрләвенә лаек характерларның хәрәкәт нәтиҗәсендә туган кайгы-хәсрәтләрне күрсәтеп, жанрны драмага яки, киресенчә, драманы көчләп комедиягә тарта башлый икән, димәк, ул әсәрнең тормышчанлыгына зыян китерә.

Автор үзе куйган жанр тамгасы белән әсәрнең иҗади рухы туры килмәү очракларына, мәсәлән, Шәриф Хөсәеновның «Әниемнең ак күлмәге», «Зөбәйдә — адәм баласы», Туфан Миңнуллинның «Адәм баласына ял кирәк» кебек бүтән кайбер әсәрләрне дә мисал итеп була. Хәтта «Зәңгәр шәл» кебек тиңсез әсәрнең дә жанрлыгы мелодрама гына түгеллеген исбатлап булыр иде.

Алда сүз булган иде инде — «Зифа»ны «саф» комедия итеп күрергә теләүче тәнкыйтьчеләр анда комедияле сыйфатлар гына эзләргә мәҗбүр булдылар. «Зифа

ни өчен комик хәлдә калды? Чөнки Зифа Айдарга булган мәхәббәте хакына иренең кайбер обывательлек гадәтләре белән килешү юлына баскан, ташлама артыннан ташлама ясаган» («Совет әдәбияты», 1961, 7 сан, 139—147 битләр). Дөрес, Зифа иренә ташламасын да ясагандыр (ә ясамаган булса), аның обывательлек гадәтләре белән дә килешкәндер (ә килешмәгән булса?), ләкин аның характеры комедия битәрләвенә лаек түгел. Айдарның карашларында искелек сөреме сакланган, ә Зифаның ни гаебе бар? Ир белән хатын шәһәр шаулатып аерылышуга җитteләр — «курчак уены» уйнадылар, Зифа көлке хәлдә калды. Ләкин Зифаның үзе өчен дә, укучы-тамашачы күңеле өчен дә, бу хәл комик түгел, ә драматик. Айдар исә комедия битәрләвенә лаек характер. Аның комик характеры комедияле хәлләр тудыра, һәм шул хәлләр эчендә аның үз йөзе ачыла — Айдар үзен-үзе адәм көлкесенә калдыра.

Соңгы өч пәрдәдә Зифа үзе бөтенләй диярлек күренми, комедияле конфликтка мөнәсәбәт күрсәтми. Әгәр «Зифа» чыннан да драма жанрында язылган булса, проект «югалту» конфликтының әсәргә керәге дә калмаган булыр иде, бәлки, әсәр алга таба ир белән хатын низагына нигезләнеп үстерелгән булыр иде. Комедияле проблеманың икенче пәрдәдә генә хәл ителеп бетмәве ир белән хатын арасындагы низагны да тәмам чишәргә ирек бирмичә тоткарлап тора. Беренчедән, ир белән хатын мөнәсәбәтенең тагын да кискенләшүе мөмкин түгел — бу хәл әсәрне драма итәр иде, ә икенчедән, әсәр конфликтсыз дәвам итә алмый. Һәм автор проект югалу ситуациясен китереп чыгара. Чөнки проблема комедияле, һәм аны хәл итәр өчен комедияле конфликт кирәк. Бер үк вакытта проект вакыйгасы Зифаны алгы планнан алды. Әйтик, автор баштан ук тискәрелекләрне шул ук проект югалу конфликтына корып фаш итәргә уйлаган булса, сюжет кысасында Зифаның үзен яшәтү, аның кайгы-хәсрәтләрен күрсәтү бәлки кирәк тә булмас иде.

Игътибар итик. Беренче пәрдә: Зифа драматик ситуация өчен кирәк. Икенче пәрдә башы: Зифа проектны «югалтыр» өчен кирәк. Өченче пәрдәдә Зифа юк. Чөнки комедияле хәлләрне фаш итүгә аның катнашуы кирәкми. Чөнки Зифа характерында комедия фаш итәрлек тискәре сыйфатлар юк. Дүртенче пәрдә ахыры, финал. Зифа ир-хатын мөнәсәбәтенең ни белән беткәнлеген һәм проектның «табылуын» күрсәтер өчен кирәк. Бу ике мәсьәлә дә әсәр җилкәсенә йөкләнеп, алар икесе дә вакыйгалар үсешендә хәл ителделәр инде, аларны күрсәтеп бирү эше генә калган иде. Шуңа күрә аларны күрсәтеп бирү эше дә финалда бергә һәм бер-бер артлы чиратлашып күренергә тиеш булдылар.

Эсмеральда һаман Айдарны өметен өзмәгән, Айдар да аның чын йөзен таный гына башлады әле. Айдар кызның чын йөзен тәмам фаш итми торып, гаилә мәсьәләсе дә ахыргача чишелмәячәк. Бу эш әсәрнең өченче пәрдәсенә йөкләтелгән. Дөрес, тамашачы Эсмеральданың юньсезлеген моңа кадәр дә күргән иде инде, ләкин әлегәчә бу кыз күбрәк тышкы яктан ачылган иде. Ә бит нинди генә буш куык булмасын, аның да үз эчке дөньясы, тормышка карашлары, үзенә күрә омтылыш-теләкләре, уй-хыяллары бардыр лабаса. Өченче пәрдәдә драматург Эсмеральданың черек дөньясын актарып фаш итә, аны сатирик тип дәрәҗәсенә үстереп күрсәтә. Әсәрнең комедия «яртысында» төп герой — Эсмеральда. Ул булмаса, комедия дә килеп чыкмас иде. Ә Зифасыз комедия була алыр идеме? Бу сорауга уңай җавап бирәсе килә. Һәрхәлдә, әсәрнең комедияле өлеше Зифа юклыкка карап аптырап калмас иде, үз эшен башкарып чыгар иде.

Бу урында үзенә күрә кечкенә генә йомгак ясап, әсәрне комедия итүче төп шарт — комедияле характер, тискәре характерның үз хирыс мәнфәгатьләре өчен көрәше булуына басым ясарга кирәк. Бары тик тискәре характер гына комедияле ситуация китереп чыгара, үз теләкләрен тормышка ашыру юлында комедияле конфликт тудыра, комедияле вакыйгалар оештыра. Тискәрелек сыйфатлары булмаган кешеләр, тискәреләр тудырган тормыш хәлләренә барып эләксәләр, икенең берсен сайларга мәҗбүр булалар — я шул хәлдән котылганчы җәфа чигәләр, хатта көрәшеп һәлак булалар, я кем чанасына утырсаң, шуның җырын җырларсың дигәндәй, тора-бара үзләре дә тискәреләр кубызына бии башлыйлар һәм көлкегә калып фаш булалар. Беренче очракта әсәр — драма, яки трагедия була, икенче очракта — комедиягә әйләнә.

# КЕШЕЛЕКЛЕЛЕК ТАЛАНТЫ

Мин Шабайның күләм ягыннан әллә ни зур булмаган мирасы, аның әсәрләренең озын гомерлелеге турында озак уйландым мин. Моның сере нәрсәдә икән дип йөрдем. Һәм шундый нәтиҗәгә килдем: бу «сер» Мин Шабай иҗатына хас кешелеклелек талантында икән. Аның һәр әйберендә башка беркемдә дә булмаган үзенчәлек ярылып ята. Әлеге үзенчәлек — олы йөрәкле әдипнең кешеләргә булган мәхәббәтеннән, җылы хисләреннән гыйбарәт. Бу сыйфат әсәрләр аша укучыларга тәэсир итми калмый, әлбәттә. Ул күңелләрдә мәрхәмәтле хисләр уята, кешелеклелек тәрбияли, димәк, әдәбиятның төп вазифасын үти.

Мин Шабай минем хәтердә аеруча тыйнак, гади һәм бик тә сизгер күңелле, оялчан кеше булып калды. Моннан егерме ел элек Татарстан язучылар союзында язучының илле еллыгын үткәрергә булдылар. Идарә тиешле карар чыгарды, юбилей комиссиясе төзелде. Миңа, җаваплы секретарь буларак, юбилей кичәсен оештыру йөкләнде. Ләкин бу хакта ишеткәч, Мин Шабайның үзенең кәефе кырылды. Бүлмәдән чит кешеләр чыгып киткәч, үзенә хас шаянлык белән, әмма бик катгый рәвештә ул болай диде:

— Рафаэль туган, зинһар өчен дип әйтәм, юбилейсыз гына булмасмы?! Мин башкаларның юбилеенда да кызарып утырам, бигрәк тә аны мактарга керешсәләр, ә үземнекендә оятымнан үлеп китүем дә бар.

Мин аны күндерергә тырышып, үгетләп тә карадым: «Күптән инде сезнең турында сүз әйтелгәне юк, юбилей бит сезнең генә түгел, укучылар өчен дә үткәреләә»,— дидем. Ләкин ул барыбер риза булмады. Шулай итеп без, аның рөхсәте булмау сәбәпле, юбилей кичәсен үткәрә алмый калдык.

Ул, Хәсән Туфан сүзләре белән әйтсәк, язучылар арасында соңгы «мамонт» — ягъни өлкән буын әдипләреннән без ишетеп-күреп белгәннәрнең соңгысы иде. Тормышта да нәзберек түгел иде ул, өстендә утызынчы еллардан калган күн пальто булыр иде. Көнкүреш мәсьәләләрендә дә талымсыз, төрле уңайлыкларга бер дә омтылмый, исе китми иде аның. Хәтта яңа квартирага да аны көчләп диярлек күчерделәр! Квартира артыннан йөрисе урында Мин Шабай, хатыны һәм баласы яшәп яткан биш-алты метрлы квартираны мактап, идарә членнарын бу мәсьәләне кузгатмаска үгетләп йөрде.

Идарәгә ул фәкать башкаларны кайгыртып кына мөрәҗәгать итә торган иде. Ике арада булган тагын бер сөйләшү истә калган. Көннәрдән бер көнне миңа больницадан шалтыраттылар — Мин Шабай бездән качты, дәваланырга теләми, ә анда бик җитди ялкынсыну процессы бара, гангренага әверелүе бар,— диләр. Мин әдипне үгетли башлагач, ул кулын гына селтәде:

— Эшләр гангренага җиткәнче, инфарктан китеп барырмын. Мотор тәмам эштән чыкты, анысын мин врачлардан яхшырак беләм!— диде.

Берничә айдан әдипне йөрәге тотты. Ул бездән китеп барды. Тик больница коймасында түгел, ә үзе хыялланганча, сентябрьнең тып-тын бер иртәсендә, дусты белән алма бакчасында сөйләшеп утырганда.

Үз сәламәтлеген кайгыртмау Мин Шабай өчен ниндидер егетлек билгесе түгел иде, киресенчә, үз авыруы белән кешене борчырга теләмәүдән иде бу. Мин аның зарлануын бер генә тапкыр да ишетмәдем — һаман шаян сүз, уен-көлке, әкәмәт хәлләр, вакыйгалар иде теләндә... Бары тик соңыннан, көндәлекләрне укыгач, соңгы елларны язучыга әллә нинди газаплар кичерергә туры килгәнен белдем мин. Авыр

булса да, бернигә карамыйча, бертуктаусыз иҗат иткән ул. «Биш минут язам, бер сәгать ятып торам, ял итәм»,— дип сыкранып язган иде әдип ул көннәрдә.

Тормыш аның белән шактый каты кыланса да, әдипнең күңел көче, сизгерлеге, инсафлылыгы таңга калдыра иде. Авыр балалык еллары, ятимлек... Ачлык-ялангачлык... Алты яшьлек малай әнисе белән бай кырында иген ура, җиде тулгач, тамак хакы өчен кулакка батраклыкка яллана. Бервакыт байның абзар түбәсен кардан чистартканда егылып төшеп ул аягын имгәтә. Бай, авыруны тиккә ашатып яткырмас өчен, аны шунда ук урамга куып чыгара. Ачтан үлмәс өчен булачак язучы өй борынча хәер эстәп йөри, соңрак бөтен илне йөреп чыга, ни эләксә шуның белән туена...

Иң яхшы әсәрләреннән саналган «Уйналмаган скрипка» хикәясендә Мин Шабай әле беркемнең дә кулы тимәгән яңа скрипка турында сөйли. Фанатиклардан саклап калу өчен, хикәянең герое аны тирес астына күмә. Шунда ятып, скрипка чери... Бу скрипканы мин халык арасыннан чыккан талантның авыр шартларда, сыйнфый изү аркасында һәлак булуының гәүдәләнеше, гомумиләштерелгән образы дип карыйм. Күпме халык талантлары шулай ачыла алмыйча һәлак булды!

Бәхеткә каршы, Мин Шабай бу куркынычтан котыла алды.

1931 елны йолкыш, бетерешкән, юлдан язган малайны чекистлар тәрбиягә алалар. Мәскәү тирәсендәге 1 нче номерлы хезмәт колониясенә урнаштыралар. Бу колониядә Макаренко методлары белән тәрбияләү кулланыла. Кыргыйлашкан малайда әкренләп кеше уяна. Шушы көнгә чаклы мәктәп бусагасын атлап кермәгән, «блатнойлар» теленнән башка телне белмәгән малай үзе өчен Пушкин һәм Тукай, Толстой һәм Галимҗан Ибраһимов, Лермонтов һәм Такташны ача... Ачып кына да калмый, үзе дә иҗат итәргә омтыла, еллар буе җыелган тәэсирләрен тизрәк кәгазьгә төшерергә тырыша. 1934 елны (ул елны Мин Шабайга 21 яшь тула) аның «Таныл» (елга исеме) дигән романы дөнья күрә. Шуннан соң матбугатта бер-бер артлы үзенчәлекле хикәяләре, документаль очерклары, колхоз-совхоз театрларында куелган пьесалары күренә башлый.

Мине язучыдагы контрастлар һәрвакыт гаҗәпләндерә килде: тормышның караңгы, авыр якларын күпме күреп тә, үз әсәрләрендә кешенең гел уңай, якты сыйфатларын тасвирлый иде ул. Әдипнең күңелгә үтеп керә торган лирик новеллаларын укыганда мин аның карлыкканрак тавышын, йомшак кына, гүя гаебе булганга шулай кебек тоелган елмаюын күрәм һәм күз алдыма бер вакыйга килеп баса. Кыш урталары иде, бер көнне ул Язучылар союзына килеп керде дә, бәхетле елмаеп:

— Яз килә, егетләр!— диде.— Әле парктан үтеп барышлый сизеп алдым — яз исе килә. Кайдан бу, мәйтәм? Карыйм, тирәктәге бөреләрдән икән. Кояшта кызынып утырып, шундый нечкә һәм тәмле ис тараталар. Билләһи менә!

Әле каты суыклар тора, кул тимәгән февраль кары зәңгәрләнеп ята, тротуарлар пычрак боз белән капланган, ә ул инде яз килгәнне сизеп алган, бәхетле елмая һәм шул бәхетен башкалар белән дә уртаклашырга ашыга иде...

**РАФАЭЛЬ МОСТАФИН.**

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ӘДӘБИЯТ КӨННӘРЕ

8—12 февральдә Актанышта татар әдәбияты көннәре булып узды. Әдәбият көннәрендә катнашучылар арасында Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе язучы Г. Ахунов, язучылар А. Гыйләҗев, В. Нуруллин, шагыйрьләр М. Садри, Р. Харис, Р. Гатауллин, Р. Мингалимов һәм башкалар бар иде.

## ШАГЫЙРЬНЕҢ ТУГАН ЯГЫНДА

Күренекле татар совет язучысы Шәйхи Маннурның васыяте нигезендә, Мамадыш районының «Чулпан» колхозындагы Ш. Маннур исемендәге китапханәнең еллык премиясе булдырылган иде.

Шагыйрьнең туган көнендә Олыяз культура йортында Ш. Маннурны искә алу һәм әлеге премияне тапшыру тантанасы булды. Шәйхи Маннур исемендәге китапханәнең 1982 ел премияләре 1980—82 нче елларда республика матбугатында чыккан әдәби тәнкыйть мәкаләләре өчен тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиевкә, «Утлы бозлар» исемле китабы һәм 1982 елда «Яшь ленинчы» газетасында «Алар Ильичка ант иттеләр» дигән рубрика астында басылган публицистик язмалары өчен шагыйрь Зөлфәткә, алдынгы комбайнчы, юбилей елы урак батыры Шаһинур Хөсәеновка, колхозның экономикасын һәм культурасын күтәрүгә, Ш. Маннур истәлеген мәңгеләштерүдә зур көч куйганы өчен «Чулпан» колхозы председателе, ТАССРның атказанган культура работнигы Галимҗан Җиһаншинга, әдәбиятны пропагандалау һәм агитмасса эшен нәтиҗәле алып баруга зур өлеш керткән өчен Ш. Маннур исемендәге китапханә мөдире Вәсига Зәйнетдиновага, елның иң алдынгы сыер савучысы Һаҗирә Мәүлинага бирелде.

Кичәдә авыл үзешчәннәре концерты булды. Анда Шәйхи Маннурның күп кенә әсәрләре яңгырады. Р. Вәлиев, Зөлфәт, Р. Низамиев үзләренең шигырьләрен укыдылар. Мамадыш якларында туып-үскән җырчы, ТАССРның атказанган артисты Миңгол Галиев башкаруындагы җырларны да авыл эшчәннәре яратып тыңладылар.

*

* *

РСФСР Язучылар союзы һәм Саратов язучылар оешмасы органы булган «Волга» журналының 11—12 саннарында Шамил Бикчуринның «Тирән катлам» романы рус телендә дөнья күрде. Аны Юрий Сбитнев тәрҗемә иткән. Иң яхшы проза әсәрләре өчен «Волга» журналы редколлегиясе 1982 ел премиясен Ш. Бикчуринның «Тирән катлам» романына бирергә дигән карар кабул итте.

*

* *

14 декабрьда В. И. Ленин исемендәге фәнни китапханәдә ТАССР Язучылар союзы һәм Республика китап сөючеләр җәмгыяте тарафыннан оештырылган китап күргәзмәсе ачылды. СССР төзелүенең 60 еллыгына багышланган бу күргәзмә «Татарстан язучыларының әсәрләрендә СССР халыклары дуслыгының чагылышы» дип атала. Күргәзмә вакытында әдипләр белән очрашулар, китап укучылар конференцияләре, диспутлар, китап премьералары һәм башка кызыклы чаралар уздырылды. Аларда Г. Ахунов, Ф. Миңнуллин, М. Садри, Р. Фәйзуллин һәм башка бик күп язучылар катнашты. Күргәзмә бер ай буе дәвам итте.

*

* *

Калинин өлкәсенең Бежецки шәһәре һәм районында СССР төзелүгә 60 ел тулуга багышланган Россия әдәбияты көннәре булып узды, Мәскәүнең «Современник» нәшрияты бастырып чыгарган китаплардан күргәзмәләр, нәшриятның актив авторлары белән очрашу кичәләре оештырылды. Анда 1982 елда «Современник»та дөнья күргән «Курай моңы» («Напевы курая») китабының авторы Гәрәй Рәхим катнашты.

*

* *

Латвия Язучылар союзы чакыруы буенча Равил Фәйзуллин бөек латыш шагыйре Ян Райниска багышланган тантанада катнашты. Ул Ригада Коммунарлар паркында һәм республика районнарында игенчеләр, балыкчылар, студентлар һәм укучылар алдында чыгыш ясады. «Күпмилләтле совет поэзиясендә милли һәм интернациональ үзенчәлекләр» дип исемләнгән конференциядә доклад белән чыкты.

*

* *

Чиләбе шәһәренең татар-башкорт китапханәсе уку залында Ә. Ерикәйнең тууына 80 ел тулуга багышланган әдәби-му-

зыкаль кичә булды. Кичәне китапханә белән берлектә Муса Җәлил исемендәге әдәби берләшмә оештырды. Тамашачылар шулай ук С. Орджоникидзе исемендәге завод каршындагы «Таң нурлары» дигән ансамбльнең шагыйрь әсәрләреннән төзелгән концертын тыңладылар.

* * *

Республикабызның М. Җәлил исемендәге комсомол премиясе лауреаты Зиннур Нурмөхәммәтовның Молдавиядәге гастрольләре зур уңыш казанды. Җырчы тыңлаучыларны Советлар Союзы халыклары җырлары, хәзерге заман татар композиторлары Н. Җиһанов, Р. Яхин, Ф. Әхмәтов әсәрләре белән таныштырды. З. Нурмөхәммәтов шулай ук күп кенә җырларны молдаванча да башкарды. СССР төзелүнең 60 еллыгына багышланган интернациональ программа Ватанга һәм партиягә, совет халыкларының дуслыгына дан булып яңгырады.

## БРЕЖНЕВ ШӘҺӘРЕ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Брежнев шәһәрендә СССР төзелүнең 60 еллыгына багышланган сәнгать фестивале булды. Анда язучылар, композиторлар, рәссамнар, хор һәм инструменталь-вокаль коллективлар катнашты. Әдәби-музыкаль кичәләрдә язучылар Э. Касыймов, Р. Вәлиев, Г. Кашапов, шагыйрьләр Х. Хөснуллин, Н. Мадъяров, Я. Игәнәй, Р. Бәшәр укучыларны үзләренең яңа әсәрләре белән таныштырдылар.

Әлеге иҗат кичәләрендә шулай ук Мәскәү шагыйрьләре Л. Ошанин, Л. Шаменкова, Ф. Ведрашку, Ленинград язучылары В. Суров, В. Суслов, Казаннан Р. Мостафин, М. Зарипов катнаштылар.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР

1 декабрьда Татарстан укытучыларының белемен күтәрү институтында шагыйрь Г. Латыйп белән очрашу булды. Ул кыскача гына үзенең тормыш юлы турында сөйләде һәм соңыннан шигырьләр укыды. Очрашуда яшь язучылар Р. Низамиев һәм К. Кәримов та катнаштылар.

* * *

Компрессорлар эшләү заводының тулай торагында Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты шагыйрь Р. Миңнуллин белән очрашу үткәрелде.

Соңыннан заводның кызлар ансамбле Р. Миңнуллин сүзләренә язылган җырларны башкарды.

* * *

Киров районында СССР төзелүгә 60 ел тулу уңаеннан зур әдәби-музыкаль кичә булды. Кичәдә язучылар М. Скороходов, Р. Батулла, М. Галиев, К. Кәримов һәм Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең яшь башкаручылары катнашты.

* * *

Декабрь аенда шагыйрьләр Э. Рәшитов, Җ. Дәрзаманов һәм прозаик М. Насыйбуллин Баулы районының Урыссу эшчеләр поселогында булып кайттылар.

* * *

Казанның Яшьләр үзәгендә язучылар Ш. Рәкыйпов һәм М. Елизарова зона комсомол мәктәбендә укучы яшьләр белән очрашуда катнаштылар.

* * *

Язучы М. Хәбибуллин Төзүчеләр культура сараенда, 42 нче һәм 34 нче техник училищеда, 41 нче урта мәктәптә әдәбият сөючеләр белән очрашты.

* * *

Шагыйрьләр М. Хөсәен, Р. Фәйзуллин, Р. Кутуй, Г. Зәйнашева, М. Скороходов «Васильево» санаториесендә, сәүдә работниклары һәм Сәетгалиев исемендәге культура сарайларында, ЭВМ заводында, 3 нче тегү фабрикасында, Казан авиация һәм кулинария техникумнарында, 9 нчы урта мәктәптә, А. М. Горький музеенда очрашулар үткәрделәр.

* * *

8 декабрьда Казанның Пионерлар сараенда мәктәп китапханәсе хезмәткәрләре белән очрашуга шагыйрьләр Р. Миңнуллин, М. Әгъләмов һәм М. Зарецкий килде. Очрашуда сүз балалар әдәбияты, аның үсеш тенденциясе һәм проблемалары хакында барды. Соңыннан шагыйрьләр яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *

Прозаик В. Нуруллин Галимнәр йортында китап сөючеләр белән очрашты. Язучы рус телендә чыккан китапларының язылу тарихы, геройларының язмышы хакында күп санлы сорауларга җавап бирде.

# В. И. ЛЕНИН ПОРТРЕТЫ

Татарстан сынлы сәнгатендә Ленин темасы алгы урында тора. Ана төрле чор рәссамнарыбыздан: Н. Сокольский, М. Кәримов, В. Тимофеев, Л. Фәттахов, Х. Якупов, М. Семенов, В. Скобеев, Е. Киселева, Е. Симбирин һәм башкалар мөрәҗәгать иттеләр. Аларның һәрберсе революция юлбашчысы образын тудыруда үз өлешен кертте, аның шәхесе һәм эшчәнлегенең төрле якларын ачып бирергә тырышты.

Казан «ленинниана»сының чыганагы күренекле Казан рәссамы Николай Иванович Фешинның 1918 елда иҗат иткән «В. И. Ленин портреты» булды.

Әсәр натурадан, портрет героена карап ясалмаган. Бу хезмәткә нигез итеп, күрәсең, юлбашчының фоторәсеме алынгандыр. (Ә аны рәссамга В. И. Ленинның дусты һәм көрәштәше — ул вакытта Казанда яшәгән В. В. Адоратский бирергә бик мөмкин.) Шуңа да карамастан, портрет — сирәк очрый торган, уникаль әсәр. Чөнки ул Ленинның Совет власте таңында тасвирланган иң беренче портретларыннан санала. Н. Фешин даһи юлбашчыбыз портретында документаль төгәллек белән оратор һәм трибунны гына түгел, ә кешелекле кешене сурәтли. Бирелә юлбашчының бөеклеге, зирәклеге, аның кешелекле сыйфатлары — гадилеге, гаять аңлаешлы булуы ачып бирелә. Әнә шулай образны ихлас күңелдән психологик рәвештә аңлату хезмәткә гади булмаган үзенчәлекле төсмер бирә. Фешин даһи кешенең рухи дөньясына тулысынча үтеп керә алган. Ильичның гадәттән тыш игътибарлы, тере йөзен, «сократларча» киң маңгаен, аз гына кысыла төшкән күзләренең үткер, сынаучан карашын гына түгел, алҗулы елмаюын, җиңелчә талчыкканлыгын да күрсәтә белгән.

...Ильичның эш кабинеты. Ул китапларыннан, кәгазьләреннән аерылып, безгә сурәтте күренми торган әңгәмәдәше белән сөйләшеп утыра. Владимир Ильич бераз әңгәмәдәше ягына борылган, үзенә генә хас кыяфәт белән башын ия төшкән. Һәм аның шулкадәр игътибарлы булуына, күзләренең җанланып балкуына карап, әңгәмәнең нинди кызыклы, искиткеч тәэсирле, уйландырырдай икәнлегенә абайларга була. Портрет безгә якын ук китереп, зур масштабта ясалган. Мондый композиция алымы әсәрнең төп идеясе белән аклана. Чыннан да, рәссам безне, әйтерсең лә, әсәрендәге зур вакыйгалар кайнаган эштә катнашырга, юлбашчы белән әңгәмә корырга чакыра, безнең бу әчкерсез әңгәмәдә фикердәш булуыбызны тели.

Портретның матурлыгы үзенең ышандырырлык һәм көчләп тагылмаган җанлылыгында гына түгел әле. Гаҗәеп үзенчәлекле көрән-соры гамма — юлбашчының сурәттәге образы характеристикасына туры килгән сабыр, җылы гамма да бизәп тора аны.

Зур останың иң күренекле әсәрләреннән саналган «В. И. Ленин портреты»н Казанда яшәгән Ковалевскийлар гаиләсе 1934 елда Дәүләт музеена тапшыра, ә 1962 елда ул Татарстан сынлы сәнгать музеена күчерелә һәм даими рәвештә күп санлы тамашачыларны үзенә тартып, экспозицияне бизәп тора.


**Г. МОГИЛЬНИКОВА,**
Татарстан сынлы сәнгать музее директоры урынбасары.

**Тышлыкның дүртенче битендә.** Казанда шигъри сабантуй.

Р. Мансуров слайдлары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)